ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2007



# ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ—АКАДЕМИКЛАР



*Равил Фәйзуллин*



*Туфан Миңнуллин*

2007 елның 26 июнендә Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъза (академик), әгъза-мөхбир, шәрәфле әгъзаларын сайлау буенча гомуми җыелыш уздырды. Тавыш бирү нәтиҗәсендә Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзалары—академиклар булып Татарстанның халык шагыйре, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Фәйзуллин Равил Габдрахман улы** һәм Татарстанның халык язучысы («Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы) **Миңнуллин Туфан Габдулла улы** сайландылар. Каләмдәшләребезне дәрәҗәле исем белән тәбрик итәбез!

# Казан утлары
# Qazan utları

*2007*

**8**

(1018)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт ӘХМӘТҖАН. Киләчәкнең, шөкер, киләсе бар... *Шигырьләр.* .... 5
Мәдинә МАЛИКОВА. Тылсым. *Роман.* .... 10
Луиза ЯНСУАР. Кемдер ача күк ишеген. *Шигырьләр.* .... 47
Идият АШИРОВ. Бардамда—басу капкасы. *Шигырьләр.* .... 70
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кыз-хатын. *Хикәя.* .... 74
Гөлнур ӘХМӘДУЛЛИНА. Йөрәк тагын җыр язды... *Шигырьләр.* .... 88

### ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Рөстәм МИНГАЛИМ, Эсфир ЯҺУДИН. Өч балдызга бер ялгыз. *Музыкаль комедия.* .... 52

### ӘДӘБИ МИРАС

Наис ГАМБӘР. Ачык калган тәрәзәм. *Шигырьләр.* .... 90

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәрит ХАТИПОВ. Әсәрнең эстетик җегәре. .... 94
Илшат ВӘЛИУЛЛА. Равил Фәйзуллин шигъриятендә моң һәм сабантуйлык рухы. .... 102

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Рифат СВЕРИГИН. Тойгылар сафлыгы. .... 122

### ФӘН

Беренче татар басма китабына ничә ел? .... 127
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .... 129

### ХӘТЕР

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Бер авылның күргәннәре. .... 135
Фәрит БАТТАЛ. Салих абый турында уйланам... .... 145

### ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Габдулла ГАЛИЕВ. Күңелемдә яңарган хатирә. .... 154

### СӘНГАТЬ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Әй, гармуным, гармуным! *Документаль повесть.* .... 159

### 2007—ХӘЙРИЯ ЕЛЫ

Асия ЮНЫСОВА. Ният гамәлнең башы. .... 176

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. .... 180
«Казан утлары» архивыннан. .... 184
Берлекнең яңа әгъзалары. .... 186
Укучы сүзе .... 187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман М. МАЛИКОВОЙ «Очарование» (начало); рассказ Р. ЗАЙДУЛЛЫ «Женщина»; стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Н. ГАМБАРА, Л. ЯНСУАР, И. АШИРОВА.
«Драматургия»: музыкальная комедия Р. МИНГАЛИМА и Э. ЯГУДИНА «На три свояченицы—один холостой».
«Новые имена»: стихи Г. АХМАДУЛЛИНОЙ.
«Литературная критика»: Ф. ХАТИПОВ. «Эстетическая сила произведения»; И. ВАЛИУЛЛА. «Дух сабантуя в поэзии Р. Файзуллина».
«Книжное обозрение»: Р. СВЕРИГИН. «Чистота чувств».
«Наука»: «Сколько лет первому изданию татарской книги?»; А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение).
«Память»: статья Р. ШАРАФИЕВА об истории деревни Карадуган; воспоминания Ф. БАТТАЛА о Салихе Баттале.
«Рассказы из жизни»: Г. ГАЛИЕВ. «Ожившие воспоминания».
«Искусство»: документальная повесть Л. ХАМИДУЛЛИНА «Эй, гармонь моя, гармонь».
«2007—Год благотворительности»: статья А. ЮНУСОВОЙ о деятельности «Татэнерго».
В номере отмечаются 100-летие Г. Губая, 80-летие З. Мазитова.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Из фотоархива журнала.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Мгновения праздника; писатель Азат ВЕРГАЗОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by M. MALIKOVA «Charm» (beginning); story by R. ZAYDULLA «Woman»; verses by R. AHMETZYANOV, N. GAMBAR, L. YANSUAR, I. ASHIROV.
«Dramatic art»: musical comedy by R. MINGALIM and E. YAGUDIN «For three sisters in-law there is one single man». «New names»: verses by G. AHMADULLINA.
«Literary criticism»: F. HATIPOV. «Aesthetic force of work»; I. VALIULLA. «Spirit of sabantuy in R. Fayzullin's poetry».
«Book review»: R. SVERIGIN. «Cleanliness of feelings».
«Science»: «How old is the first edition of Tatar book?»; A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation).
«Memory»: article by R. SHARAFIEV about history of village Karadugan; memoirs of F. BATTAL about Salih Battal.
«Life stories": G. GALIEV. «Revived memoirs».
«Art»: documentary story by L. HAMIDULLIN «Hey, my accordion, my accordion».
«2007th year of charities»: article by A. YUNUSOVA about «TATENERGO» activity.
In number are celebrated 100th anniversary of G. Gubay, 80th anniversary of Z. Mazitov.
Pages from «Tatar encyclopedia».
From photoarchive of magazine.
Word of reader.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Instants of holiday; writer Azat Vergazov.


* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.07.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-885 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2007 ел.



Роберт
Әхмәтҗан

## КИЛӘЧӘКНЕҢ, ШӨКЕР, КИЛӘСЕ БАР...

### Элегияләр

А. Т.

**1**

**...Көнем матурланып килә, дисәм,
Син сагышлы иткән көннән соң,
Болар бар да бер төш кенә бугай,
Шулай микән? Сорыйм кемнән соң...**

**Беркем җирдә минем күзләр белән
Карамый бит, тоя үзенчә.
Алар сине югалтуны белми,
Миндәй Сине көтми, көз килсә...**

**Көнем инде үзенә кайта, дисәм,
Яши башлыйм, дисәм, искечә,
Ябырылып төшә җаныма моң,—
Кайтмаслыгың
исемә төшә!..
...Тәрәзәләр ут алуын көтеп,
Ачып кереп таныш капканы,
Онытылып кичке эңгерләрдә
Көтеп йөрдем Синең кайтканны...**

**2**

**Юксынулар «аннан сәламдер», дим,
Күңелемә тулып хис килсә...
Һәрчак шулай: мин сәгатьне борам,
Пәрдәләрне тартам кич килсә.
Тормыш шулай бара—искечә...**

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935)—*шагыйрь; «Егерменче яз», «Идел-йорт», «Таң шәһәре» һ. б. китаплар авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

И шулчакны кинәт килеп чыга
Киңәшергә Синең кирәгең?..
Үткәннәргә кайтып киттеңме соң,
Әллә инде киләчәккә...
Алып китте синең йөрәгең?..

Кошлар булып китә диләр сезне,
Аккош юлы—сезнең юлдыр ул.
Җиде кат күккә ашкан бөек мизгел,
Иң соңгы юл безнең—шулдыр ул...

Гомер чаңы суккач, мин дә бер көн
Кушылырмын сезнең төркемгә...
Күк юлында очрашырбыз... Ләкин
Сөйли алмам кайтып
беркемгә...

3

Мин шулкадәр хәсрәт өйдем Сиңа,—
Үзе белә аны бер Ходай...
«Барын күрдең, инде аңа, дидем,
Миңа бирмәгәнне бир, Ходай!»

Әмма беләм: Ходай һәркемгә дә
Үз өлешен гадел чыгара.
Ә шулай да... бурычлы мин. Сиңа
Түләр чаклар җитте ни ара?!

Ничек итеп бер карашы белән
Нурлы Кояш гөлне яшәткән,
Күз яктыңны сирпеп, Сөю гөлем,
Син идең ул җанны яшәрткән!..

Сиреньнәрең шаулый! Сине сагынып,
Күз алдында дөнья яшәрә.
Меңнәр арасында җисемең юк бит,
Бер исемең... җитми дәшәргә...

Син киттең дә киттең, Пенелопам,—
Ак җилкәнем юлга киерелгән.
Одиссейдай, юлым—Сиңа... Яшим,—
Үз өлешем—
үземә бирелгән...

4

Бу дөньяда кемне шаккатырдык,
Нинди онытылмаслык эш кылдык?—
Әллә инде какшау җилкапкага
Ябагалы эттәй ышкылдык?

Әллә инде килмәскә дә булган,
Бу дөньяга бездән башка да
Туар иде көннәр... Әйтерсең лә
Җир тормышы бездән башлана?..

Аборигены да түгел җирнең,
бездәй
Миллион гасыр килеп киткәннәр.
Ә шулай да...
Киләчәкнең, шөкер, киләсе бар,
Сагындыра, җандаш, үткәннәр!

Үткәннәрне инде күтәп булмый,
Сабырлыклар бирсен көткәнгә!
Кино тасмасыдай, сүтелә-сүтелә,
Киләчәк тә китәр—
Үткәнгә!..

Ә шулай да...
Белсәк тә бит аның орчык кебек
Бөтерелеп бездән каласын,
Бу гомерне кабат сагынырбыз...
Сагындырмый гына карасын!..
Таба алсак әле чарасын!

## Безнең тарих

Булган, халкым, безнең «ертык» тарих,
Карамзиннар, кара морзалар...
Монархия байрагына сыенып,
Алар шулай түргә узалар...

Түргә түгел, гүргә узганнар да
Бик күп булган юкса татарда:
Маңгаена кургаш алган җаннар,
Теләмичә денен сатарга...

Дөньялыкта җанын саклау хакына
Тәре төпләрендә ятарга
Риза булып, денен алыштырган,
«Тугры» булып алтын алтарьга,

Яшәгәннәр... Сөйли елъязмалар,
Күтәрелеп төптән, тирәннән...
Милләт угылы, атылып йә сатылып,
«Мәңге яшәү» серен өйрәнгән.

Яшәгәннәр... Әләксандр, имеш,
Карамзиннар, имеш, морзалар...
Исемнәрен шулай алыштырып,
Патша мөнбәренә узганнар.

Язлар җитте исә, әнә шулай
Кабыкларын сала еланнар.
Кием алыштыру түгел бит бу,
Динен алыштыру, оланнар!..
Кем укысын сезгә догалар?..

Юкәләрне каезлаган ыруым,
Чабаталар кигән курыстан...
Кем әйткән бит: «тиресен каезласаң,
Татар чыгар бик күп урыстан».

Хак шулайдыр. Сарай шагыйрьләре,
Державиннар, тагын кайсыгыз,
Күтәрелеп тарих катламыннан,
Без белмәгән серне
ачыгыз!

Сөйләгез сез, янган елъязмалар,
Көлдән ут-кош ничек терелгән?
Татар җилкәсенә төшкән камчы
Ничә җәпле итеп үрелгән?

Сөйләгезче, кайчан Ай янында
Койрыклы йолдыз күренгән...
Халык өметләре, ничек итеп,
Канатланган
торып...
гүреннән?..

***

Сез дә картаясыз, таллар,
үзгәрәсез көз алдында...
Күз алдында
әнкәй утырып байый
(кичелә гомер)!
Сеңелем ап-ак яка кайый
көзге алдында...

Кояш төшә үлән арасына,
сулар менә ярга;
җилләр китә күчеп тау артына,
кошлар төшә
ялга...

Сез дә картаясыз, таллар,
үзгәрәсез күз алдында...
Замананың купшы кызы—
көзге алдында!..

Хатын-кызның баешыннан да моңсу
бер җыр юктыр бу дөньяда...

## Кем булыйм соң?..

*«...Гел шагыйрь була күрче...»*
Зөлфәт култамгасы

...Сез яшәгән киңлекләрдән
Җитмеш ел барам,—юлчы:
«Гел шагыйрь генә була күр,
гел шагыйрь була күрче...»

Кем булыйм инде соң, димен,—
тик... патша булмас идем,
адәмнәрне авызлыклап,
явызлык кылмас идем.

Күр, мондый җылы язларда
Һәр сабак яфрак яра,

ачыла яңа фикерләр,
һәр бөҗәк канат кага;
яшел чәчәкле талларда
һәр кош үз көен таба,
күңелләр канатланганда
шагыйрь булмыйча кара!..

Гөлләнәдер шигъри сүзләр,
җан иңә түтәлләргә...
Гөлләр пышылдаша! Ишетәм.
Ишетәме бүтәннәр дә?..

Кояш үзе алтын Чәчәк—
Балкып, яктырып тора!
Таулар—биек,
күкләр—чиксез,
офыклар—чакырып тора!..

Гөлләнеп, йөгереп, еллары
Синең каршыңа чаба!
Шуңадыр гомерең тиз үтә,—
моңарга юктыр чара.
...Үткәннән качып та булмый,—
каян да килеп таба!..

Башым тияр-тимәс бара
заманым күкләренә.
Фәрештәм канат куйгандай
күтәргән йөкләремә...

Яфрак—яфракка охшамый,—
кеше юк минемише...
Шагыйрь ул—яшәүче түгел,—
очып баручы кеше!

Дөньядан Матурлык эзләү—
Ходай биргән өлеше.

❋



Мәдинә
Маликова

# ТЫЛСЫМ

РОМАН

*Нурга төренгән фәрештә—*
*Аһ, сөю, әллә синме?*
*Бер кулыңда баллы касә,*
*Берсендә—утлы сөңге...*

* * *

Яшен вакытында биек агач астына ышыкланырга ярамый. Ялан кырда ялгыз үскәненә якын тору аеруча куркыныч. Андыйлар яңгырдан шәбәргән кешеләрне генә түгел, болытлар арасындагы ут сөңгеләрен дә үзенә тарта.

Тәҗрибәле өлкәннәр бу хакта яшьләрне җай туры килгән саен искәртеп тора. Тик, күрәсең, кемдер аларның сүзен ишетми кала, кемдер ишеткәнен күңеленә салмый. Ә бәлки, давылга эләккәч, онытып җибәрәдер? Андый чакта зиһен чуала, чыланып калтыранган тән исә ихтыярсыздан якында гына кинәеп утырган каенның куе ябалдашы астына омтыла.

Һәм кеше юеш аркасын җылы, нык кәүсәгә терәп, җиңел сулыш алгач кына, кинәт...

Аннан соң ни булганын адәм баласы үзе аңламый-сизми дә кала. Күзне чагылдырган яктылык, колак тондыргыч шартлау исә, еракларга таралып, бөтәннәрнең өнен ала, күңеленә шом сала.

Алсу кофта, джинси чалбар кигән, кара чәчен киң ал тасма белән бәйләгән, кулына ак полиэтилен чиләк тоткан унбиш яшьлек кыз белән нәкъ менә шулай булды да. Көтмәгәндә болытлар куерып, кинәт яңгыр коя башлагач, ул, аны-моны уйлап тормастан, юлдан ун-унбиш адымда кинәеп үскән карт каенга таба йөгерде. Агачның куе ябалдашы астына кереп, сыгылмалы гәүдәсе белән кытыршы кәүсәгә сөялде дә, битендәге тамчыларны сыпырып, җиңел сулап куйды. Шунда кинәт җир-күк ярылгандай булды... Яшен сөңгесе җиргә сенеп, шартлау авазы еракларга таралып тынганда, урталай ярылган, көйрәп-пыскып торган каен кәүсәсе янында кызыкай күренми, ишелеп төшкән ботак-яфраклар арасында ак чиләк кенә аунап ята иде.

Мәдинә МАЛИКОВА—*язучы; "Кар сулары", "Шәфкать", "Алтын ятьмә", "Өермә" һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

... Район үзәгеннән кайтып баручы яшел «Уазик» та яңгыр астына эләкте. Эре тамчылардан шадраланган юлдан үргә менеп килгәндә, машинадагы ике кеше кинәт ялтыраган яшен яктысыннан күзләрен чытырдатып йомып, коточкыч шартлаудан муеннарын җыердылар.

—Аллаһемә! Минем түбәгә бәрде, дип торам!—диде шофер—кырык яшьләр тирәсендәге ир кеше. Һәм кабаланып рульне боргаларга тотынды: машина юеш асфальтта таеп, юл читендәге чокырга борылган иде.—Чак мәтәлмәдек. Әле дә ярый, рульгә сине утыртмадым. Ә син сораган буласын... Бу юлны беренче күрүен, белмим, нишләп бетәр иден...

Аның янәшәсендәге егетнең кояшта янган чыраеннан кан качкан, иреннәре кысылган иде. Тырыша торгач, шофер машинаны турылады, башын алгарак сузып, парланган пыяла аша юлга текәлде. Бераз читтәрәк, клевер басуы эчендә пар чыгарып утырган каен кәүсәсен күрми дә үткән булыр иде, егет шәйләп алды.

—Сабит абый, карале, теге агач нишләгән ул?

—Кайсы агач? Бәлеш, яшен суккан бит моны! Әйтәм аны янда гына кебек иде! Бетергән бу каенны. Тураган да ташлаган, кибән итеп өеп тә куйган.

—Нинди ак нәрсә ята анда?

—Нидер бар бугай шул. Карарга кирәк. Ботак астында берәрсе ятмый микән...

Сабит тормозга басты. Машинадан төшеп, пычрак су тулы канауны сикереп чыктылар, чыклы клеверны ерып, эчкәрәк уздылар. Кроссовкалар, джинси чалбар балаклары манма булды, күлмәкләр, чәч-баш чыланды. Чыннан да, ботак өеме янында кечерәк кенә ак полиэтилен чиләк ауный, үлән арасына җир җиләге сибелгән. Яфраклар астында сандалилы аяклар шәйләнде... Моны күреп, икесенең дә тыны кысылды...

Ашыгып, ботакларны араларга керештеләр.

—Әнисә бит бу!—диде Сабит.—Ярый әле, синең күз очлы, Мидхәт! Күрми дә үтеп китә идек бит!

Мидхәт кызның битенә ябышкан яфракларны алгалый иде. Кыймшанган ботаклардан эре тамчылар коелды, әмма кызыкайның йомык күз кабаклары тибрәнмәде. Егет тетрәнеп куйды. Үсмер бала лабаса бу! Ал тасма астыннан бөселеп чыккан эре кара чәч бөдрәләре арасында томрап торган бит, дугаланып килгән кашлар, озын керфекләр. Бераз чөенке, килешле борын, нәфис уелган алсу иреннәр, алар арасыннан күренеп торган эрерәк, әмма тип-тигез, ак тешләр... Иң нык җәлеп иткәне исә кечерәк кенә миң табы иде. Миңле кызлар күп, ә менә сөйкемле тамчысы ияк уртасындагы чокырга тамганы... Дөньяда андый тагын берәр бар микән? Гади миң генә түгел, мөгаен, илаһи бер көчнең тылсымлы тамгасы иде бу...

Мидхәт, сокланудан айнырга тырышып, күзләрен чет-чет йомгалады. Лачма су яфраклар өстенә тезләнде дә, кызның күкрәгенә башын салып, йөрәк тибешен ишетергә тырышты. Әмма чыланган ефәк аша яшь тәннең кайнарлыгы гына сизелде. Кечкенә, тыгыз күкрәк алмасы астында шомлы тынлык иде. Әллә... үлгәнме?..

Йөзендә үсмерлек ярылып ятса да, тыгыз, калку күкрәкләренә караганда, җитлегеп килгәнгә охшый. Аңына килә алмас микәнни?!. Бөтенләй китте микәнни инде?

Ясалма сулыш ясарга кирәк... Мидхәт монын ничек эшләнгәнен исенә төшерергә тырышты. Институтның беренче курсын тәмамлагач, спорт лагерына китәр алдыннан, ашыгыч ярдәм итү курсларына йөргәннәр иде бит.. Авызына сулышыңны өрергә дә йөрәк турына өч-дүрт тапкыр каты-каты басып алырга... Иптәш егетләрне идәнгә сузып салып, кыланып та караганнары

булды... Ул чакта бик ансат кебек иде дә бит... Хәзер зиһен чуалган шул.

Мидхәт кызның битенә ябышкан чәч бөтеркәләрен артка сыпырды да, иреннәрен аның ярым ачык авызына терәде. Тетрәнеп сулышын өрде. Аннары калттыранган учын кызның күкрәк йомгагы астына куйды. Тәненә ток бәргәндәй булып, эсселәнеп китте. Шундук: «Нәрсә җебеп төштен?—дип эченнән үз-үзен тиргәп алды.—Әгәр шушында тәмам үлеп китсә? Синең кул астында, ә?»

Бу уй сискәндерде, ныклык бирде. Ул янә иреннәрен кызның авызына терәде.

Сабит агач ботакларын читкәрәк авыштырды. Ничек кенә сак кыланса да, яфраклардан шыбырдап эре тамчылар коелып, кыз белән егетнең икесен бергә чылатты. Хәер, Мидхәт моны тоярлык хәлдә түгел иде. Һушыннан язган кешенең теле артка китеп, сулыш юлын каплау ихтималы барын исенә төшереп, ул кызның авызын ныграк ачтырып карады. Тын юллары ачык, һава үтәрлек икән. Тагын аның иреннәренә авызын терәп, кайнар сулышын өрде, күкрәгенә басты... Әледән-әле башын кызның күкрәгенә терәп, йөрәк тибешен ишетергә теләде, әмма үзенең колак шавын гына тойды. Бераздан ул ясалма сулышны икенче төрле ысул белән ясарга кереште: кызның баш очына тезләнде дә, кулларын әле як-якка җәйде, әле күкрәгенә кушырып кысты.

Баштанаяк чыланган һәм күшегә үк башлаган Сабит ахыр чиктә түзмәде, кызарынып-пешеп чыккан энекәшенә:

—Ярар инде, азаплама,—диде.—Киткән бит инде. Урыны җәннәттә булсын...

Ә Мидхәт ишетми дә кебек, һаман үз эшендә иде.

—Кешенең мие биш минуттан үлә,—диде Сабит тагын бераз тынып торгач.—Син монда ун ук булмаса да, җиде-сигез минут азапланасың инде. Әле без килеп җиткәнче күпме шулай яткандыр... Тор әйдә, машинага кертеп салыйк!.. Әлифә апага ничек әйтербез инде, ә?..

Егетнең карашы исә кызның йөзенә төбәлгән, куллары бер җилпенә, бер аска төшә иде. Вакытның күп узганын үзе дә чамалый, тик ниндидер үҗәтлек, әҗәл белән ризалашырга теләмәү аны хәрәкәтеннән туктатмый иде. Менә кинәт кызның йөзе тетрәнеп куйгандай булды, иреннәре ныграк ачылды. Күкрәк читлеге, тыштан кысканга түгел, үзеннән-үзе тибрәлгәндәй тоелды. Әллә чыннан да сулыш алдымы? Бу уй егетнең күңеленә кайнар дулкын булып бәреп керде.

Ул янә яңагын кызның күкрәк йомарламы астына терәде. Һәм... һәм... Тигезле-тигезсез генә лепелдәү ишетте! Егетнең йөрәге аша ләззәтле дулкын йөгереп узды. Кешенең гомерендә менә шушындый бәхетле минутлар да була!

Ул сикереп торды да, абыйсына:

—Бар, машинанны бор!—диде.—Хәзер үк больницага илтергә кирәк!

Кыз нечкә сынлы булса да, тыгыз тәнле, һушсыз булганга шактый авыр иде, ләкин Мидхәт моны тоймады. Ул ашыгырга кирәген аңлап, шул ук вакытта куе үләнгә абынудан, юл кырыендагы юеш балчыкта таеп китүдән сакланып, машинага таба атлады.

—Илтеп җиткерә алсак кына ярар иде, бездән исән килеш кабул итсеннәр генә иде,—диде Сабит кабаланып.

...Юлда барганда ул, әледән-әле башын борып:

—Син анда авызынны ачып утырма!—дип кисәтте.—Тагын начараеп китмәгәе!

Арткы утыргычтагы Мидхәт, керфек кагарга да куркып, тезләрендә яткан кызның йөзенә текәлгән иде. Керфекләрен күтәрмәс микән? Күзләрен күрергә иде—нинди икән?

Тик бу юлы Мидхәткә аларны күрү насыйп булмады. Хастаханәгә барып житеп, Сабит кереп әйтүгә, ак халатлы ике хатын йөгереп чыкты. Һушсыз гәүдә тирәсендә ыгы-зыгы башланды.

* * *

Алар кайтыр юлга чыкканда, яңгыр туктаган, баюга борылган кояш болытлар арасыннан ярты битен чыгарып, озын нурларын сузган, каршыда дугаланып, кинәеп, илаһи бер тантаналык белән салават күпере күтәрелгән иде.

—Ну, син дә молодец, булдырдың,—диде Сабит энесенә.—Тәки исән килеш илтеп житкердек бит. Ә мин өметне өзгән идем инде. Әлифә апа синең аяк астына егылып рәхмәтләр укыячак болай булгач. Үз кызыннан артык күрә ул аны. Мин, ди, аның анасы урынында, ди.

—Үз анасы үлгәнме әллә?

—Исән, диләр. Кишиневта яши. Әгәр аннан да арырак алып китмәгән булсалар... Ишетеп кенә беләм. Монда кайтып, күзгә-башка күренгәннәре юк. Атасының да, анасының да.

Бу сүзләр Мидхәткә серле йомгак булып тоелды. Нишләп бу кызның анасы Кишиневта? Әлифә дигәне бу кызның кеме дә, ник ул аны үз кызыдай якын күрә?

Егет шуларны сорамакчы булып авызын ачкан иде, күзе юл кырыена төшеп, туктап калды. Анда, яшен суккан каен янында, ак чиләк аунап ята иде.

—Кара, тегенең чиләге һаман шунда бит,—диде ул.

—Алыйк әле без аны. Әлифә апага кайтарып бирик.

Шулай итсәләр, күңелсез хәбәрне әйтү жиңелрәк булыр кебек тоелды. Машинаны юл кырыендарак туктаттылар. Чалбар балакларын күтәрә төшеп, абына-тая янә сынган агачка таба киттеләр. Сабит, иелеп, чыклы үлән арасында чәчелеп яткан жиләкне учлап-учлап чиләккә салырга кереште. Һәм берничәсен авызына капты.

—Эшнең рәтен белә икән бу кызый. Эреләрен, баллыларын сайлап кына жыйган. Кызларның уңмаганы аны учлап-учлап умыра, савытына бөресен-яфрагын кушып тутыра. Ышанасыңмы, бу Әнисәне көненә дүртәр чиләк жиләк жыя, дип сөйлиләр. Ну, ана өйләнгән кеше егылып уначак инде!

...Кече урамга кереп, тыкрык янындагы ихата каршына барып туктагач, Сабит:

—Шушыларның кунагы инде ул Әнисә,—диде.—Әлифә апаның туганнан туганы Илгизләр йорты бу. Әйдә, бергә керик. Берүземә читен... Ал чиләкне..

...Әлифә—кечкенә генә буйлы, арык гәүдәле, өлкән яшьтә булуына карамастан, вак сипкелләре беленеп торган аксыл йөзле, алтмышлар тирәсендәге карчык икән. Мидхәт кулындагы чиләкне күрүгә, аның сирәк керфекле күксел күзләре зур булып ачылды, йөзе күгәренеп чыкты.

—Үзе кая?!.—диде ул кинәт карлыккан тавыш белән.

—Исән ул, исән,—диде Сабит ашыгып.

—Кызлар белән жиләккә киткән иде. Башкалар кайтты, ул юк. Адашкандыр, бер-бер хәл булмагае, дип курыктым. Давылы да көчле булды бит... Курыкканга куш диләр... Яшен сукмады микән, дип котым очты бер мәл...

—Әйе шул...

Әлифә тынсыз калып Сабитка текәлде.

—Больниска илттек без аны. Менә шушы егет коткарды. Бик озак ясалма сулыш ясады. Син борчылма, иң авыры үткән инде, диде врачлар. Жиләк жыйган булган менә...

Әмма апакай аны-моны күрер хәлдә түгел иде. Ул каударланып, өстәлдәге савыт-сабаны ары-бире шудырырырга кереште.

—Ни алып барыйм икән?

—Кая?

-—Больниска инде, кая булсын.

—Син әллә хәзер бармакчымы? Кертерләр микән? Соң бит инде.

—Нишләп кертмәсеннәр? Аның бүтән кешесе юк ла. Мин генә. Хәзер, өстемә киям дә... Машинагызны сүндермичә торыгыз.

—Мин бара алмам шул,—диде Сабит.—Болай да әрле-бирле күп йөрелде. Идарәдә көтәләрдер.

Әлифә аның хәлен аңлый: Сабит—колхоз рәисе, һәр көнне кичке җидедә, бригадирлар, ферма мөдирләре белән бергәләшеп, көнлек эшкә йомгак ясарга, килгәннәрнең гозерен тыңларга тиеш.

—Юлга чыгып бассам, машина очрамый калмас әле,—диде апа.

—Әллә син алып барып кайтасыңмы соң?—дип энесенә борылды Сабит. Мидхәт әле һаман, кулындагы чиләкне кая куярга белмичә, ишек төбендә басып тора иде, Әлифә аның беләгенә килеп ябышты.

—Ал син моны, үскәнем. Чиләге белән ал.

—Кирәкми мина... Рәхмәт.

—Син танымыйсыңдыр да әле, бу безнең Пермь ягындагы Әсгать абыйның малае, Мидхәт исемле,—диде Сабит.—Казанда институтта укый. Авылга беренче кайтуы. Районга аны каршы алырга барган идем.

—Алайса безнең урман җиләге тансык инде сиңа! Ал, үскәнем, ал! Шәһәргә кайткач, дусларыңны сыйларсың...

Әлифә моны шулкадәр ялварып әйтте ки, Мидхәт каршы тора алмады. Тик шунысы: инде күчтәнәчен алгансың икән, апаның гозерен дә аяк астына салып булмый иде.

—Правам бар, дип мактанасың, кайтканда ук рульгә утырмакчы идең,—дип, егетне үгетләвен дәвам итте Сабит.—Идарәгә кереп, путевка яздырыйк та, егетләрчә тәвәккәлле булмаса...

...Күп тә үтмәде, яшел «Уазик» район үзәгенә таба бара иде инде. Мидхәт рульдә, Әлифә аның янәшәсендәге утыргычта. Озын юлны сүз кыскарта, егетнең исә бу апа турында, аннан да бигрәк тылсымлы тамгасы булган кыз турында күбрәк беләсе килә иде. Ул сер йомгагын кайсы җебеннән тартырга икән, дип уйлап барганда, Әлифә:

—Мием түнгән, кеше әйткән колагыма керә, зиһенемә барып җитми,—дип куйды.—Бая Сабит сине Әсгать малае диде бугай.

—Әсгать малае.

—Аның хәлләре ничек соң?

—Ярыйсы болай. Авылга күчеп кайтасылары килә. Эш табылыр микән, йортлар кыйбатмы, кайтып белеш әле, дигән иде. Сабит абыйның үзен күреп сөйләшергә кушты.

—Туган яклар сагындырадыр шул,—диде Әлифә һәм тынып калды. Бу сүзне озайтмады, өстәп сорау бирмәде, чөнки күңеле башкада иде. Сабитның, Әнисәне шушы егет коткарды, дигән сүзләре, ниһаять, аңына барып җитте дә, йөрәгенең хәле китте. Керфекләрен сарган яшь тамчылары аша Мидхәтне әле генә күргәндәй күздән кичерде ул. Урта буйлы, ипле, ыспай гәүдәле, көлсу йомшак чәчле, ак йөзле, зәңгәр күзле бу егет аңа ифрат чибәр булып күренде. Нык үзәкле ирләргә хас калын тавышы йөрәккә ятышлы. Урыс арасында үскәндер—«къ» ны йомшартып, «һ»ны катыландырыбрак әйтә, тик бу да аңа үзенә бер сөйкемлелек өсти шикелле.

—Сез дә монда кунакта икәнсез,—диде Мидхәт.

—Еш кайтабыз без. Казан моннан якын бит, сез үскән Урал ягы ише

түгел. Туган авыл сагындыра. Нигез генә таралды.

Әнисә көрсенеп куйды.

—Кызыгыз тумышы белән бу якныкы түгел, ахрысы. Абый шулай диде.

—Молдавиядән ул... Анын атасы—минем апамның малае.

Аннары, Мидхәткә анлаешлырак булсын өчен:

—Племянник була инде ягъни,—дип өстәп куйды.—Апам үлеп китте дә, аның улын тәрбияләү мина калды, менә хәзер шул баланың кызын үстерергә насыйп булды.

—Ә үзе?

—Кишиневта яши. Хатыны молдаванка анын.

Мидхәтнең сораулы караш ташлаганын күреп:

—Балалары күп—өчәү, тәрбияләргә хәлләреннән килми,—дип өстәде Әлифә.—Ә мин ялгыз бит. Пенсионер карчыкка иптәш булу әйбәт ул.

Мидхәт бераз тынып торды да:

—Ике кеше бер пенсиягә яши алмый бит, әтисе ярдәм итә торгандыр инде,—диде.

Әлифә мәзәк сүз ишеткәндәй кеткелдәп куйды.

—Алардан аны-моны өмет итү юк инде ул. Үзем бераз булса да акча юнәтәм, сату-алу белән шөгыльләнәм.

—Фирмагыз бармы әллә?—дип сорады Мидхәт гаҗәпләнеп.

Әлифә бу юлы тәмам яктырып китте:

—Ниткән фирма инде ул мина! Палаткам бар,—диде.—Урам чатында. Кешедән ким яшәмибез, Аллага шөкер. Әнисә үзе дә каникул вакытында эшләп алырга атлыгып тора.

Һәм апакай егеткә озак итеп сокланып карады. Үз гаме ничек кенә көчле булмасын, юлдашының йөз чалымнарыннан, гамьле дикъкатеннән табигате йомшак, күңеле нечкә икәнлеген тоеп алды ул. Аннан күзгә күренмәс жылы нур бөркелеп, жанга дәва булып инә, бүгенге хәлләрнең ахыры хәерле булачагына ышаныч бирә иде. Больницада Әнисә, тәрәзәгә карап, аны көтеп утырадыр, хастаханәгә барып керүгә килеп кочаклап алыр... Бәлки, әле менә шушы машинага утырып, бергәләшеп өйгә кайтырлар.

...Әмма аларны хастаханәгә кертмәделәр. Вакыт соң, диделәр. Кызыгызның хәле начар түгел, янында кизү торунын кирәге юк, иртәгә килерсез, дип ишек төбеннән кире бордылар.

* * *

—Исәнмесез!

Капкадан бер оя каз куалап чыгып килгән кыз, урамнан узып барган егеткә башын күтәреп карады. Танымады. Әмма сәлам бирүенә гаҗәпләнмәде: авыл кешеләре очраган һәркем белән исәнләшә. Егетләр кунак кызына елмаеп сүз кушмыйча узмый да узмый инде. Әнисә авылдагы мондый гадәтне белә иде, шуна күрә битараф кына:

—Саумысез...—диде дә:—Кая киттегез? Көш-көш!—дип, кулындагы чыбыкны селтәп, таралыша башлаган биш-алты бәбкәне аналары янына тупларга тырышты. Мидхәт, ысылдып, томшыгын сузып каршысына килгән ата каздан кулындагы юл сумкасы белән ышыкланып туктап калган, үзе исә кызны күзәтә иде. Әнисә теге көндәгечә киенгән: терсәккәчә төшеп торган киң җиңле ал кофта, балак очлары сәйлән белән чигелгән джинси чалбар. Хәзерге кызлар өчен гадәти кием, ләкин күзгә ташлана торган үзенчәлеге дә бар: эре дулкынлы кара чәчен баш артына җыеп, кофтасы төсле үк ал тасма белән бәйләп куйган. Чыбык белән селтәнгән саен, җиннәре җилпенеп куя. Бөтен дикъкате бәбкәләрдә, узгынчы егеттә һич гаме юк. Ах, белсә иде ул аның кем икәнен! «Без синең белән күп мәртәбәләр иреннәрне иреннәргә

тәрәдек—үбештек, дияргә була. Ничек кенә үбештек әле! Мин синең күкрәгенә башымны салдым... Мин сине кочаклап, кулыма күтәреп йөрдем»,—дисән, нишләр иде икән? Ә бит аның иреннәреннән тәме хәтердә сакланган икән. Җиләк тәме килә иде алардан. Тәненнән дымлы үлән исе аңкый иде. Якынрак килеп иснәп карыйсы иде—һаман да шулай микән?

Әнисә исә егетне, ата каздан шүрли, дип уйлады. Борылып килде дә:

—Көш-көш!—дип, чыбыгы белән селтәнде.—Куркытма кешене! Ул синең бәбиләреңне...—кыз тотлыгыбрак калды, сүз эзләде, ахрысы.—Алып китмәс...—дип тәмамлады ул җөмләсен.

Белсә иде ул Мидхәтнең аяклары нилектән хәлсез калганын!

Теге чакта аңсыз яткан бу зифа сынны үз тәненә кысу, күкрәк алмаларына орыну табигый иде. Ә хәзер якын да килеп булмый... Әйтер сүз табылмый, тел бәйләнгән, тик эчке бер рәхәтлектән авыз гына ерылган.

Әнисә сәерсенеп, тамгалы ияген чөя төшеп, сораулы караш ташлады—бәгырьнең нәзек бер кылына орынгандай итте. Күзләре кара, карашы тирән, серле икән. Менә ул сыгылмалы, нечкә сыны белән әле бер, әле икенче якка талпынып, алсу җиңен җилпи-җилпи казларны тыкрыкка таба куып, ераклашты.

Авыл җирендә үскән Мидхәтнең күңеленә бик якын күренеш иде бу: кояшлы, тыныч көн, күктә, каурый болытлар арасында кара тилгән әйләнә... Як-ягына куерып кычыткан, тигәнәк үскән, уртасына бәбкә үлән келәме түшәлгән киң тыкрык буйлап кыз бала казлар куып бара. Мидхәт аякларын чирәмнән аера алмыйча басып торганда, капкадан ашыгып Әлифә килеп чыкты:

—Исәнме, Мидхәт! Ярый әле очрадың, үзем сезгә барып килергә дип тора идем. Кич белән, безнекеләр эштән кайтуга, сезне кунакка чакырабыз. Хәзер тавык суйдырам... Абыеңнарга ныгытып әйтеп куй: җыелышып килегез! Рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз бер.

—Мин китәм,—дип, кулындагы сумкасын болгап куйды Мидхәт.

—Нишләп алай бик тиз?

—Йомышны үтәдем, сөйләшәсен сөйләштек. Иртәгә безнең спорт лагерында смена башлана.

—Ай Алла, сезгә рәтләп рәхмәт тә әйтә алмый калабыз бит! Әнисә кичә генә кайтты. Күрми дә китәсең бит, болай булгач...

—Күрдем. Әнә бит!—дип ияге белән тыкрыкка ымлады Мидхәт.

Әлифә ашыгып ул күрсәткән тарафка атлады, кулын болгап:

—Әнисә! Кил әле монда!—дип кычкырды.—Мидхәт абыең бит бу! Сине коткарган...

—Кирәкми, кирәкми!—дип, кыенсынып аны бүлдерде Мидхәт.—Ашыгам. Автобустан калуым бар... Сау булыгыз!

Һәм ашыгып китеп барды. Әлифә уфтанып, Әнисә сәерсенеп аның артыннан карап калдылар.

...Аларның башка бүтән очрашмавы да ихтимал иде. Бер авылдан чыккан кешеләр, шәһәргә килеп яши башлагач, гадәттә күп халык арасында эреп юкка чыккан кебек булалар. Очрашмыйлар-күрешмиләр, бер-берсенең хәл-әхвәлен, авылга кайткач, туганнар аша гына белешәләр. Бу юлы да шулай булыр кебек иде. Мидхәт белән Әнисә арасында кардәшлек-туганлык юк, очрашырга ни сәбәп булыр иде икән?

Дөрес, кара бөдрә чәчен ал тасма белән бәйләгән кызны тагын бер күрәсе килү үзе зур бер сәбәп була алыр иде алуын. Ләкин аларга күрешмәү хәерлерәк иде, чөнки очраклы танышлыкны дуслыкка әверелдерергә ярамый иде. Беренчедән, кыз яшь иде—мәктәп баласы. Икенчедән, шәһәрдә Мидхәтнең йөргән кызы бар иде. Үзе белән бер группада укый, бер тулай торакта яши торган Лениза белән шактый ук дуслашып киткән иде инде ул.

Ләкин Әнисә белән аны яшен очраштырган иде бит. Акыл ирешмәслек бер хикмәте булгандыр моның, мөгаен. Бу очрашу онытылырга, алар бер-берсен югалтырга тиеш булмаганнардыр. Югыйсә, ничек итеп Әнисә егетнен барыр юлына чыгып басар иде икән?

* * *

Спорт лагерында смена алышынган көнне Мидхәт белән Лениза шәһәргә аны-моны алырга дип кайттылар. Трамвайга утырып, тулай торакка баралар иде, бер тукталышта Лениза кулындагы ромашкалар бәйләме аша үрелеп, ачык ишектән урамга карады да:

—Глядь, морожный саталар анда,—дип ялманып куйды.—Әйдә төшәбез!

—Безнең тукталышта да бардыр әле,—диде Мидхәт урамга күз салмый гына.

—Әллә бар анда, әллә юк. Әйдә.

Һәм алар ябыла башлаган ишекне этәреп, эссе кояштан кызып йомшарган асфальтка сикерделәр.

Урам почмагына өстәл биеклегендә ак тартма китереп куйганнар, алсу кофта, джинси чалбар кигән, кара бөдрә чәчен киң алсу тасма белән бәйләгән кыз аның эченә иелгән иде. Менә ул турайды, янындагы балалы хатынга туңдырма бирде. Мидхәтнең йөрәге дерт итте—Әнисә иде бу. Үзенә төбәлгән карашны күреп, ул башта сагаеп калды, нәрсәнедер исенә төшерергә тырышкандай булды. Аннары йөзе яктырып китте—таныды. Аның кара күзләре төбендә очкын кабынгандай булды, шома бит очлары алланды, ирен читләрендә елмаю балкыды, кыенсыну аша сөенү йөзендә, хәтта тылсымлы ияк уемында да чагылды кебек.

—Ике пломбир!

Ленизаның төксе тавышы аларны айнытып җибәрде. Әнисә карашын аңа күчерде һәм кинәт үзгәрде: йөзендәге балкыш сүнде, борын канатлары тетрәнеп куйды, керфекләре аска төште.

—И-и, кем бу, дисәм, Мидхәт, син икәнсең бит!—диде таныш тавыш. Биш-алты адым гына арырак, азык-төлек кибетенең почмагына терәп, зәңгәр палатка корылган, аның эчендәге тәбәнәк прилавка артыннан Әлифә ике кулын сузган иде.

Мидхәт дулкынланып, киң елмаеп, аңа таба атлады. Исәнләштеләр, хәл-әхвәл белештеләр. Баксаң, Әлифәнең сату итү урыны биредә икән дә, Әнисәгә дә каникул вакытына шушында ук эш табылган.

—Сатып алучыларым ярдәм итте инде,—диде Әлифә.—Блат бар бит минем дә.

Һәм, тәбәнәк прилавкада тезелеп яткан оекбаш, кульяулык, бейсболка, чүәк ише вак-төяккә караган егетнең йөзендә гаҗәпләнү галәмәтләре күреп, шаярткандай кеткелдәп куйды.

—Моның ише нәрсә һәр кешегә кирәк ул!—диде.—Мин аны вьетнам базарыннан барып алам да, хакын арттырыбрак сатам. Бер-ике кием оекбаш йә кульяулык өчен генә күпләрнең әллә кая барып, вакыт уздырып йөрисе килми, моннан гына алалар. Тегенә-мона заказ бирүчеләр дә бар.

Күренеп тора: апакай «бизнес»нын җаен алган, күңеле хуш иде. Тик иркенләп сөйләшергә мөмкинлек булмады, трамвайлар килеп тора, аннан төшкән халыкның күбесе палатка йә туңдырма тартмасы янында тукталып кала. Көн эссе, тамаклар кибә, битләр тирли, ялан башларга кояш тия—кульяулык-бейсболкаларның иң кирәк чагы. Туңдырмасын әйткән дә юк.

—Кич белән безгә килеп чык әле!—диде Әлифә.

—Мин үзем генә түгел бит...

—Иптәшең белән килегез! Күңеллерәк булыр! Ник таныштырмыйсың соң әле син безне?

Ленизa читтәрәк, бер кулы белән ромашкалар бәйләме кочаклап, икенче кулыннан тундырма ашый, үзе, эче пошкан сыман, карашын читкә төбәгән иде. Мидхәт барып, аның терсәгеннән тотты да, палатка янына алып килде. Кызның холкын белгәнгә, чит кешегә кунакка барырга риза булмас, дип уйлаган иде ул. Әмма ялгышкан икән. Лениза башын борып, ак тартма янында әвәрә килгән ал тасмалы кызга күз салып алды да, палатка эчендәге апага:

—Чакыруыгыз өчен рәхмәт,—диде.—Обязательно киләбез. Әйе бит, Мидхәт?

Һәм ул, егеткә борылып, бик якын, үз икәнлекләрен белдереп, мөлаем елмайды.

—Килегез, кил,—диде Әлифә куанычыннан нишләргә белмичә.—Рәхәтләнеп өй ашы ашарсыз. Монда сезнең пешеренер җирегез дә юктыр әле.

—Тулай торакта кунып чыгарбыз, дигән идек,—диде Мидхәт.—Кертсәләр. Анда хәзер ремонт бит.

—Кертмәсәләр, туры безгә генә килегез! Сыярбыз! Сәгать сигездә өйдә булабыз без.

Лениза кулындагы ромашкаларның яртысын аерып алып, Әлифәгә сузды.

—Бусы сезгә урманнан шүрәле бүләге,—диде шаярып.

Әлифә тәмам эреп китте.

—И-и, рәхмәтләр яусын!—дип, чәчкәләрне алып, битен каплады апакай.—Бер җаен табып, кибеттән су алып чыгармын да утыртып куярмын. Без монда җидегә кадәр торабыз. Сигезләргә килсәгез, әйбәт кенә булыр.

Һәм кәгазь кисәгенә адресын сызгалап, Ленизага сузды.

Кире трамвайга утыргач, Лениза тәрәзәгә карап басты. Тик урам манзарасын күрми дә кебек, үз уйларына чумган иде. Мидхәт аны беренче күргәндәй баштанаяк күздән кичерде һәм ихтыярсыздан Әнисә белән чагыштырды. Әйе, аларның аермасы—җир белән күк арасы иде. Лениза буйга Мидхәт белән бертигез диярлек, биек үкчәле танкетка кигәнгә, калкурак та тоела. Юка көлсу чәче тигезле-тигезсез булып маңгаен каплаган, беразы соры күзләренә үк төшкән, ян-яктан иңнәренә тиеп тора. Хәзер мода шундый: кызлар, мунчадан чыккач чәч тарап тормыйлар, диярсең. Сыны төз, чандыр Ленизаның, спорт белән шөгыльләнгәнгә—тәне тыгыз. Джинси чалбары, күкрәкләрен кысып торган, кендектән югары кара кофтасы бик килешле. Ачык изүенә катлы-катлы сары чылбырлар салынган. Ясалма алтыннан. Кыскасы, егетләрне бер карауда җәлеп итәрлек үк булмаса да, төшеп калганнардан түгел. Модный киенгән, сынын—туры, башын югары тоткан мондый кызлар тормышта үзенекен ала... Кинәт Лениза борылып, кистереп карап куйды. Мидхәт керфекләрен аска төшерде...

Тулай торакның коменданты, таза гәүдәле чая хатын ромашкаларны бик сөенеп кабул итте. Мидхәт аңа гел ярдәмләшә, Лениза белән булган дуслыгы да яхшы мәгълүм, шунлыктан, яшьләрне кире борып җибәрү уе хатынның башына да килмәде.

—Кунып чыгарга рөхсәт бирмәссез микән?—дигән сорауга:

—Кайда урын табасыз, шунда урнашыгыз,—диде.—Хәзер чиста җәймәләр бирәм.

Лениза яши торган бүлмәдә тимер караватларны уртага тезеп куйганнар, әмма ремонтка керешмәгәннәр иде. Әйберләрен куйдылар да, кичен килербез дип, шәһәргә чыгып киттеләр.

...Әлифә Азинодагы яңа панель йортта, җиденче каттагы бер бүлмәле фатирда яши икән. Кайчан ничек өлгергәндер, кунаклар килүгә, туй табыны әзерләп куйган иде: алма-әфлисун, кыяр-помидор, өрек-йөзем. Табын

уртасында яшел тажын як-якка сибеп, алтынланган кабырчыклары белән кәперәеп, ананас тырпаеп утыра. Анын янындагы бәллүр вазада ромашкалар, янәшәдә—шампан шешәсе.

—Шартлатып ач әле шуны, Мидхәт!—диде бәхете тулып ташкан Әлифә.

Күбекле шәрабны затлы бокалларга салып куйгач, йөзләр тагын да яктырды, телләр чишелде. Ленизанын бите алланган, соры күзләре яктырган, һәр ымында, сүзендә, керфекләрен сирпүендә янындагыларга ягымлы игътибар, шул ук вакытта үз дәрәҗәсен белү дә сизелеп тора. Мондый чакларда ул бик тә сөйкемле була иде. Спорт лагерында балаларнын төрлесе бар, кызык хәлләр булгалап тора, берничәсен сөйләп алды. Аш бүлмәсе белән ике арада йөргән Әнисәнен чыгып торган чагын туры китереп, жай гына:

—Внучкагыздыр инде бу сезнен?—дип сорап куйды. Әлифә Ленизага таба башын сузып, шыпырт кына:

—Племяннигымнын кызы бу,—диде.—Тормышлары житеш түгел, тагын ике малайлары бар. Шуна үз янымда торырга чакырдым.

Лениза апакайнын хәленә кергәндәй, тирән итеп көрсенде дә:

—Вот оно ка-а-ак...—дип сузды.—Хәзерге вакытта кайберәүләр үз балаларын ничек кулда тотарга белми. Әнә, безнен лагерьда да ниндиләре генә юк. Бик зур жаваплылык алгансыз икән үз өстегезгә...

Ул арада бүлмәгә чәйнек күтәреп Әнисә килеп керде, сүз өзелде. Кызыл чәчәкле, жинсез халат кигән, чәчен гадәттәгечә ал тасма белән бәйләп куйган Әнисә жәлт кенә карап куйды. Карашы шундый үткен иде, әйтерсен лә һәммәсен фотокарточкага төшерде. Ул сурәттә өстәл артындагыларнын тышкы кыяфәте генә түгел, эчендәге уйлары да чагылды булса кирәк, һәрхәлдә Мидхәткә шулай тоелды.

Әлифә унайсыз тынлыкны таратырга тырышып, жиләк кайнатмасы салынган бәллүр савытны Ленизага таба шудырды.

—Менә моны авыз ит әле син. Әнисә сые бу. Жиләкнен татлысын гына жыя, газда күпертеп кенә ала. Һәммәсен үзе эшли!

—Бергә пешердек,—дип куйды Әнисә житди итеп.

—Кайнаттык диген!—дип көлеп төзәтте аны Әлифә.—Кайнатма бит ул!—Аннары Ленизага борылып:—Татарчасы бик шома түгел шул әле,—дип куйды.—Бик тырыша, өйрәнер, Алла боерса.

—Мина жиләк ярамый,—дип пыяла савытны читкәрәк этте Лениза.—Аллергия.

—Хәзер, үзем ашыйм да, сина әйтермен нинди икәнен,—дип кара бизәкле көмеш балкашык белән савытка үрелде Мидхәт.

Сый-нигъмәт татлы, шәраб затлы булса да, күнелләр жылынып житмәде, чөнки биредәге дүрт кеше арасына ниндидер бер киеренкелек кереп оялагандай иде.

—Ә син нигә берәр кая ял итәргә бармадын?—диде Лениза Әнисәгә.—Әгәр теләсән, мин сина үзебезнен лагерьга путевка табып бирәм. Бездә синен кебекләр күп.

—Мин дә әйткән идем ана, каникулында ял ит, дип,—диде Әлифә.—Эшлим ди бит. Кыз кешенен матур киенәсе килә. Энеләренә бүләк жибәреп булмасмы, ди.

Лениза «хм-м» дип көлемсерәп, башын чайкап куйды. Анын йөзендә, күзендә хужа хатынны—сай акыллыга санау, Әнисәне исә баласыту ярылып ята иде. Моны тоеп алган Әлифә, ара-тирә гадәтенчә кеткелдәп куйса да, боегуын яшерә алмады. Бераздан сүз дә өзелде.

Китәргә вакыт иде. Саубуллашканда Әлифә мәжбүрләп диярлек Мидхәтнен кулына авыр гына полиэтилен капчык тоттырды.

Үзе, чәчәкле күлмәк өстеннән иненә ефәк шәл салып, кунакларны озата

чыкты. Трамвай тукталышына шактый барасы иде. Көн эссесе сүрелгән, биек агач башларына энгер эленә башлаган, тирә-юньгә җәйге жилсез кичләрдә генә була торган рәхәт тынычлык ингән иде. Алар биек тупыллар ышыгыннан сузылган сукмак буйлап әкрен генә атладылар.

—Странная девочка,—диде Лениза үзалдына уйлангандай.—Шактый сәер.

—Ярамаган сүз ычкындырмады кебек бит үзе?—диде куркынгандай Әлифә.

-—Рәнжеп китә күрмәгез тагын... Мин үзем ана караган саен сөенәм. Теге хәлләр искә төшкәндә, йөрәгем жу-у итә, тез буыннарым йомшап китә. Әгәр шунда Мидхәт булмаса... Ул коткармаса, беткән булган икән бит балакай!..

—Нәрсәдән коткарды аны Мидхәт?!

—Үзе сөйләмәдемени? Яшен суккан иде бит безнең Әнисәбезне.

Лениза күзләрен зур ачып егеткә төбәлде:

—Слушай, кайчан булды бу?

—Узган айны... Абый белән без районнан авылга кайтып килгәндә, юл кырыенда егылып ята иде...—диде Мидхәт сүрән генә.—Ну, күргәч туктадык инде. Машинага салып, больницага илтеп тапшырдык. Анын нәрсәсен сөйлисең. Без күрми үтсәк, бераздан үзе дә торып басар иде...

—Врачлар бер дә алай дими,—дип каршы төште ана Әлифә.—Әгәр вакытында ясалма сулыш ясатмаган булсалар, ай-һай, без ярдәм итә алыр идек микән, диләр.

—Ах, шулаймыни?! Син ана ясалма сулыш ясаттыңмыни?!

Лениза Мидхәтнең йөзенә сынап һәм шикләнеп карады.

—Абый бар иде бит анда,—диде Мидхәт. Үзе йөзенең кызарып чыкканын тойды.—Ул ясады аңа ясалма сулышны. Ул белә... Тәжрибәсе зур...

Әлифә ана каршы әйтергә авызын ачкан иде, Мидхәтнең каушаганын күреп, тыелып калды.

—То-то странная. Башына зыян тимәде микән ул кызның?—диде Лениза уйланып.—Шактый сәер күренә. Мин яшьләр белән эшлим бит, чамалыйм...

—Үзем дә сизәм инде,—диде Әлифә кинәт тирән көрсенеп.—Шундый өздереп карый кайчакта, эчтән бөрешеп китәм. Күз карашы белән эчеңне актаргандай итә, ни уйлаганыңны белеп тора шикелле. Элек алай ук түгел иде, кинәт үзгәрде. Әллә чыннан да яшеннең тәэсиреннән, әллә башка берәр сәбәптән...

—Ә башкасы нәрсә?—дип, барган җиреннән туктап, апага таба борылды Лениза.

—Мидхәт сөйләгәндер бит инде... Анасы молдаванка бит анын. Кармен исемле.

—Безнең арада анын хакында сүз булганы юк.

—Жай чыкмагандыр,—диде Мидхәт ризасызлык белән.

—Кичә урын-жирне алыштырганда, диван япмасы астыннан бер төргәк хат килеп чыкты,—диде үз гамьнәре белән мавыккан Әлифә.—Анасы белән хат алышып ята икән. Адресы «до востребованья» язылган. Миңа белгертәсе килми...

—Ниләр язган соң анасы?

—Шайтан белсен... Үз телләрендә бит... Молдаванча... Хәрефләренә хәтле икенче, латин алфавиты...

—Ә үзе ни ди?

—Сорамадым инде... Әйтәсе килсә, үзе әйтер иде... Болай бит артыгын тыкшыну була...

—Вот как...—диде Лениза.—Сез саграк булыгыз. Алтыннарыгызны яшереп тотыгыз. Акчагызны да...

Әлифә сискәнеп китте.

—Авызыннан жил алсын! Бөтен нәрсә тарау ята, сорамыйча бер тиенгә дә

орынганы юк!.. Күпме гомер бергә яшибез бит инде!

—Моллаваннар чегән токымыннан бит алар,—диде бер дә исе китмәгәндәй Лениза.—Кармен исемле дә булгач, чын чегәндер әле. Алар күз буярга оста!.. Хат аша кинәшеп, бозып ташламасыннар тагын. Аның ишене хәзер бик күп сөйлиләр. Фатирыгыздан колак кактырмагайлары!

—И, анасы сихерли белсә, тикшерүчеләрне сихерләр иде, төрмәгә кереп утырмас иде,—диде пошаманга төшкән Әлифә.

—Ах, төрмәдәмени-и-и! Нәрсә өчен икән?

—Сату эшендә иде. Растратасы чыккан...

Әлифә, артыгын ычкындырганын тоеп, телен аркылы тешләде. Тик соң иде инде. Аңарчы хатын-кызлар сүзенә катышмыйчарак килгән Мидхәт, нык кына итеп:

—Бәла агач башыннан түгел, кеше башыннан йөри,—диде.—Ни генә булса да, юньле кеше анасыннан йөз чөерми.

—Анысы шулай инде...—диде Әлифә, юанырга тырышкандай.

—Но, алма агачыннан ерак төшми, дигәнне дә онытырга ярамый, нәселнәсәпкә, тилчә тамырга, ди минем әби,—диде йомгак ясагандай катгый итеп Лениза.

Бу сүзләр егетнең күңелен нык кына кырса да, каршы әйтергә теле кычытса да, ничектер кирәкле сүзләр табылмады.

—Сәерлегеннән зыян күргән юк үзе, ә файдасын бик сизәм,—диде әңгәмәдәшләреннән бигрәк үз-үзен юатырга тырышкандай Әлифә.—Соңгы вакытта мине дәвалый башлады әле ул. Көн буе басып торгангадыр инде, аякларым белән интегәм. Төннәрен кая куярга белмим. Йоклап булмый. Берчак шулай төн уртасында кухняда таптана идем, Әнисә уянып килеп чыкты. Урындыкка утыртты да, каршыма тезләнеп, учларын балтырым тирәли әрле-бирле йөртә башлады. Орынмый да, кагылмый да үзе, ә җылысы тия. Ике-өч минут үткәндерме-юкмы, аякларым җылынып-йомшарып киткәндәй булды, җаныма тынгы инде. Иртәнгә хәтле изрәп йоклаганмын...

—Гипнозга сәләте бармы әллә?—диде Лениза.

—Әйтәм бит, андый сәләтен сизгән юк иде моңарчы. Бик рәхәт икән ул! Хәзер үзем сорыйм, непрямой массажыңны яса әле, дип. Врачлар булдырмаганны булдыра...

Сүз белән мавыгып, тукталышка килеп җиткәннәрен сизми дә калганнар икән. Урам уртасында трамвайның ишеге ачылганын һәм юл чатындагы светофорда яшел ут кабынганын күреп, Мидхәт Ленизаның шәрә беләгеннән эләктереп алды.

—Йөгердек! Икенчесе тиз генә килмәс! Сәгать уннан соң транспорт йөрми!

—Безне онытып бетермәгез, тагын килегез!—дип кул болгап калды Әлифә.

• • •

...Бу кич һәммәсен кинәт үзгәртеп җибәрде. Алай гына түгел, тормышны әйләндереп салды, дияргә була. Алдагы көндә күрәчәкләр нәкъ менә шушы кичтән башланды да.

Моңарчы үзара мөнәсәбәт дуслыктан ары китмәгән иде әле. Аларны берберсенә егет белән кыз арасында була торганнан бигрәк, абый белән сеңел арасында була торган якынлык бәйли иде шикелле. Хикмәт шунда, Ленизага уку шактый авыр бирелде. Дөрес, ул тырыша: лекцияләрнең берсен дә калдырмый язып бара, семинарларга һәрвакыт әзерләнеп килә. Әмма химик һөнәре өчен кул яту дигәне дә бик мөһим бит әле. Бу җәһәттән Ленизага читен иде, чөнки, башка кызлар көлеп әйткәнчә, аның кулы инбашына кире ягы белән утыртылган булса кирәк.

Мидхәтнең исә бу һөнәргә күңеле дә тарта, кулы да ята иде. Башкаларның

башы житмәгәнне шундук тотып ала, үтә катлаулы анализларны бер талпынуда башкарып куя.

Сораган кешегә ярдәм итүдән дә беркайчан баш тартмый. Группада исә ярдәмгә иң мохтаҗы Лениза булып чыкты.

Чөнки ялгыз иде бу кыз. Әллә артык нечкә күңелле, әллә үпкәчел булгангамы шунда, кызларның берсе белән дә якынаеп, сердәш булып китә алмады. Андыйлар турында, серкәсе су күтәрми, диләр. Шул ук вакытта андыйлар яклаучыга, киңәшчегә аерата мохтаҗ да. Мондый очракта Мидхәттән дә кулайрагы булмагандыр. Ул кечкенәдән үзенең ике сеңлесе өчен нәкъ менә шундый таяныч булды да инде.

Беренче елны ук Ленизаның курс эше өчен кирәкле тикшеренүләрне алар бергәләп башкардылар. Рәхмәт йөзеннән кыз кичләрен аны борщ, тәмле салатлар белән сыйлый иде.

Менә шуннан китте бу якыннан аралашу. Лабораториядә кыз егетнең ярдәменә мохтаҗ булса, сессия вакытында Мидхәткә дәфтәрләрен биреп тора. Билгеле инде, кайбер имтиханнарга бергә әзерләнү уңайрак булып чыкты. Дөрес, нәтиҗә төрле була—Мидхәт бишле ала, ә Лениза дүртле белән генә кала. Әмма кыз моңа күңелен төшерми, дусты өчен куана.

—Югары стипендияне синең кебек егетләргә бирми, кемгә бирсеннәр тагын!—ди.

Ярдәм итешеп яшәү икесе өчен дә кулай, бер-берсенең эчен пошырган чаклары исә шактый сирәк. Нәкъ шундыйлар үзләре хакында, без фәкать дуслар гына, дип сөйлиләр һәм, күңелне кузгатырлык башка берәү очрап куйса, бу дуслыкны өзәргә дә күп сорамыйлар. Үпкән-кочкан жилгә очкан, дип күптәннән әйтелгән бит инде... Тик моңарчы ни Мидхәткә, ни Ленизага андый «башка берәү» очрамаган иде әле.

Әмма бүген хәл кинәт үзгәргән иде...

Алар тулай торакка барып житкәнче, караңгы төште. Ишек төбендә генә лампочка яна, эчтә утларны кабызмаганнар. Буш коридорлар серле һәм шомлы, ничек кенә сак атларга тырышсалар да, аяк тавышлары диварларга бәрелеп, каты яңгырый иде. Лениза таныш бүлмәнең ишеген кармаланып ачканда, шыгырдау авазы колакны ярды.

Бусаганы атлауга, Мидхәт туктап калды. Эчкә керүдән нидер тыя, нәрсәдер шикләндерә иде.

Лениза исә һичкайчан булмаганча кыюланган, аның адымнарында, ярым карангыда шәйләнгән хәрәкәтләрендә, сулыш алуында ниндидер тәвәккәллек, гасабилану сизелә иде.

—Әйдә, утны яндырып тормыйбыз,—диде ул.

Чыннан да, күз тиз ияләште, пәрдәсез тәрәзәләрдән урам фонарьларының яктысы саркый, аннан да бигрәк, тулган ай идәнгә киң итеп нур тасмасы сузып салган иде.

Лениза бер җәймәне жилпеп өстәлгә япты, өстенә Әлифә биреп җибәргән пакетны китереп куйды.

—Син нишләп йомышка кергән күрше малае кебек басып торасың?—диде.—Апаң шампанский тыгып җибәргән монда! Ә бу нәрсә?.. Ох ты-ы! Пластик стаканнар да куйган!..

Шампан күбеге стакан тоткан бармакларны кытыклады, авызда эреде, баш миен сарды.

Алай да бөтенләй үк онытылып булмый кебек иде. Айның нуры якты булса да, салкынча тоела, ул нәрсә хакындадыр кисәтә кебек иде. Әйтерсең лә, тәрәзә артына берәү поскан да, Мидхәтнең һәр хәрәкәтен, йөзенең алланганын, күзләренең сәер ялтыраганын күзәтеп- күреп тора, башны томалаган томанны куарга, күңелне ургыткан хисләргә бирешмәскә куша.

Юк, куша гына түгел, ялвара, монын яхшыга алып бармаячагы хакында кисәтә кебек.

Мидхәт карангыда үзалдына елмайды: юкка күзәтәсен, юкка кисәтәсен, диде ул эченнән генә күз алдына килгән кара күзле кызыкайга. Ленизa белән аралар чиста, вәгъдәләр бирелмәгән, ант касәләре эчелмәгән әле. Һәм шулай булып калыр да. «Ул оялчан, тыйнак кыз, мин дә үземне кулда тота беләм».

Дөрес, анын күкрәге кызнын иңбашына якынайганнан-якыная бара. Әйе, тән ихтыярга буйсынмый, ана таба авыша, куллар үзләреннән-үзләре анын тәненә урала. Мондый очракта, мондый шартларда эчендә жаны булган егет башкача була ала димени?! Ләкин гадәттә ифрат тотнаклы, оялчан Ленизага ни булган әле бүген? Үзе дә гажәпсенә ахрысы, йөзгә кайнар сулышын бөркеп: «Әллә ни булды мина,—ди.—Шампанскийга сөйдергеч салганнар микән әллә?»—«Бардыр, бардыр...»,—дип жавап бирә Мидхәтнен теле акылга каршы килеп. Колагы белән моны ишеткәч, гажәпләнми, эченнән: «Әй, бер суырып үпкәннән ни була!—дип уйлый.—Аннан артыгын Ленизa барыбер рөхсәт итми. Бер чиктән уздырмый, вакытында туктата, айныта белә... Андыйга оста ул...»

Аулакта ялгыз калулары беренче генә түгел... Бу юлы да ахыр чиккә житмәсләр, үз-үзләрен кулга алырлар...

Мидхәт, бераз тын алырга, чуалган зиһенен тәртипкә китерергә, йөрәгенен шашып тибүен басарга тырышып, стаканнан жылымса шәрабне зур йотымнар белән голт-голт итеп эчеп куйды. Әмма тынычлану-айну урынына зиһен тагын да ныграк чуалды, ай нуры аша кисәтеп карап торган күзләр эреп юкка чыкты. Ленизa шоколад кисәген авызына яртылаш кабып, яртысын анын кызган иреннәренә китереп терәде... Ах, бигрәк баллы ла кәнфите! Аннан татлы иреннәре! Аннан ләззәтле бөтен тәненен орынуы... Анын бу кадәр кайнар, тәненен бу чаклы ипле икәне монарчы ничек беленмәгән сон әле?

Ләкин... нишләп Ленизa башка чактагы кебек читләшми? Юка гына кофта тукымасы аша күкрәк алмалары йөрәк турын көйдерә... Кызнын гадәттә кырыс хәрәкәт белән аны читкә этәрә белгән куллары ничек болай йомшарган, тоташ назга әверелгәннәр сон әле? Муенны, битләрне шушы рәвешле акылдан шаштырырлык итеп иркәләргә кайчан өйрәнгәннәр? Менә алар ачык изүдән күкрәккә шуыштылар, аннары аска таба...

—Нишләтәсен син мине, Ленизa?

—Ә син мине?...—дип шашып сарыла кыз.—Кадерлем... Бердәнберем... Иркәм...

Ленизанен теле дә шундый татлы була ала микәнни? Анын кәнфит исе аңкыган авызыннан шундый сүзләр сирпелеп чыга аламыни?! Еллар буе моны Мидхәт ничек белми йөргән сон әле? Тыштан караганда сары чыпчык кебек гадәти күренгән бу кызыйнын эчендә кыйммәтле хәзинәләр ята икән бит. Менә кинәт затлы сандык ачылды, андагы асылташлар күзне чагылдырып, зиһенне чуалтты. Юк, бу затлы сандык түгел икән лә, бу тылсымлы касә икән... Анын эче тулы татлы шәраб икән...

—Әйдә, тагын берне эчәбез... Анда калды бит әле...

—Ленизa, шаштырасын син мине, акылдан яздырасын...

—Мин түгел, син... Син шаштырасын мине... Мин берни дә белмим... Син өйрәт мине, пожалуйста, өйрәт...

—Әгәр син риза булсан...

—Мин риза... Мен риза... Син мине үкенерлек итмәссен бит, жаным?

—Мин синеке, Ленизa... Фәкать синеке генә... Без бергә булырбыз... Мәнгегә...

Мидхәт ни сөйләгәнен үзе дә аңламас хәлдә иде. Куллар кызның чалбар чылбырына шуышты, бармаклар бармакларга уралып чәбәләнде...

Кызның тәне һәр ишарәгә буйсына һәм бу акылдан шаштырырлык дәрәҗәдә ләззәтле иде... Ул ыңгырашып кычкырып җибәргәндә, Мидхәт үзен кайнар өермә күтәреп алып киткәндәй хис итте һәм бу очыш бернәрсә белән чагыштырып булмаганча татлы иде.

Бәгъзе мәгъшуклар менә шушындый мизгелләрне кичерү өчен гомерен бирергә әзер...

Әй сез, заман егетләре! Гомерлек яр булачак мәгъшукагызның сафлыгы, чисталыгы белән кайсыгыз түш киереп мактана ала? Андыйлар бик аз бит сезнең арагызда! Дөрес, күбегезнең башка төрле мактанырлык гамәлләре бардыр. Кайсыларыгыз зур ачышлары белән, кайсыларыгыз төзегән йортлары, салган күперләре белән горурлана. Яуда күрсәткән батырлыклары белән дан алганнар, биек кыяларга менгәне өчен, матур җырлар чыгарган өчен макталучылар бар. Болар бик яхшы, бик кирәк. Тик бер саф кызны гомерлек яр итеп, аның белән ләззәт дәрьясында йөзмәгән ир, нинди генә өлкәдә танылса да, тулысынча бәхетле була алмый. Ир-егетлек ул сөюнең тәмен татуда һәм аның өчен җаваплылыкны үз җилкәнә алуда да. Ир заты үзенең зурлыгын, гайрәтен, көчен менә шунда аңлый. Моны аңлау аны үстерә, биегәйтә, рухын ныгыта!

Күпмедер минутларданмы, сәгатьләрдәнме соң, йөрәк тибеше тынычланып, баштагы уйлар бераз тәртипкә салынгач, Мидхәт шушы минутларда язмышының бик кискен борылыш ясаганын аңлады. Моннан соң аның яшәеше бөтенләй башкача булачак иде. Ул хәзер ялгызы түгел. Алар икәү. Дөрес, моны әле аларның үзләреннән гайре һичкем белми. Ләкин анысы мөһим түгел. Антлар кызулык белән әйтеп ташланса да, Мидхәт аларны хәтерли, онытмаячак, сүзеннән кире кайтмаячак. Сафлыгын аңа бүләк иткән бу затны ул беркайчан да авыр хәлгә куймас, аңа газаплар китермәс, күз яшьләрен түктермәс...

Мидхәт борылды да, култык астына сыенып яткан Ленизаны хуҗаларча нык, ышанычлы хәрәкәт белән күкрәгенә кысты.

Шулчак аның йөзенә салкын җил бәргән кебек тоелды. Ул эчтән сискәнеп китте... Күзләрен ачып, тәрәзәгә текәлде. Нинди җил булсын, ай нурының тасмасы күзгә төшкән, фәкать шул гына. Тик каян соң күңел почмагына салкын тамчы булып кисәтүле уй төште: «Артык мавыгасың.... Ялгышасың... Хаталанасың...»

«Монда нинди хата булуы мөмкин?—дип эченнән каршы төште Мидхәт.— Очраклы кеше түгел, бер-беребезне күптән беләбез. Мин аны гел үземнеке генә итәрмен. Үзем дә гел аныкы гына булырмын. Житешмәгән якларын гафу итәрмен...» Ул сөйгәненең һәр әйткән сүзен шундук үтәргә әзер, барлык моң-зарларын назлары белән таратыр кебек иде.

* * *

Сентябрьнең җилле-яңгырлы көнендә трамвай таныш урам чатына килеп туктады да, ишеген ачты. Мидхәт үрелеп тышка карады. Зәңгәр палатканы күреп, үзе дә анышмастан, чыгу ягына китте.

Юеш асфальтка төшеп баскач, ихтыярсыздан күзләре белән туңдырма тартмасын эзләде. Үтереп «Пломбир» ашыйсы килгән икән. Вафлясы теш арасында шытырдап торганны... Тик урам чатында ак тартма да, аның янындагы ал тасмалы кыз да юк иде. Ә менә Әлифә үз урынында. Җилдә җилпенеп шытырдаган зәңгәр брезент куышы эчендә, тәбәнәк, тар прилавкасы артында басып тора. Калын гына куртка кигән, башына кара чәшке бүрек чәпәп куйган—колагы өстендә җепкә тагылган катыргы кисәге болгана—сатарга дигән әйбер, күрәсең...

Егетне күргүә, апакайның авызы ерылды. Елмаешып, кул бирешеп исәнләшкәч, хәлләрнен хәер икәнен белешкәч, Мидхәтнен бүреккә караштырганын күреп:

—Ошыймы әллә?—дип сорады Әлифә.—Бүләккә алам дисәң, үз хакына бирәм...

Исемен әйтмәде, әмма кемгә бүләк алу турында сүз барганы икесенә дә аңлашылды. Мидхәтнең Әнисә хакында сорашасы килә, ләкин нидер тыя иде. Кызның исемен әйткәндә тавышы калтырап китәр шикелле... Үзе, карашын аска төшереп, прилавкада яткан оекбашларны сыйпаштырды.

—Менә болары әйбәт, чыдамлы. Бер биш парны бүләк итим әле мин сиңа,—дип, Әлифә товарын төрә дә башлады.

—Кирәкми, кирәкми, оекбашларым күп минем....

—Оекбашның артыгы булмый аның. Көн саен алыштырып торырсың. Сезнең тулай торакта бүлмә саен кер юу машинасы юктыр.

—Прачечный бар безнең...—диде Мидхәт.

—Юучысы да бардыр әле,—дип кеткелдәп куйды Әлифә. Мидхәт кызарынып чыкты. Әмма апакай аңа карамый, бүләген салырга матуррак пакет эзли иде.

—Оекбаш күп булса, юучыга да ансат ул. Һәммәсен бергә җыеп җибәтә дә, болгаткалап элеп куя. Алмасаң, үпкәлим!

—Ничек инде мин сезнең хисапка...

—Нинди исәп-хисап ул безнең арада? Студентка ярдәм итү фарыз гамәл.

Мидхәт, баш тартса, апакайның күнеле кителәчәген күреп, бүләкне кире кага алмады.

—Сине бик күптәннән күрәсе килә иде,—диде Әнисә ничектер җитдиләнеп.—Тулай торагына барыйммы әллә дип тора идем әле. Әнисә һич тынгы бирми, көн саен күренмәдеме дип сине сорый. Бик борчыла...

Мидхәт сискәнеп китте.

—Бер-бер хәл булмагандыр бит?...

—Ул-бу булмады. Әйбәт кенә укып йөри. Ул яктан җан тыныч. Җәй эшләгән акчасына өс-башын рәтләде, энеләренә дә бераз җибәрде...

Әлифә кеткелдәп куйды.

—Менә шундый шул ул безнең Әнисәбез. Үз авызыннан өзеп, туганнарына бирә.

—Ә мине ни дип сорый?

—Сиңа әйтергә дә уңайсыз инде...

—Нәрсәне?!

—Бер караганда, бала-чага сүзе белән йөреп, кеше тормышына кысыласы да килми... Икенче яктан, Әнисәне бала гына дип тә булмый. Бездән күпне күрә, күпне белә.

—Минем өчен ник борчыла соң ул?

—Син миңа үпкәләмә. Аның гозерен генә үтәвем... Безгә алып килгән кыз белән сак булсын, башын шуңа бәйли күрмәсен, ди.

Мидхәт ике бит очының уттай кызышканын тойды, керфек кагарга да онытып, Әлифәгә текәлде.

—Кара эчле, ди. Мәңге үтмәс хәсрәт китерәчәк, тере бәхетсез итәчәк, ди!

Мидхәтнең эченә шом бәреп керде.

—Теге көнне мин сезне озатып кергәч үк нишләргә белми бәргәләнде,—дип дәвам итте Әлифә.—Сине исенә төшермәгән көне юк. Мин әйтәм, лагерьда бит алар, дим. Сонарабыз бугай инде, ди. Нишләп соң булсын, дим мин, Мидхәт өйләнгән дигән хәбәрнең ишетелгәне юк...

Ә егетнең күз алдыннан теге кичтә булган хәлләр, ай нуры, күләгәдә чалынган шәүлә чагылып узды, бөтен тәне тирләп чыкты.

—Сон шул инде...—диде үзе дә сизмәстән.

—Әллә... язылыштыгыз дамы? Туганнарыгызга, ата-анагызга әйтеп тә тормыйча?

—Язылышуын язылышмадык әле... Әтиләрдән рөхсәт аласы бар... Каникулда кайтып килербез, дип торабыз...

—Әле... вакыт бар икән,—диде тынычланып киткәндәй Әлифә.—Нишләп соң булсын... Кайсы парлар загска гариза биргәч тә кире уйлый... Билгеләнгән көнне язылышырга бармыйлар гына...

—Мин андый түгел,—диде Мидхәт кискен итеп.

Әлифә башын иде дә, прилавкасындагы әйбер-караны рәтләштергәндәй итенде.

—Үзең беләсеңдер инде...—диде.—Мәктәп баласының сүзенә карап йөрмәссең... Алай дисәң, ул әйткәннең расланмый калганы да юк... Беркөнне күршебез кергән иде. Әллә нәрсә ямансу булып китте әле, эчне бушатасы килә, ди. Узган гомерләрен сөйләп шактый утырды. Ул чыгып киткәч, Әнисә әйтә, бу апа озак яшәмәячәк, ди. Юкны сөйләмә, дидем мин, саусәламәт кешегә ни булсын... Өч көннән җирләдек без ул хатынны. Машина бәргән...

—Астрология белән мавыкмыйдыр бит сезнең ул кызыгыз?—дип сүзне шаяртуга борырга омтылыш ясады Мидхәт.—Хәер, алар фаразларын күпкә төгәл итеп әйтә бит. «Игезәк»ләр иртәгә начальникларына ярарга тырышсын, «арыслан»нар кесәсен сакласын, акча янчыкларын урлатулары ихтимал, «кәҗәмөгез»ләр бу атнада сөяркәләре янына бармый торсыннар, хатыннары килеп тотуы бар, дигән кебегрәк киңәшләр белән гәзитләр тулган. Андый фараз кылулар бик төшемле шөгыль, күрәсең. Әнисә дә, мондый сәләте булгач, морожный сатып йөрмәс инде бүтән! Күрәзәлек итеп кенә акча эшләр!

Әмма Әлифә шаяртуны кабул итмәде, кыска керфекләрен кагарга онытып, бик җитди карап торуында иде.

—Анын һәр әйткәне рас килә, дигән сүз түгел анысы,—диде аннары башын иеп.—Алай да күзенне ачыбрак йөрү зыян итмәс... Кешене ярып карый алмыйсын, эчендә ниләр ятканын белеп булмый, диләр.... Гомер озын бит ул, яши-яши, иң якын кешеңнең дә әллә нинди яклары ачыла, шаккатарсың. Бер кавышкач, аерылулар бик читен ул. Балаларыгыз туар... Әнисәнең үз атасы белән анасы ничекләр генә булып бетмәде. Мәхәббәтләре Ләйлә белән Мәҗнүннән бер дә ким түгел иде югыйсә... Хәзер, әнә, аларның тормышын дошманына да теләмәссен. Уйла әле син... Вәгъдәне бирү бар, аннары кире алу бар...

—Уйларбыз, ник уйламаска, баш үзебезнең муенда бит... әлегә...—дип елмайган булды Мидхәт.

* * *

Йөгереп барып трамвайга утырган Мидхәт артыннан Әлифә моңаеп карап калды. Егетнең йөзендә чагылган сискәнү, кыенсыну, ничектер үзен гаепле сизү сагайткан иде аны. «Соңаргансың бугай шул инде...» Бу уй Әлифәнең күңелен әрнетте дә әрнетте. Көндез, янынннан кеше өзелеп торган минутларда, әледән-әле егетнең аксыл керфекләр аша мөлдерәп караганын күз алдына китерде. Төнлә исә бик озак йоклый алмый уйланып ятты.

Мидхәткә ул Әнисә хакында, бала-чага гына әле, дип әйтте әйтүен дә, әмма бу баланың сүзләре хак икәнен бик яхшы сизә иде. Менә бүген Мидхәтнең йөзендә дә чагылды ул дөреслек. «Соң инде... Тик ялгышмадыммы икән?»—диде егетнең алдый белмәс ихлас күзләре...

Ах, җаный, ялгыша гына күрмә инде берүк! Мәхәббәттә хаталану адәм баласын юкка чыгара, язмышын җимерә. Андый хәлләр Әлифәнең үз күз алдында да булды...

Беренчесе—апасы Сәрия. Колхозда механизатор булып эшләгән әтиләре иртә үлеп, алар, мәктәп яшендәге ике кыз бала, хаста әниләре кулында калганнар иде. Сәрия урта мәктәпне тәмамлаганнан соң курсларда укып кайтты да, колхоз бухгалтериясенә эшкә урнашты. Ул елларда һәр җәй саен авылга читтән төзүчеләр килә, колхозга абзар-кура сала торганнар иде. Сәрия шуларның берсе белән очраша башлады. Куе коңгырт чәчле, кара кашлы, елтыр күзле шаян егет беренче карашка бик тә сөйкемле иде. Сәрия ана башын югалтып гашыйк булды. Танышуларына ай үттеме-юкмы, язылышып, кавышты болар. Кечкенә өйдә дүртәү яши башладылар. Тик кияү дигәнең узгынчы булып чыкты, чын ир була белмәде, җигелеп көн итәргә теләмәде. Бала да тугач, нужадан туепмы, әллә җилбәзәклеге җиңепме, каядыр чыгып китте дә гаип булды. Яшь әни, күкрәк баласы тотып, ялгыз калды. Кайчандыр аталары салган дүртпочмаклы өй тәмам череп, ишелер хәлгә җиткән иде. Авыл советы аларга урманнан делянка бүлеп бирде. Шунда өстенә агач авып, Сәрия үлеп китте...

Ул чакта Әлифә шәһәргә барып урнашкан, заводта эшли, тулай торакта яши, читтән торып техникумда укый иде. Апасының җеназасыннан соң сабыйның язмышы турында уртага салып сөйләштеләр. Әби кешенең үз-үзен дә авырлык белән караганын исәпкә алып, баланы приютка илтеп тапшыра алган булырлар иде. Әмма намус кушмады. Бала әбисе тәрбиясендә калды, шуның аркасында Әлифәнең җилкәсенә икеләтә җаваплылык төште: анасы өчен генә түгел, апасының баласы өчен дә.

Ә соң үз тормышы? Авылда бер чибәр булып саналмаса да, төшеп калганнардан түгел бит ул. Сүз кушучылар бар иде, күзне йомып суга сикергәндәй тәвәккәллек күрсәтсә, ялгыз калмас иде. Әмма, беренчедән, ашыгып кияүгә чыккан апасының ачы язмышы күз алдында булса, икенчедән, анасының сүзен аяк астына салып таптый алмады. Тәрбиясе ул түгел, канына ата-ана хакы дигән зур нәрсә салынган иде. Ә ананың сүзе бер булды: «Кияүгә чыгып, бала тапсаң, синдә безнең кайгы калмас. Нишләрбез, ничек көн итәрбез?!!»

Апасы кисеп өлгергән агачлардан бер җәйне ничек кирәк алай азапланып бура торгызып куйдылар, икенче елны Әлифә бар булган акчасын туплап, җиң сызганып, ялга авылга кайтты. Буаз сыерны, кышлаган бозауны сатып, атасын хәтерләгән кешеләрнең ярдәме белән кечкенә генә бер йорт салып керделәр. Бу мәшәкатьләр арасында күзгә ак-кара күренерлек булмады. Йортны өя-өя иеп беттем, дигәннәре хак шул...

Ул шулай гаиләне кайгыртып йөргәндә, чордаш егетләр үзләренә пар табып, җылы кочакларда эрегәннәр, Әлифә кебекләрнең базары узган иде инде.

Алай дисәң, чын мәхәббәт дөнья мәшәкатьләре белән, акыл белән санашып тора димени? Ахыр чиктә үзенең кыюсызлыгы ялгыз калдырды Әлифәне. Ятимлек вә фәкыйрьлек ул кесә такырлыгында гына түгел. Иң беренче чиратта күңелнең изелгәнлегендә ул. Ә бу—бөтен кыяфәтенә бәреп чыккан, һәр сүзендә, кыланмышларында чагылган кимсенү дигән сүз. Моның шулай икәнлегенә ышану өчен, тулай торакларның дүртәр-алтышар кеше яши торган бүлмәләрендә картаеп килгән кызларга бер күз салу да җитә. Никадәр игелекләр кылынмый калган, назлы хисләр һичкемне иркәләмичә сүнгән... Нәкъ менә шундыйлар турында шагыйрь: «Җирдә күпме җаннар йөри иясез шатлык булып!..»—дип язгандыр да.

... Ах, кайларда йөрисез сез, мәхәббәткә сусаган, җан җылысына мохтаҗ егетләр? Нигә сез Әлифә кебек кызлар яныннан күз дә салмыйча гына узып китәсез? Күңел күзегез кайда сезнең? Йөрәк сизгерлегегез кайда? Нигә сез минутлык хискә бирелеп, чәчкәдән чәчкәгә очып йөргән күбәләк кебек

жилбәзәк кызларның елмаюына, ялагайлануына ышанып, капкынга эләгәсез?..

Йөрәкне гыйшыкның ялкыны ялмаса, акылны аның төтене сара, күрәсең. Гашыйк кеше унга-сулга карамый, бер ноктага—мәгъшугына гына карап бара. Юлында дөрләп учак янса да, читкә тайпыла белми...

Әлифәнең апасының малае Әнәснең дә башын гыйшык дигән афәт ашады... Басынкы гына кебек иде югыйсә, үскән чакта күзгә чүп керткәне булмады.

Апасы янына ул сигез классны тәмамлагач күчеп килде. Нәкъ шул елны әбисе вафат булды, Әлифә исә Казанда бер бүлмәле фатир алган иде инде.

Ә анысы болай булды. Тулай торакта яшәп ятканда, бергә эшләүче Фатыйма исемле хатын үзләренең күршесендә яшәүче ялгыз, хаста карчык белән таныштырды.

—Исәнлеге чамалы, үзе генә яши алмый, фатирга кертергә ышанычлы кеше эзли,—диде.—Синнән ышанычлырагы табылмас. Килешеп китсәгез, пропискага кертер үзенне. Өебез бик иске, сүтәчәкләр дигән сүз йөри. Сүтсәләр, безнең белән бер очтан син дә фатирлы булып калырсың!

Фатыйма—шәһәр хатыны, дөньяның рәтен белә. Сүзе дөрескә чыкты: күп еллардан бирле чирләгән маржа түтәй Әлифәдән бик канәгать булып, ике ел бергә яшәгәч, пропискага кертте. Шуннан соң озакламый үлеп тә китте. Өйне чыннан да сүттеләр, анда яшәүчеләрне Казанның Азино дигән яңа районына күчерделәр.

Әлифә ялгыз калган энекәшен үз янына алып, заводның һөнәр училищесына укырга кертте. Күктән йолдыз чүпли торган булмаса да, малай ипле иде, ярыйсы гына укып, әйбәт кенә фрезеровщик булып чыкты. Аннары армиягә китте.

...Һәм кире әйләнеп кайтмады. Ул чакта комсомол төзелешләре күп иде, тотынып кешесе булмаган яшьләрне илнең әле бер, әле икенче тарафына озатып кына тордылар: кайда электростанция, кайда завод торгызырга, кайда шахта казырга. Берсеннән берсенә йөри торгач, Әнәс Молдавиягә барып эләкте.

...Кишиневтан туйга чакыру килеп төшкәч, Әлифә пошаманга калды: бигрәкләр дә ерак китеп, бигрәк тә чит-ятка башын бәйләргә ниятләгән иде егеткәй!

Әмма анда барып төшкәч, Әнәснең хәлен аңлады. Иңнәренә дулкын булып ишелеп төшкән кара чәчле, ут чәчеп торган кара күзле, бит очында миңе чекрәеп торган түгәрәк йөзле бу кызны яратмый мөмкин булмагандыр. Янындагы һәммә кешене бөтереп ала, биетә дә җырлата иде ул.

Бу туй Әлифәнең хәтеренә ярминкә кебек чуар, мул һәм шау-шулы тамаша булып кереп калды. Кояшлы көн, ишегалдындагы озын өстәлләр, кайсыберсен танып та булмаган җимешләр һәм тезелеп киткән шәраб шешәләре. Аксылы, яшькелте, саргылты, кызылы, кара-кучкылы... Өстәл башында гаҗәеп пар: кин чур итәкле, кара чәченә кызыл роза кадаган Кармен янәшәсендә озын буйлы, йомшак саргылт чәчле Әнәс. Аның елмаюдан кысылган яшькелт күзләреннән сирпелгән бәхет чаткылары...

Тирә-якта халык ду килә. Ят телдәге дәртле җырлар арасында әледән-әле танышын сузып җибәрәләр:

«Как-то утром на рассвете заглянул в соседний сад... »

Итәген җилпеп кәләш уртага атылып чыга:

«Любовь—дитя, дитя свободы, законов всех она сильней»... Китә бөтерелеп, күзләр камаша!

Проспер Мерименың «Кармен»ы иде бу! Андыйның сөюенә каршы торып буламыни?

...Әйе, Әнисә—чын мәгънәсендә мәхәббәттән яралган бала. Ә андыйларның үзәге нык була. Аннан ике яшькә кече Александр да шулай ук... Катнаш

гаиләләр өчен гадәттә четерекле булган исем кушу мәсьәләсен дә бу пар үзара килешеп хәл итте: беренчесенә әтисе теләгәнне, икенчесенә әнисе сайлаганны куштылар. Шулай итеп, Кишинев загсларының берсендә Гумеров Александр Анасович теркәп куелды. Аннан соң тагын да ике ел узгач туган малай исә—Раду Анасович Гумеров булды. Хәер, анысына исемне башка кеше биргән булып чыкты.... Анысының серен Әлифә өч ел узгач кына белде.

Ул чорда Әнәстән хатлар бик сирәк килә иде. Адресы ят кул белән язылган конвертны алгач, Әлифәнең йөрәге жу итте. Юкка булмаган икән. Хат Әнәснең күршеләреннән иде. «Адресыгызны Әнисәдән таптырып алдык та, сезгә хат җибәрергә булдык,—диелгән иде анда.—Йөрәгебез түзмәде. Энегезнең хәле мөшкел... Килсәгез, яхшы булыр иде. Безнең телефон...»

Икенче көнне таңнан Әлифә шәһәрара телефон станциясенә йөгерде. Үзендә телефон юк иде әле. Әнәс чирләгәндер, дип коты алынган иде, Аллага шөкер, сау-сәламәт икән. Аргы баштан ир кеше читләтеп-йомшартып нидер аңлатмакчы булып азаплана иде, трубканы хатыны тартып алды булса кирәк:

—Кармен өйдән чыгып китте, Әнәс эчүгә бирелде, балалар караусыз калды,—дип ярды да салды.

...Анда барып кереп, бер күз ташлауда Әлифә хәлләрнең чыннан да бик аяныч икәнлеген аңлады: өй җыештырылмаган, балаларның өсте-башы керле, ашарга рәтле ризык юк иде.

Карменның канатлы гыйшкы зәңгәр чәчәкле нәфис гөлдән очып китеп, әллә каян күзне ертып торган эре чәчкәлесенә барып кунган икән. Аның хәзерге мәгъшугы—Әнәснең капма-каршысы иде: башында куе кара бөдрә, кара мыеклы йөзендә ваемсыз елмаю, кулында гитара. Бармаклары кылларны чиртүдән, аяклары тыпырдаудан бүтәнне белми. Читтән караганда күзнең явын алып, балкып торган бу гөл якынрак килгәч шайтан таягы булып чыккан. Егеттә җыр-бию, күңел ачу кайгысы гына, тамак ягын кайгыртырга дәрте юк икән. Анысын ул үзен сөйгән хатыннар җилкәсенә йөкләргә көйләнгән. Күңел күбәләгең андыйга бер кунса, тиз генә ычкына алмассың. Кармен белән дә шулай булган. Раду исемле малайны да шуннан табып куйган икән ул. Ирне көйләү, балаларны тәрбияләү кирәклеге аның башыннан чыгып очкан, сөяркә кайгысы гына калган. Чөнки тегесен аз гына күздән ычкындырсаң да, эләктереп алырга гына торалар икән. Андыйларны буш тотмыйлар!

Ә Әнәс?..

Әнәс апасына макмырдан томанланган күзләре белән ялварып карады да:

—Аңламыйсың ла син! Минә монда яна, яна...—дип күкрәгенә кулы белән шап-шап суккалап куйды.—Эх, вәгазь сөйләмә син миңа! Лутчы бер илле тәңкә акча бир!

Аның кырынмаган чырае сулып җыерчыкланган, иреннәре күгәренгән иде. Вакытсыз картайган иде балакай...

Әлифә балаларга ботка пешереп өлгергәнче, ак канистр күтәреп кайтып та керде ул. Монда шундый зур савытлар белән йөзем шәрабы саталар икән. Агын, кызылын, төрлесен... Әнәс алсуын алып кайткан иде, тимер кружкага салып чөмерде. Һәм апасына Карменны яратуы, аннан башка яши алмавы турында кат-кат сөйләде.

Әлифә каршында мәхәббәт дигән афәт харап иткән икенче кеше утыра иде. Беренчесе—апасы Сәрия, икенчесе менә аның улы... Мондый очракта нишләп була?

Әнисә белән Александрны пионер лагерына, Радуны атналык бакчага урнаштырып, Әнәсне үзе белән алып китмәкче булган иде Әлифә. Айнытып, хәлләндереп җибәрмәкче иде. Әмма паспортын таба алмадылар. Соңыннан

ачыкланды: Кармен иренең паспортын сатып җибәргән икән. Рәсәй паспорты анда ярыйсы гына бәһале таварга әйләнгән, аның белән Мәскәүгәме, башка берәр урыс шәһәренәме килеп эшкә урнашырга була... Ә паспортсыз ничек юлга чыкмак кирәк?

Бу шәһәрдә шәрабларны татып карау, ягъни дегустация урыннары бар. Әлифә Карменны шуларның берсеннән—тугыз катлы йортның идән астына урнашкан кибеттән табып алды. Йөзем тәлгәшләре, ләкләк сурәтләре белән бизәлгән тәрәзәсез бүлмәне төрле төстәге лампочкалар җемелдәшеп яктырта, диварның бер ягындагы пыяла шкафның киштәләрендә төрле-төрле шешәләр тезелеп тора иде. Ымсындыргыч, серле куышның фәрештәсе булып, ян ишектән Кармен килеп чыкты. Туйдагыча ук чибәр, биле нечкә, сыны сыгылмалы. Өч бала табып, юанаймаган да ичмасам, чукынмыш! Тик күзләре генә тынгысыз яна, кызартылган иреннәре генә дерелдәп-дерелдәп куя.

—Әйе, мин Әнәстән киттем,—диде ул гади генә итеп.—Андый бозау белән яшәп буламыни?

Әлифә ана балалар турында, аларны карау кирәклеге хакында акыл сата башлаган иде, Кармен, тыңлап бетермичә, каядыр эчкә кереп китте дә, түгәрәк өстәлгә яртышар литр сыешлы ике бокал китереп куйды. Андый зур савытлар белән Казанда гадәттә сыра чөмерәләр. Кара бокалларның тышына ак ләкләк сурәте ясалган, эченә мөлдерәмә итеп карасу-кызгылт сыекча салынган.

—Әйдәгез, очрашу хөрмәтенә берне күтәреп куйыйк әле. Сездә мондый нәрсә юк бит. Яшь вино дип атала бу,—диде Кармен.

—Яшен яшьтер дә, зәһәре чамасыз икән шул. Әнәсне бөтенләй эштән чыгарган,—диде Әлифә бокалга орынмыйча. Кармен исә үзенекен тын да алмый каплап куйды. Бу якларда хәмер эчкәч нидер кабып кую гадәте юк, күрәсең, ул иреннәрен балдаклы бармакларының очы белән генә сыпырып алды. Сүз сүзгә ялганмады. Паспорт турында сорауга:

—Кирәк булса, паспорт өстәленә барсын да алсын,—диде Кармен исе китмичә.—Нәрсәсе бар аның. Ә мине көтмәсен.—Һәм кызыл кофта астыннан калкып торган күкрәген сыйпап куйды.—Менә монда аңа бер очкын да калмады. Сүнгән мәхәббәтне кире кабызып булмый. Күптән мәгълүм бит инде!

—Сөям-сөймим дип кенә булмый, балалар...—дип башлаган иде Әлифә, Кармен, син, кортка, йөрәк хәлләрен аңлыйсыңмыни соң, дигәндәй астыртын елмаеп, аның инбашыннан сыпыргалады.

—Сөймичә яшәп булмый!—диде.—Ә балаларның үз бәхете үзләрендә.

Кармен җинел генә әйтсә дә, паспорт артыннан йөрү гаять зур мәшәкать булып чыкты. Паспорт өстәлендәге хатыннар син килеп кергәндә урысча сөйләшеп утыралар, сәламенә исә молдаванча, ягъни дәүләт телендә җавап бирәләр. Гозереңне аңламамышка салышалар...

Әлифә Әнисәне алып китеп, ике ай үзендә яшәтте. Укулар башланыр алдыннан Мәскәүгә илтеп, шуннан Кишинев поездына утыртып җибәрде.

Аннан соң йөрәктәге сызлавык белән яшәргә генә калды. Әнәс хатларга җавапны сирәк яза, Әнисә исә балалыгы белән, ә бәлки тормыш авырлыгы беләндер дә, тутасын сирәк искә ала иде, күрәсең.

...Көннәрнең берендә аны шәһәрара телефон станциясенә чакырдылар. Әлифә, әлбәттә, иң элек Әнәс хакында уйлады. Ни булды икән?..

Әмма трубканы алуга колакны каты холыклы ят ир-атның тамак төбеннән ургылып чыккан тавышы ертты. Сәламне дә алып тормыйча, әмер биргәндәй:

—Заберите детей!—дип каркылдады ул.—Алып китегез балаларны!

Әлифә коелып төште. Теле бәйләнде, мие кайнады. Гәрчә нинди балалар хакында сүз барганын шундук аңлап алса да, авызыннан үзеннән-үзе:

—Каких детей?—дигән сорау ычкынды.—Нинди балаларны?

Калын тавышлы адәм Кишинев шәһәренең участок милиционеры икән.

Кармен шәраб кибетеннән куылып, яшелчә сатарга алынган булган икән дә, акчасы өстенә чыккан. Суд ясап өч елга утыртып куйганнар. Элек тә караусыз балалар бөтенләй ялгыз калган. Һич кенә дә айнымый торган Әнәсне барга чутлап булмый бит инде! Милиционер, күршеләрдән сорашып, Әлифәнең адресын белгән... Һәм менә таләп итә:

—Хәзер үк килегез дә, балаларны алып китегез!

Әлифә үзенең бер бүлмәле фатирында өч баланы күз алдына китерде дә тетрәнеп куйды. Бер пенсиясенә дүртәү ничек яшәрләр?

—Мин берне генә ала алам,—диде ул тотлыгып.—Өлкәнен... Әнисәне...

Милициянең мона ачуы чыгарга тиеш иде, Әлифә, аның телефон трубкасы аша кулын сузып сугып җибәрүеннән курыккандай, инбашларын, муенын җыерып куйды. Әмма, ни хикмәт, теге адәмнең тавышы йомшап китте: үзе дә шуннан артыгын өмет итми иде булса кирәк.

—Озакка сузмагыз,—диде җинел сулап.—Кайчан киләсез?

Аның йомшарганын тойгач, Әлифәнең башы нык кына эшли дә башлады. Молдавия чит илгә әверелгән, анда барып йөрү мәшәкатьле дә, ике кешегә билет алырга кесәдә акча да чамалы...

—Поездга утыртып җибәрсәгез, Мәскәүгә барып алыр идем,—диде ул.

—Юлга акчаны кем бирә?

— Мин җибәрермен... Күршеләргә.

— Мин контрольдә тотармын,—диде милиционер.

...Шулай итеп, кайсы ягы беләндер чегәнне, кайсы ягы беләндер татарны хәтерләтә торган, җитеп килгән кыз бала бөтенләйгә Әлифәнеке булды да куйды.

Тыштан караганда чат әнисе үзе, суйган да каплаган. Мине генә бит очында түгел, иягендә, чәченә генә ефәк тасманың кызылын түгел, алсуын бәйли... Әгәр холкы-табигате белән дә әнкәсенә охшаса?!

Бу уйдан Әлифәнең җаны убылып төшкәндәй була иде. Юк-юк, Әнисә андый булмас. Кечкенәдән энеләрен кайгыртып үсте, әле хәзер дә ярдәм итәргә тырыша. Бу яктан уйлап карагач, Әлифә аның анасы белән яшереп кенә хат алышуын да аңлый, гаепкә санамый. Димәк, үзен генә уйлый торган бала түгел, газиз кешеләрен авыр хәлдә ташламый. Туганнарына, ата-анасына игелекле кеше тормыш юлдашына да тугрылыклы булыр, иншалла. Гомумән, бик тә сизгер, шәфкатьле бит үзе. Мидхәт өчен дә әнә ничек өзгәләнә...

Һәм бу—Ленизаның кимчелекләрен күргәнгә генә түгел. Анысы да бардыр, әмма төп сәбәбе бүтән. Көнләшә кызыкай. Мөгаен, йөрәгенә тылсымлы чаткы төшкән һәм ялкын үрләтеп, көйдерә дә башлаган. Ни белән бетәр моның ахыры?

Әллә соң Әлифәгә тагын бер тапкыр мәхәббәт фаҗигасының шаһиты булырга туры килерме? Алла сакласын! Үз тиннәрен, гомер юлын бергә үтәрлек парларын таба гына күрсеннәр инде берүк. Әнисә Мидхәт кебекне, Мидхәт Әнисә төслене...

Аларны янәшә куеп карагач, Әлифә сискәнеп урыныннан торып утырды: «Тәүбә диген, Әстәгъфирулла! Акылына кил! Бала бит әле ул, кем белән мавыкмас та кемгә күзе төшмәс! Укып бетерәсе бар, һөнәр аласы... Мидхәт шул Ленизасына өйләнеп куйса, безнең өчен хәерлегә булыр, мөгаен. Күзгә-башка чалынып йөрмәс, ныклап аягына басарга өлгермәгән кыз баланың күңелен алгысытмас ичмаса!»

• • •

«Соң инде»,—диде диюен Мидхәт Әлифәгә, әмма үзе асылда ныклы бер карарга килеп җитмәгән, һаман уйлана, һаман икеләнә иде әле. Тик бу

хакта урам уртасына басып, бер-ике тапкыр гына күз күргән апа белән ачылып сөйләшеп буламыни? Иптәшләреннән берәрсенә эченне бушату да унайсыз, мәсьәлә ифрат четерекле иде бит.

Мөнәсәбәтләр бер тирәнгә китсә, кире элекке эзенә кайтмый. Мидхәт белән Лениза да бер-берсенә тыелгысыз тартыла, яшерен очрашу өчен уңайлы вакыт һәм урын эзли торган булдылар. Кайчан бүлмәдәшләрнең юк чагын туры китереп, кайчан тулай торактагы спорт залының ачкычын алып торып, ашыгып-кабаланып сөешүләр гадәткә керде. Һәм табигый нәтиҗәгә китерде. Икесе дә тәҗрибәсез иделәр шул. Инсаф ияләре булганга, бер-берсен ничек кенә якын итсәләр дә, оялу хисен югалтмадылар, бик күпләр өчен бияләй кебек гади тоелган нәрсәләрне кулланырга өйрәнмәделәр. Ә табигать синең чамаң-хәлең бармы, дип сорап тормый, үз тәртибен үти бирә.

Октябрь урталарында Ленизаның кәефсезләнгәне сизелә башлады. Беркөнне студентлар ашханәсендә:

—Кажется, винегретлары свежий түгел иде, күнелем болгана,—дип зарланды. Шуннан соң:

—Щи исе күңелемә тия,—дип, кичләрен аш пешерергә авырсына торган булды.

Мидхәт шыр томана түгел, хатыннарның болай кәефсезләнүенә нәрсә сәбәп булганын чамалый. Тик мона ышанасы килми иде. Аның гына түгел, Ленизаның да ышанасы килми иде булса кирәк, чөнки көннәр уза торды, алар арасында бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү булмады.

Өендәге хәлне күршеңнән сора, дигәннәр, янәшә бүлмәдә яшәүче егет күзне ачты.

Кичен Мидхәт, бик сонарып кына бәрәңге кыздырып ашады да, юыну бүлмәсеннән тәлинкә-табасын юып чыгып килә иде.

—Әй, парин, сиңа бер сүз бар иде,—дигән тавышка туктап калды.

Коридорның бу почмагында кичләрен парлар очраша. Серләшәләр, кеше юк чакны туры китереп, үбешеп-кочышып та алалар. Баш очларында лампочка янып торганны яратмыйлар, куйган берсен борып алалар. Шунлыктан, биредә ярым-караңгы иде. Тәрәзә төбенә терәлеп баскан егеткә урам лампасының саран яктылыгы арттан төшә, тавышы тәмәке төтененнән карлыгып чыкты, шунлыктан Мидхәт беренче мизгелдә аны танымады. Өч якты ноктага—сигарет очына һәм янып торган күзләргә—якынрак килгәч кенә күрше бүлмәдә яшәүче Фаязны шәйләде һәм, кулындагы савытларны тәрәзә төбенә куеп, күрешергә кулын сузды.

Алар якын дуслар түгел, Мидхәт бу егет белән икәүдән-икәү генә сөйләшкәнен хәтерләми иде. Аның пош-пош сигарет суыруыннан сүзнең бик үк матур булмаячагы сизелә, ләкин кырт борылып китеп тә булмый иде.

—Кабызасыңмы берне?—дип, Фаяз кесәсеннән сигарет кабы чыгарды.—Йөрәк януларың басылыр.

—Рәхмәт. Мин өйрәнмәдем инде... Ә син нишләп минем йөрәк яна, дип уйлыйсың?

—Андый хәлгә тарысаң, йөрәккә ут каба инде ул.

—Нинди хәлгә тарыган әле мин?

—Сине йөгәнләргә чамалыйлар, дигән сүз йөри,—диде Фаяз.

—Йөгәнләргә мин ат түгел лә...

—Ат булсаң, бәлки, тибеп очырыр идең дә, чабып котылыр идең. Ә менә кайсыбер егетләрнең андый көче дә, елгырлыгы да юк. Андыйларга йөгәнне тиз кигезәләр. Авызлыклыйлар да, сыртларына менеп атланалар. Ә аннары гомер буе шпор белән, шпор белән!.. Синең кебек эчми-тартмый торган тәти егетләрне күргәч, андый шпорлы затларның нәфесе котыра инде ул!

Фаяз хихылдап җавап көтте, Мидхәт дәшмәде.

—Карап-карап торам да, кызганып куям әле мин сине...—диде Фаяз аның битенә төтен өреп.

—Кызганырга мин бичара кыз түгел лә!

—Кызлар бичара түгел бу заманда! Егетләрнең кайсылары бичара! Ә син, күрәм, үзең хаталанып сабак ала торганнардан, башкалардан гыйбрәт ала белмисең. Күптән әйтелгән бит инде, эшләгән җиреңдә хатын-кыз белән бәйләнергә ярамый, дип. Укыган җиреңдә дә ярамый. Егет кеше күңеле төшкән кыз янына сагындырып кына барып кайтыр. Теләгәнен эшләр, күңеле кайтса, араны кырт өзәр дә китәр. Ә монда башыңны читкә борып кара! Бөтенесе аны яклап якаңа килеп ябышачак!

—Кемнең ни эше бар миндә?

—Ахмак булма. Йөгәнгә баш тыгарга ашыкма! Хәзерге кызлар оста алар һәм хәйләкәр. Башта килеп үзләре муеныңа асылыналар, аннары балага уздым, дип шантажларга тотыналар. Борылырга да җай калдырмыйлар. Андыйлар белән бәйләнүдән Алла сакласын. Бер баш биргәнсең икән, ычкындырмый ул сине!

Мидхәт аның чыраена ачу катыш гаҗәпләнү белән текәлде. Ләкин тупас сүз әйтүдән тыелды. Фаяз өч-дүрт яшькә өлкәнрәк, институтка ул, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң заводта бер ел эшләп, әзерлек курсларын тәмамлап кергән. Таза гәүдәле булуы да, ярты башка калкыбрак торуы да аңа күпмедер дәрәҗәдә өстенлек бирә иде. Мидхәт тешен кысты, сабырлыгын җыеп, дәшмәде. Фаязның тавышы исә йомшара бара, ул чыннан да ихлас күңелдән, яхшылык теләп сөйли иде.

—Күпме асыл егетләрдән юньсез хатыннар күндәм алаша ясадылар инде,—дип, чын күңелдән сыкрангандай дәвам итте ул.—Аң бул! Өйләнүче син, шуны онытма! Син хәл итәргә тиеш аны! Нindидер бер чәчби түгел! Ниләр генә кыланмый аларның кайсылары. Балага уздым, дигән була, беренчесен төшерсәм, бүтән булмаячак, дип куркыта. Кызгандыра! Шантажлый! Ә син курыкма. Сәламәт хатыннар унар бала таба. Ә хаста хатын сиңа кирәкми!

—Лениза турында алай сөйләгәнне...—дип башлаган иде Мидхәт, Фаяз сигаретын идәнгә төкереп, башмагы белән ышкыды да:

—Ташла...—диде.—Мин аның турында бер начар сүз дә әйтмәдем бит әле. Кияүгә чыгасы килә торгандыр, гына дидем. Аның ни начарлыгы бар? Ә менә шул кияүгә чыгу чарасы итеп шантажны сайлый икән...

—Нинди шантаж? Аның берниндi шантаж ясаганы юк!

—Ә корсак?

—Нинди корсак?

Фаяз хихылдап куйды.

—Анысын син миннән сорама инде, энекәш. Нинди икәнен миннән яхшырак беләсеңдер. Кыскасы, эшең комга тәрәлгән, дияргә була. Монда сиңа басым көчле булачак. Кызлар ягыннан да, деканат тарафыннан да.

—Нинди басым? Юк сүз ул. Кем сөйли андый кара гайбәтне?

—Бирсен ходай, юк сүз булсын! Мин сине на всякий случай кисәтәм. Ачык авыз булма! Әгәр андый хәл сизелсә, шау-шу купканчы, алдан чарасын күр. Ул сине шантаж белән алдырмакчы булса, син аны хәйлә белән алдыр. Көйлә, җайла, юмала, укып бетерүгә өйләнешербез, дип ант эч, теләсә ни кылан, тик ничек тә булса бүлнискә илтеп тык. Ул анда бер кич куныр өйләнеп чыгуга, дөньяларың яктырып киткәндәй булыр, менә күрерсең. Иптәш Сталин ни дигән? Хәер, сез бит яшьләр, белмисездер. «Нэт чэловэка—нэт проблэмы» дигән ул. Ә ул, зөбани, акыллы булган! Безнең шартларга яраклаштырып тәрҗемә итсәң, «кызның корсагы булмаса, егетнең гаме булмый» дигән сүз. Хәер, егетнең генә түгел, үзенең дә хәсрәте бетәр!

Тынычлап, иркенләп дипломын яклар. Ә болай бит биш ел укыганы җилгә очуы да ихтимал!

Күнелне наждак белән генә түгел, рубанок белән кыра торган сүзләр сөйли иде Фаяз! Тынлап тормаска иде аны, борылып китәргә кирәк иде.

Әмма Мидхәт мәгънәсез елмаеп, басып торуында булды. Аның аяк табаннарын бетон идәнгә беркеткән сумала—дөреслек иде. Әйе, хак иде шул Фаязның сүзләре!

...Ул төнне тәрәзәләр яктыра башлаганчы Мидхәтнең күзенә йокы кермәде.

Ленизa буйга узган, дигән гайбәт кай арада шулай таралып өлгергән? Ә бәлки, бу әле үтә торган хастадыр?.. Бөтен язмышны хәл итә торган чорда—диплом якларга әзерләнгәндә, нинди бала ди ул тагын? Ул да шыр дивана түгел, алдын-артын уйларга, саклануның берәр чарасын күрергә тиеш иде. Ә бәлки, кулланганд‍ыр да... Тик әйтмәгәндер генә...

Әмма Мидхәтнең күнеленә шик кергән иде инде. Соңгы вакытта очрашу-сөешүләрнең кызуы да сүрелә төшкән, беренче кавышкан айлы төндә башны томалаган алтынсу томан таралып, зиһен ачылган иде. Һәм ул Ленизага тартылу көченең кими барганын тоя иде. Лекцияләрдә утырганда да башы элеккеге кебек ихтыярсыздан гел аның тарафына гына борылып тормый. Битенә текәлеп караганда, кызның юка ирен читләренең түбәнәеп, авызының кысылып куюы ямьсез булып тоела башлады. Һәм кичләрен йокыга китә алмый уйланып ятканда, тормышымны аның белән гомерлеккә бәйләү дөрес булырмы, аның бу кысылган ирен читләренә, соры күзләренең сынап каравына чыдап яши алырмынмы, дигән уйлар башка килә иде.

Кыскасы, йөрәк кызуы сүрелә төшкәч, салкын акыл өскә чыкты. «Ашыкма»,—ди Мидхәт хәзер үз-үзенә. Чыннан да, кая ашыгырга? Диплом якласыннар, эшкә урнашсыннар. Анда инде хәлләр үзгәрәчәк. Иртән торып юыну бүлмәсенә барганда ук бер-беренә юлыгасы да, лекцияләрдә бергә утырасы да булмас. Бер-беренә ерактанрак карарга мөмкинлек туар. Ерактан карасаң, яхшырак күренә, диләр. Кем белә, бәлки әле Ленизa үзе үк Мидхәткә суынып китәр...

Коридорның караңгы почмагында Фаязның авызыннан тәмәке сасысына уралып бөркелгән кинәшләре саруны кайнаткан иде. Ә менә кара төндә ялгыз калып уйланып ятканда, нәкъ менә шулар җанны тынычландырып җибәргәндәй итте.

* * *

Гайбәт группаның кураторы, философия укытучысы Алия Фәргатовнаның да колагына барып ирешкән иде инде.

Гыйшык-мыйшык мәсьәләләрендә бу заманның «шәригать»е никадәр генә кинәйгән булса да, мәктәп балалары арасында да гыйффәтле кызлар аз калган икән, дип сөйләсәләр дә, барыбер бозыклык белән мактанып булмый. «Йоклашып йөриләр икән», дигән чыш-пыш сүзләр кешенең маңгаена күзгә күренми торган дегет белән кара тамга салып куйгандай итә.

Ленизa белән Мидхәтнең мөнәсәбәтләре тирәнгә киткәне кураторга, каникул тәмамланып, укулар башлангач ук килеп ирешкән иде. Алия Фәргатовна күпне күргән кеше, таләпләрне каты куйса да, кеше хәлен аңлый, яшьлекнең абыну-сөртенүләрен гаепләргә ашыкмый иде. Группаның старостасы Аня белән профсоюз җитәкчесе Гөлнар аның янына кереп:

—Аларга берәр чара күрергә кирәк,—дигәч, Алия Фәргатовна:

—Мәҗит Гафуриның «Кара йөзләр»е заманы күптән узды бит инде,—дип, авызларын бик тиз каплады.—Үз хәлләрен үзләре беләләрдер. Безгә аларның укуы гына кирәк. Дипломнарын яклый алсалар, шул җиткән. Сезгә зыяннары тими торгандыр бит?

—Ничек итеп диплом яклый алсын ул? Бүлмәгә бала алып кайтса, безгә дә рәхәт булмас...

—Бала дисезме? Эшләр шул дәрәҗәгә җиттемени инде?

—Дипломын барыбер яклый алмаячак ул быел. Берәр чарасын күрмәсә... Административ отпуск алсын әнә!

—Сезнең үзегезнең диплом хәлләре ничек соң әле?

—Эшләр өчен шартлар начар бит, Алия Фәргатовна. Янында косып йөрсәләр, дикъкать тарала шул ул...

—Сез сабыр булырга тырышыгыз инде, ана каты бәрелмәгез,—диде укытучы.—Мондый чакта ыгы-зыгы килүдән бер файда да юк.

Кызлар куратордан башкачарак сүз көткән иде. Ләкин укытучың белән әрепләшеп булмый—шым гына чыгып китүдән башка чара калмады.

Анын урынында башка берәү булса, теге ике кыз белән сөйләшкәннән соң иң элек Ленизаны чакырып алыр иде. Әмма кызның сагаюлы чыраен күз алдына китергәч, Алия Фәргатовна уйга калды. Чөнки бу кыз белән аның женнәре туры килми иде.

Мидхәт исә бөтенләй башка. Анын елмаюлы йөзен, якты зәңгәр күзләрен исенә төшереп, Алия Фәргатовна тирән көрсенеп куйды... Мидхәткә ул һич кенә дә Лениза кебек пар теләмәс иде. Кайда бу егетләрнең күзе? Фәндә молекулаларның серләрен ача белгән яшьләрнең күбесе адәм баласының чыраенда ярылып яткан сыйфатларны нилектән күрми? Нинди пәрдә күзләрен каплый аларның, нинди тылсым сукырайта??!

Нишләмәк кирәк, дөнья шулай корылган шул инде. Язмыш дигәнен, булачак парларны укмаштырганда, «бер яхшыга бер яман, бер яманга бер яхшы» дип бүлә икән, дигән мәзәк бар бит. Шулай саный торгач, сирәк кенә саташып китеп, «бер яхшыга бер яхшы» дип җибәргәли икән. Шул рәвешле язмышның ялгышуы аркасында гына бәхетле парлар барлыкка килә, диләр.

Алия Фәргатовна үзе, мөгаен, шундыйлардан булгандыр. Ире белән алар егерме ел ел тату яшәделәр. Кызганыч, Вахитның гомере иртәрәк өзелде. Берданбер кызлары исә, институтта укыганда ук кияүгә чыгып, ире белән бергә Харьковка китеп барды. Бер ялгызы калган тол хатынның сүнмәгән-сүрелмәгән күнелендә башкага бирелеп бетмәгән наз калды. Шул назның нуры җай туры килгән саен күз карашы аша саркып Мидхәткә сибелә иде. Ничек дип атарга мондый кичерешләрне? Нечкәлекләрен уйлап тормыйча, «ярата» диләр инде. Ләкин бу сүз, уйлап карасаң, хис-тойгыларның, кичереш-омтылышларның мең төрле төсмерен үз эченә сыйдыра бит... Ананы, йә баланы ярату бер, дусларны—икенче, сөйгән ярны—өченче... Яшьтәш булсалар, Алия Фәргатовнаның кыланыш-гамәлләре, уй-хыяллары бер төрле булыр иде, ә хәзер бөтенләй башка...

Ничек кенә булмасын, Мидхәт ана һәрьяктан камил зат булып күренә, анын җирдә яшәве генә дә тормышны ямьле кебек. Андыйлар башка берәүгә авырлык, бәхетсезлек китерә алмый. Һәм тиеш тә түгел...

Икенче көнне үк, семинардан соң, Алия Фәргатовна Мидхәтне үз бүлмәсенә чакырды.

—Утыр әле, Халиков,—диде. Һәм өстәле аркылы каршысындагы урындыкка ымлады.—Ну, ничек анда, диплом эше языламы?

—Узган елгы курс эшенең темасын үстерергә дип килештек без Андрей Николаевич белән,—диде Мидхәт. Андрей Николаевич анын фәнни җитәкчесе иде.

Алия Фәргатовна, дулкынлануын яшерергә тырышып, сүзне турыдан башлады:

—Синең шәхси борчуларың да бар икән... Мин шулай дип ишеттем.

—Юк... Берни юк...

Мидхәт агач төсендәге элпә белән капланган арзанлы өстәлдән нидер укырга теләгәндәй, карашын аска төбәде.

—Лениза Фәхруллина белән мөнәсәбәтләрне ничегрәк җайларга ниятлисез соң?

Мидхәт бу кадәр үк маңгайга бәреп сораганны көтмәгән иде, кызарынып чыкканын тойды.

—Шәхси тормышны хәл итү турында диплом яклагач уйларбыз инде,— дип мыгырданды ул.

—Шулай дисеңме?

Алия Фәргатовна дулкынлануын яшерер өчен, өстәлдә яткан журналны ары-бире шудыргалады.

—Һәрчакта да эш-мәшәкатьнең берсен алып, икенчесен куеп торып булмый шул,—диде үзалдына уйлангандай.—Ничек булса да, хәл кылырга туры килә. Сез дә шундый кыен хәлдә калгансыз менә.

Аннары бераз тынып торды да, җавап булмагач, башын күтәреп егетнең йөзенә туры карады һәм гадәтенчә нык итеп:

—Сезгә бу хәлдән чыгу җиңел булмас,—диде.—Күп егетләр мондый чакта югалып, хәтта куркып кала. Җилкәләренә күтәрә алмаслык авыр йөк төшәр сыман тоела. Ничек тә булса котыласылары килә. Бәлки, сиңа да, шома гына ычкыну җаен тап, дип киңәш бирүчеләр булыр.

Мидхәт сискәнеп китте. Каян белгән? Ничек?

—Ә бит мәсьәләнең икенче ягы да бар әле,—дип дәвам итте Алия Фәргатовна.—Әйтик, туачак җан... Бу дөньяга килергә талпынган кешене әйтәм... Кайчандыр без дә аның кебек булганбыз... Кемнәрдер безнең язмышны хәл итү хакында уйланган... Яшәргә мөмкинлек бирергәме, юкмы... Уйлап карасаң, бик гаҗәп бу. Әгәр шунда, бу бала безгә әлегә кирәкми, аны карарга-тәрбияләргә шартларыбыз юк, дисәләр... Ул чакта безнең каршыда җиһанның ишеге ачылмас иде. Һәм моның өчен беркемне дә гаепләмәсләр иде... Әгәр туып өлгерсәң, сине болай гына юк итеп булмый. Суд каршына бастыралар, төрмәгә утырталар. Ә алданрак хәстәрен күрсәләр, моның өчен бернинди җаваплылык юк. Ә аерма нәрсәдә соң? Икесе дә җан кыю бит инде... Монда кешенең үз намусы хөкемдар булырга тиеш.

Сүзнең бөтенләй көтелмәгән мондый борылышыннан, аннан да бигрәк, Алия Фәргатовнаның бик хисләнеп, күңел төбен актарып сөйләвеннән Мидхәтнең зиһене чуалып, йөрәге тигезле-тигезсез тибә башлады. Ул укытучысының утлы карашына түзә алмыйча, башын түбән иде!

—Монда бит берничә айга гына түзәргә кирәк,—дип дәвам итте Алия Фәргатовна тавышын йомшартып.—Егет кеше үз кылганнары өчен үзе җавап бирергә тиеш. Намус белән. Үз баласын пычак астына салып түгел!

Бу сүзләр башка яшен булып китереп суккандай итте. Мидхәтнең иңнәре салынды. Студентлар: «Алия Фәргатовнаның теле пычактай телә»,—диләр, хак шул.

Артык каты бәрелгәнен ул үзе дә сизде, ахрысы, көрсенеп, тавышын йомшартты.

—Бер-ике айга чыдау турында гына сүз бара бит,—диде кабатлап.—Ничек тә түзәргә кирәк. Бер җае табылмый калмас. Без дә ярдәм итәргә тырышырбыз.

Соңгысын һич көтмәгән Мидхәт, кыеш елмаеп, аңа күз сирпеп алды:

—Ничек итеп?

Алия Фәргатовна җиңел сулап, елмаеп җибәрде:

—Күз күрер анда. Загска кайчан барасыгызны миңа алданрак әйтегез. Матур киенеп килергә кирәк булыр. Шаһит булып үзем кул куярга риза! Курыкмагыз, ятим итмәбез.

* * *

Тулай торак янындагы кечкенә бакчада аларның күнегелгән эскәмиясе бар иде. Кичен шунда чыгып утыргач, Мидхәт кызның салкын бармакларын кайнар учына алды да:

—Лениза, син хатын-кызлар консультациясенә бармадыңмы әле?—дип сорады.

Ярым-караңгыда башын иеп, бөтен чигәләреннән салынып төшкән чәчләре астына яшергән кызга бу сорауның ничек тәэсир иткәнен сизеп булмады.

—Юк... барган булсам, конечно инде сиңа әйтер идем,—диде ул ярым-пышылдап.

—Күңелем болгана дисең, ашавыңның рәте юк. Соңгы вакытта агарынып киттең. Андый чакта... врачка күренергә кирәктер бит...

—Куркам...—диде Лениза.

—Ә нәрсәдән куркасың? Әгәр теләсәң, үзем озатып куям. Иртәгә, лекцияләрдән соң...

—Кабул итәрләрме соң? Анда бит башта талон алырга кирәктер...

—Иртәгә барыйк, син тәртибен белешеп чыгарсың, мин көтеп торырмын. Килештекме?

Лениза ризалыгын белдереп ияген каккалады да, башын Мидхәтнең күкрәгенә салды.

...Хатын-кызлар консультациясенә, трамвайдан төшкәч, бакча аша кыйгачлап салынган сукмак буйлап барасы иде. Мидхәтнең беләгенә ныгытып ябышкан Ленизаның нык дулкынланганы сизелде.

—«Хатын-кыз консультациясе» дигән вывесканы күргәч, йорт эшләренә өйрәтә торган урындыр, дип уйлый идем мин,—дип көлде ул.—Кызлар әле күптән түгел генә аңлатты.

Яше егермедән узган, югары уку йортында укучы кызның мондый наданлыгы сәер булса да, Мидхәткә бу гаеп булып тоелмады: гыйффәтле кызның андый җиргә ни йомышы төшсен?

Мидхәт джинси чалбар, саргылт куртка кигән Ленизаның, урам аша чыгып, иске кызыл кирпеч бинага таба барганын, кыршылган ишектән кереп киткәнен бакчадан карап калды. Ямансу иде аңа. Төсен җуйган күк гөмбәзен октябрь аеның алама болытлары чуарлаган. Каеннарның шәрә ботакларында сирәк-мирәк сары яфраклар җилпенә, куе-яшел яшь чыршылар да сагышка уралган шикелле. Аяк астына коеш яфрак түшәлгән, сулган үләннең әчкелтем исе, дымлы җир исе килә. Якыннан гына трамвай гүләп узды, тимер тәгәрмәчләр, борылышта рельсларга нык ышкылып, сызлангандай чыелдады. Бу шау-шуга агач башларында әвәрә килгән чәүкәләрнең эчпошыргыч «чаң-чаң»ы килеп кушылды.

Мидхәт яфракларны шытырдатып әрле-бире йөренде, уйларының очына чыга алмады. Ах, әгәр дә фаразлар дөрескә чыкмаса икән! Нинди яхшы булыр иде лә!

...Әмма бу зәгыйфь өмет акланмады. Иске бинадан чыкканда, Ленизаның кызарынган йөзен чалыш елмаю бозган, дымлы күзләрендә курку һәм ялвару ярылып ята иде.

—Кабул иттеләр, карадылар,—диде ул.—Алты атналык диделәр.

Ул бик кызганыч һәм көчсез булып күренде. Мидхәт аның салынып төшкән кулыннан тотып, сукмак янындагы артлы эскәмиягә утыртты.

—Нишлим инде?—дип, башын күтәреп аңа карады Лениза.

—Үзең ничек уйлыйсың соң?

—Белмим инде. Башым буталган. Мин куркам, Мидхәт...

—Нәрсәдән? Бер синең башка гына килгән хәл түгел...

—Башкаларда минем ни эшем бар? Укуны дәвам итә алмасам нишләрмен?!

Стыдно да бит... Кызлар сизеп алды инде. Ләйсән әйтә, котылу ягын кара, ди. Син беренчесе түгел, ди. Бер-ике көнгә күздән югалып торалар да балкып кире кайтып керәләр, кайда булганнарын, ни кылганнарын беркем белми кала, ди. Ахмак булма, мингерәп йөрмә, вакытын ычкындырма, ди... Наверно, башка чара юктыр... Анда миннән кайбер анализларны алдылар инде. Ике атнага чыдасам...

Ул укшыгандай итеп кесәсеннән кульяулыгын чыгарды.

—Ике атнадан ни була?

—Шуннан соң яткызырбыз, диде врач.

—Нәрсәгә?

—Кереп чыкмый булмас бит инде...

Менә шулай әвәрә итте дә куйды ул Мидхәтне! Фаяз әйткәннәрнең киресен сөйләде, шунын белән бөтен шик-шөбһәләрен таратты да ташлады. Баксаң, форсаттан файдаланып кияүгә чыгып калу турында түгел, бу хәлдән ничек тә булса котылу хакында уйлый икән бит ул!

Әмма Мидхәт, сөенәсе урынга, үзгенә карлы янгыр койгандай хәлдә иде. Йөрәге астында яңа җан йөрткән хатын-кызның кичереш-уйларын ул башкачарак күз алдына китерә иде. Алия Фәргатовна сөйләгән төслерәк итеп. Ә монда...

Әйе, кеше күнеле—кара төн, дигәннәр... Хатын-кызларның эчке дөньясы, Мидхәт күз алдына китергәнчә, гел бертөсле генә түгелдер. Берәүләрдә ул кояшлы көндә балкып торган гөлбакчага тиң булса, икенчеләрендә—айсыз төндәге кара урман кебектер, күрәсең. Аның ешлыкларында елтыраган утлар да җылы учак түгел, ә яктырткыч койрыклы бөҗәкләр генәдер, бәлки...

Мидхәт тизрәк бу уйларыннан арынырга тырышты.

—Теләсә кем белән кинәшкәнче, башта миңа әйтергә ярамадымыни?— диде.

—Мин үзем дә ышанып җитмәгән идем бит әле... Алар инде күреп тә алган... Ләйсән әйтә, егетләргә ышаныч юк, мондый чакта күбесе йөргән кызын ташлап китә, ди. Иргә ышанма, Иделгә таянма, дигәннәр, ди.

Мидхәт аның беләгеннән янтыгына кысты.

—Мин егетләрнең күпчелеге рәтенә керәммени, синеңчә? Синең өчен бердәнбер түгелмени?

—Бердәнбер, конечно, бердәнбер,—диде Лениза ашыгып.—Ә син мине ташламассыңмы?

—Ташларга... Иске күлмәк түгел лә син...

—Алайса...—Лениза тураеп утырды.—Нишлибез соң?

Мидхәт анын яктырып киткән йөзенә, нурланган күзләренә карады. Таңнар атып, кояш чыкса, карурманнар да ямьләнә...

Нишләргә? Билгеләнгән көнне тагын шушында Ленизаны озатып куйсаң, барсы да элеккечә дәвам итәчәк, бернинди мәшәкать өстәлмәячәк...

Ләкин бу—үз-үзен берничек тә яклый алмаган гөнаһсыз җан иясен үтерү була түгелме? Алия Фәргатовнаның күзенә ничек карарсың да үз вөҗданың каршында ничек җавап бирерсең?

—Как-нибудь дипломны якларга иде ...—диде уйлангандай Лениза.

—Анысы өчен кайгырма. Үзем язып бирермен. Ә безгә хәзер башканы хәл итәргә кирәк. Әйдә, киттек.

Мидхәт нәрсәгәдер тәвәккәлләгәндәй кискен хәрәкәт белән аягына басты да, Ленизаның кулыннан тартып торгызды.

—Кая киттек?

—Иң элек безгә язылышырга кирәк,—диде.

—Чынлапмы?

—Андый эшне шаярып эшләмиләр инде. Аннары без хәзер икәү генә

түгел бит. Өченчебез бар. Үскәч ул, минем әти белән әни бергә укыганда танышканнар, фәлән айда туйлары булган, фәлән айда мин туганмын, дип сөйләячәк.

—Язылышу таныклыгыннан числосын да карар микәнни?

—Безнең әни ел саен туй көнен искә төшерми калмый, тәмле әйбер пешерә. Сездә...—Мидхәт киселеп калды.

—Бездә аның ишене искә алучы юк...—диде Лениза карашын түбән төшереп..

—Кайбер халыкларда кешенең туган көнен кеше дөньяга килгәннән түгел, тугыз ай электән санап бәйрәм итәләр. Чөнки яңа җанның гомере икәүнең кавышуыннан башлана, дип саныйлар. Ике чакматаш бәрелешсә ут чыга бит? Менә шулай күз алдына китерәм мин аны. Аерым-аерым булганда, ул ут ташларның эченә яшеренеп яши. Бер-берсенә орынгач, чәчрәп тышка чыга. Үзенә бер төрле шартлау була, ялкын теле үрли, учак кабына...

—Точно!—дип ана елышты Лениза.—Мин сине чыннан да ут чыгардай яратам. Синең кебек матур итеп әйтеп бирә генә белмим. Дворец бракосочетаниягә барабызмы?

—Анысына ук үрелеп булмас шул... Беренчедән, анда чираттыр, озак көтәргә кушарлар. Икенчедән, андый җирдә зур тантана ясыйлар. Ата-ана, туган-тумача, дус-ишләр белән... Туй күлмәкләре кыйбатлы, машиналар бизәкле ул тирәдә...

—Аның өчен акча күп кирәк шул,—диде Лениза монаеп.—Әгәр бу юлы ашыкмасак, диплом яклаганнан соң, акча туплап... Без дә...

Күренеп тора: кызыкай туен гөрләтеп үткәрү турында хыялланган икән. Хәзер исә бу хыяллар җимерелә... Нәрсә хакына? Тумаган, күзгә күренмәгән җан хакына! Лениза икеләнеп калган иде.

—Бәби туен гөрләтеп уздырырбыз,—диде Мидхәт.—Ә хәзергә район загсы да ярап торыр. Балдакны мин сиңа эшли башлагач бүләк итәрмен. Паспортың янындамы?

...Загста алардан гариза яздырдылар да бер айдан килергә куштылар. Язылышу тантанасы ноябрьнең җепшек кар явып торган салкын, җилле көненә туры килде. Тантана үзенә күрә күңелле генә узды. Студентлар арасында, озын итәкле кызыл бәрхет күлмәк кигән Алия Фәргатовна аерылып торды. Ул бер кулына купшы кәгазьгә төрелгән кызыл розалар бәйләме, икенче кулына зур гына катыргы тартма күтәреп килеп керде. Тантана башланганчы эчке бүлмәгә узып, загс хезмәткәре белән нидер сөйләшеп, тартмасын калдырып чыкты. Баксаң, туганнарча кайгыртып йөрүе булган икән. Яшьләр дулкынланып тантана залына барып кергәндә, киң өстәлдә калын тышлы кенәгә белән алтынланган ручкалар гына түгел иде. Анда берсенә бал, икенчесенә май салынган ике бәллүр касә һәм зур подноста яшел-кызыл-сары монпасьелар белән бизәлгән чәкчәк тора иде. Кибетнеке кебек вак түгел, эре-эре итеп өйдә пешерелгән. Андыйларны авылларда гына ясыйлар. Кияү белән кәләш ягыннан туганнар килмәгән, бу, билгеле инде, Алия Фәргатовнаның эше иде. Түшенә кыеклап кызыл тасма таккан, өлкән яшьтәге, туры сынлы апа, һәр парга әйтелә торган сүзләр әйтсә дә, тавышы рәсми түгел, җылы, йөзе якты иде. Кенәгәгә алтын каләм белән имзалар салынып, Мендельсон маршы яңгыраганда, Алия Фәргатовна кияү белән кәләшкә бал-май каптырды. Аның куллары тетрәнә иде.

Котлаучылар елмаешып моңдый очракта галәттә әйтелә торган: «Пар килгәнсез, бәхетле булыгыз, батыр уллар, матур кызлар үстерегез»...—дигән теләкләрне кабатладылар. Ә менә Алия Фәргатовна сүз алгач, колаклар тырпайды, чөнки ул бик җитди иде һәм әйткәннәре дә көтелмәгәнчәрәк булды.

—Мин сезгә, авырлыклар күрмичә, бер-берегездән гайрәтегез чикмичә

озын гомер кичерегез, дип теләк тели алыр идем. Жырда жырланганча, күзләрне күзләрдән алмыйча яшәгез, дияр идем. Ләкин бу дөнья җәннәт түгел, кеше фәрештә түгел. Төрле чакларыгыз булыр. Бер-берегезнең хата-ялгышларын, кимчелекләрен гафу итә белегез! Ул ачы суган каптырса, менә шушындый балны капкандай, «татлы-татлы» дип елмаеп йотыгыз. Рәнжегән минутларда да, гомер юлдашыгызның яхшы якларын исегезгә төшерергә тырышыгыз. Шуларга тотынып яшәргә өйрәнегез.

Алия Фәргатовнаның керфекләрен яшь сарган, һәм бу үзенә бер ямансулыктан да иде. Яшь парның барыр юллары бик тә, бик тә сикәлтәле-чокырлы булып тоела иде ана.

* * *

Апрель ахырында яшь гаилә тулай торакка бәби күтәреп кайтып керде. Кая барсыннар тагын?.. Тик менә биш кыз яшәгән бүлмәдә балалы хатынны күз алдына китерәсезме сез? Ул бишәүгә тынычлык кирәк—семинарларга әзерләнәсе, курс, диплом эшләрен тәмамлыйсы бар. Әни кешенең дә төшеп каласы килми, инде биш ел укыгач, соңгы имтиханын да тапшырасы, дипломын да яклыйсы иде.

Житмәсә, бала елак булып чыкты. Кыз бала гадәттә тыныч була, диләр. Ә Рамилә—ана шулай дип исем кушканнар иде—төненә өч-дүрт тапкыр уяна, сәгатьләр буе туктамый елый. Өч көн түзде кызлар, бер атна. Аннан артыгына чыдар әмәлләре калмады.

—Булмый бу болай,—диделәр.—Үзегезгә аерым бер почмак табыгыз!

Ә каян табасын ул аерым почмакны? Яшь балалы гаиләне фатирга кертергә атлыгып торучы бармы әллә?

Ярый, рәхмәт яусын, Алия Фәргатовна әйткән сүзендә торды, ярдәм итү чарасын тапты: нәнине вакытлыча, ике айга гына сабыйлар йортына урнаштырырга рөхсәт алдылар.

Билгеләнгән көнне иртүк алар, бала күтәреп, тулай торак ишегеннән чыгып киттеләр. Трамвайга утырдылар, төшкәч, чиста итеп себерелгән тын урам буйлап жәяү киттеләр.

Мул кояшлы, әмма салкынча май иртәсе иде бу. Шәһәр урамнарының—чиста, күнелләрнен тыныч вакыты. Мидхәт кочагында йоклап яткан сабыйны уятудан сакланып, бер көйгә ипле генә атлап бара. Баланың кыймылдаганын сизеп, йөзен каплаган челтәрле ак тукыманы күтәрде дә, битен ана якын китерде. Һәм аннан килгән татлы истән башы әйләнеп киткәндәй булды. Тукымалар аркылы сабыйның йөрәк тибешен сизде. Ана үз йөрәгенең дөпелдәп җавап биргәнен тойды. Ике йөрәк бергә тибә, дөресрәге, олы йөрәк белән анын дәвамы—кечкенәрәге сулкылдашып, бер-берсенә якынлыгын, газизлеген аңлаталар кебек иде. Бу хис шундый яна, шундый көтелмәгәнчә иде ки, Мидхәт, сулышына кабып, тукталып калды.

—Әйдә инде,—диде Лениза.—Сигезгә килеп житегез, дигәннәр иде бит. Сонга калмыйк!

Соңыннан, бу минутлар исенә төшкәндә, ул тетрәнеп китә һәм: « Шундый бәхет тә була икән!»—дип үзалдына гажәпләнә иде.

Ул елмаеп баланың йөзен ак челтәр белән каплады да урыныннан кузгалды. Ике ягына әлегә шәрә юкәләр тезелеп баскан, зур йортларының тәрәзәләре иртәнге кояш нурыннан балкыган бу урам анын сабыен бәхет йортына илтеп кертергә тиеш иде кебек.

Менә алар унга борылдылар да, милиция урнашкан бина янынннан узып, янәшәдәгесенең ишеген ачтылар. Каршыга ак халатлы, юан гәүдәле апа чыкты. Аның чырае житди, хәтта кырыс иде. Рәтләп сәлам алып та тормыйча:

—Китердегезме?—диде.

—Сез беләсездер бит инде, без вакытлыча гына... Диплом яклаганчы, ике айга...—диде Лениза акланырга тырышкандай.

—Ул сезгә вакытлыча,—диде үзалдына мыгырдагандай апа.—Мондый бала өчен ике ай үзе бер гомер ул. Сез дә без вакытны айлар, еллар белән саныйбыз. Ә аныкы сәгатьләп исәпләнә. Имезә торгансыңдыр бит?

—Имезәм, әлбәттә... Мин килеп йөриячәкмен...

—Өч сәгатьтән өч сәгатькәме?! Ай-һай ла!...

Апа Лениза белән сөйләшә, Мидхәт тарафына күз дә салмый, гүяки аны күрми дә иде. Ул бу ирне кешегә санамый иде! Мидхәт ихтыярсыздан аннан баланы тартып алырга кулларын сузды. Апа аңа аркасы белән борылды да:

—Имезеп китәсең килсә, туфлиләреңне салып, башмаклар ки әнә,—диде Ленизага.—Хәзер халат чыгарып бирермен. Тәрбиячеләрнең эше тыгыз әле анда, сабыйларны ашаталар. Бераз бушаганнарын көт, үзләре белән сөйләшеп китәрсең.

—Мин дә...—диде Мидхәт.

—Ә син нәрсәгә? Син имезмисеңдер бит! Монда чит кешеләрне кертмиләр! Бу бала гомумән бокста ятачак әле. Ким дигәндә бер атна карантинда булырга тиеш ул.

Шулай итеп, бичара сабый, әти-әниле була торып, бер атналык чагында үксезләр арасына кереп ятты. Һәм бу аның бөтен язмышына кара тамгасын салгандай итте.

...Көннәрнең берсендә Лениза сабыйлар йортыннан ничектер сәер елмаеп кайтып керде дә:

—Рамилә мине ташлады,—диде.

Бу хәбәр Мидхәтнең йөрәген сызып, җәрәхәт ясады. Тик ул моның бала өчен ясалган яраларның иң җиңеле, тиз төзәлә торганы икәнен белми иде әле. Бу минутта аны гаҗәпләндергәне—хатынның чыраендагы җиңеләю галәмәте булды.

—Тәрбияче Лидия Кузьминична әйтте, хәзер инде тынычлабрак укысаң да була, диде. Кайчан житешәсең, шунда килерсең, без монда аны анасыннан ким карамыйбыз, диде.

—Чит күз шул син аларга,—диде Мидхәт сыкранып.—Еш килеп йөрүеңне теләмиләрдер. Житешмәгән якларын күрсәтәселәре килмидер.

* * *

Ничек кирәк алай бу чорны үткәрделәр, Лениза да ире әзерләп биргән дипломны яклады—ул чәйнәп биргәннәрне комиссия каршында шартлатып сөйләде. Кулга диплом белән эшкә юллама керде.

Әле генә диплом алган инженер-химикка үз һөнәре буенча эшкә урнашу—бу заманда зур бәхет иде. Соңгы вакытта яшь белгечләрне кочак җәеп каршы алып торучы сирәк. Ә менә Мидхәтне чакырдылар. Чөнки ул студент чагында ук «Н» шәһәрендәге зур бер заводның белгечләре белән танышып өлгергән иде инде. Шартлаткычлар эшли торган цехның инженеры Федор Никифорович үзе дә заманында шушы институтта укыган, елына бер-ике тапкыр Казанга килми калмый. Лабораториядән чыкмый яткан Мидхәтне ул бик тиз күреп алды, килгән саен аның белән очрашып, ясаган тәҗрибәләре һәм яңа фикерләре белән кызыксынып торды, үзләренә эшкә чакырды. «Бер ел эчендә фатирлы итәрбез»,—дип тә вәгъдә бирде хәтта.

«Н» шәһәре Себер ягында, шактый ерак, фатиры да, мөгаен, завод тирәсендә булачак, Ленизаның анда барасы килми иде. Ләкин Казанда яхшы эшкә урнашу мөмкинлеге юк, аннан да бигрәк, фатирлы булу турында хыялланып та булмый. Шуңлыктан, дипломнарны сумкага салып, бала күтәреп, самолетка утырудан башка чара калмады.

Завод җитәкчеләре вәгъдәләрендә тордылар: яшь парны килүгә тулай

торакка, аерым бүлмәгә урнаштырдылар, өч айдан фатир бирделәр. Нәкъ шул чорда шәһәр читеннән генә җир алганнар, теләгәннәргә дүртәр сутыйлап өләшәләр иде. «Бик вакытлы килеп җиттегез»,—дип, аларны да исемлеккә керттеләр.

Бәхетле булыр өчен ни кирәк тагын? Чөкердәшеп яшә дә, сабыеңны кадерләп үстер!

Ләкин... Аһ, бәхет дигәнең тормышның житеш булуыннан гына торса икән лә!

...Аларның яңа урынга килеп урнашуына елдан артык вакыт үткән, Рамилә шактыйдан ук тәпи киткән иде инде. Үзәккә үтә торган ачы җилле, карлы-яңгырлы бер кичтә Мидхәт трамвайдан төште дә, куртка якасын күтәреп, муенын жыерып, светофор каршына барып басты. Яшел ут янгач, башкаларга бәрелә-сугыла, кабаланып урам аша чыкты: халык эштән кайта, ыгы-зыгы күп иде. Машиналарның тәгәрмәчләреннән чыжылдап бозлы су бөркелә, вак тамчылар башка-биткә сарыла.

Ишек төбенә җиткәч, ул туктап калды, ярдәм эзләгәндәй тирә-ягына каранды. Алар яшәгән урам бик киң һәм шау-шулы булып, каршы якта, биек каеннар һәм тирәкләр арасында, кызыл кирпечтән салынган борынгы чиркәү киңәеп, биегәеп тора. Алгы ишеге янына куелган лампалар аны астан яктыртканда, гөмбәзе, манарасы гадәттәгедән дә биегрәк тоела, аларның алтынланган түбәсе тонык һәм серле ялтырый иде.

Эче поша иде Мидхәтнең, өйгә керәсе килми иде. Һәм моның җитди сәбәбе бар иде. Иртәгә иртүк ана командировкага китәргә кирәк. «С» карьерында фаҗигале хәл булган: шартлатулар уздырганда, зарядларның берсе исән калган да, актарылган тау токымын көрәргә кергән бульдозерның тәгәрмәче астында шартлаган. Бульдозерчы авыр хәлдә хастаханәгә эләккән. Ярый әле үлмәгән. Хәзер менә комиссия төзеп, кем гаепле икәнен тикшерәчәкләр: шартлаткыч сыйфатсыз булганмы, әллә шартлату эше дөрес башкарылмаганмы?

Монда инде карьер кешеләре аклану өчен бик нык тырышачак, гаепне заводка, ягъни Мидхәткә сылап калу өчен бөтен көчне куячак.

Бу хакта хатынга канын кыздырмаслык итеп ничек, нинди сүзләр белән җайлап-майлап әйтергә? Командировка диюгә җене котыра, ике генә көнгә күзеннән югалып торсаң да, җәнҗал куптара. Ә монда, мөгаен, бер атнасыз кайтып булмаячак.

Бер уйласаң, аны аңларга да була: әлегә кадәр эшкә урнаша алганы юк—тәкъдим ителгәнен яратмады, күңеленә ятышлысын тапмады. Бар карап торганы Мидхәт. Әгәр дә тормыш иптәшен бер генә көн дә синсез яшәргә теләми икән, аны гаепләп буламыни? Ярату билгесе түгелмени бу?

Мидхәт, нинди сүзләр әйтергә, чырайга нинди галәмәт чыгарырга, дип уйлана иде. Кайгырган булып кыланыргамы, әллә, җинелчәгә сабыштырып, елмаергамы? Ике ел бергә яшәп, гомер юлдашының җаен алып бетермәгән иде әле ул. Сөешү үпкәләшүсез булмый—алар арасында да әледән-әле салкын җил исеп куйгалый, буранлаган чаклар да була. Баштагы чорда болар, кояшлы яңгыр кебек, тиз үтә иде.

Әмма тора-бара бик үк тиз үтми башлады...

Пыскып яуган карлы яңгыр аркылы тәрәзә утларын уйнатып, тагын бер трамвай узып китте. Ишек турыннан сирәк-мирәк узгынчылар үткәләде. Мидхәт башын селкеп, сынын турайтты, күңелсез уйлардан арынырга тырышты. Аны хатыны гына түгел, кызы да көтә бит әле. Оеклы ыштан кигән тәпиләре белән тавышсыз атлап каршыга килер дә, тезләрне кочаклап алыр...

Бу уйдан Мидхәт үзалдына елмаеп җибәрде. Һәм подъездның кыршылган,

какшаган, ямьсез итеп коңгырткa буялган ишеген каерып ачты.

Алгы бүлмә бик кысан, бер кеше генә сыя. Мидхәт курткасын салып, капюшонын каккалаган арада бүлмә ишегенә аркылы Ленизa килеп басты.

—Кайда йөрдең син?!

Шул-шул менә, бусаганы атлап керүгә җавап алу башлана... Мидхәт чыраена елмаю галәмәте чыгарырга тырышты.

—Трамвай начар йөри. Озак көтәргә туры килде.

Ленизаның күзне ертa торган эре кызыл чәчәкле зәңгәр халат итәген бүлмә ягыннан бала тарткалый, нәрсәдер лепелди, әтисе янына талпына, әмма хатын моны сизми иде.

Мидхәт дәшмәде, елмайган килеш, аны сак кына читкәрәк этәреп, кызын күтәреп алды һәм йөзен анын сөткә чыланган бумази күлмәгенә терәде. Бала йөрәгенең еш-еш лепелдәве анын битенә-йөзенә бәрде һәм йөрәкне җылы куаныч белән тутырды.

Кызның штан төбе юеш һәм салкын икәнлеге анына бераздан барып житте.

—Ай-яй, кызым, нишләп болай какайланып йөрисең? Егетләр карамас үзеңә!

—Синдә һаман шул бер нәрсә кайгысы инде,—дип мыгырданды Лениза.— Заводыгызда җилпенгән юбкалар исеннән чыкмыйдыр...

Мидхәт кулында боргаланган Рамиләнең астын алыштырды да, юыну бүлмәсенә кереп китте. Сулы ваннада шактый кер җебеп ята иде. Кер юу машинасы алырга кирәк тә бит, әлегә хәлдән килми...

Ул көрсенеп кулын юды да, аш бүлмәсенә чыкты. Лениза шап итеп анын алдына бәрәңге боламыгы белән сарделька салынган тәлинкә китереп куйды да:

—Без ашадык инде,—диде.

Ә Мидхәт үскән йортта кичләрен әтиләре эштән кайтмыйча табынга утырмыйлар иде...

Ата канаты астында үскән бала түгел шул бу Лениза. «Әти мин туганчы ук машина астына кереп үлгән»,—ди үзе. Баштарак Мидхәт монa ихластан ышанган иде, соңрак, уйлана торгач, ә бәлки аның әтисе исәндер дә әле, тик Лениза исемле кызы барын белмидер, дигән фикергә килде. Хәер, әтисе генә түгел, әнисе дә аны дөньяда юк, дип исәпли түгелме? Тансык бала булмаган ул, комачау гына булган. Нәни чакта ук әнисе, кечкенә шәһәрдә яшәүче әбисенә тапшырып, зуррак шәһәргә китеп кияүгә чыккан һәм баласы барын иреннән яшереп яшәгән.

Шикәр чире белән җәфаланган карчыкның исә оныгын назлап-иркәләп кенә үстерергә акчасы да, дәрте-көче дә җитмәгән булса кирәк. Ә балалар әти-әниләренең яшь, чибәр, бай булганын ярата. Лениза әбисе өчен оялып үскәндер, шуңлыктан, аны чын күңелдән ярата да алмагандыр.

Салкын, сусыл бәрәңге боткасын тамагыннан көчләп уздырганда, Мидхәтнең башыннан шундый уйлар узды. Сүз ялганмады. Ләкин ялгарга кирәк иде, командировка хакында әйтәсе бар, димәк, алда озаклап аңлашу, алай гына түгел, мөгаен әрләшү тора иде. Кайнар, әмма тәмсез тоелган чәйне эчеп куйгач, Мидхәт хатынының күзеннән бераз котылып торырга, әрепләшүне дә күпмедер вакытка чигерергә чара тапты:

—Мин баланың керләрен юып алыйм әле,—дип юыну бүлмәсенә кереп китте.

Рамиләнең керләрен юу җанны бераз тынычландырса да, күнеккән куллар бу эшне тиз тәгаллләде. Юеш әйберләрне җылыткыч батарейларга таратып салу да ярты минутлык эш иде. Иң мөһим сүзне башларга исә һаман җай чыкмады.

Бер мәзәк искә төште: борынгы заманнарда бер хатын самавырын сусыз

куеп эреткән икән дә, шуны иренә ничек әйтергә белми аптырап йөри икән. Ул чорда самавыр олы бер хәзинә, аны югалту зур фаҗига иде бит. Уйлый торгач, хәйләсен тапкан теге хатын. Йокларга ятып, утларны сүндергәч, иң дәртле минут килеп җиткәч кенә әйткән, имеш: «Карале, картым, мин самаварны эреттем бит!»—ди икән. «Ташла, чукынсын самавыры!—дип аны тагын да катырак итеп кочагына кыскан ире.—Аның кайгысымыни монда!»

Мидхәт шушы мәзәкне искә төшерде лә, командировка хакындагы сүзне шундыйрак минутка калдырып торырга булды. Тигез хокуклылык хөкем сөргән бу заманда ир-ат затына яраган хатын-кызга ярамый калмас!

Кичнең калган сәгатьләре телевизордан президент Путинның безне бәхетле итү турында кайбер министрлар белән киңәшеп утырганын карау, Рамиләне әле теге, әле бу уенчык белән юату, аның эренләгән күзен, маңкалаган борынын сөрткәләү мәшәкатьләре белән узып китте.

Инде менә тиздә тибрәтеп, үчтекели торгач, бала да арды, караватына ятып йокыга китте. Телевизордан нәфис дип аталган фильм күрсәтә башладылар, андагы геройлар тиз арада танышып-иснәшеп дигәндәй, киң караватларда әүмәкләшергә керештеләр, Ленизаның чыраенда уйнак елмаю пәйда булды. Телевизордагыларның кыланмышларын үзләренә дәвам итәр минутлар килеп җитте...

Адәм баласы яши-яши һәрнәрсәгә күнегә, көндәлек ашка әйләнгән сөешүнең-назланышуның да балы әчеп киткәндәй була. Моны Лениза да сизә башлаган, һәм, ирем читтән татлыракны тапмагае, дигән шикле уйдан вакыт-вакыт сискәнеп куйгалый иде. Ирне кулда тотар өчен, аш төрләндергән кебек, сөешүнең дә төрле ысулларын кулланып торырга кирәк, дип өйрәтә бу шөгыльнең осталары һәм белгечләре. Бик тә нәзберек, яшерен һәм күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә торган бу гамәл дә безнең заманда үзенә бер фәнгә әверелеп, аның «профессор»лары да барлыкка килде бит. «Мин—сексолог!»—дип түш киереп, масаеп йөрүчеләр бар. Борынгы заманнарда бөтенләй мәгълүм булмаган, гади кешеләр карашынча, шактый сәер һәм хәтта оят булып тоелган һөнәр белән тамагын туйдыру гына түгел, баеп китүчеләр очрый, аларның калын-калып китаплары кибет киштәләрендә тулып ята һәм матур әдәбиятка караганда күпкә артыграк сатыла.

«Миңа да шыр надан булып яшәргә ярамас»,—дип, аш пешерү турындагы китапларны ачып та карамаган Лениза да бу өлкәдә белемен һәм осталыгын арттыру чараларын күрүне кирәк санады.

...Менә алар өске утларны сүндерделәр, сару кайнаткыч кызыл япмалы торшерны кабыздылар. Кайсыдыр журналда, кызыл төс женси теләкне арттыра икән, дигәнне укыгач, Лениза үзләренә шундыйны алып куйган иде. Менә ул телевизордагы стриптиз биюче кызларның кыланмышларын кабатларга тырышып, әкрен генә халатын салды. Иллә дә кәттә тегәләр инде хәзерге заманда хатыннарның эчке киемнәрен! Челтәр белән бизәлгән, ука белән чигелгән җете кызыл атлас тукыма күкрәкләрнең яртысын һәм аннан түбәнрәк түшнең иң җаваплы ноктасын гына каплап тора. Бала тапканнан соң, башка күп хатыннар кебек симермәде Лениза, корсагы бүлтәеп чыкмады. Аяклары төз, биле нечкә, күкрәкләре, баланы аз имезгәнгәмедер, йомры, тере. Шәп, чукынмыш! Караватка сузылып яткан Мидхәтнең күңеле йомшаган, авызы ерылган иде. Мондый ымсындыргыч эчке киемнәр, бу кыланмышлар һәммәсе аның өчен бит!

Лениза караватка аркасы белән борылды да, салмак хәрәкәт белән чүгәләде. Ире атлас лифчикның каптырмаларын ычкындырсын өчен. Стриптиз, билләһи! Аның да иң кәттәсе! Чөнки мондыйны бик мактанган төнге клубларда да татый алмассың: андагы өсталләр артында хәмер чөмереп утыручы ирләргә сәхнәдә биюче кызларны үз куллары белән чишендерергә рөхсәт ителми,

читтән карап ялманып утырырга гына кала.

Каптырмаларны ычкындырганда, хатынының шома тиресенә орынган бармаклары калтырана иде Мидхәтнең. Ул, үрелеп торшерның утын сүндерде дә, Ленизаны кочагына алды.

—Кил әле,—дип кайнар пышылдады.—Туйганчы иркәлим әле үзеңне. Сагынып көтеп алырлык булсын!

Хатынның май кебек йомшарга тиешле сыны кинәт ныгып, тураеп китте.

—Каян көтеп алырга? Тагын командировкага китәсеңме әллә?!

Әйе, наздан тәкатьсез калып, дөньясын оныта торган зат түгел шул ул! Тәкатьсез итәрсең, бар, Ленизаны!

Менә ул тураеп утырды, урындыктан халатын алып, йомарлап түшенә кысты. Боздай салкын тавыш белән пышылдап:

—Кая?—дип сорады.

Әйтми котылып була торган түгел. Мидхәт аякларын салындырып карават кырыена утырды. Һәм берничә сүз белән хәлне аңлатып бирде. Карьерда бер шартлаткычның үз вакытында түгел, өстенә бульдозер баскач кына шартлавын, бульдозерчының авыр хәлдә больницада ятуын... Берәр дуска, йә туганыңа сөйләсәң, хәленә керми калмас, синең өчен борчылыр иде. Ләкин Лениза түгел. Аның башындагы уйлар иренә аңлашылмый торган юнәлештә ага иде.

—Син врач түгел лә, аны терелтә алмыйсың,—диде ул.

Мидхәт авыр итеп көрсенеп куйды:

—Алар, мөгаен, электр чыбыкларын дөрес сузмаганнардыр. Ләкин гаепне безгә аударыр өчен җан тырмашачаклар. Һәм, бармасак, мона ирешәчәкләр дә.

—Күпме буласың инде син анда?

—Комиссия составына керергә кирәк инде. Ә комиссияләрне үзең беләсең... Атна-ун көндә берәр нәтиҗәгә килә алсалар, шөкер итәрсең...

Лениза халатын иненә салды да, торшерны кабызды.

—Атна-ун көн?! Шул гомер нишлисез анда? Бер чокырдыр бит инде ул? Атна буе җыелышып шунда казынып ятмакчы буласызмы әллә?

—Чокыры нинди бит... Кешене имгәтеп ыргыткан упкын дияргә була...

—Сиңа күз күрмәгән кешеләр жалко, ә безгә наплевать! Өйдән чыгып качар өчен мең төрле сәбәп табасың! Читтә рәхәтрәктер шул!...

Аһ каһәр, сизгер үзе, Мидхәтнең бик яшерен рухи халәтен белеп алган! Әйе шул, аякларның үзеннән-үзе өйгә таба әлдертә торган чаклары узды... Тик мона кем сәбәпче соң?

Әмма алай дип әйтергә ярамый иде. Мидхәт тамагына килгән ачы төенне йотарга тырышты.

—Әкрен,—диде.—Рамилә уянмасын... Сүндер утны!

—Ут комачаулыймы сиңа? Чыраеңны миңа күрсәтәсең килмиме? Яшерер серләрең күпме?

Лениза кычкырына башлады, Рамилә уянып елап җибәрде. Әнисе аны караватыннан тартып алды да кочагына кысты.

—Күр, кызым, атанны! Безне күрми торыр өчен әллә ниләр уйлап чыгара!...

Дәвамын тасвирлап тормасаң да була, чөнки, һәркемгә мәгълүм: мондый ызгыш-талаш текә тау башыннан ишелгән ташкын кебек: аска төшкән саен көчәя, кинәя һәм юлларны җимереп, һәммәсен күмеп китә... Бала елавы, бала кулы гына туктата торган түгел!

Дөрес, күпләр әйтер: «Һи-и, ир белән хатынның үпкәләшеп-әйткәләшеп алуы ул бит ашка борыч сибү кебек кенә! Аның ише ачылышып алулардан соң сөешү бигрәк татлы була»,—дияр.

Кемгә ашка борыч сибү дә кемгә таш өеме астында калу... Кычкырышу-

әйткәләшү күпмегә сузылгандыр—андый чакта сәгатькә карамыйсын. Ахырда хәл бетте, елаудан баланың тамагы карлыгып китте. Ул ысылдый башлады. Мидхәт аны Ленизa кулыннан алмакчы иде, хатын этеп җибәрде.

Һәрнәрсәнең ахыры була, ниһаять, бу фатирда да тынлык урнашты. Рамилә үз караватында тынгысыз йокыга талган, борғаланып, әледән-әле сулкылдап ала. Лениза караватка аркылы диярлек сузылып яткан, мендәргә капланып мышык-мышык елый. Урамнан төшкән яктылыкта, идәндәге атлас трусикның чигүендәге укалар елкылдап куя. Мидхәт исә кысан аш бүлмәсенең идәнендә чалкан ята, астында—эшкә кия торган курткасы, баш астында диван мендәре, өстендә плащ. Беркайчан да аның мондый уңайсыз урында төн уздырганы юк иде әле. Кадерле бала булды, урыны йомшакта иде. Институтка кергәч, анасы, андагы сасыган матрасларга аунама, дип, сарык йонынннан сырылган сырма биреп җибәргән иде. Хәтта туристик походларда да үлән, йә ботак җыеп, ятагын йомшак итеп әзерли Мидхәт...

Ләкин бу төндә ул бөтенләй кадерсез калды. Үз йортыңны да көйсез итеп була икән... Эштәге борчулар өстенә бит бу. Карьердагы шушы бер шартлау үзе генә дә аяктан егарлык хәл ләбаса!.. Мондый чакларда ир-белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең дусларча төсмер алуы бик тә табигый булыр иде ласа. Төннәрнең кайберләрендә, күккә ашып, ялкын телләрендә янып, бөтен жегәрне биреп сөешү урынына, үзара серләшеп, юатышып, бер-береннең тигез-тыныч сулышын тыңлап ял итү дә җанга ял бирер иде.

Бәгъзе акыл ияләре: «тату яшәгән ир белән хатын арасында яшерен сер булырга тиеш түгел»,—диләр диюен дә, күңел төпкелләреннән шуышып узган уйларның һәммәсен дә яктыга сөйрәп чыгарып бетереп була микән? Һәм бу кирәк микән?

Әгәр дә Мидхәт, синең шашынган булып кыланууларың мина ясалма булып тоела, дисә, нindирәк җавап алыр иде икән?

Кушылу-назлануларны көнкүрештәге күнегелгән тәртипнең бер өлеше дип кабул итәргә кирәк. Табынга да көн дә саен майлы бәлеш, кара уылдык куелмый, йоклаганда да гел генә татлы төшләр керми. Һәрнәрсәдә уртачага канәгать булып яшисең. Түшәк мәсьәләсендә дә шулайрак инде ул. Һәммә парлар дистә еллар буе бер-берсен өзелешеп сөеп, һәр төн саен акылны җуяр дәрәҗәдә назлашып яшиләр, дисәләр, моңа сай акыллы бәндәләр генә ышаныр. Ир-хатынның кушылуы—яшәешнең иң мөһим ихтыяҗларыннан берсе. Һәм аны канәгатьләндергәндә дә адәм баласы чама белергә тиеш. Күп көчен хезмәт итүгә биреп, ипле яшәүче кешегә ата-бабача кылану да бик житкән. Ач карынга үз вакытында ипи белән бәрәңге дә ризыкның иң татлысы булып тоела һәм артыгы кирәкми дә. Шул ук вакытта балны да чиләкләп чөмереп булмый! Тик моны Ленизага ничек аңлатырга?.. Уйлар буталды, керфекләр авырайды...

Анарчы Мидхәт чәчен ал тасма белән бәйләгән кызны исенә төшермәскә тырыша иде. Ә менә бу төнне ул кыз аның төшенә керде: ак чиләгеннән бер уч кызыл җиләк алып бирде. Мидхәт аларны иреннәренә китергән иде, сусыл, татлы тәмен телендә алдан ук тойган иде, тик каба гына алмады, уянып китте...

*Дәвамы киләсе саннарда*



Луиза
Янсуар

# КЕМДЕР АЧА КҮК ИШЕГЕН

## Хәтер

**Тәрәзәмне ачтым…
Китерде җил
Итәгендә тозлы диңгез шавын.
Гөлләр исен үрде чәчләремә,—
Хәтерләдем… туфрак булган чагым…**

**Кыяларга дәштем
һәм тыңладым
Кайтавазның тынмас зарлы чаңын.
Хәтерләдем… үксез киңлекләрне
Берьялгызым гизгән бөркет чагым.**

**…Үз-үземә кайттым,—
Бар Үткәннәр
Күтәрелә, калка миндә тагын.
Хәтерлә, җан, мең күкрәүдән торган,
Яшәү серен тойган—Кеше чагың…**

* * *

**Үләннәр эземне яшерер…
Онытылыр, онытылыр барысы да.
Нинди йөк күтәреп кайтыр җан
Саф күзле йолдызлар каршына?**

**Гомер дип аталган мизгелнең
Сүнә дә, кабына учагы…
Җаннарны ни белән юатыр
Дәһшәтле Мәңгелек кочагы?!..**

Луиза ЯНСУАР — *шагыйрә; «Мин күкләргә кайтам», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Август

**Йолдызлар тынгысызланыр,—**
**Август бу—уңыш ае.**
**Яралы чагы йөрәкнең,**
**Юатчы, көмеш аем!**
**Убылыр Күктән һәр галәм**
**Гаме юк сабый кебек.**
**Саргаеп калган болында**
**Колыннар куяр... чүгеп.**
**Көзгә дә күнегелер бер,—**
**Сагышлар—көшел-көшел.**
**...Бу—август куенындагы**
**Йолдызлы соңгы төшем...**

## Җан

**1**

**Галәм буйлап очтым...**
**Йолдыз булды бу җан—**
**Күккә чөюемнән.**

**Күл суларын эчтем...**
**Бер мизгелгә тынды**
**Хисләр көюеннән.**

**Тупылларны кочтым...**
**Көмеш чыңнар калды,**
**Җырлар—Сөюемнән...**

**2**

**Төсләр арты төсләр,—**
**Җәйге шәфәкъ яккан**
**Учакларда коенам.**

**Хисләр арты хисләр,—**
**Онытылып, шашып,**
**Йөрәгенә сыенам!**

**Эзләр арты эзләр,—**
**Ак кәгазьгә, җиргә,**
**Офыкларга уелам.**

**Күзләр арты күзләр,—**
**Учларына җилнең**
**Яфрак булып коелам.**

**Йөзләр арты йөзләр,—**
**Яшәү—бөжра. Мәңге**
**Китә алмас күк тоелам...**

* * *

**Кемдер орынды айлы үрләргә...**
**И яуды йолдыз, үкседе киек.**

Ә карт тупылның һәрбер яфрагы
Саташып дәште:
«Ул килде!»—диеп.

Җилләр өненә ышанмыйм күптән,
Узган ымсыныр, талпыныр чагым.
Әмма... томаннар, үләннәр ерып,
Ялган эзләрдән
Ник атлыйм тагын?!

Кемдер орынды тынган кылларга...
И шашты йөрәк, саздай иңрәде!
Ә карт тупылның, түзми сагышка,
Ярылды
Чорлар кичкән йөрәге...

* * *

Калкан-калкан болыт иде күкләреңдә...
Ул болытлар инде эреп таралгандыр.
Ә күңелнең аяз чагы булмас төсле,—
Безнең Язмыш күз яшеннән яралгандыр.

Сөйгән көннәр... Куз-күмердәй көйгән көннәр...
Җан тузлары шул эзләрдән каралгандыр...
Һәр мизгелен соң тамчыдай эчәм йотылып,—
Гомер үзе күз яшеннән яралгандыр...

* * *

Ташлар йөрәгенә уелырмы җырым,
Җилләр хәтеренә чигелерме моңым?
Таллар бөдрәсенә йөзем яшерәм дә,
Төнге чишмәләрнең тыңлыйм көмеш чыңын.

Мәңгелектә безнең юллар кисешәсен
Белгәнме бу чишмә, сизгәнме бу таллар?
Күңел дәрьясында таудай дулкын калка,
Шомлы уйга чумып, тибри утлы саллар.

Шул салларга салып агызыйммы җанны?!
...Җилләр тынды кинәт, ташлар аваз салды...
Янган учларыма болыт керфегеннән
Сүзсез дога булып... көмеш тамчы тамды!..

* * *

Орынырга кыймыйм...
Синекедәй
Яралы күк шәфәкъләрнең җаны.
Назга сусап җилгә томырылган
Йөрәктә тик—сулган моңнар чаңы.
Мең кат узган юлдан
Бәхет эзләп,
Әрнү эзләп, җиргә кайтам тагы.
Йә терелт, йә сүндер учларыңда,—
Җанның шәфәкъ булып янган чагы!..

* * *

Бер учактан бер учакка мәңге
Ташлар микән җилләр кабыгымны?!
Карашларын, назын оныта алмам
Һәм җуймамын барыбер сабырымны.

Сез, җаныма ят кулларын сузган
Дошман икән... юк, килмәгез якын!
...Йөрәгемдә—Сөю яккан сусау,
Күзләремдә—нәфрәт сүткән ялкын...

Ярдәм көтеп йолдызларга баксам,
Күктән утлы юллар укылырмы?
Еллар кичеп, чорлар кичеп, беркөн
Бер учакта көлләр кушылырмы?!..

* * *

Син мине аккош кызына,
Нәфис гөлгә тиңләдең.
Эх, Дөнья күтәрмәс йөкне
Күтәргән бу иңнәрем.

Җил булып йөгерәмен дә,
Җыр булып өлгерәмен.
...Кем күңел көзгесе итәр
Хыялым өлгеләрен?!..

Утларга салырсың, беләм...
Калкырмын кабат көлдән!
Беләгең тала йөгемнән,
Йөрәгең сакла, иркәм!..

* * *

Нурга, Моңга оя бармы җирдә,
Бармы кабык, читлек җаннарына?
Мин йолдыздай төнең балкытам да,
Саф чык булып иңәм таңнарыңа.

Кочагыңны җәеп, дәшмә мине,—
Бушлык багар күзләреңә тагын.
...Көзгеләрдә тибри өнсез шәүләм,
Мәңгелеккә кайтып бара җаным...

## Үтенеч

Читлектән дә кысан тар Ирегем
Газизрәк затлы түреңнән.
Килсәм, колач җәеп каршыла син,
Китсәм... озат биек үремнән.

Канатымны җилләр теткәндә дә
Шелтә-сүзсез терелт җанымны.
...Бер тәхеткә беркөн шаһ булырбыз,
Бер туфракка җәеп тамырны...

* * *

Кайнады елгалар,
Ярыннан ташыды...
Уйладык: Табигать
Бәхеттән шашынды.
...Таң чыгын иреннән
Җилбәзәк җил өзде.
Яралар күңелдә
Никадәр—ун, йөзме?..
«Ялгыш» дип, «Язмыш» дип
Юрау ник? Кирәкме?!
...Биеккә чөямен
Былбыл-кош—йөрәкне!..

* * *

Җирдә әле без узасы сукмаклар бар,
Без табасы энҗеләр бар диңгезләрдә.
Туктат, Вакыт, агымыңны бер мизгелгә,—
Тере шаһит бул түгелер хис-сүзләргә.

Сөю юлы—йолдызлардан үргән күпер—
Бу Галәмдә гашыйкларны әйдәр мәңге.
Туктат, Вакыт, агымыңны мең гасырга,—
Безнең җаннар кушылганчы, җиңеп тәнне.

## Оныт!

Кайтмам инде... Мин калырмын дөрләп
Көзге урманнарның кочагында.
Вакыт җиле Сөю-күбәләкне
Әйләндерер җанлы курчагына.

Кайтмам инде... Күмелермен кереп
Алтын дәрья—арыш кырларына.
Кайтавазым иңрәп кушылыр бер
Килер Язның көмеш чыңнарына.

Кайтмам инде... Ялгыз бөркет кебек
Оялармын таулар бәгыренә.
Син юлларга яфрак сип тә... оныт,—
Җилләр күмәр эзне хәтереңә...

* * *

Канатларым җир тузанын
Йолдыз итеп җилгә сибә,
Җаннар җанга бәхет илтер
Сукмак сала, эзләр чигә.

Монда үзем ят кунак мин,
Юк куышым, үз бишегем...
«Сакла җаның»,—диеп һәр төн
Кемдер ача Күк ишеген...



Рөстәм Мингалим



Эсфир Яһудин

## ӨЧ БАЛДЫЗГА БЕР ЯЛГЫЗ

МУЗЫКАЛЬ КОМЕДИЯ, ИКЕ ПӘРДӘДӘ

**Катнашалар:**
Имам
Мәрьям
Микулай
Сания
Әминә
Фәридә

*Вакыйга безнең көннәрдә, таралып бетә язган ташландык авылда бара.*

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

1

*Авыл йортының ишек алды. Болдыр янындагы агачлар арасында тирә-ягына эскәмьяләр куелган өстәл. Җәйге көн. Тышта машина тавышы ишетелә. Ике сумка күтәреп Имам, аның белән Сания ишек алдына керәләр.*

Сания. Менә шушында яшим инде мин.

Имам. Искиткеч матур урында яшисең икән.

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) — *шагыйрь, драматург; егермедән артык китап (лирика, балалар өчен шигырьләр, поэмалар, пьесалар) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Эсфир ЯҺУДИН (1949) — *драматург, прозаик; «Мәхәббәткә мәдхия» исемле китап авторы. Казанда яши.*

**Сания.** Тырышабыз инде шунда... *(Акчасын эзли.)* Күпме бирим сезгә?

**Имам.** Куй әле, Сания, акча өчен китермәдем, мин шундый ярдәмчел кеше.

**Сания.** Шулай рәхмәт ялына гына йөрисеңме?

**Имам.** Әйдә, әйберләреңне кертик, үзеңне күрдем, өеңне дә күреп китим.

**Сания.** Керик, акча да алмагач, чәемне булса да эчеп кит.

*Алар өйгә кереп китәләр, ишегалдына Фәридә белән Әминә килеп керәләр.*

**Фәридә.** Әнекәем, гомер буе ялгыз Сания машиналыны ияртеп кайткан!

**Әминә.** Кайтса соң! Ул кемнән ким?

**Фәридә.** Максатына кергән юк, мин дә ялгыз ятмас идем.

**Әминә.** Мондый машинаның авылга килгәне юк. *(Капка янына барып машина күзәтәләр.)* Каян каптырды икән мондый байны?

*Имам болдырга чыгып баса да, тәмәке кабыза, кызларны күреп ала, сүзләренә колак сала.*

**Фәридә.** Андый машиналарны безгә япун китерә диләр, бик кыйммәт ди алар. Нәчәльниктыр бу.

**Әминә.** Валлаһи нәчәльник эләктергән бу.

**Фәридә.** Шәһәргә баргач, вактөякне эләктермәс инде.

**Имам.** Нәчәльник түгел мин, кызлар.

*Фәридә белән Әминә ана борылып бераз уңайсыз хәлдә калалар.*

**Фәридә.** Абау!

**Әминә.** Исәнмесез!

**Имам.** Исәнмесез, курыктыгызмы әллә?

**Фәридә** *(уңайсызлана төшеп).* Юк, юк, курыкмадык, исәнмесез!

*Шул вакытта болдырга Сания чыга.*

**Сания.** Менә, Имам, авылыбызның асыл кошлары килеп тә житкәннәр. Уңдагысы—Фәридә, сулдагысы—Әминә.

**Имам.** Жырда мактала торган исемнәр икән. Жыры гына истә калмаган менә... *(Башын кашып.)* Ничек соң әле?..

**Әминә.** Яныгызда басып торган кызның да исеме жырга кергән, анысын да белмисезме?

**Имам.** Менә, кызлар, сезне күргәч хәтерем чуалып китте бит әле...

**Сания.** Аларга әйт кенә—жырлап та күрсәтерләр сиңа, биеп тә күрсәтерләр.

**Имам.** Китсәнә!

**Сания.** Күрсәтегез әле кызлар минем кунакка безнең авыл кызлары икәнегезне!

**Фәридә.** Куй әле, Сания...

**Сания.** Минем чәем куелган, гаеп тапмыйк уеннан!

*Сания кызларның кулларыннан ала, Имамны уртада калдырып, жырлап-биеп әйләнәләр.*

> Сания апа суга бара,
> Яшел чиләген асып.
> Сандугачлар чут-чут сайрый,
> Көянтәсенә басып...
>
> Кая бардың, Сания апа,
> Кайдан кайтып киләсең?
> Гөлләр арасыннан узып,
> Гөлләр сыман көләсең...

**Сания.** Концерт бетте, хәзер чәйләп алабыз!

**Әминә.** Туктап тор, Сания. Без үзебезне күрсәттек, кунагын безгә кушылмады. Үзен күрсәтмәде.

**Имам.** Төшеп калганнардан түгел мин! Шире круг! *(Биеп китә.)*

*Имам ике төрле бию башкара. Башкалар кул чабып торалар.*

**Сания.** Житте! Күрдек сәләтеңне! Самавырым суына.

**Имам.** Суынсын! *(Кинәт биюнең өченче төрлесенә күчә.)*

**Фәридә белән Әминә:** —Булды! Сәләтеңне күрдек бит инде!

**Сания.** Күрдек, Имам, күрдек!

**Имам** *(биюдән туктап).* Нәрсә дисез?

**Хатыннар** *(бер-бер артлы).* Күрдек, сәләтеңне күрдек!

**Имам.** Мин күрсәтеп бетермәдем әле! *(Тагы да кызыбрак, сызгырып-сызгырып, табан асларына суга-суга, биюнең дүртенче төренә тотына.)*

**Фәридә.** Булдыра бу, булдыра!

**Имам** *(биеп Фәридә каршына*

*бара).* Их, әттәгенәсе! *(Фәридәне култыгыннан тотып бер әйләндереп ала да кинәт капкадан йөгереп чыгып китә.)*

Хатыннар аның артыннан карап беравык телсез калып торалар.

Сания. Китте бит бу! Чәй дә эчми китте!

Әминә. Шундый машина белән йөргән кеше синең чәеңә мохтаҗ ди!

Фәридә *(көлеп).* Ул китте, урын калды, әйдә үзебез эчәбез!

Сания. Гаҗәп булды, артыннан булса да карап калыйм әле... (Капкага бара.)

*Шул вакытта бер кулына аракы, икенчесенә нindидер төргәк тоткан Имам капкадан атылып керә, Сания белән чак бәрелешми калалар.*

Имам. Әйдәгез, бәйрәм итеп алабыз! *(Йөгереп өйгә кереп китә.)*

*Хатыннар чыр-чу килеп аның артыннан йөгерәләр.*

## 2

*Шул ук ишек алды. Җәйге өстәл артында Сания белән Фәридә чәй эчеп утыралар.*

Сания. Тәмлеме Имам калдырган чәй?

Фәридә. Чәе тәмле дә, үзе нишләп күренми, киләм дип киткәч?

Сания. Килмәве дә ихтимал бу ташландык авылга.

*Капкадан кергән Әминә боларның сүзләрен ишетеп кала.*

Әминә. Киләм, барыгызны да үзем карыйм дип шапырынган иде.

Фәридә. Ул иманга кайтырга йөрим дип тә шапырынды.

Әминә. Карале, моңа чаклы имансыз булды микән соң ул?

Сания. Ходай кичерсен инде, барыбыз да иманнан язып барабыз ахыры...

Әминә. Шундый машинада йөргән кеше шәһәрне ташлап, безнең ташландык авылда иман эзләп йөри, имеш!

Фәридә. Белмиләр юкса аңа нәрсә кирәген...

Әминә. Ахмаклар да инде үзебез! Балалар кайтып карамаганны, чит кешедән ни көтеп була?

Сания. Шәһәрдән туйдым, авылга килеп төпләнәм дип матур сайрады.

Фәридә. Теләсә нинди узгынчының матур сайраганын тыңлап яшәргә калдык инде.

Сания. Сайраучылары да гел килеп тормый. Олы юлы ерак бит аның.

*Машина килеп туктаганы ишетелә.*

Әминә. Әллә чынлап та килде инде?

Сания *(урыныннан торып).* Килде бит бу!

Фәридә *(тора).* Караучыбыз килде бит!

Әминә *(киерелеп, җайлабрак утыра, көлемсерәп).* Килүен килде дә... Карар микән соң? Әллә тагын Саниягә чәй генә калдырып китәрме?

Сания. Сиңа ниләр калдырып китәләр?

Фәридә. Ник? Ә былтыр?.. Завхоз-Микулай корбанга чалырга дип чучка китерде, чиелдатып Әминәнең абзарына кертте. Оныттыңмы?

*Имам керә, кулында сумка.*

Имам. Исәннәрме, минем аккошларым!

Сания. Мактап йөрисең икән. Сине дә искә алып чәй эчеп утырабыз.

Имам. Ничегрәк искә аласыз инде мине?

Фәридә. Тизрәк килеп житсен иде дип.

Имам. Онытмагач рәхмәт. Менә чәй янына шәһәр күчтәнәчләре. *(Сумкасыннан өстәлгә алып килгән нигъмәтләрен бушата.)*

Әминә. Әллә шаяртып кына киттеме дип тә уйлый башлаган идек.

Фәридә. Шаярта торган кеше түгел икәнсез.

Имам. Әйткән сүземнән чыккан кеше түгел мин.

Сания. Утыр, Имам. Үзеңә тәмле итеп чәй ясап җибәрәм. Егетлегең өчен. *(Чәй ясый.)*

Имам *(утыра һәм җырлап җибәрә):*

Рәхәтләнеп эчәбез!
Их чишмәгез, чишмәгез!
Чишмәгезне — тәмле суын
Миннән башка эчмәгез.

*Шул вакытта Микулай килеп керә. Бераз салмыш. Туп-туры өстәл янына килә.*

Микулай *(Имамга текәлеп карап).* Балдызлар, кайсыгыз кияүгә чыкты? *(Әминәгә.)* Синме?

Әминә *(шаяртып).* Әллә кияү ошамыймы? Минем үземә бик ошый.

Микулай. Ала-ай... Мин хәзер, мылтыкны алып керим әле...

*Микулай чыгып китә. Хатыннар да, Имам да беравык ис җыя алмый торалар.*

Әминә *(паузадан соң).* Атарга җыена түгелме соң бу?

Фәридә *(шелтә белән).* Уеннан уймак чыгарам дип уйламадыңмы?

Әминә. Качтык, егетләр! Чебен урынына кырып бетерәчәк ул хәзер безне.

*Әминә белән Фәридә урыннарыннан кубып бакча ягына йөгерәләр.*

Сания *(Имамны кулыннан тотып).* Әйдә минем белән мунчага!

*Алар житәкләшеп йөгереп чыгып китәләр. Бераздан кулына бер шешә көмешкә тоткан Микулай килеп керә. Беркемне дә күрмәгәч, аптырап, буш өстәлгә карап тора, тирә-якны күзәтә.*

Микулай. Болар кая киттеләр? Әминә! *(Пауза.)* Фәридә! *(Пауза.)* Сания! *(Пауза.)* Балдызлар-ялгызлар, кайда сез?!

*Сак кына Әминә керә. Микулайның кулында шешә генә күреп ала да, батыраеп янына бара.*

Әминә. Атмаска булдыңмыни, Микулай?

Микулай *(паузадан соң).* Ни дигән сүз инде бу тагын?

Әминә. Мылтыкка дип чыгып киткән идең бит.

Микулай. Сантый баш, кайчан миндә мылтык күргәнең бар?

Әминә. Ир кеше мылтык белән дә йөрер, ышанып булмый.

Микулай. Булды да ди, шуннан? Кеше атарга мин психбольницадан качып, адашып йөри торган кеше түгел бит әле. Сөйләп тә куясыз инде тегеләй!

Әминә *(кычкыра).* Фәридә! Сания!

*Фәридә, аннан Сания белән Имам күренәләр.*

Фәридә. Атмый әллә Микулай?

Әминә. Атмый, атмый, җүләр түгел бит ул көпә-көндез кеше атып йөрергә.

Сания. Үзебезгә ярдәм итеп йөргән иң якын кешебездән куркып качып ят инде!

Микулай (шешәне өстәлгә куя). Исемең ничек, кияү, әйдә утыр әле.

Имам *(куркыныч юклыгына төшенеп, тынычланып утыра).* Имам.

Микулай. Иман дисеңме?

Имам. Мин әле иманга кайтып кына барам.

Микулай. Кайдан кайтып барасың?

Сания. Зур эш белән йөри ул, Микулай.

Микулай. Нинди эш белән?

Имам. Шәһәрдән качам.

Микулай. Нигә качасың, кеше таладың әллә?

Имам. Шәһәр шавы туйдырды, шушы авылга килеп төпләнергә булдым.

Микулай. Бик дөрес уйлагансың. Искиткеч авыл иде бу. Чишмәләрекүлләре ни тора! Шәһәр йотты. Калдылар бит шушында ялгыз гөлләр кебек шушы өч хатын да берничә карт-коры. Әйдә шуның өчен минем сыйны кәгеп куябыз. Фәридә, йөгер суганга! Әминә, син минем гармунны сатмадыңмы әле?

Әминә. Кемгә сатыйм мин аны? Синнән башка гармун уйнаучы калмады бит монда.

Микулай. Бар, алып чык. *(Саниягә.)* Нәрсә катып торасың инде, чыгар стаканнарыңны, бәйрәм ясыйбыз! *(Әминәгә.)* Атны тугарып куй. Арбадагы печән астын кара. Өчегезгә булыр.

*Хатыннар китәләр.*

Имам. Керәшенме син, Микулай?

Микулай. Керәшеннең дә иң чистасы, менә шушы көмешкә шикелле. Ут төртәсең—яна, йөз градус!

Имам. Шушы авыл кешесеме?

Микулай. Күршедән, керәшен авылыннан. Шушы авылда бик якын дустым бар иде. Аны да шәһәр йотты, өе бикле тора. Завхуз мин. Үзең нинди

эш остасы?

Имам. Эшләмим мин.

Микулай. Урлашып яшисеңме әллә?

Имам. Пенсиядә.

Микулай. Бик яшь күренәсең бит?!

Имам. Хокук саклау органнарында эшләдем.

Микулай. Ә-ә... Сезне иртә браковать итәләр шул. Акчасын күп бирәләр икән, синеке шикелле машинага теләсә кем өмет итә алмый.

Сания *(өйдән кычкыра)*. Микулай, кер әле!

Микулай. Ни бар анда? *(Кереп китә.)*

*Гармун күтәреп Әминә, аның белән Фәридә керә. Ул кулындагы сумкадан өстәлгә бакча җимешләре бушата.*

Фәридә. Менә мондый кыярларны безнең авыл бакчасында гына үстереп була.

Имам. Аның өчен үстерүчесе дә оста булырга кирәк шул.

Әминә *(гармунны куя)*. Гомер буе җиргәберегеп яткач, остармый хәлең юк.

*Өйдән Микулай белән Сания чыгалар. Микулай рюмкалар тоткан, Саниянның кулында тәлинкә.*

Сания *(тәлинкәне өстәлгә куя)*. Мин тозлаган кыярдан да авыз итегез, гомер буена сагынып сөйләрсез.

Микулай. Анысы хак сүз, мактансаң да килешә.

Әминә. Әнә күр, Микулай, гармунның исән-сау.

Микулай *(рюмкаларга эчемлек салып чыккач)*. Күтәрдек, гармунның да, сезнең дә исән-сау булу хөрмәтенә.

Имам. Гафу итегез, миңа ярамый.

Микулай. Нигә ярамый?

Имам. Мин рульдә.

Микулай. Мин дә рульдә.

Әминә. Синең дилбегә генә шул. Ә кешенең шәһәргә кайтасы бар.

Микулай. Танышу хөрмәтенә ярый ул. Җибәрмибез бүген. Бәйрәм ясыйбыз, мунча ягабыз. Шулай ярыйсы буламы?

Хатыннар:—Әйе шул.

—Урын беткәнмени?

—Өендә хатыны ни уйлар?

Микулай. Хатыныңнан куркасыңмы әллә?

Имам. Хатын Мәскәүдә әле, җомга көнне генә кайта. Якшәмбе көнне сезнең авылны икәү карап китәргә сөйләштек.

Микулай. Шулай булгач, утырма сынатып... шушы гүзәлләрдән! Күтәрдек! *(Рюмкасын Имам белән чәкештерергә суза.)*

Имам. Әйдәгез булмаса, бергәлек өчен!

Микулай. Вәт егет ичмасам!

*Чәкештерәләр дә эчәләр.*

Имам. Бик зәһәр эчемлек бу. Батыр кызлар икәнсез.

Сания. Авыл эше өйрәтте.

Фәридә. Авылның авыр эше өйрәтте.

Әминә. Микулай өйрәтте диегез инде, күңеле булсын кешенең.

Микулай. Дөрес әйттең, Әминәкей. *(Имамга.)* Мин аларны дуңгыз ите ашарга да өйрәттем. Заманы шундый. Ашасыннар, ач ятмасыннар. Беләм мин, китап рөхсәт итә. *(Рюмкаларга сала.)* Тагын берне күтәрәбез! Закускага—татар биюе аралаш керәшен җыры. (*Чәкештереп эчәләр, ашыйлар.)*

Имам. Аракыга караганда шәбрәк бу.

Микулай. Аракы агу диләр, ә монысы—дару. Минем дуслар гына кыландыра белә шулай. Минем өчен бигрәк тә тырышалар. Завхоз мин! Сез, кызлар, ашау ягын кыскарак тотыгыз. Закускага татар биюе дигән идем.

Әминә. Без аны керәшен җырыннан башлыйк. Талантыңны беләбез, тавышыңны сагындык.

Имам. Керәшен җырларын яратам мин, тыңлаганым бар.

Микулай. Ә мин син тыңламаганны уйныйм. *(Уйнап, җырлый башлый.)*

Үзәннәрдә якты көннәр күрдек,
Көннәреннән, көннәреннән якты ла күл күрдек.
Көннәреннән, көннәреннән якты ла күл күрдек.
Түгәрәк күл генә—
Үрдәк өчен юл гына,
Юлың булса янәшәмдә
Кулларыңа кул гынам.

Күлләр күзе иде ике үрдәк,
Күлләр күзе, күлләр күзе икән лә пар үрдәк.

Кулләр күзе, кулләр күзе икән лә пар үрдәк.
Түгәрәк күл генә —
Үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,
Кулларыңа кул гынам.
Китәрме үрдәге,
Саргая ла камышы.
Камышларга җил киселә,
Жанга үтә тавышы.

**Имам** *(ул жырлап бетергәч)*. Синең белән янәшәдә яшәү күнеле булачак!

**Микулай**. Безнең белән моңача беркемнең дә кайгыга батып яшәгәне юк. Гади генә әйткәндә: дус-иш кирәк дөнья көтәргә.

**Әминә**. Без ярата торган теге матур жырны да уйнап күрсәт әле, Микулай.

**Микулай**. Сез яратмый торган жыр бармы соң ул? Кунак кешене ялкытып бетермибезме?

**Имам**. Мин танга чаклы тыңларга да риза.

**Микулай**. Минем бармаклар атна буе туктаусыз уйнасам да арый торган түгел. *(Уйнап жибәрә.)*

Кызлар жырлыйлар:

Иркәм, иркәм дигән булды,
Карады күзләремә.
Шикәр иде, ширбәт иде,
Бал иде сүзләрендә.

Ай иркәм,
Вай иркәм,
Яр сөяргә ашыкма да,
Соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәжәсенә
Төшеп югалма икән.

Иркәм, иркәм дигән булды,
Баш куйды иңнәремә.
Мәңге янар учак булып
Урнашты йөрәгемә.

Ай иркәм,
Вай иркәм,
Яр сөяргә ашыкма да,
Соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәжәсенә
Төшеп югалма икән.

Иркәм, иркәм дигәненә
Нигә ышандың диләр.
Өйләнде дә, хатынынnан
Инде бушамый диләр.

Ай иркәм,
Вай иркәм!
Яр сөяргә ашыкма да,
Соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәжәсенә
Төшеп югалма икән.

**Микулай** *(жыр бетүгә, Имамга)*. Йә ничек безнең сандугачлар тавышы?

**Имам**. Күнелем булды, рәхмәт.

**Микулай**. Син аларның ничек биегәннәрен күр әле! Әртистләрдән уздыра болар тотынсалар!

**Сания**. Алай ук мактама инде, Микулай.

**Микулай**. Мин кемнең ничек басканын чамалый торган гармунчы, белеп-күреп мактыйм. *(Уйнап жибәрә.)*

*Әминә урыныннан торып такмаклап бии башлый, ана башкалар кушылалар.*

**Әминә**.
Тыпыр-тыпыр биергә
Тимер идәннәр кирәк.
Тимер идәннәр өстенә
Хәтфә паласлар кирәк.

**Фәридә**.
Хәтфә паласлар өстенә
Имән өсталләр кирәк,
Имән өсталләр өстенә
Көмеш табаклар кирәк.

**Сания**.
Көмеш табаклар эченә
Хөрмә җимешләр кирәк.
Хөрмә җимешләр ашарга
Алтын кашыклар кирәк.

*Хатыннар жырына ирләр дә кушыла.*

**Бергә**.
Алтын кашыклар тотарга
Кара кашлы кыз кирәк.
Кара кашлы кыз янына
Батыр егетләр кирәк.

**Микулай** *(бию тәмамлануга)*. Авыл ташландык булса да, калган хатыннары менә шундый асыллар! Дөрес сөйлимме, балдызлар?

**Фәридә**. Безнең күнелне син генә мактап күтәрмәсәң инде...

**Имам**. Сезнең белән һәр көнне бәйрәм итеп яшәп була. Мин монда сөенеп кучәм.

**Сания**. Хатының риза булмаса?

**Имам**. Минсез ни эшли ала ул?

**Әминә**. Ир—баш, хатын—муен.

**Имам**. Мин үземнең тормышта баш та, муен да. Үзем судья, үзем прокурор, үзем адвокат.

**Микулай**. Егет булсаң шулай тиеш. Йә, балдызлар, ошадымы кунакның сүзләре?

**Сания**. Жанга жылы май булып ята.

**Микулай.** Алай булса, без себерке алып кайтабыз. Сез шәп итеп мунча ягып җибәрегез дә, кунакның аркасын ышкырга әзерләнә торыгыз.

**Сания.** Барыбыз бергә ышкырбызмы?

**Микулай.** Мин парлап торырмын, сез ышкырсыз.

**Фәридә.** Түзәрме соң?

**Микулай.** Ник түзмәсен, нык күренә бит.

**Әминә.** Кунак үзе ничек уйлый?

**Имам.** Түзәргә тырышырмын.

**Микулай** *(Имамның аркасына сугып).* Үзебезнең авыл егете икән син! Моңа чаклы кайда югалып йөрдең? Киттек әйдә!

*Ирләр чыгып китәләр. Машина кузгалып киткән тавыш.*

**3**

*Кич җиткән. Кызлар өстәл артында чәй янарталар.*

**Фәридә.** Озаклады әле болар.

**Сания.** Шәһәр кешесенә авыл мунчасы тансык ул. Онытмаслык булсын, йә кире уйлап куяр.

**Әминә.** Бер дә кире уйларга охшамаган әле. Күзәтеп утырдым, икегездән дә күзен алмый.

**Сания.** Хатыны бар шул аның.

**Фәридә.** Ә нигә ул барыгызны да карыйм ди, тел төбен анламадым.

**Әминә.** Шуны да анламагач инде...

**Сания.** Син нәрсә анладың?

**Әминә.** Барыгызга да яр булырмын димәкче була.

**Фәридә.** Кит әй, юк сүз сөйләмә, хатыны була торып...

**Әминә.** Хатыны тәүлек буена чалбар каешына тотынып йөрми торгандыр әле.

**Фәридә.** Оялтырмын дип тә уйламыйсың, Әминә.

**Әминә.** Оялып утырырга унҗиде яшьлек кыз түгел син.

**Сания.** Дөрес, без генә ир күрми картаерга дип пичәт басмаган әле.

**Әминә.** Үзебезнекеләр ташлап китәләр. Типтерәләрдер әле башка хатыннар белән.

**Фәридә.** Саниянеке типтерә район үзәгендә. Үзе складта, хатыны—сатучы.

**Әминә.** Син үзеңнеке турында бер дә сөйләгәнең юк, Фәридә.

**Фәридә.** Сөйләр җире булса бик сөйләр идем. *(Авыр сулап.)* Ишеттерделәр...

**Әминә.** Өйләнгәнме?

**Фәридә.** Каян өйләнсен инде ул? Шәһәрдә «бич» булып йөри ди. Шундый хуҗалыкны ташлап, бер тузган хатынга барып кер инде... Куып чыгарган... Менә хәзер йөри йортсыз-җирсез.

**Сания.** Кайтса кертер идеңме?

**Фәридә.** Бер «бич»лыкка өйрәнгәннәр авылга кире кайтып та тормыш итә алмый диләр. Гафу үтенеп кайтса кертер идем, билгеле...

**Сания.** Анда малаең янына кереп йөридер әле.

**Фәридә.** Керми ди, ояла торгандыр.

**Әминә.** Читәнгә элмәгән икәнне анлагандыр да бит...

**Фәридә.** Туй узгач биеп булмый...

*Мунчадан Микулай кайта.*

**Әминә.** Җиңел пар белән!

**Микулай.** Рәхмәт. Ну шәп булды! Җәннәт!

**Фәридә.** Кунакка ошадымы?

**Микулай.** Тагын бер-ике тапкыр чабынам дип калды.

**Сания.** Чабынсын, онытмаслык булсын.

**Микулай.** Онытырга җыенмый әле ул. Беләсезме, нәрсә ди?

**Сания.** Арка ышкырга йомшак кул юк диме?

**Микулай.** Риза булсалар, шул ялгыз хатыннарга өйләнеп торам ди.

**Әминә.** Мунча чыккач, боларга тагын бер ярты кирәк була инде.

**Сания.** Миндә бар. Аның өчен җәл түгел. Теге вакытта акча да алмый китте. Менә тагын килеп җитте.

**Фәридә.** Ул чакта бер биеп күрсәткәне өчен генә дә ике ярты куярлык. Анысы гына миндә дә бар. *(Җырлап җибәрә.)*

Алым җәл түгел сиңа,
Гөлем җәл түгел сиңа.
Алым түгел, гөлем түгел,
Җаным җәл түгел сиңа.

**Әминә.** Җырлап утырыр вакыт бетте. Мунчадан соң өлгерерсез. Әйдәгез, эшебезне карыйк.

Фәридә. Хатыны өстеннәнме?

Микулай. Шәригать законы буенча, көченнән килгән ир-атка берничә хатын белән яшәү дә гөнаһ түгел.

Сания. Кеше көләр.

Микулай. Коммунизм вакытында көләрләр иде. Ә без аны, төзергә акыл житмәгәч, булган кадәрен дә жимереп ташладык. Димәк, элеккечә яшәргә кала. Ә нәрсә, балдызлар, сез барыбер ялгызлар.

Фәридә. Бер хатыннан икенчесенә кунак булып йөри торган матур сайраучы гына түгел микән?

Микулай. Күрмисеңме нинди машинада йөргәнен?

Әминә. Машинасын бирәр иптәшеннән прокатка да алып тора ала бит әле ул.

Микулай. Хәзерге заманда кеше прокатка машина түгел, юл унгаенда хатынын да ышанып тапшырмый.

Фәридә. Бер танышым сөйләде. Шабашкага килгән бер әрмән, авылдагы кызга өйләнгән булып, үзе белән Мәскәүгә чаклы алып киткән. Билет алып киләм дип, Мәскәү вокзалынын бер почмагына сөяп киткән тегене. Сутка буена көткән теге мескен, ышанып. Билет та юк, әрмән дә.

Әминә. Безнен якта җәй буена яткан солдатларнын берсе дә яшәгән татар кызы белән кияү булып. Китәр вакытлары житкәч, алып барган вокзалга үзе белән. «Сине солдатлар белән кертмәсләр, яшереп алып керәбез, тын гына утыр» дип капчыкка тыгып авызын бәйләп куйган да үзе поездга утырып сызган.

Микулай. Сез әллә нинди шикләргә бирелә башладыгыз әле. Ул бит үзе монда килеп төпләнмәкче була, һәрберегезгә мал биреп, акча биреп торырга ниятли.

Фәридә. Андый нияте булса ярый да бит, кеше сүзе генә...

Микулай. Фәлән фәләнәвич өч хатын белән яши дип кешегә кычкырып йөрмәссез бит инде. Икенче яктан карaганда, монда кемгә кычкырасын? Әнә теге, бомба шартлаcа да юньләп ишетми торган әби-чәбигәме? Мәрфуга карчык иң атаклы сангырауны да уздыра. «Исәнме, әби!» дисән дә: «Бик рәхмәт, балам, бик мәслихәт» дип жавап бирә, балаларын үлеп бетте, дисән дә шулай ди.

Сания. Үзе ничегрәк сүз башлар икән бу турыда?

Микулай. Менә шуна мине илче итеп куйды да инде ике арага. Сезнен жавап ничек булыр?

Фәридә *(такмаклап)*:

Бөтенләй булмаган ише  
Булмас әле, булмас.  
Гомер үтеп барганда да  
Кирәк була юлдаш.

Сания *(такмаклап)*:

Буй житмәскә кулын сузар,  
Тиң түгел бу димәс.  
Хатыннарның күңелләре  
Мәңге иләс-миләс.

Микулай. Бик шәп! Янында бераз терәк, кинәшче булса, тормыш бөтенләй икенче төс ала бит ул.

Фәридә. Өч хатынны карарлык хәле бар микән?

Микулай. Булмаса сөйләмәс иде. Күченеп килгәч күренер.

*Мунчадан Имам кайта. Барысы да: «Жинел пар белән!» «Ошадымы мунча?»—дип каршы алалар.*

Имам *(такмаклап)*:  
Их, татар мунчасы,  
Көн дә шулай булсачы.  
Мунча яккан матурларга  
Йөрәгемә юл ачык.

Әле анда бөтен авылыгыз кереп чыгарлык суы да, эссесе дә калды.

Фәридә. Ярты авыл монда жыелган.

Сания. Без тиз генә коенып чыгабыз. Анача сез әйрән белән хушлана торасызмы, әллә чәйнен катырагын башлысызмы?

Имам. Дус-иштән качып чәкештерә торган гадәт юк. Үзегез чыккач бергәләп хәл итәрбез анысын.

Микулай. Әйдә утыр, Имам, балдызларның әйрәннәрен чөмереп алыйк әле!

*Имам белән Микулай өстәл янына утыралар. Микулай икесенә дә әйрән сала. Мунчага китеп барышлый кызлар туктыйлар да шат елмаеп борылып карыйлар.*

Фәридә. Егетләрдән бер жире ким түгел, әйеме, Сания?

Сания. Сокланып туярлык түгел.

Әминә. Ир күреп бөтенләй башыгызны югалттыгыз.

Сания. Ә без таптык дип торабыз.

Әминә. Судагы балык бит әле ул.

Фәридә. Безнең кармакка насыйп булуы ихтимал.

*Көлешәләр.*

Әминә. Әйдәгез инде, әйдәгез...

*Китәләр.*

Имам. Их, шундый тәмле әйрән авылда гына була шул!

Микулай. Шәһәрне макта да авылда тор дип юкка гына әйтмәгән инде борынгылар.

Имам. Син нигә һаман аларга балдызлар дисең?

Микулай. Алар бик озак ялгыз яшиләр инде. Килеп-килеп ярдәм иткән булам. Берсенең киртәсен төзәтәсең, берсенең коймасын дигәндәй... шулай, балдызлар дип шаярткан булып күнелләрен күтәрергә тырышам. Матур яңгырый бит!

Имам. Ә теге мәсьәләдә балдызларның кылын тарткалап карамадыңмы?

Микулай. Капшап карадым мин аларны.

Имам. Әһә, әле син шулаймы? Әминәне капшамаска кушкан идең үзең, минекеләргә өлгергәнсең. *(Көлешәләр.)*

Микулай. Синең теләгең тормышка ашар төсле.

Имам. Ул чагында хатынны гына ризалаштырырга кала икән. Ә синең хатын балдызларга ярдәм итеп йөрүеңә ничек карый соң?

Микулай. Ул да кызгана инде. Бер мәктәптә укыганнар бит алар. Көнләшеп тә куя.

Имам. Эшләр мин дигәнчә барып чыкса, беләсеңме нишлибез? Һәрберенә икешәр сыер, сарыклар, үрдәкләр, казлар алып бирәм. Умартачылык эшен җайга салып җибәрербез. Сиңа бер машина алабыз. Монда житештергәнне урнаштырып кына йөрерсең.

Микулай. Анысы минем кулдан килә торган эш. Хатын ризалашса, мин дә монда күчеп киләм. Вәт яшәп күрсәтәбез аннары!

Имам. Шунысын да уйлап куйдым әле мин. Монда күчеп яши башлагач, мәчет салдырам.

Микулай. Ун-унбиш кеше өченме?

Имам. Изге юлда ун-унбиш кеше дә житә. Үземнең дә гөнаһлар шактый җыелды. Иманга кайтырга вакыт житте дип уйлыйм.

Микулай. Гөнаһ кемдә генә юк инде ул... Салдыр әйдә! Мин үзебезнең чиркәүгә кайтып йөрермен, юллар бозылып торган чакларда мәчеткә генә керермен. Бөтенләй йөрмәсәң дә зыяны юк инде аның. Ә син ничек, үзең мулла буласыңмы?

Имам. Үзем инде... Укырга өйрәнеп киләм.

Микулай. Әйтәм аны теге вакытта, йөз грамм эчкәч, бисмилла пышылдап куйдың.

Имам. Бер йөз граммнан соң бер тапкыр бисмилла әйтә торган гадәт бар минем.

Микулай. Ике йөз грамм эчсәң?

Имам. Ике тапкыр.

Микулай. Өч йөз грамм эчсәң?

Имам. Өч тапкыр бисмилла әйтәм. Иманга кайтам. Хатын киңәш итте. Үзе мәчеткә йөри. Монда күчеп килгәч, бу хатыннарны да иманга кайтарам әле мин.

Микулай. Киңәш итеп әйтәм, ниятең изге булса да сак кылан алар белән.

Имам. Нигә?

Микулай. Аларның күнелләре тулы моң булса да, бер кызып китсәләр үзеннән иманыңны укыта башларлар. Әй, хатыннарның барысы да бер чамада инде ул. *(Гармунын ала, уйнап җибәрә.)*

Сандугачлар килеп сайрый
Безнең җир межасына.
Бер җырлап җибәрик әле,
Төкерик нужасына.

Имам.
Сандугачлар куныш сайрый
Урманда имәннәргә.
Җанны ярып бирер идем
Кадерне белгәннәргә.

*Мунчадан хатыннар кайталар.*

Хатыннар:
Агыйделгә басма салдым
Каенын сайлап кына.
Серләремне сөйләр идем
Кош булып сайрап кына.

*Пәрдә.*

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Шул ук декарация. Пәрдә ачылганда сәхнә буш. Тышта машна килеп туктаганы ишетелә. Имам белән Мәрьям керәләр.*

Имам. Менә шушы инде без яшисе йорт.

Мәрьям. Хуҗасы юкмыни?

Имам. Хуҗабикәсе бар. Әнисә исемле. Ике абыйсы шулай зур итеп салганнар заманында. Менә бу ишектән бер ягына керәсең, әнә тегендә, мунча ягыннан—икенчесенә.

Мәрьям. Без кайсы ягында яшәргә тиеш?

Имам. Менә шушы ягында. Бу ягы зуррак, ике бүлмәле. Йә, ничек, ошыймы авыл?

Мәрьям. Тирә-ягы искиткеч матур. Бу җирдән күчеп киткән кешеләрнең җаны юктыр. Монда безнең балалар ял итәргә кайтсалар, ис-акыллары китә инде.

Имам. Бушлай курорт диген син. Әле урманнарындагы җиләген, гөмбәләрен күрсәң! Җыючы да юк.

Мәрьям. Шәһәр сагындырыр инде.

Имам. Без квартирны сатмаган бит. Кайттың киллең. Машина кулда, ничек барып җитәргә дип изаланасы юк. Телисең икән, Мәскәүгә элдерт. Каян акча табарга дип баш кашып утырасы көнгә калган юк.

Мәрьям. Авыл эшенә өйрәнеп китә алырмынмы-юкмы, шунысы да борчый.

Имам. Аңлаттым мин сиңа, боерык биреп түр башында гына утырырсың. Татар китабы—күктән иңгән ул. Җиде хатын алырга рөхсәт итә. Ә болар икәү генә, синең белән өчәү.

Мәрьям. Аның каравы, син бер генә.

Имам. Мин кыенлыктан курыкмыйм. Синең җан тынычлыгы өчен, тәннәрең ватылмасын өчен тәмугка керергә дә риза.

Мәрьям. Җае туры килгәндә син анысын миннән сорап кермисеңдер инде, картым. Тик тәмугка түгел, оҗмахына.

Имам. Юк, Мәрьям, моңа чаклы күңелемдә син генә булдың.

Мәрьям. Валлаһимы?

Имам. Валлаһи!

Имам. Әгәр ялган булса, торган җиремдә җир йотсын, хатын-кыз чырае күрмим.

Мәрьям. Ышандым инде, ышандым.

Имам. Мин сине шәһәрдә калдырып качмыйм бит, тормышыңны җиңеләйтергә йөрим. Хуҗабикә булып утырырга күңелеңдә ризалык барын да сизенәм, гөлкәем.

Мәрьм. Ризалыгым да бар, көнләшеп тә куям.

Имам. Түр башында гына утырыйм дисәң, көнләшмисең инде. Алар—коллар, син—байбичә. *(Шаярып җырлап җибәрә.)*

Түр башында байбичә,  
Ефәк кия, бал эчә.  
Их коллары, коллары —  
Ут уйната коллары!  
Алла белән кояш кына  
Байбичәдән югары.

Сандугачка тал кирәк,  
Байбичәгә ял кирәк.  
Их коллары, коллары, —  
Ут уйната коллары!

Икәү:

Алла белән кояш кына  
Байбичәдән югары.

Шулай да артык очынып та китмә әле син.

Мәрьям. Ник алай дисең?

Имам. Алар синең кол булырга ризалашыр микән, менә бит эшнең катлаулы ягы кайда.

Мәрьям *(хатын-кыз үҗәтлеге белән).* Тырышырсың.

Имам. Тырышып та булдыра алмасам?

Мәрьям. Шуны да булдыра алмагач, син миңа ник кирәк?

Имам. Син миңа гел кирәк. *(Үзалдына.)* Сыер алсаң савасы бар, сарыкларын карыйсы бар, кош-котларга җим саласы, су ташып мунча ягасы... Авыр булса да, синең хакка булдырырга тырышырмын, гөлкәем.

Мәрьям. Кәйлә тотып таш ватарга әзерләнгән кеше шикелле сөйләнгән

буласың. Яшь чагында нинди идең?

Имам. Яшь чагында бит ул!

Мәрьям. Син әле махы бирә торган түгел. Үзенне картлар рәтенә кертергә ашыкма.

Имам. Синнән җылы сүз ишетсәм, җаннарыма ял булып китә.

Мәрьям. Ә тегеләрдән җылы сүз ишетсән—ни кыланырсың икән?

Имам. Менә син көнләшә дә башладың инде.

Мәрьям. Көнләшә дип... Бер дә көнегелгән хәл түгел бит.

Имам. Көнегерсең... Үзенне бердәнбер байбичә итеп күрә башлагач, алар синең тирәдә йөгергәләп йөри башлагач, барына да көнегерсең.

*Тырыс тоткан Сания кайтып җитә.*

Сания. Кунаклар килеп тә җиткәннәр икән. Исәнмесез! Мин җиләктә идем. Быел шулкадәр нык унган, җыеп бетерә торган түгел. (Тырысын өстәлгә куя.)

Имам. Минем хатыным Мәрьям була инде бу, Сания.

Мәрьям *(кул биреп)*. Исәнме, Сания...

Сания. Бик озак көттегезме?

Мәрьям. Без авыл тирәләрен карап йөрдек бераз, әле генә кердек.

Сания. Ошадымы сон?

Мәрьям. Бик ошады. Табигатькә еш чагабыз, тик мондый ямьле урынга очраган юк иде әле. Курортларга да алыштырырлык түгел.

Сания. Ташлап киттеләр бит шушындый оҗмахны. Без калдык. Башка җиргә җан тартмый. Шөкер, яшәп була әле.

Имам. Менә тагын ишәергә торабыз. Ходай насыйп әйләсә, киләчәктә гөрләп торыр әле бу авыл. Кайтырга теләгәннәр урын таба алмый интегерләр.

Мәрьям *(тырыска күз салып)*. Йә илаһым, шулай күп җыеп буламы?

Сания. Әле бер-ике сәгатькә генә кереп чыккан идем. Озаграк йөрсән, ун литрлы сөт чиләген тутырып кайту уен эш кенә. Авыз ит, Мәрьям, мин хәзер «ә» дигәнче чәй өлгертермен, үзегезнең яшәү урынына кереп күреп чыгыгыз, мин әйберләремне кече якка ташып куярмын. *(Ишекне ача.)* Әйдәгез...

Имам. Мин күрдем инде, таныштым, син карап чык, Мәрьям.

*Мәрьям Саниягә ияреп өйгә кереп китә. Капкада Фәридә күренә.*

Фәридә. Исәнмесез, килеп җиттегезме?

Имам. Сәлам, балдыз, килеп җиттек, калдырып булмас сезне ялгыз.

Фәридә *(өстәл янына килеп, тырыстан җиләк алып каба)*. Кай арада өлгергән бу Сания?

Имам *(җиләк каба)*. Бакча җиләге генә түгел шул инде бу.

Фәридә. Хатының да килдеме?

Имам. Өй белән танышырга кереп китте.

Фәридә. Ничек ниятләдегез инде?

Имам. Үзебез сөйләшкәнчә. Все на мази.

*Өйдән Мәрьям чыга.*

Имам. Таныш бул, Мәрьям, монысы Фәридә була инде. Күршедә генә яши.

*Хатыннар күрешәләр. Сания чыга.*

Сания. Чәй хәзер өлгерер. Монда гына әзерлимме, әллә өйгә керәбезме?

Мәрьям. Менә шушында агачлар арасында бик күңелле булыр. Бик сирәк эләгә торган романтика.

Сания. Янгыр яумаганда мондый романтика бездә иртәннән төнгә кадәр дәвам итә.

Мәрьям. Син кучтәнәчләрне алып кер, Имам.

Имам. Хәзер, балдыз...

Мәрьям. Нәрсә?

Имам. Гафу, гөлкәем, гафу... Мин сина сөйләгән яна дустым Микулай бу хатыннарны балдыз дип йөртә. Матур янгырый ди, шул искә төшеп ялгыш ычкынды.

Мәрьям. Алай булса гафу үтенеп торма, чыннан да матур янгырый.

Имам. Әллә мин дә сезне балдыз дип кенә йөртимме?

Мәрьям. Өчебезне дәме?

Имам. Әйе, кеше арасында гына, мода өчен. Ә сине, ялгыз калганда элеккечә, гөлкәем дип атармын.

Мәрьям. Чынлап та матур янгырый, мин каршы түгел.

*Сания белән Фәридә бер-беренә мәгънәле карашып, елмаеп куялар. Имам чыгып китә.*

Сания. Мин самавырны алып чыгам.

Фәридә. Булышыйм әле ана. *(Өйгә үтә.)*

*Имам сумка алып керә, аннан өстәлгә кучтәнәчләрен алып куя.*

Мәрьям. Гөлкәең балдызга өйләнеп куйды, ә?

Имам. Үпкәләдең, әллә, гөлкәем?

Мәрьям. Юк, юк, мина ошый. Балдыз—хатынга караганда яшьрәк тә була бит әле.

*Өйдән Сания самавыр, Фәридә подноста чынаяклар күтәреп чыгалар.*

Сания *(самавырны куя).* Утырышыгыз, безнең урман җиләге белән сыйланып алыгыз.

Имам. Йә, утырыгыз әле, бик җитди сүз бар. Шушы өстәл артында хәл итәргә кирәк аны. Бүген үк, хәзер үк. Калган эшкә кар ява. *(Хатыннар өстәл тирәли утырышалар.)* Мин сезне, балдызлар, хатынлыкка алырга булдым.

Сания *(белмәгәнгә салынып).* Безнеме?

Имам. Сезне.

Фәридә. Ә үз хатының?

Имам. Шәригать кушканча, үз хатыным—өлкән хатын була.

Фәридә. Ул ризамы?

Имам. Үзе әйтсен әнә...

Мәрьям. Асылда мин каршы түгел. Мәскәүгә киткән чакларымда минем Имамга күз-колак булып торырсыз. Ә монда чагында мин үзем барыгызга да күз-колак булып торырмын.

Сания. Өлкән хатын буларак, шулай булырга тиеш тә инде ул.

Мәрьям. Мин сездән бик өлкән түгел бугай әле.

Фәридә. Беренче хатын буларак, сез өлкән буласыз шул.

Мәрьям. Анысы шулай, акыллы фикер йөртәсез.

*Сания һәрберенә чәй өләшеп чыга.*

Сания. Бар булганыннан житешегез.

Имам. Менә шулай, һәрберегез үз урынын белеп яшәсә, мина зур хуҗалыкны алып бару җиңел булачак. Чөнки минем хатыным Канар утрауларына барып йөрергә дә ярата. Ә мондагы хуҗалыкны һәрвакыт тәртиптә тоту мәслихәт. Сез шуна каршы түгелме?

Сания. Безгә ул утрауларның киргәге дә юк. Җиләк, гөмбә җыя торган урманнарыбыз, печән чаба торган тугайларыбыз, йоклар урыннар бар.

Фәридә. Сирәк-мирәк шәһәргә барып килсәк, шул да җитә.

Имам. Анысы булыр, машина кулда.

Сания. Син безгә ничек өйләнмәкче буласың, ЗАГСта язылыпмы?

Имам. Юк, шәригать буенча. Иманга кайтабыз бит.

Фәридә. Мулла никах укырмы?

Имам. Үзем генә укырмын. Йә булмаса әнә Мәрьям укыр. Чын күңелдән булса, кем укыса да кабул әйләр Аллаһе Тәгалә.

Мәрьям. Сез миннән намаз укырга, дини сүрәләргә дә өйрәнерсез, хатыннар.

Сания, Фәридә *(икесе бергә)*: Өйрәнербез, өйрәнербез!

Имам. Мәсьәлә хәл ителде алайса, әйдәгез, бер дога кылыйк! Укып җибәр әле, Гөлкәем!

Мәрьям *(укый, калганнар кулларын күтәреп амин әйтергә әзер торалар).*

Әгузе-билләәһи-минәшшәйтаанир-раҗиим.
Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.
Әлхәмдү лилләәһи Раббилгәләмиин.
Әррахмәәнир-рахиим.
Мәәлики яүмид-диин.
Иййәкә нәгъбүдү вә иййәкә нәстәгыйн.
Иһдиинәс-сыйраталь мөстәкыйм.
Сыйратал-ләзиинә әнгәмтә гәләйһим,
гайрил мәгъзуби гәләйһим вәләд-дааллиии-н-ин.
Әмин.

## 5

*Шул ук урында кичкырын. Имам агачлар арасында утыра. Вакыйга—Имамнар күченеп яши башлаганнан соң. Үз ягыннан Сания күренә.*

Сания *(Имамны күреп).* Ник монаеп утырасың, Бөркетем?

Имам *(көйләп):*

Саниякәй, сандугачым,
Карлыгачым, гүзәлем.
Бер кич сине күрми торсам,
Өзелә бит үзәгем.

Сания. Өзелә микән?

Имам. Өзелә, Саниякәй, өзелә.

Сания *(бераз үпкәле).* Бер йортта яшәп мин сине төштә күргән шикелле генә күреп калам. Әллә кайларга китеп югаласың.

Имам. Шәһәргә эшләр белән йөрим бит, Саниякәй балдызым. Сезгә сыерлар, сарыклар белешеп кайттым. Иртәгә бер көтү төяп китерәләр.

Сания. Йә Хода, безнең бушап бетә язган абзарларга да маллар керер микәнни?

Имам. Маллар гына түгел, Саниякәй балдызым. Әле бал кортлары да белешеп йөрим.

Сания. Үзеңне ешрак күрсәм, малсыз яшәргә дә риза булыр идем шикелле.

Имам. Юк, Саниякәй балдызым, малсыз хуҗалык—җансыз хуҗалык бит ул.

Сания. Әллә син бүтәннәрне ныграк яратасынмы, Имам?

Имам. Юк, Саниякәй, мин сине ныграк яратам.

Сания. Ышандырам дисеңме?

Имам *(гәрәбә муенса чыгара).* Минем чын мәхәббәтем син. Бу шуның билгесе. Бу серне йөрәгеннең иң тирән почмагына салып куй. Муенсаны сандыгыңның иң тирән җиренә яшер, тегеләргә күрсәтмә. Икәү очрашкан кичләрдә генә киярсең.

Сания *(муенсаны ала).*

Аз гына күрми торсам да,
Тилмереп көтәм менә.
Үтсен иде һәр минутым
Гел синең белән генә.

Имам. Чәй әзер иде, балдызым. Бар кер, Мәрьям балдыз көтә торгандыр.

Сания. Минем янга ешрак керергә тырыш, бөркетем.

Имам. Гел сиңа гына омтылам, Саниякәй, тырышырмын.

*Сания кереп китә, капкада Фәридә күренә.*

Фәридә. Килеп життем, сине сагынып беттем.

Имам. Сине көтеп тора идем.

Фәридә. Син дә сагынып көтәсеңмени, Имам?

Имам *(көйләп):*

Фәридәкәй, сандугачым,
Карлыгачым, гүзәлем.
Бер кич сине күрми торсам,
Өзелә бит үзәгем.

Фәридә.

Рәхәтләнеп, ләззәтләнеп
Сиңа гына багалам.
Сиңа гына табынам мин,
Син бит алтын баганам.

Имам. Их, Фәридәкәй балдызым, сине очрату бәхетенә ирешмәсәм, бу дөньяда ничек көн итәр идем?

Фәридә. Шулай ык яраттың әллә, арысланым?

Имам. Төшләремә керәсең.

Фәридә. Миңа мондый татлы сүзләрне беркемнең дә әйткәне булмады. Канатлы кош сыман очып йөрисем килә.

Имам. Сине мактап җыр язсаң да лаек, балдызым-бердәнберем. Талант килсә, бәлки, яза да башлармын әле.

Фәридә. Күңел юату өчен генә шаяртмыйсыңмы, арысланым?

Имам *(гәрәбә муенса чыгара).* Зур мәхәббәтемнең билгесе итеп менә нинди бүләк алдым сиңа. Бу серне беркемгә дә чишмә. Күңелеңнең иң түренә, сандыгыңның иң тирән җиренә яшер. Тегеләр күрмәсен, икәү булган кичләрдә генә киярсең.

Фәридә. Рәхмәт, арысланым, моңа кадәр әле миңа берәүнең дә мондый бүләк биргәне юк иде. Иң зурысы—син үзең минем өчен, арысланым.

Имам. Синең өчен җаным да җәл түгел, Фәридәкәй-балдызым.

Фәридә. Сүзләрең балдан татлы.

Имам. Синең өчен, синең өчен генә балдызым.

Фәридә. Сине генә сөям дигән сүзләреңә ышандым хәзер.

Имам. Чәй әзер иде, көтәләрдер, керә тор, гүзәлем.

*Фәридә муенсаны яшерә дә, елмаеп, борылып карый-карый өйгә кереп китә.*

*Бераздан Микулай керә.*

Микулай. Нихәл, братуха? Менә... Килеп життем.

Имам. Мин көттем. Ничек анда?

Микулай. Бик начар.

Имам. Ничек... Начар?

Микулай. Әминәне ризалаттым. Хатынны күндереп булмады.

Имам. Нәрсә ди?

Микулай. Маржа бит. Гомер кичергән хатын, ташлап та булмый... Бәхетсез кеше икән мин... Барыйк әле Әминә янына, анда минем яна торган бар. Бераз кайгы-хәсрәт басылыр.

Имам. Бирешмә. Башын ялгыз калмаган бит әле. Әйдә сон... Мин дә бераз бушанып алырмын. Юкса бер көтү күгәрчен арасындагы песи шикелле йөрим. Кайсын тотып кимерергә дә белеп булмый, ә күз барына да майлана.

6

*Шул ук кичне бераз соңлабрак. Ихатада Мәрьям үзенә урын таба алмаган шикелле әрле-бирле йөренеп тора. Имам кайтып керә.*

Имам *(Мәрьямгә бераз карап торгач).* Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! *(Мәрьям ана арты белән борыла.)* Сина ни булды әле, нинди корт чакты? *(Анын янына бара, Мәрьям икенче жиргә күчә.)* Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Мәрьям *(үртәлеп, аңа борыла).* Әйе, аңлашылды!

Имам. Нәрсә? Мин, мәсәлән, берни дә аңламыйм әле.

Мәрьям. Ә мин аңлыйм!

Имам. Нәрсәне? Алайса тәфсилләп аңлат минем сантый башка.

Мәрьям. Тәфсилләп торасы юк. Ике тапкыр бисмилла: Саниядә бер стакан чүмереп чыккансың, Фәридәгә барып икенчесен.

Имам. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Өчне, хатын, әмма ләкин Микулай белән.

Мәрьям. Ышандырам дисенме?

Имам. Әминә күреп торды, барып сорый аласын.

Мәрьям. Ул Микулайда иман юк та юк инде.

Имам. Аның каравы яхшы күнеле бар. Минем дус.

Мәрьям. Иманга кайтучыны юлдан яздырып йөргәч, нинди дус була инде ул?

Имам. Кайтырбыз, хатын, кайтырбыз, бераз сабыр ит. Борчулар да күп бит әле соңгы вакытта. Үзен күреп торасын, кырыкка ярылырдай булып йөрим.

Мәрьям. Өч хатын арасындамы?

Имам. Килешеп эшләнде.

Мәрьям. Син үзен котырттын.

Имам. Котыртырга шайтан түгел мин, сине яратучы ирен.

Мәрьям. Тегеләрне күбрәк ярата-сын шикелле.

Имам. Юк шул, сине күбрәк яратам, балдызым-Мәрьямем!

Мәрьям. Шулай ук микән?

Имам. Исбат итимме, жанкисәккәем?

Мәрьям. Йә, итеп кара.

Имам. Киләсе якшәмбедә туган көненме?

Мәрьям. Шуннан ни?

Имам *(анын янына бара, кочаклап жырлый):*

Мәрьямем, сандугачым,
Карлыгачым, гүзәлем.
Бер кич сине күрми торсам,
Өзелә бит үзәгем.

Мәрьям *(ләззәтләнеп, эчкерсез, наз һәм горурлык белән).* Китсәнә, Имам, яшь чагындагы кебек кыланма әле. *(Читкә тартыла.)*

Имам. Тукта, тукта. *(Түш кесәсеннән гәрәбә муенса чыгара.)* Минем чын мәхәббәтем син генә. Бу гәрәбә муенса шуның билгесе. Бу серне йөрәгеннең иң ярешен түренә салып куй. Муенсаны сандыгынның иң түренә яшер. Тегеләргә күрсәтмә. Икәү булган кичләрдә генә киярсен.

Мәрьям *(муенсаны муенына аса).* Рәхмәт, картым! *(Жырлый.)*

Үбәрсең дә, кочарсың да,
Үзеңнеке үз булгач.
Жанга жылы, тәнгә рәхәт,
Сөям дигән сүз булгач.

Имам.

Әнкәсенә охшаш булыр
Сандугачның баласы.
Йөрәгемнең иң түрендә
Син мәңгегә каласың.

*Җәйге иртә. Шул ук урын. Тышта машина тавышы. Имам керә. Өйдән Мәрьям чыга.*

Мәрьям. Шундый каты йоклаганмын, син торып киткәнне дә тоймадым.

Имам (көйләп):

Сандугачка тал кирәк,
Байбичәгә ял кирәк.
Их, коллары, коллары, —
Ут уйната куллары!
Алла белән кояш кына
Байбичәдән югары.

Мин бит, хатынкаем, йокың татлы булсын, син уянмасын өчен аяк очларына гына басып йөрдем.

Мәрьям. Очып йөрдем дисәң дә ышанам.Сания белән Фәридә тәэсиреде бу. Нык үзгәрдең.

Имам. Кайсы якка?

Мәрьям. Унай якка *(Шаярып көйли.)*:

Җырлап кына йөрүләрең,
Кара таңнан торуларың,
Гел балкып елмаюларың —
Шуны сөйли, Имамым, кадерлем.

Имам. Элек тә җырлый идем, акыллым, синең күңелне күтәрү өчен. Хәзер—сез күбәйгәч, эшем артты. Шуңа кара таңнан торам. Синең ярдәмчеләрең бар. Мин үз эшемдә берьялгызым. Иннәремдә өч фәрештә. Яхшылыгымны язып йөриләр.

Мәрьям *(көлеп)*. Индә ике генә фәрештә була. Иманга кайтам дип йөрисең, шуны да белмисең. Ул фәрештәләрнең берсе яхшылыкны яза.

Имам. Начарлык язучы фәрештәгә минем индә, Микулай әйтмешли, ничу делать хәзер *(шаярып көйли)*:

Җырлап кына йөрүләрем,
Кара таңнан торуларым,
Гел балкып елмаюларым —
Шуны сөйли, Мәрьямем, кадерлем!

Мәрьям.

Агыйделгә басма салдым,
Басма салдым киң итеп.
Мин сине сөйдем тиң итеп,
Син калдырма ким итеп.

## 7

Мәрьям.

Рәхәтләнеп тыңлыймын да,
Карыймын да күзләреңә,
Ышанам да сүзләреңә,
Ышанмыйм да, Имамым, кадерлем!

Имам. Ышан миңа, бердәнберем!

Мәрьям. Има-ам?! Ничек инде... Бердәнберем?

Имам. Ярый, алайса, өчтән берем. Әйт дөресен, тынычлансын күңелем, канәгатьме син ярдәмчеләреңнән?

Мәрьям. Дөресен генә әйтимме?

Имам. Чын дөресен әйт.

Мәрьям. Әгәр мин канәгать булмасам, аларны аерасыңмы?

Имам *(башын иеп, чигәләрен тотып)*. Авыр сорау бирдең. Син мине уйга салдың. Юк, утка салдың. Юк, юк, суга батырдың. Сулый алмый торам.

Мәрьям. *(Имамның иягеннән тотып башын күтәртә)*. Күтәр акыллы башыңны, син мине бөтен эштән коткардың. Бүген дә иртүк килеп життеләр. Синең шикелле аяк очларына гына басып үттеләр. Малларны кырга чыгардылар. Фәридә каз-үрдәкләрне күлгә куа китте. Кайтып та житәр инде. Иртәнге аш белән мәшәкатьләнмә, хәзер килеп үзебез әзерлибез диделәр. Иртәгә бәйрәмен дип шатланып-шатланып йөриләр.

Имам *(шатланып)*:

Ал итәсе бар икән,
Гөл итәсе бар икән.
Кайгы-хәсрәт күрми генә
Көн итәсе бар икән.

Мәрьям.

Ал итә-итә генә,
Гөл итә-итә генә,
Рәхәт икән яшәүләре
Ял итә-итә генә.

## 8

*Шул ук урында Әнисә, Фәридә өстәл әзерләп, Мәрьямнең туган көне мәҗлесенә әзерләнеп йөриләр. Әминә керә.*

Әминә. Исәнмесез, кызлар! Үзегез генәмени?

Сания. Районда алар. Баерга киттеләр. Кайтып җитәрләр инде.

Әминә. Яхшы хуҗага тап булдыгыз.

Фәридә. Зарланып булмый инде. Бу киемнәрне каян алыр идек ул булмаса?

Сания. Менә чаклы да хәерче чикмәне киеп йөрмәдек әле.

Әминә. Аның каравы, сез бүгеннән яшь егеткә тотып бирерлек күренәсез.

Сания. Безгә яшьләр кирәкми.

Фәридә. Алар болай киендерә алмаслар иде.

Сания. Эш киемдә генә түгел, таянырлык, ышанырлык кеше кирәк бит.

Әминә. Микулайга таянып яшәдек бит әле.

Фәридә. Бер Микулайга да авыр булгандыр.

Әминә. Зарланганы юк ла...

Сания. Хәзер инде иш янына—куш булды.

Әминә. Күктән төшкән бәхет инде бу сезгә.

Фәридә. Без бәхеткә лаек түгелме әллә?

Сания. Шайтан котыртып, шәһәргә кире таймасалар гына инде.

Фәридә. Миннән таярга ошамаган әле. Үлеп ярата.

Сания. Мине дә үлеп ярата ул.

Фәридә. Ә шулай да мине күбрәк ярата.

Әминә. Юк, мине!

Фәридә. Юк, мине!

Әминә. Туктагыз әле, нигә бәхәсләшәсез? Бәлки, шәһәрдән килгән хатынын күбрәк яратадыр?

Фәридә. Мине күбрәк ярата!

Әминә. Каян беләсең?

Фәридә. Сере бар. Колагыңа сөйлимме? Әйдәле! *(Әминәне читкә алып китә, гәрәбә муенсаны күрсәтеп аңа нидер сөйли.)* Ышандыңмы инде?

Әминә. Ышандым да, юк та.

Сания. Ышанмавың дөрес. Чөнки Имам мине күбрәк ярата.

Әминә. Каян беләсең аны?

Сания. Кил әле... *(аны читкә алып китә, муенсаны күрсәтеп колагына нидер сөйли.)* Ышандыңмы мина?

*Әминә кычкырып көлә башлый. Фәридә белән Сания югалып калалар.*

Сания. Нигә көләсең?

Фәридә. Нинди кызык таптың?

Әминә. Ахирәтләрем, икегез дә муенсаларыгызны асып куегыз әле.

*(Фәридә белән Әнисә бер-беренә карап катып калалар. Әминә алар янына барып муенсаларын ала да муеннарына асып куя.)* Тиләләр икән сез! Икегезне дә бертигез ярата икән бит ул!

*Гармун тотып Микулай керә.*

Микулай. Их, карасана ничек матур киенгәннәр! Болындагы гөлләр шикелле! *(Уйнап җибәрә.)*

Хатыннар *(такмак әйтеп бииләр)*:

> Син уйнаган чакта, дустым,
> Сандугач көнләшерлек.
> Сагышланып йөргәннәр дә
> Җырлашып-гөрләшерлек.
> Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
> Уздырыйк гомерләрне.

Әминә *(биеп туктагач)*. Ә син бу гөлләрнең муеннарын күр әле, Микулай?

Микулай *(игътибар белән кызларны күзләп)*. Аларның муеннарына ни булган?

Әминә. Бер үзгәреш тә сизмисеңме?

Микулай. Муен тек муен! Синекеннән артык түгел.

Әминә. Минем муенда гәрәбә муенса юк бит.

Микулай. Аның каравы, минем иреннәрнең эзе бар.

*Көлешеп алалар.*

Фәридә. Вәт, Микулай, әйт шулай!

Сания. Моңга оста, телгә оста, үзебезнең Микулай!

Әминә *(Микулайны култыклап)*. Үземнең Микулай бит ул!

*Имам белән Мәрьям кайтып керәләр.*

Микулай. Бездә элгәре хужалар кунакларны көтә иде. Хәзер кунаклар хужаларны көтә.

Мәрьям. Шәһәрдән үк урап кайттык. Синең туган көндә башкаларга да өлеш чыгармасак, күңелләре кителер дигән нәтиҗәгә килде Имам.

Имам *(сумкасындагы төргәкләрне берәм-берәм алып өләшә башлый).* Монысы сиңа, Фәридә. *(Пауза.)* Микулай гаепләмәс, монысы сиңа, Әминә.

*Мәрьям игътибар белән Фәриденең һәм Санияның муенсаларына карый. Аннары, шикләнеп, Имамга күз ташлап ала.*

Мәрьям. Беләсезме, Имам минем туган көнгә нәрсә бүләк итте?

Барысы да *(берәм-берәм)*:

—Нәрсә?

—Яле күрсәт!

Микулай. Сезнеке ише бүләкләр генә түгелдер инде.

*Ул арада Мәрьям Имам биргән муенсаны алып килә. Муенына тагып куя.*

Микулай. Кара! Өчесендә бертөрле муенса!

Әминә. Димәк, Имам өчесен дә тигез ярата!

Хатыннар (бергә). Өче-без-не дә!

Микулай. Их-ма! Имам, егет икәнсең! *(Микулай гармун уйнап җибәрә. Хатыннар җырлап Имам тирәли биеп әйләнәләр. Әминә Микулай тирәли җырлап-биеп йөри башлый.)*

Сары-сары гәрәбә,
Ярдан түбән тәгәрә,
Су буенда калтыра,
Йолдыз булып ялтыра.
Сары-сары гәрәбә —
Югалмасын әрәмгә,
Нәрсә икән уенда?
Муенса, муенса,
Ямьле инеш буенда.
Гәрәбәсе муенда ла,
Нәрсә икән уенда?

Микулай *(уйнаудан туктап).* Җәмәгать, өстәл артына утырып Мәрьям хөрмәтенә бер йөз грамм җибәрик әле!

Мәрьям. Безнең өстәлдә аракы юк бит.

Микулай. Нишләп?

Мәрьям. Мин эчмим.

Сания белән Фәридә. Без эчмибез.

Микулай *(Имамга).* Әйткән идең, боларны тәки иманга кайтаргансың!

Имам. Мин түгел, Мәрьям.

Микулай. Минем йөз граммлык шатлыгым бар иде бит. Бу авылны тагы да зурайту исәбе белән бирегә күчеп килергә булдым. Хатын да ризалашты.

Әминә. Синең өчен табарбыз!

*Сәхнә караңгылана. Өйдә бәйрәм шавы ишетелә. Авансценада—Имам.*

Имам. Печәнлеккә менеп, болардан башка гына бүген бер рәхәтләнеп йоклыйм әле. *(Китә.)*

## 9

*Икенче көнне иртә белән. Өйдән Мәрьям чыга. Рәхәтләнеп бер киерелеп, иснәп ала. Физзарядка ясый башлый. Фәридә килә.*

Фәридә. Хәерле иртә, Мәрьям!

Мәрьям *(елмаеп).* Хәерле иртә! Әллә бәйләп калдырдыңмы?

Фәридә *(аңлап житкерми).* Нәрсә?

Мәрьям. Имамны әйтәм, әллә караватыңа бәйләп калдырдыңмы? Бик иртә тора иде.

Фәридә. Төнлә ул минем янда булмады. Кичтән әйтте, төнгә Саниягә керәм, үпкәләмәссең, Фәридәм, диде. Аллам сакласын, юкка үпкәләп тораммы? Сания янында ул, шунда.

Мәрьям. Миңа ул бу төндә Фәридәдә булырмын дигән иде.

Фәридә *(Санияне күреп).* Әнә Саниябез килә!

*Сания керә.*

Сания. Хәерле иртә, ахирәтләрем!

Фәридә. Хәерле иртә! Имамны катырак йоклаттың. Иртүк аякта була торган кеше бүген уянмыйгынамы?

Сания *(көлә-көлә).* Йокласын. Шундый зур бәйрәмнән соң...

Мәрьям *(бармакларын уйнатып).* Уятырга иде, кети-кети итеп.

*Бар да көлешәләр.*

Сания *(бармакларын уйнатып)*. Менә шулай бармакларың белән эченә кагылсаң, урыныннан түшәмгә кадәр сикерә.

Мәрьям белән Фәридә көлешәләр:

—Әйе шул.

—Ну сикерә!

*Көлешәләр.*

Сания. Ә бу төндә Имам миндә булмады. Кичә әйтте, Мәрьямнең бәйрәме, диде. Аны ялгыз калдыру сезгә дә, мина да килешмәс, мин аның янында булырмын, үпкәләмәссеңме, Саниям, диде. Бигрәк тәмле телле шул, бәгырькәем.

Фәридә. Шулай шул.

Фәридә һәм Сания *(шаярып, Мәрьямне үртәбрәк)*:

Әйе, әйе, шулай шул,
Бигрәк тәмле телле шул.
Синнән качып машинада
Йоклый торгандыр ла ул.

Мәрьям тышка йөгерә.

Сания. Тапты бит!

Фәридә. Таптык диген!

*Мәрьям әйләнеп тә керә.*

Мәрьям. Машинасы да юк! Әллә тәмле теле белән бергә башын йоттыгызмы Имамның?

Фәридә һәм Сания:

—Тфү, тфү!

—Авызыңнан жил алсын, Мәрьям, мондый сүзне!

*Бу сөйләшүне ишетеп Әминә килә.*

—Жил алсын мондый сүзенне.

—Аның башы барыбызга да кадерле.

Мәрьям. Кая соң... Аның башы! Кая машинасы?

Әминә *(үзалдына)*. Тү-түт микәнни, Ходаем...

Фәридә. Шәһәргә киткән.

Мәрьям *(елар хәлдә)*. Мине авылга ташлап...

Әминә *(Мәрьямгә)*. Ялгыз түгелсең ич.

*Тышта машина тавышы.*

Сания. Кайтты бит!

Фәридә. Кайтты!

Әминә *(залга)*. Машина Микулайда иде. Кичә төнлә хатыны янына ашыкты.

Мәрьям *(шатланып жырлап жибәрә)*:

Кайтты бит ул, табылды.
Жырлап алабыз каршы.
Яшәсен аның башы да,
Яшәсен машинасы!

*Хатын-кызлар жырлаган көйгә гармун уйнап Микулай керә.*

Хатыннар:

—Имам кая?

—Кая Имам?

Микулай *(аларны ишетмәгән дә кебек жырлап жибәрә)*:

Табылуы да яхшы,
Табылмавы да яхшы.
Минем кулда машинасы,
Сезнең кулдадыр башы.

*Шул вакытта өстендәге печәннәрне каккалап Имам керә.*

Имам. Башым әлегә үз жилкәмдә. Балдызлар, ялгыш йоклап киткәнмен.

*Хатыннар Имам янына жыелалар.*

Мәрьям *(Имамны иркәләп)*. Менә бит ул, башы исән-сау!

Сания *(Имамны иркәләп)*. Миннән качып йоклаган.

Фәридә *(иркәләп)*. Исән-сау минем бәгырем...

*Әминә рәхәтләнеп көлә-көлә Микулай янына бара.*

Микулай. Нигә көләсең?

Әминә *(Имамга күрсәтеп)*. Мескенкәй качап йоклаган... Хәле беткән...

Микулай. Булыр, шундый зур бәйрәмнән соң... Гаеп түгел.

Имам *(аларның сүзләрен ишетеп)*. Минемме? Минем хәлем беткәнме? Уйна, Микулай! Шире круг!

*Имам беренче пәрдә башындагы биюен башкара.*

*Пәрдә.*



Идият
Аширов

# БАРДАМДА—БАСУ КАПКАСЫ

## Кычытканнар

Кешеләре киткән, авыл беткән.
Урыны гына ята каралып.
Кычытканнар тора еламсырап,
Нигез ташларына сарылып.

Кычытканнар исән, ни хәлдә дә
Нигезләрен ташлап китмәгән.
Үз кадерен белеп яшәгәнне
Туган туфрак ятим итмәгән.

Туган җиргә тугры кычытканнар
Азмы бала чакта елаткан.
Кычытканнан чагылып үткән еллар
Бәхетлерәк булган күп яктан.

Кычытканнар! Әрсез кычытканнар!
Шифалы да, усал, хәтәр дә...
Беткән авыл рухын саклап торган
Кычытканнар китмәс хәтердән.

## Йөрәкне уйлар талый

Җәйге авыл. Урам тып-тын.
Бу хәл соң кемгә ярый.
Шау-гөр киләсе балалар,
Чабып йөрисе малайлар
Өйдә «боевик» карый.

Идият АШИРОВ (1947)—*шагыйрь; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ике шигырь китабы авторы. Пермь өлкәсенең Барда район үзәгендә яши.*

Чәчелмичә калган кырлар...
Кемнәр тикшергән, карый,
Сыер савасы апалар,
Иген игәсе агайлар
Ачы язмышын каргый.

Һәр йорт аша ялгыз карчык,
Күзләре моңсу карый.
Таза-сау чагын сагынып,
Бары ходайга табынып,
Калган гомерен саный.

Җәйге авыл. Урам тып-тын.
Чәчләрне җилләр тарый.
Җилләр түгел, шушы халәт,
Авыл кешеләрен җәлләп,
Йөрәкне уйлар талый!

## Кайтам әле

Кайтам әле туган авылыма.
Монда минем тәүге эзләрем.
Туганнарның, күрше-күләннәрнең
Күреп килим нурлы йөзләрен.

Кайтам әле, авыл картларының
Ишетим әле киңәш сүзләрен.
Иртә киткән әткәй-әнкәйләрнең
Күргән төсле булыйм үзләрен.

Кайтам әле, яшьлек кенә бары
Ничек узган, кайчан? Сизмәдем.
Миләш-баланнарда кызыл тәлгәш.
Көтеп тора инде күзләрем.

Язмыш җиле кая ташласа да
Кайтырмын мин барыбер, түзмәмен,
Кендек каным тамган туган җирне
Сагынып яшәүләрдән бизмәмен.

## Искә төшә әнкәй сүзләре

Әйтә торган идең: «Өлкәннәргә
Авыр сүз әйтмәгез, балалар!..»
Шул сүзләрең, әнкәй, бүгенгедәй
Җанга кагылып-кагылып алалар.

Әйе, киңәшеңне тотмаганбыз.
Калдырганбыз картлар хәтерен:
Гаепләп йә ватып кичәгене,
Җайлап әйтәлмичә әйтерен...

Намус беткән, әхлак зәгыйфьләнгән,
Имансызлар арткан заманда
Кем гаепле? дигән кискен сорау
Борчып тора шуңа һаман да.

Нинди булыр бездән соңгы буын,
Аңларлармы кеше кадерен?
Тәрбияләп, соңгы юлга озаткач,
Зиярәт кылырлармы каберен?

«Өлкәннәрне берүк рәнҗетмәгез!»—
Искә төшә әнкәй сүзләре...
Шушы сүзне әйткән әнкәйләрнең
Кадерләдек микән үзләрен?

## Басу капкасы

Еш кайтыла хәтер буйлап
Үткәнгә—малай чакка.
Килә дә баса күз алга
Авыл башы... Зур капка.

Гади нәрсәләр, югыйсә:
Усак киртә, җил капка...—
Тотып тора мал-туарны
Җибәрми басу якка...

Акыллырак булган картлар:
Күңеле саф, кулы алтын.
Яшәгәннәр, көрәшкәннәр
Аңлап чын икмәк хакын.

Җаным сыкрый күреп бүген
Тапталган иген кырын,
Һәм сагынып куям авылның
Басу капкалы чорын.

* * *

Гомер кыска... Китә тора
Ил карты—ветераннар.
Тарих битләренә күчкән
Алар көрәшкән таңнар.

Гомер кыска... Китә тора
Яшь кенә егет-җаннар.
Чечня җирендә ни өчен
Кан койганын кем аңлар?!

Гомер кыска... Бер сәбәпсез
Түгелмәс иде каннар,
Ут эчендә корал тотып
Сугышмый түрә-җаннар...

* * *

Бездә шундый тәртип: югарыда
Утыручы Илбаш агалар
Көн аралаш закон чыгаралар,
Указ арты указ язалар.

Менә берсе, безгә кагылганы—
Җирле реформалар буласы:
Авыл түгел, поселение булып
Кирәк булыр яшәп каласы.

Сельсоветлар түгел, үзәк булыр
(Бу этапны узган идек бер).
Киңәш итү дә юк, аңлашу да,
Халык өчен, имеш, барыбер.

Үзәк күчкәч, мәктәп, ясле беткәч,
Яшьләр китәр, нигез таралыр,
Киткәннәрдән бары ядкәр булып
Зыярат калыр, хәтер, моң калыр.

Вәриз, Толач, Кордак, Күчтәнти баш...—
Тагын күпме бетеп калырбыз?!
Еллар үткәч, беткән авылларда
Сабантуйлар ясап алырбыз(!)...

Бездә шундый тәртип. Нәтиҗәсен
Уйлап бетермәүдә хатабыз:
Чит үрнәкләр күреп кайтабыз да,
Үзебезчә җимереп ятабыз.

## Җитмәү

*«Җитми»ләрне җиткерергә*
*Вакыт җитеп бетми...*
Фәнис Яруллин

Табигатьтә бары да җитеш,
Күпне өмет итми.
Кешеләргә генә җирдә
Гел нәрсәдер җитми.

Кемнәргәдер эчәр суы,
Йә икмәге җитми.
Саф һавалы туган ягы
Истән чыгып бетми.

Кемгә акча, кемгә чүпрәк,
Кемгәдер җир җитми...
Качак булып куылулар,
Кан коюлар бетми.

Ил башында торганнарга
Уйлап эшләү җитми.
Адым саен ялгышулар...—
Башка сыеп бетми.

Үрнәк гаиләләрдә дә
Нидер җитеп бетми:
Әти-әниле «ятимнәр»
Күз алдыннан китми...

Җитми акыл, җитми намус...—
Бик күп нәрсә җитми...
«Җитми»ләр җитәр иде дә...—
Кеше булу җитми.

♣



Ркаил
ЗӘЙДУЛЛА

## КЫЗ-ХАТЫН

Ул аяк очына гына басып кабинетына чыкты. Чыгар алдыннан борылып йокы бүлмәсенә күз салды. Тәрәзәдән төшкән электр яктысында, бар нәрсә мондагы караңгылык белән буталып, әйле-шәйле күренә иде. Киң караватның бер ягында хатыны мыш-мыш килеп йоклап ята. Янәшәдәге тумбочка өстендәге кырлы стаканга ясалма теш казналыгын салып куйган. Ул аның хәтта саргылт төсен дә аергандай булды. Миллион ел элек яшәгән мамонт тешенең кыйпылчыгымыни...

Кабинетта да утны кабызып тормады. Ул монда күзен йомган килеш тә йөри ала. Менә стенаны каплаган китап киштәләре, менә зур өстәл, култыксалы урындык... телефон...

"Сондыр инде хәзер,—дип уйлады ул.—Унмы икән, унбер үкме?.." Шулай да имән бармагы гасабиланып телефон төймәләренә баскалады. Озын-озак гудок...

Колагында чыңлады: озак-озак-озак...

Ул аксыл сирәк чәчен артка сыпырды. Уч төбе юпь-юеш иде.

Ниһаять төрепкәдә хатын-кыз тавышы ишетелде:

—Алло?..

—Венера...

—Кем бу?

—Альберт...—Тамак төбендәге төерне йотып җибәрергә теләде... тавышы өзелде. Алай да үз-үзен тиз кулга алды.—Марленович,—дигәндә тавыш элекке халәтенә кайтып, шактый ук көр яңгырады.—Мин бу, Венера, Альберт Марленович... Гафу ит шулай соң борчыганга...

Төрепкә эндәшмәде.

—Венера!

Кайдадыр шәһәрнең теге ягындагы хатын тиз-тиз берничә җөмлә ыргытты:

—Мин әйттем бит инде сезгә. Иртә дә, соң да борчымагыз. Неужели сез берни дә аңламадыгыз?!

Кыска-кыска гудоклар нәни чүкеч кебек гүя баш миен чүки. Альберт Марленович өстәл өстендәге күзлеген алып киде. Култыксадагы агарып күренгән бармакларына сәерсенеп карап торды. Эчтәге нindidер кайнар дулкын муен тамырларын бүрттереп башына менеп житте.

Ул... Ул... Кем дип белә ул аны? Аны—Альберт Марленович Нагаевны! Профессор Нагаевны! Кем ул, ә? аның белән шулай тәкәллефсез сөйләшергә?

Шлюха!

Сөйрәлчек...

Монарчы бер генә кыз-хатын да шулай дорфа рәвештә Альберт Марленовичның сүзен жиргә екканы юк иде әле.

“Картайдым микәнни? Гомер үтте дәме?”—Эче өшеп китте. Кыз-хатын мәче белән бер бит ул—андыйны бик тиз сизә.

Корсак тирәсендә янә кайнар дулкын пәйда булды. Юк... Ул әле дулкын түгел... гүя бер йомарлам ут... Хәзер анардан өскә таба дулкыннар тарала башлар. Нагаев үзе дә анламастан кулына каләм алды. Аннары корт чаккандай аны өстәлгә ташлады. Чынк! итте каләм, өстәл өстендәге калын пыяла зенләп куйгандай булды.

Венера бүләк иткән иде бит аны.

—Алтын каләм...—диде.—Язганнарын да алтын бәһасенә торсын.

—Минем язганнарым бәһасез,—диде Нагаев.

Ияген өскә чөеп—ә ияге анын шундый йомры, матур!—нинди көлгән иде Венера.

—Нигә көләсен?

—Ирләр үзләре турында бик югары фикердә...

—Үзебез мактанмасак, безне кем мактар?

—Мин сине мактыйм...—Венера тагын бер сәбәпсез көлде.

Нагаев аңа игътибар белән карады. Сумаладай кара чәченен чугы үсмерләрнекечә маңгаена төшкән, кыйгач кашлары каядыр ике якка ашкына... чем-кара күзләренен төпкеленә сизелер-сизелмәс көлемсерәү яшеренгән. Курнос борынынын яфраклары дерелдәп куйганда Нагаевнын карт йөрәге әллә нишләп китә, шайтан алгыры! Кечкенә авыз, сусыл иреннәр—гүя ул салам кабып затлы коктейль йотарга гына яратылган... Ни белә Нагаев бу кыз-хатын турында?

Сораштырып караган иде ул, әлбәттә... кылларын тарткалап, кем әйтмешли.

Венера тагын чыркылдады гына.

—Казна эшендә түгел...—дип куйды.—Минем дә сезнеке кебек ижади эш... Кешеләрнен психологиясе белән кызыксынам.

—Син Зоя Космодемьянская сыман икән...—Нагаев үпкәләгән сыман кыланды.—Ул да бит дошманнарга чын исемен әйтмичә, үзен Таня дип атый. Аны асарга жыеналар, ул исемен яшереп маташа...

—Хатын-кыз үләр алдыннан да серле булып калырга тиеш.

—Исеме кем булса да, ул фашистлар өчен авыл йортларын яндырып йөрүче,—диде Нагаев; эрудициясен күрсәтеп алсын әле бу кыланчыкка.— Совет кешеләре аны үзләре тотып биргән. Кыш уртасында кемнен чатнама суык урамда каласы килсен? Ярый әле тотуга ук кыйнап үтермәгәннәр, югыйсә бер геройдан коры калыр идек.

—Ә нигә өйләрне яндырып йөргән сон ул?

—Фашистларга нәфрәт уятыр өчен...

Мондый мантыйкны Венера анлап бетермәде. Гомумән, әллә кайчан үлгән ниндидер маржа кызы турында сөйләшү аны туйдырган иде. Сугыш турында, геройлар турында, безнен аларга үлгәнче бурычыбыз барлыгын мәктәптә дә күпме тукыдылар инде.

Нагаев телен тешләде. Венера ише ымсындыргыч кыз-хатын белән кем шундый темага сөйләшә? Ә нәрсә сөйләшергә? Менә шундый тет-а-тет, интим шартларда, чибәр жан иясе борын яфракларын ара-тирә дерелдәтеп алганда ни хакында сүз куертырга?

Ул моны белми иде. Егет чагында кызлар белән сәгатьләр дәвамында нинәрсә сөйләштеләр икән? Төн узуы сизелми дә иде бит. Хикмәт сүздә булмаган, күрәсен...

Кемгә дә мәгълүм, юк-бар сөйләшкән саен син кыз-хатынга кызыграк

тоеласын. Чөнки сүз ул прелюдия генә... Сандугач та үз сайравына фәлсәфи мәгънәләр салмый, аның максаты анык: ул былбыл кызын кавышырга чакыра... Максатына ирешкәч тынып та кала. Хәер, ояда бала кошлар пәйда булгач, сайрау кайгысымыни? Аларга җим ташырга кирәк!

Ләкин юк-бар сүзләрне табуның ни чаклы кыен икәнен белмәгән икән Нагаев. Гел бит "мин сине яратам",—дип торып булмый.

Гашыйклар сүзсез дә аңлаша, диләр дә... Юктыр, дөрес сүз түгелдер ул. Мәхәббәт поэмалары, җырлар язылмас иде юкса. Утын пүләне мичтә мәхәббәттән янса да, аның кемгә кызыгы бар... җылысыннан башка...

—Нигә тынып калдың?—диде Венера.—Гәүдәң монда, ә үзең...

—Үзем дә монда.

—Юк, син әллә кайда, үз уйларың белән. Синең өчен бу дөньяда үзеңнән башка кызыклырак бер кеше дә юк. Мин моны беренче күрүдә үк аңладым.

Нагаев кызарды.

—Нигәдер каушыйм,—дип ялганлады ул.—Тәүге мәртәбә кыз кулын тоткан яшүсмер кебек. Валлаһи менә...

Венера бу юлы көлмәде.

—Артык борчылма,—диде.—Син инде яшүсмер түгел.

Нагаевның сыны катты: "Минем яшькә төрттерә инде бу..."

Шулайдыр... шулайдыр. Хатын-кыз астыртын явыз була бит ул, нәгаләт. Астан чеметеп алырга ярата. Нагаев монда да үзенә юаныч тапты: чеметкәч, димәк, битараф түгел! Анысы да сөенеч олыгайган кешегә.

Исендә тотмаса да, хәтерли, хәтерли Нагаев үз яшен. Дошманнары исә гел истә тоталардыр. Кайчан пенсия яшенә чыгасын бармак белән саныйлардыр әле, хәсисләр. Санамый ни, зур бер институтның директоры ла Альберт Марленович. Юк-бар кеше түгел, әлбәттә. Сизә ул үзеннән яшьрәкләрнең мыш-мыш килеп үкчәсенә басып килгәнен. Басып килә-килә үзләре дә пенсия яшенә җитәчәкләр тиздән, ничауа! Кемнең директор кәнәфиендә утырасын алар түгел, өстәгеләр хәл итә. Өстәгеләрнең исә үзләренең дә яше... ну, бик үк яшь түгел, дип әйтик инде.

Хезмәткәрләренең сабырсыз карашын күреп ләззәт ала иде Нагаев. Алар бит үзләрен әллә кем дип саный. Генийлар, янәсе... Югыйсә житди галим аның институтында чалбар төбе туздырамы?

Венераның гүя каяндыр ерактан, томан эченнән яңгырагандай тавышы ишетелде.

—Алло, алло! Кайда югалдын син?

—Ә?

—Чык, чык үз эчеңнән.

Нагаев көлгән атлы булды.

—Вәт рәхмәт төшкере,—диде.—Чынлап уйга батканмын шул.

—Мине дә онытырлык булгач, нинди уй инде ул?

—Минем яшьтә шулай онытылып китәсең икән...—Нагаев үзенчә ышандырырлык итеп көрсенеп куйды.—Нинди уй керсен инде бездәйләргә?..—Аннары гади генә итеп:—Эш турында уйладым,—диде.

—Мин синең хакта бөтенләй белмим...—Венераның чем-кара күзендә якты чаткылар биешеп алды.—Сөйлә әле—кайда эшлисең, кайда торасың, гаилә хәлең ничек?

Нагаев теләмичә генә көлде.

—Галим мин...—Аннары хатын аңламас дип өстәп куйды:—Ученый...

—Әллә профессор?—Венера кулларын чәбәкләде. Бит алмаларына алсу төс йөгерде.

Аһ, нинди чибәрләнеп китте ул шушы мәлдә. Нагаев аның җыйнак гәүдәсен кочагына кысудан чак тыелып калды... шунда ук... урам уртасында...

үтеп-сүтеп йөргән кешеләрнең аяк астында... бераз гына беленеп торган күкрәкләрен учлап...

Ул мәрттән уянгандай башын чайкап куйды.

—Әйе, профессор да...—диде ул. Фәнни эшчәнлеге турында сөйләшергә яратмый иде. Хәер, нинди эшчәнлек инде? Житәкченең фән белән шөгыльләнергә вакыты каламы? Аннары ул үз фәнен дә, аның галимнәрен дә сөйми, аларны бушбугазларга, эшлексез бәндәләргә саный иде.

Әйе, шулар белән әвәрә килеп гомере узды менә! Югыйсә бит ул зур эшләргә, биек кәнәфиләргә лаек шәхес иде. Ары китә алмады, күтәрмәделәр.

Чыннан да шәм кебек төз гәүдәле, кырыс чырайлы Нагаевның кыяфәте һич тә министрларныкыннан ким түгел иде. Кыска буе да үзенә килешеп тора. Шунамы, хезмәткәрләре аны артында Наполеон дип атый, бу кушаматын ул үзе дә белә, әз генә горурлана да иде әле.

—Фатирым үзәктә—Щапов урамында,—дип сүзен дәвам итте ул.—Ике балам бар, аерым яшиләр.

Аларга нинди юллар белән фатир юнәтүен сөйләп тормады. Ә бит мактанасы килгән иде! Нигәдер шушы ярым таныш хатын алдында үзен зур итеп, әһәмиятле кеше итеп күрсәтәсе килде. Чыны да шулай бит!

—Ах, син нинди важный!—диде Венера, йомшак учы белән аның янагын яратып кына чәбәкләп алды.—Сез, ирләр, үзегезне дөньяның кендеге итеп тоясыз инде.

—Ә син? Син дә үзең турында сөйлә әле?

—Гап-гади хатын-кыз мин,—диде Венера.—Әмәттә яшим. Үз йортыбыз белән... Ирем юк... Кияүгә чыккан идем үзе... тик... ничек диләр әле... характерлар килешмәде. Сиңа кызык түгел инде болар.

"Дөресе дә шул",—дип уйлады Нагаев, тик:

—Нигә кызык булмасын,—диде.—Синең турыда һәр информация кызыклы миңа...

—Культура институтында укыдым...—Венера сынап Нагаевка карап алды, әмма сүзен бүтән озайтмады.—Менә отельгә дә кайтып життек.

—Кечкенә ашка кадәр вакыт бар әле. Диңгез буенда йөреп килмибезме?

—Юк. Мин алҗыдым, бераз ял итеп алам.

Нагаев аның артыннан карап калды: сыгылмалы гәүдәсе—әйтерсең лә һавадан йөзеп бара!—нәфесне кузгата, яшь үгездәй селәгәйне агызып ана ияргәсе килә! Карт канны да кузгата торган, анны җуйдырырдай ниндидер дулкыннар тарала иде анардан.

Шул дулкыннарга күрәме, ашханәгә кергәндә күз кырые белән үк күреп алды ул Венераны. Фойеның бер почмагында ыспай киенгән бер төрек егете белән сөйләшеп тора иде. Венера көлә—нәкъ аның белән йөргәндәге көлү!—әледән-әле бармак очлары белән төрекнең күкрәгенә кагыла... бик иркен сөйләшәләр!.. якын кешеләрчә. Күренеп тора... бер-берсенә ят түгелләр... Нагаевның йөрәге чәнчеп куйды.

Шул чәнчү хәзер—ярым караңгы кабинетында утырганда—тагын кабатланды.

—Сөйрәлчек! С... сөйрәлчек...—дип үзалдына пышылдады ул.

Өстәл лампасын кабызды. Кәгазь кисәкләренә ашыгып яза башлады: "Венера—сөйрәлчек!", "Венера—шлюха!"

Шлюха! шлюха! шлюха!

Әйе, белсеннәр, белсеннәр аның кем икәнен. Туган-тумачалары, күршеләре белсен.

Шул! Шул аны—Нагаевны, аны—Альберт Марленовичның үзен!—кире кагамы?

Ул еш-еш сулый иде, гажәпләнеп язуыннан туктап калды, түбән карады—

йонлач халатының итәге гашыйклар шалашыдай өскә калыккан иде.

Ah!

Венераның теге серле дулкыннары монда—аның аулак кабинетына үтеп кергән түгелме?

Нагаев ашыгып өстәл яныннан торды, халатын салып ташлап тиз-тиз киенде, кесәсенә өстәлдәге язылган кәгазь кисәкләрен тутырды, келәй шешәсен алып тыкты...

Аяк очына гына басып, шауламаска тырышып өеннән чыкты, югыйсә хатыны барыбер ишетмәс иде—ул инде биш-алты ел чукраклыгыннан зарлана, өстәвенә йоклаганда колагын мамык белән томалый.

Машинасы ишек алдында гына тора аның. Нагаев аны башка ишләре арасыннан җай гына алып чыкты да буш урамнар буйлап Әмәткә таба куды.

Олы юлга чыккач, чатта басып торучы ике кызны күреп алды ул. Кул күтәрделәр. Тик Нагаевның кемне дә булса утыртырга бөтенләй нияте юк иде. Үтеп киткәч кенә аңлады: урам фахишәләре бит болар! Төн күбәләкләре. Чү, берсе Венерага охшаган иде түгелме? Әллә шулмы? Ул тормозга басты. Шактый ук артта калган "күбәләкләр" ана кул болгыйлар иде.

Юк ла инде... Нагаев көлемсерәп куйды. Төнге урамга ук чыкмыйдыр ла Венера. Ул тагын кузгалып китте. Шунда бер ачыш ясады Нагаев: үз-үзенә дә сиздермәскә тырышып урам чатында калган теге кыска итәкле, җәтмә оек кигән фахишәнең Венера булуын тели ләбаса ул! Бернинди кыенсынусыз килер иде дә аның янына... шулчакта үзара мөнәсәбәтләр бөтенләй ачыкланыр иде. Һәркем үз урынын, үз вазифасын белә! Бернинди уйнау да, әллә кем булып кылану да кирәкми.

Әнә тагын берәү кул күтәреп тора. Кара, бу да кыска итәкле, җәтмә оеклы... Чәче иненә ишелеп төшкән...

Юк, Венерага охшамаган бу... Охшаган да кебек...

Машинасы әлеге кызның каршысына килеп туктады.

Ачык тәрәзәдә иң әүвәл кып-кызыл иреннәр күренде.

—Утыртасызмы?—Бик яшь түгелме соң бу?

—Кая?

—Кая алып барасыз инде, абзыкай,—дип чытлыкланып көлде кыз.

Аның нинди һөнәр иясе булуына хәзер шик юк иде, Нагаев ишекне ачты.

—Хәзер Әмәткә генә барып килик,—диде ул.—Мин сиңа өстәп түләрмен.

Кыз яшь иде. Унсигездәме? Егерме үкме? Нагаев өчен оныкяшендә... "Иртәрәк өйләнгән булсам",—дип ачы көлемсерәде ул.

Кыз борсаланып куйды.

—Ә нигә Әмәткә барабыз?

—Бер эшем бар...—Нагаев җентекләп кызның чыраена күз салды.—Бер ялгызың төнге урамда басып торуы куркыныч түгелме?.. Венера...

Кыз ана гаҗәпсенеп карады.

—Мин—Ленария... Хотя, теләсәгез, Венера дип тә атый аласыз.

—Көндезләрен ни белән шөгыльләнәсең инде?

—Көндезләрен йоклыйм...—Кыз көлгән сымак итте.—Сораулар бирергә яратасың икән, абзыкай.

Шактый гына эндәшмичә бардылар.

—Студентка мин,—диде кыз бераздан.—Университетта укыйм.

"Кайсы университетта?"—дип сорарга җыенган иде дә Нагаев, тыелып калды. Барыбер түгелмени? Мондый әңгәмәләр өчен легенданы бу кызлар алдан ук иҗат итеп куя.

Венера яши торган кыска гына урамга керер алдыннан машинасын туктатты Нагаев. Ачкычны оясыннан суырып алып кесәсенә тыкты да кызга: "Мин хәзер киләм, шушында гына утыр",—дип караңгы урамга ашыкты.

Фонарьлар янмый иде, яхшы булды әле. Тик салкынайткан. Нагаевнын өстендә жинел куртка гына иде—ул калтыранып алды... тик эчендәге үч ялкыны тагын дөрләп китеп, шунда ук бөтен тәне кызыша башлады. Күзгә төн үзе дә куерып битне эссе сулышы белән куырып алгандай тоелды. Җәй быел озак торса да, көз барыбер килә шул, килә. Бер нишләтеп булмый...

Әнә ике йорт аша гына Венералар өе. Бер тәрәзендә ут яна түгелме? Бәлки анда—жылы бүлмәдә—Венера кем беләндер чөкердәшеп утырадыр? Ә ул—Альберт Марленович!—кара төндә, карак сыман качып-посып кесәсендәге кәгазь кисәкләрен урам баганаларына ябыштырып йөри. "Венера—шлюха!" Менә аларнын туры. Монда ул белдерүнең татарчасын ябыштырачак: "Венера—сөйрәлчек!" Белсеннәр әле анын да кем икәнен!

Ул шулай йөгерә-чаба кыска урамны әйләнеп тә чыкты. Йөрәк атылып тибә, кан кызган... күзләре дә төн эчендә утлы күмер кебек кызарып күренә сыман...

Машина ишеген ачкач, теге кызның саңгырау тавышы ишетелде:

—Син кайда йөрдең?

—Киттек!—Ачкыч ярсып оясына ыргылды.

Күпмедер баргач, "күбәләк" тагын тавыш бирде:

—Мин курыктым...

—Һәр һөнәрнең үз куркынычы бар.

Кайтып житәр алдыннан гына ул машинасын аулак тыкрыкка борды.

Кысан иде, тик Альберт Марленович аны сизмәде.

—Венера! Венера. Венера...—дип кабатлады ул, бүтән сүз дә, бүтән исем дә анын теленә килмәде.

—Ашыкма, ашыкма...—диде кыз аңа яраклаша алмыйча.

—Венера-а...

Хәтта машина да, бер урында торудан гажизләнеп, ава-түнә аулак тыкрык буйлап каядыр кузгалып китте...

Алар Анталиядә таныштылар.

Таныш-белешләре бик мактагач, шунда ял итәргә барган иде Нагаев. Табигать манзарасына сокланып—аңардан да бигрәк үз-үзенә!—күтәренке күңел белән һотеленә кайтып барганда бер-бер артлы куелган эскәмияләрнең берсендә кесә телефоныннан сөйләшеп утыручы каратут йөзле яшь ханымны—әйе, әйе ханым! анын һәр хәрәкәтендә инде шактый тәжрибәле ханымнарда гына була торган нәзакәть сизелеп тора иде...—күреп кинәт туктап калды ул. Бер караштан гашыйк булу дигән сүздән көлеп йөри иде югыйсә. Анын яшендә...

Хәер...

Нәкъ анын яшьләрендә кайбер ир-атнын тилереп, дөньясын онытып мәхәббәт дингезенә чумуын, инде батам дигәндә шыншый-шыншый көчхәл белән ышанычлы ярга үрмәләп чыгуын белә иде ул. Бәгъзеләрнең бөтенләй батып калуын да яхшы белә иде.

Каршында шундый сылу хатын торганда—ул юан да, бик артык ябык та түгел, нәкъ Альберт Марленович зәвыгында иде,—әллә кемнәрнең мәхәббәт иләндәге тәжрибәләре турында уйлап маташасынмы? Нинди тәжрибә? Юк ул монда... Үлем тәжрибәсе булмаган кебек...

Хатынның бөтен барлыгыннан татарлык аңкып тора иде. Юкса менә бу татар!—дип әйтерлек аерым бер чырай юк бит бездә. Нинди генә кыяфәтләләр очрамый арада. Тик күп очракта үз сөягеңне әллә кайдан аерып, танып аласың икән! Шуңа да бу ханымнын татар булуына тамчы да шикләнмәде Нагаев.

Якынлашкач, сөенеп куйды—чынлап та ялгышмаган икән бит!

Хатын кесә телефоныннан татарча сөйләшә иде.

—Рәхәтләнеп ял итәм, сөйләмә миңа алар турында!—Хатын үз янәшәсенә

килеп утырган ир-атка бөтенләй игътибар итмәде—күз кырые белән дә карап алмады!—монда минем җаным тыныч... Туйдырганнар иде барысы да... А ему не скажи минем кайда икәнне...

Урыныннан кузгалган хатынга ашыгып сүз кушты Нагаев:

—Гафу итегез...

—Итмим!—диде хатын һәм бу нинди җан иясе соң әле, дигәндәй кызыксыну катыш сынаулы карашын Нагаевка төшерде.—Сез кем?

—Ә-әйе... Таныш булыйк—Альберт Марленович. Казаннан.

—Венера,—хатын аңа гади генә итеп кулын сузды.

—Сезнең сөйләшкәнне колак очы белән генә ишеткәч, Казанга кайткандай булдым,—дип сайрый башлаган иде дә Нагаев, хатын аны коры гына туктатты.

—Нәрсә бар анда—Казанда?

—Соң, нәрсә дип... Ватан... туган ил, так сказать...

—Алай бик тиз сагынырлык булгач, нигә монда килдегез соң?

Нагаев җавапны тиз табуына сөенеп:

—Сагынырга!—диде.

—Алайса Казанны бик еш искә төшерерсез. Мондагыларның яртысы диярлек Казаннан.

—Сез дәме?

—Күренмимени?—дип көлде хатын.

—Ужиннан соң бәлки бергә-бергә сөйләшеп утырырбыз?

Венера тагын аңа сынап карады... керфекләре аша...

Һай, кыз-хатынның шул карашыннан үлә иде Нагаев.

—Утырып торасым килми, абы-ы-ый,—дип сузды Венера.—Дискотекага чакырсагыз инде... бәлки риза да булырмын. Төнге клублар бик классный монда... Тик...—Тагын керфек арасыннан караш...

Тит-тит-тит... Картсына, дип рәнҗеп уйлады Нагаев. Белми әле... әле... әле ул... әле...

—Пажалысты,—диде Нагаев көр тавыш белән.—Биербез кара яндырып.

Хәзерге музыкага үрле-кырлы сикерүен күз алдына китереп үзалдына көлеп куйды ул. Тик юкка курыккан икән. Әби яшендәгеләрнең дә биеп маташуларын күргәч, эченә җылы керде. Һи, болар арасында әле ул...

Шулай да биергә ашыкмады.

Үз яшен онытып кыланучылардан да көлке һәм кызганыч кем бар тагын? Картаясы килми беркемнең дә, тик табигатьне алдап булмый шул... булмый...

Ә Венера очынып биеде дә биеде.

Нагаев, ара-тирә шәраб йота-йота, сокланып аңа карап утырды. Кулыннан тартып диярлек торгызгач, биергә дә чыкты әле. Бию дип... бер урында таптанып кулларын селеккәләде бугай. Институттагы хезмәткәрләре күрсә, эчләре катып көләрләр иде, мөгаен. Юк, аның алдында түгел, әлбәттә, бәдрәфкә чыгып бии-бии шаркылдарлар иде.

Өметең төшкән хатын-кызның күңелен күрәм дип, бию генә түгел, әллә ниләр эшләргә риза инде җүләр ир-ат. Андый чакта исем-дәрәҗәләр дә истән чыга, асылыңны яшерә торган битлек тә онытыла.

Венера аның гына түгел, бүтәннәрнең дә күзен кыздыра иде, күрәсең: чәчен арттан учламга җыеп бәйләгән кәкре борынлы егет бигрәк тә бөтерелде инде шул тирәдә.

Һәм юкка гына бөтерелмәгән икән!

Официант белән исәп-хисап ясаган чагы булгандырмы, Венераның югалуын искәрмичә калды ул.

Башта көтте әле, бәлки бәдрәфкә генә чыккандыр, дип үз-үзен юатты. Инде өмете бөтенләй киселгәч тә—клубта бер кеше калмады, официантлар гына өстәлләрне җыештырып йөри...—тиз генә урыныннан кузгала алмады.

Һавага чыккач та озак кына аңгы-миңге булып торды ул. Ни инде бу? Ничек шулай кешедән көлеп була? Рәнҗү катышкан ачу борын тишекләреннән ургып чыккандай булды, күз төпләрен әчетте. Оятсыз рәвештә аны файдаландылар ич! Уенчык итеп... юк, савым сыеры урынына... Лох! Карт юләр... Әгәр шушы мизгелдә каршысында Венера пәйда булса, ул аны ботарлап атар шикелле иде.

Пәйда булмады.

Иртәгесен кич белән берни булмагандай аның бүлмәсенә килеп керде ул.

Нагаев иртән үк температурасы күтәрелгәнен сизде. Кан басымы да уйный бугай. Кимсенүдән, гарьлектән килгән авыру иде бу. Ул ашханәгә дә төшмичә көн буе бүлмәсендә генә ятты. Эче яна иде аның—су эчте дә су эчте. Эчте дә укшыды.

Наивлыгы өчен үзен сүкте, эттән алып этка салды: аңгыра... ахмак... дуррак... Шулай кызык итәләр синдәй азгын картларны. Теге оятсыз кыз-хатынны әллә нишләтәсе килде. Тик нишләтә ала ул аны?

Менә килеп керде. Елмайды. Мангаен җыерып куйды.

—Сез күренмәгәч борчылдым,—диде.—Авырдыгызмы әллә?—диде.

Бөтен ачуы, рәнҗүе, кимсенүләре онытылды Нагаевның. Әйтерсең лә җил чәчәк тузанын каядыр алып китте. Ул аның теләсә нинди гамәлен кичерергә әзер икән ич! Бары тик янәшәдә генә басып торсын, чатнаган тавышы колакны гына иркәләсен...

—Син кичә кая югалдың?

Венера нәни генә салкынча кулын аның маңгаена куйды.

—Янасың бит, җаныкаем. Дару эчтеңме?

Ул шулай—әле сез, әле син дип сөйләшә иде.

Нагаев тавышын күтәрде:

—Бер сүз әйтмичә... җавап бир!

Венера маңгайдан кулын алды, бер адым артка чигенде.

—Абау!. Мондый тонда сөйләшсәгез, мин чыгып китәм.

Нагаев үзе дә сизмәстән урыныннан чәчрәп торды, Венераны күкрәгенә кысты.

—Юк, юк. Китмә. Алайса мин үләм.—Тавышы шундый ялварулы, мәэсүс иде.

Мондый тавыш әллә нинди кальгаларның капкасын ачтыра ала, әмма Венераның керфеге дә селкенмәде. Ул аны ике кулы белән читкә этте дә:

—Тынычланыгыз, зинһар,—диде салкын тавыш белән.—Сез бит интеллигентный кеше. Зерә борчылгансыз. Я же по-английски ушла.

Шулайдыр... инглизләр шулай сүз әйтми генә юкка чыгалардыр. Ләкин ул бит инглиз түгел! Ир-ат кыз-хатын хушлашмый гына гаип булсын өчен сыйланырга чакырмый.

Венера исә кыз-хатын иде. Мондыйлар олыгаеп карчык булгач та кызлык чалымнарын җуймый. Уйнаш күңелле кыз-хатыннар сине теләгәнчә алдый, ялангач калдыра, хыянәт итә, аяк астындагы тузанга әверелдерә—тик син барыбер аларга озак ачу да сакламыйсың, нәфрәтең дә дәвамлы булмый, иблис котырыгы инде бөтен җаныңны, җәсәдеңне яулап ала, яман чир кебек метастазалары бөтен әгъзаларына тарала.

Котылу юк!

Һәм котыласы да килми, шайтан алгыры!

Гаҗизләнеп басып торган Нагаевка карап Венера көлеп җибәрде.

—Юк өчен кайгырма,—диде.—Менә бит мин!—каршыңда басып торам. Йә, нишлибез? Төнге клубка чакырмыйм инде бүген...

Нагаев, аңга килеп, суыткычка ташланды—аннан җиләк-җимешләр тартып чыгарды, аларны тәбәнәк өстәлгә урнаштырды. Казаннан ук алып килгән "Һенесси" коньягын уртага утыртты.

Талгын музыка... ярым караңгы бүлмә... иненә орынып утыручы кыз-хатын... Йә, ни кирәк тагын мәхәббәткә сусаган ир-атка?

—Кем ул теге кәкре борынлы егет?—дип сорады ул инде куенында яткан Венерадан.—Син шуның белән киттеңме?

Венера исә җавап биргәнче аның куеныннан суырылып чыкты да тиз-тиз киенә башлады.

—Сез ир-атлар барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән... Хуҗа буласыгыз килә. Ә мин—ирекле. Кая телим—шунда барам, кем белән телим—шуның белән... Буйсыну таләп итәргә мин бит синең секретарьшаң түгел!

—Үзем дә аңламыйм...—Нагаев шәрә йонлач аякларын идәнгә салындырып утырды.—Көнләшәм, ахрысы. Димәк, яратам!

—Үзеңне яратасың син, җаныкаем. Күзең төшкән һәрнәрсә, һәркем синеке булырга тиеш.

—Һәм син минеке булырсың!

—Нәчәлник икәнең әллә кайдан күренеп тора.—Йөзендә чалыш елмаю пәйда булды.—Киләчәк күрсәтер. Үзең минеке булмагаең!

—Мин риза!—шулай диде инде. Үзе эчтән ирәеп уйлап куйды: Нагаевны үзенеке итүчеләр җирдә тумаган әле. Ул үз сүзен генә сүз итүче кеше... дөнья анынча гына барсын! Мондый кыз-хатынны гына иярли алыр ул...

Өстенлек хисе аның канына сеңгән. Тик кайчакта бу хис артка чигенә—оясына качып күзен генә ялтыратып ятучы эт сыман!—шунда Альберт Марленович үзен самими бала сыман сизә, кыз-хатынга сыенасы, итәгенә башын куеп иркәләнәсе килә, аның һәр әйткән сүзен җөпләп, ияреп йөрергә дә риза ул. Тик аңына килгәч оядан теге эт атылып чыга да Нагаев тагын үз кыяфәтенә кайта—битлеген җайлап кия, сынын турайта, тавышы кибарьләнә.

Кайтышлый Истанбулга туктаганда да үзенең шул күнегелгән халәтендә иде ул.

Казанга әле иртәгә генә очасы булганга, алар Солтан Әхмәт мәчетенә янәшәдә генә, Ат мәйданының түрендә урнашкан затлы кунакханәнең иркен бүлмәсенә урнаштылар.

Тәрәзәдән Айя-Суфия, бередәрәк төрек солтаны кайчандыр Мисырдан кайтарттырган фиргавен баганасы күренеп тора.

—Византия вакытында монда ипподром булган,—дип аңлатты Нагаев киярге күлмәк сайлап торган Венерага,—алар шәһәргә чыгарга әзерләнәләр иде.—Шуңа төрекләр моны Ат мәйданы дип йөртә. Берничә гасыр элек кайсыдыр төрек солтаны баш күтәрүдә катнашкан дистәләрчә мең янычарны үтертә. Бередә Кызыл мәйдандагы кебек үк кан күп түгелгән.

—И күп белә дә инде минем профессор...—Ниһаять, Венера күнелгә ятышлы күлмәк тапты бугай, канәгать елмаеп куйды.—Әйдә, әйдә, киен тизрәк. Капалы Чаршыны айкап кайтыйк әле.

Истанбулның атаклы базарына бер дә барасы килми иде Нагаевның. Гомумән ул, ир-атларның күбесе кебек, кибетләрдә, базарларда йөрергә яратмый. Әмма хатын-кыз белән булгач, нишләмәк кирәк... Ә хатын-кыз саткан-алган төштә үзен судагы балык кебек хис итә. Хәтта берни сатып алмаса да...

Баязит мәчете яныннан үтеп, алар Капалы Чаршыга юл тоттылар. Ни генә юк монда!—чын-чынлап шәрык базары. Чит ил кешесе икәнең әллә мангайга язылган, әледән-әле сине малай-шалай төркеме урап ала, штампланган арзанлы сәгатьләрен кулга соналар вак чебен кебек күзгә генә кермиләр инде.

Адым саен диярлек урысча сөйләшкән тавышлар ишетелә. Әллә ярты Рәсәй монда күчкән... Гүя элгәреге урыс сәясәтчеләренең хыялы тормышка ашкан—алар бит Петр патша вакытыннан бирле Истанбулны—янәсе Царьградны яулап алырга хыялланган. Хәер, хәзергеләренең дә күңелендә ул яшерен өмет сүрелеп бетмәгән ахрысы.

Дәрманга караганда дәрт озаграк яшәүчән шул!

Алтын кибетләре тезелеп киткән урамда—әллә кайларга сузылган рәтне урам диме ни дисен?!—Венера әллә нишләде: сулышы ешайды, йөзе кызарып чыкты, мангаенда тир тамчылары жемелдәде. Беренче кибеттә үк ул бар дөньясын онытты—йотылды! Гажәп тә түгел—монда кайчакта хатын-кызлар аннарын да жуеп егыла, имеш. Шундый ул алтынның кодрәте: "Мен дә бер кичә" әкиятендәге кебек, хәзинә тулы мәгарәгә кергәч, ишекне ачтыра торган тылсымлы сүзне истән чыгарган мәгълүм каһарманга да әверелүең бар...

Венера сатулашкан арада Нагаев каршы як кибеттән ана дип муенса алды. И сөенде инде Венера... Бүләкне кем яратмый!

—Күпмегә алдың инде?—дип сорады бераздан.

—Бүләкнең бәясен сорамыйлар.

Тик барыбер әйттерде.

—И профессорым, бигрәк беркатлы икәнсең,—дип борчылды Венера.—Өч бәясен түләгәнсең ләбаса. Төрек ул сатулашырга ярата. Сатулашмаганны кешегә дә санамый ул...

—Өйләнгән елны егетләр юмарт була,—дип, кайдандыр ишеткән әйтемне искә төшерде Нагаев.

Венера кызарып, оялчан үсмер кыз кыяфәтенә кереп, керфекләрен түбән төшерде.

Ярәттыра беләә иде ул үзен, чукынчык!

Нагаев сәгатенә карап алды. Истанбулга килеп төшкәч үк ул күптәнге танышы профессор Туран Язган белән телефоннан сөйләшеп алган иде. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, Казан сәламнәрен—алар инде Анталиядә ятып шактый искергән...—кабул итеп алгач, Туран бәй беравык тынлыктан соң сорап куйды:

—Кичен сезнең вакытыгыз булырмы? Бүген без Әзәрбәйжаннан килгән кардәшләр хөрмәтенә мәжлес жыя идек. Сез дә шунда рәхим итә алмассызмы?

—Бик рәхәтләнеп,—дип сөенде Нагаев.—Әма бән бир кадын илә...

Туран бәйнең, үзләре әйтмешли, күзәй төркләре шивәсендә әйбәт аңлашуын белә Нагаев, тик үзенең дә төрекчәдә төшеп калганнардан түгел икәнен искәртергә шул җөмләне әвәләп чыгарды инде. Янәшәсендә басып торган Венера да шаккатсын әле. Төрек банкетында катнашырга теләве дә нәкъ менә Венера өчен, аның алдында янә бер кат үзенең зурлыгын күрсәтү өчен иде.

—Әвәт, кичке алтыда вакыфка килегез,—диде Туран бәй.

Аның вакыфы базардан ерак түгел иде, алар җәяүләп кенә киттеләр.

Мәжлес Таксим мәйданындагы бер ресторанда буласы икән, Туран бәйнең машинасында барганда Нагаев сиздерми генә Венерага күз салгалады: менә бит, төрекләр дә "аның профессорын" ничаклы хөрмәт итә, күтәреп кенә алмадылар, Нугай бәй дип кенә торалар! Һәм дөрес әйтәләр. Ярлы колхозчы гаиләсендә туса да үзенең бәкләр нәселеннән булуына ышана ул.

Тостларга да колак салмады Нагаев—андый чакта ниләр сөйләнүен белә иде, аңа Венераның тән җылысын тоеп утыру рәхәт! Венера алдында үзен зур кеше итеп тоюы рәхәт. Белсен бу горур Казан кызы кем белән утыруын... Әнә Әзәрбәйжан илчесе. Ак сакаллы, ак чырайлы сымбат кеше. Әнә төрек министры. Әнә...

Нагаев та торып тост сөйләде татарча. Бәлки һәр сүзен аңламаганнардыр да... Ләкин Төркияне мактавы һәммәсенә барып житте, кул чаптылар.

Менә дәртле төрек музыкасы яңгырады. Түрдәге кечкенә сәхнәгә төрек кызы йөгереп чыкты: күкрәгендә алсу бюстгальтер, кара шифонга кызыл розалар төшкән итәк кигән. Корсак биюен башкарамы соң? Музыка кызган саен өстәл кырындагы ирләрнең дә күзләренә дәрт тула, иреннәре юешләнә иде. Ә кыз бии—еландай боргалана, коландай каядыр ашкына.

Нагаев инде үзен бәк кенә итеп түгел, хан итеп тоя иде. Татар ханнары да кайчандыр шулай кызларның биюен карап ләззәтләнгәндер. Үз чатырларында... Ә ул монда—Истанбулның үзәгендә!—төрек сылуының биюен карап соклана.

Кыз инде һәркемнең алдына килеп бии башлады. Шул бәхеткә лаек булган кеше шаккатудан тел шартлата һәм кызга акча сона иде. Нагаевның соклануы шунда ук юкка чыкты. Анарда бит вак акча юк. Вак дигәне дә йөз доллар. Безнең акча белән ул буладыр... буладыр... Артык күп була кыскасы! Ә кыз котылгысыз рәвештә аңа якынлаша. Акча бирмәсәң, оятын кая куярсың. Татарларны саран, мәнсез дип калырлар. Аннары янәшәдә Венера да бар бит әле. Һәм ул елмаюын ничек тә киңрәк итәргә тырышып, йөз долларны бераз җәебрәк—күрсеннәр!—биюче кызның күкрәкчәсенә кыстырды. "Менә мин нинди!"—дип күз кырые белән генә Венерага карап алган иде дә, аның чытык чыраен күргәч, болай да беткән кәефе бөтенләй кырылды. Бәяләмәделәр! Сизмәделәр дә... юмарт икәнен дә күрсәтә алмады, йөз доллардан да колак какты.

Кайтканда бер сүз катмады Венера. Нагаев та гаепле кешедәй эндәшмичә барды. Һотельгә керер алдыннан гына Венера аңа борылып:

—Биюче кызны күзең белән ашый яздың бит, профессор иптәш,—диде.—Йөз долларыңны да җәлләмәдең.—Бераздан соң өстәп куйды:—Бичара студенткалар...

Нагаев аптырады: студент кызларның монда ни катнашы бар?

—Бер таныш булмаган чит ил кызына шулай ымсынгач, сиңа бәйле студенткаларны нишләтәсеңдер син...

—Мин сәнгать әсәренә сокландым,—диде Нагаев коры гына.

Үзенең күңеле күл булды—җәелде, ташыды. Көнләшә түгелме соң бу тәкәббер кыз-хатын? Димәк, Нагаевның көнләшерлеге бар әле!

Һава аланында, очкыч көткәндә, Венера аның кулын тотып: "Рәхмәт сиңа, профессорым,—диде.—Бу сәфәрдән искиткеч хатирәләр калды".—Ул бераз гына дулкынлана иде төсле.

—Минем сиңа нәни генә бүләгем бар...—Һәм бизәкле тартмага салынган алтын каләм сузды.

—Алтын каләм...—диде.—Язганнарың да алтын бәһасенә торсын.

—Минем язганнарым бәһасез,—диде Нагаев.

Ияген өскә чөеп—ә ияге аның шундый йомры, матур!—Нинди көлгән иде Венера.

—Нигә көләсең?

—Ирләр үзләре турында бик югары фикердә...

—Үзебез мактанмасак, безне кем мактар?

—Мин сине мактыйм...—Венера тагын бер сәбәпсез көлде.

—Казанда да гел очрашып торырбыз бит?

—Ә хатының? балаларың? Синдәй зур кешеләргә имиджны сакларга кирәк, шаярма, иптәш профессор.

—Шундый чибәр кыз-хатын белән... дус булу имиджны бизи генә.

Тиз генә очрашырга язмаган икән. Казанга кайтуга һич көтмәгән матавыклар, борчулар бөтереп алды Нагаевны.

Матавык кынамы... Аның тез астына китереп суктылар һич көтмәгәндә.

Ялдан кайтып бер атна үтте микән, аны Министрлар кабинетына чакырдылар.

Түрә, анардан шактый ук яшь кеше, бик төксе каршы алды. Исәнлек-саулык та сорашып тормыйча—дөрес тә, Нагаевның исәнлеге аңа ниемә кирәк?!—үгезнең мөгезенә ябышты ул:

—Институт эшендә житди кимчелекләр бар,—диде.—Серьезные недостатки... Без җитәкчелекнең эшеннән риза түгел.

—Нинди кимчелекләр? Сез конкрет сөйләгез,—диде Нагаев шактый ук аптырап.

—Смена поколений, Альберт Марленович,—диде түрә өзеп.—Яшьләргә юл бирергә кирәк.

Нагаевның күз аллары карангыланды... ә чырае агаргандыр, түрә аңа сулы стакан тоттырды.

—Борчылмагыз сез ул кадәр. Без бит сезне эштән кумыйбыз. Сектор мөдире булырсыз.

—Миңа пенсиягә кадәр биш ай вакыт калды. Шунарчы көтә алмадыгызмы?

—А что это меняет?

—Мин президентка керәм.

Түрә елмаеп ике кулын җәйде:

—Пожалуйста!

Хәер, мәсьәлә иң өстә хәл ителмәсә, бу егет аның белән болай сөйләшер идеме?

—Кем инде ул?

—Сез аны беләсез. Бездә эшли...—Һәм ул таныш исемне атады.—Шаулап йөрмәскә киңәш итәм,—диде ул Нагаевның кузгалуын күреп.—Персональный машинагыз сезгә калачак... О деталях поговорим еще... Бергә-бергә яшисе бар бит әле, Альберт Марленович...—Түрә аның хәленә кереп елмайды.—Юбилеегызны зурлап уздырырбыз. Орденны лично үзем обещаю.

—Рәхмәт инде...—дип мыгырдады Нагаев.

Түрә янынннан ул туп-туры өенә кайтты. Тынычланырга, үз хәле турында ныклап уйланырга кирәк иде. Ишекне ачуга ук борынга корвалол исе килеп бәрелде. Хатынының еламсыраган тавышы ишетелде:

—Кайттыңмы? Кайда йөрисең син? Эшеңдә юк, кесә телефонын алмый...

—Ни булды?

—Үләм, ахрысы. Йөрәгем чәнчи... кан басымы күтәрелгән...

—Скорый чакырырга иде.

—Алар ни белә?

—Ни эшләргә соң?—Нагаев хәле китеп урындыкка утырды, тел астына волидол салды. Берәү әйтмешли: "Эшләргә-то нәрсә?"

—Син минем үлүемне телисең инде-е...—дип елап җибәрде хатын.—Ял итәргә дә берәр кәнтәең белән баргансыңдыр әле.

—Тынычлан, зинһар. Үз хәлем хәл...

—Гомер буе эгоист булдың син...

Нагаев ачыргаланып кычкырды:

—Житте, дим, ниһаять!

Шул чакта телефон чылтырады. Беркем белән дә сөйләшәсе килми иде Нагаевның. Ә телефон чылтырый да чылтырый.

—Әйе?

—Исәнме, профессоркайгынам... Син кая югалдың?—Төрепкәдә Венераның шат тавышы ишетелде.—Бөтенләй югалдың ич син! Кайтканнан бирле хәбәрең юк. Очрашабызмы?

—Юк... Гафу итегез...

Телефон тагын чылтырады.

—Син... шаяртасыңмы? Альберт...

—Юк, шаяртмыйм. Ишетәсезме, мин серьезно! Серьезно!

Кыска-кыска гудоклар...

Ул обойдагы бер ноктага карап утырды да утырды. Караңгы төште, хатыны күләгәдәй шуып йокы бүлмәсенә кереп китте. Ә Нагаев урыныннан кузгалмады.

Юкка шулай авыр кичергән икән ул кәнәфиеннән төшүне. Кәнәфидән төшү түгел, иңнән авыр йөкне төшерүе булган! Вакыты күп хәзер, җаваплылык аз, машина да кул астында гына, елгыр шоферы чакыруга ук подъезд төбенә килеп туктый. Институт хезмәткәрләре аны кәнәфисез килеш тә хөрмәт итәләр икән. Ни кирәк тагын кешегә?

Йөрәге генә меңә, сыкрап, нәрсәдер җитмәүне искәртә шул. Нәрсә түгел, Венера җитми икән аңа... кыз-хатын!

Директор вазифаларын тапшыргач ук аңа чылтыраткан иде югыйсә. Тавышын көрәйтергә тырышып:

—Венера, мине гафу ит, зинһар,—дип сүзне башлаган иде.

—Кем бу?

—Инде танымыйсың дамы? Альберт Марленович мин. Синең профессоркаең...

—Мин андый кешене белмим. Һәм вообще... бүтән звонить итеп борчымагыз.

—Венера!—Ләкин элемтә өзелгән иде инде.

Инде моңа бер ай вакыт үтте. Нагаев атна саен төнлә Әмәткә бара, таныш урамны әйләнә, баганаларга Венераны фаш иткән кәгазьләрен ябыштыра. Бер атнага шулай тынычланып кала. Тик бер атна узуга кимсенүе, гарьлеге, үче тагын кузгала, төн уртасында ул машинасын Әмәткә куа, кача-поса баганаларга белдерүләр ябыштырып йөри: "Венера—сөйрәлчек!", "Венера—шлюха!"

Менә хәзер дә ул төнне ертып Әмәт ягына җилдерә. Тик бу юлы урам чатларында "төн күбәләкләре" күренми, урамнар буп-буш диярлек, тик аратирә сонарган машиналар гына үтеп китә.

Беренче баганага кәгазен ябыштыруга ук, җир астыннан чыккандай, аны ике кеше ике ягыннан эләктереп алды.

—Күптән көтәбез инде сине, урод,—диде берсе.

Икенчесе сугарга кизәнмәкче иде дә, Нагаевның кыяфәтен күргәч, никтер кире уйлады.

Нагаев үзе бернәрсә анларлык хәлдә түгел иде.

Милиция бүлегендә аны күрергә кизү торучы барлык милиционер җыелды.

—Ә мин профессорларны акыллы кешегә чутлап йөри идем,—диде тәбәнәк буйлы бер сержант.

—Аларның күбесе мондый,—дип бармагы белән маңгаена төртеп күрсәтте берсе.—Күп укыганнан...

—Утыр,—диде капитан.—Хәзер беркетмә тутырабыз. Исем-фамилия?

—"Сез" дип сөйләшүегезне үтенәм.

Капитан гаҗәпләнеп калды:

—Да? Культурный, значит... Исем-фамилиягез, атагызның исеме?

—Альберт Марленович Нагаев!

Беркетмәне тутыргач, капитан аның алдына кәгазь шудырды.

—Аңлатма языгыз.

—Нәрсә язарга?

—Нигә кешегә яла яккан листовкалар таратасыз? Нинди мөнәсәбәттә сез Венера... тәк... Ибатова белән? Барысын да языгыз. Сезне өйрәтәсе юк.

—Мин бернинди листовкалар таратмадым.

—Әһе... Безнең хезмәткәрләр тоткарлаганда, багана төбенә пес итәргә тукталган идегез инде, әйеме?

—Әйе!

—Төн уртасында пес итәр өчен Әмәткә килдегез, әйеме?

—Әйе!

—Ну, языгыз шул турыда...

Язды Нагаев өйдә бәвеле килмичә интегүен дә, бары тик төн уртасында Әмәттәге бер багана төбендә генә бушана алуын да...

Капитан аңлатманы укып чыккач туйганчы көлде. Күзеннән эре яшьләр атылып чыкты хәтта!

—Ну, умора... Үләм...—Ул тагын "син"гә күчте:—Под дурачка косишь, профессор? Справкаң бармы соң?

—Нинди справка?

—Шизофреник булуын турында...

—Юк.

—Табарсын. Сез, кирәксә, әллә нинди документлар да юнәтәсез.—Капитанның ике күзе тулы нәфрәт иде.—Барыгыз. Иртәгә сәгать унбергә тикшерүче янына килерсез. Унбишенче кабинетка.

—Сау булыгыз.

Капитан эндәшмәде.

Әлбәттә, икенче көнне бу йортка килгәндә, Нагаевның кесәсендә шизофрениядән авыруы турында белешмә бар иде инде.

Тиешле кешеләргә чылтыратылган иде. Тик барыбер Нагаевның жаны, сытылган күнеле шыншып елый иде. Бетте бит ул! Гомер буе бөртекләп җыелган дәрәҗә коелды да төште. Репутация! чәлпәрәмә! Гомерен шулай хурлыкта, үлгәнче җуелмас шизофреник тамгасы белән төгәлләрме инде ул?

Бөтен Казан аңардан көлә сыман тоелды. Институтка бармас инде ул бүтән. Чукынып китсеннәр. Ә Венера? Аның күзенә ничек карар?

Ә Венера тикшерүче бүлмәсендә утыра иде.

—Исәнмесез,—дип авыз эчендә ботка пешерде Нагаев. Ул Венерага күтәрелеп карарга да кыймады. Анын болай беркайчан да шулкадәр югалып калганы, үзен бер шакшы бөҗәк итеп тойганы юк иде әле!

—Утырыгыз, Альберт Марленович.—Тикшерүче өстәлдән башын күтәрмичә генә урындыкка ымлады.

Нагаев аның алдына бүген генә алган белешмәне китереп салды.

—Нәрсә бу?

—Мин—шизофреник...

—Да? Без үзебез дә шикләнгән идек аны. Тик махсус тикшермичә булмас.

Шул чакта Венераның тавышы ишетелде:

—Махсус тикшерүнең кирәге юк.

Тикшерүче аңа аптырап карады.

—Мин гаризамны кире алам.

—Ялгышмыйсызмы?—Тикшерүче папкасыннан кәгазь алып Венерага сузды.—Бу бәндә исемегезне тагын пычратып йөрмәсме?

—Йөрмәс!

Нагаев бүртенгән чыраен кайда яшерергә белмәде.

—Алайса...—дип урыныннан торды тикшерүче.—Мин сезне тоткарламыйм. Безнең бүтән эшләребез дә баштан ашкан...

Урамга чыккач, Венера Нагаевны култыклап алды.

—Әйдә, әнә теге кафега кереп утырыйк әле. Сөйләшәсе сүзләр күп җыелган,—диде ул.

Нагаев, туктап, кыз-хатынның күзләрен эзләде. Тапты. Тик анда кызганудан башка берни дә күрә алмады.

—Мин аңламыйм... Син ничек... болай... булдыра аласың...

Кыз-хатын монсу елмайды:

—Син әле бик күп нәрсәне аңламыйсың, җаныкаем...—Һәм йоп-йомшак учы белән аның юеш яңагын сыйпады.



Гөлнур
Әхмәдуллина

# ЙӨРӘК ТАГЫН ҖЫР ЯЗДЫ...

## Син—мин

Минем тәхет—
Синең җылы кочак.
Мин—алиһә шул чак.

Минем бәхет—
Синең нурлы йөзең.
Син—җырланыр сүзем.

Минем язмыш—
Синле синсез йөрәк.—
Сандугачсыз тирәк...

## Ак нур

Ак нур сузылды кинәт
Син торган тарафлардан.
Фәрештәң каурый таратты
Иңдәге канатлардан.

Җыр яздылар йөрәккә
Каурыйлар ак нур белән:
—Сөелеп яшәп калыйкчы
Бергә парлы җыр белән.

Ишеттем мин җырыңны,
Сандугач отты көен.
...Ак нур булып кагылды шул
Синең назлы сөюең.

* * *

Мин берни белми идем—
Аңлаттың:
Сызылып атуларын таңнарның,
Ап-ак иканлеген карларның,
Тирән иканлеген хисләрнең—
Минем синле хәзер кичләрем.

---

Гөлнур ӘХМӘДУЛЛИНА (АРХИПОВА)—*шагыйрә; көндәлек матбугатта шигырьләре, хикәяләре даими басыла. «Ялгышу» исемле китап авторы. Балык бистәсендә яши.*

Мин берни күрми идем—
Күрсәттең:
Кояш баешының кызыллыгын,
Алдагы юлның озынлыгын,
Якты булуын айсыз төннәрнең—
Минем синле хәзер көннәрем...

* * *

—Син җир кызы түгел,
Син—алиһә,—дидең бүген.
Күзләреңдә—сөю,
Сүзләреңдә—сафлык,
Ал кояшлы күгем.

—Син—алиһә!—шушы сүзең—
Яшел үлән, ап-ак чәчәк:
Язга кичте салкын көзем.

—Син—алиһә!
Күзләремдә калсын күзең,
Ә йөрәктә—шушы сүзең...

* * *

Көчле булдым гомер буе,
Инде көчсез буласымы?
Көчле иңнәргә таянып
Гомер юлын узасымы?
— Көчлеңеке замана,—дип
Әйтәләр, бу дөрес микән?

Бары нахак, ялган сүзләр
Көчлеләрне көчсез иткән...
Синең иңне көчле диеп
Килә кайчак таянасым.
Көчсез булып кыланмыйча,
Көчле булып баш куясым...

* * *

Ярты бәхетемне таптым
Җәйнең тап уртасында.
Мәхәббәт канатын җәйде
Җир шарының без яшәгән
Иң матур ноктасында.

Назлы сөю чишмәсеннән
Бәлзәмнәр алып эчтем.
Күк капусы ачылдымы
Алиһә булып очтым,
Җир шарын назлап кочтым.

## Табыну

Мин сиңа табынмадым,
Син миңа табынмадың.
Сине күргәч абынмадым,
Син дә бит абынмадың.

Бер сукмактан атламадык,
Таңнар да аттырмадык.
Күктән йолдыз чүпләмәдек,
Аерылгач кайгырмадык.

Кисәк... Төннәр яктырды да
Ай нурын бергә эчтек,
Әйтерсең лә йөрәкләргә
Айның сагышы күчте.

Иреннәр татлы иде дә,
Сагышлар әче иде.
Бу безнең ялгыш сөюнең
Әремдәй яше иде.

Син миңа табынмадың,
Мин сиңа табынмадым.
Кар астында эзләр калды—
Аларга кагылмадым...

## Гел сагындырачак «тәрәзә»...

*Шагыйрь, тәнкыйтьче, мөхәррир әдип Наис Гамбәр исеме укучыларыбызга яхшы таныш.*

*Исән булса, аңа бу айда 60 яшь тулган булыр иде. Мәрхәмәтсез үлем аны моннан ике ел элек—2005 елның маенда арабыздан алып китте. Әмма эшләгән эшләре, ул редакцияләгән китаплар—безнең арада; язганнары—онытылмый. Үзе исәндә «Баш очымда—Кояш» (1991), «Күзләрем яфрак коя» (2001) исемле китаплары дөнья күргән шагыйрьнең 2006 елда «Рухият» нәшриятында «Ачык калган тәрәзәм» исемле затлы бертомлыгы басылып чыкты; быел исә Татарстан китап нәшриятында «Яшәү тамыры» исемле сайланмасы дөнья күрәчәк. Шигъри мирасы белән бергә беренче мәртәбә анда Н. Гамбәрнең хикәяләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, эсселары, Х. Туфан, Р. Фәйзуллин, Р. Даутов, Роб. Әхмәтҗан, Зөлфәт һ. б.ның иҗат портретлары, лирик язмалары тупланып бирелә.*

*Ә шагыйрьнең үз шигъри почеркына—Яшәү һәм Мәңгелек, Кеше һәм Туган җир, Матурлык һәм Мәхәббәт кебек төшенчәләрне фәлсәфи күзаллау, киңлек, җете сурәтләр муллыгы хас. Хезмәттәш дустыбызның соңгы шигырьләреннән сайланып бу санда тәкъдим ителә торган бәйләм дә шуны раслый дип ышанабыз.*

Наис
Гамбәр

# АЧЫК КАЛГАН ТӘРӘЗӘМ

* * *

**Сулар!—күпме яшьләр түктем сезгә карап…
Акты-китте еллар ярык ялгашлардан,—
Юшкын гына калды сөю, ялгышлардан…
Утыра таллар оеп, алтын чәчен тарап.**

**Җилләр!—сагышымны җилләр җилгәрделәр.
Мамык коя тупыл—уйның җәйге буран.
Бары да элеккечә: капка төбе, урам…
Җилгә язып хатлар, хатлар җибәрделәр.**

**Җирем!—табанымның эзен яшерегез!—
Тик каплагыз аны яшел чирәм белән.
Мин китәрмен беркөн… Бәлки, бүген китәм.
Җилдә,
Җирдә,
Суда—сүнми Сөю!.. Сүнми, кичерегез…**

## Теләү

Чык син, Кояш!
Күтәр әле томан пәрдәләрен...
Ачып куйыйм язгы тын җилләргә
Күңелемнең аяз тәрзәләрен.
Чык син!

Чык син, Кояш!
Ял итсен баш, күтәрелсен иңнәр,
Шатланышсын җанда бар мәләкләр;
Чәчәкләргә кунып уйнасыннар
Аллы-гөлле, саргылт күбәләкләр.
Чык син, Кояш!

Чык син, Кояш!
Коенсыннар нурга урман-кырлар.
Агач-үләннәре, барча хәят...—
Һәм уяныр танда йокысыннан
Яшәү дигән олуг бер хикәят.
Гөлләр көтә сине,
Чык син, Кояш!

## Исә җилләр...

*Җилләр агач башыннан исә.*
Халык сүзе

Исә җилләр агач башларыннан,
Сабантуйдан гөрли чаукалык[1];
Агачларда—оя, алар җилдә
Бишек сыман тора чайкалып.

Җилләр исә... Җилгә канат куеп
Кошлар бүген бала очыра;
Ходай ныклык бирсен,
Аһ, кошларның
Оялары агач очында.

Ә биектә җилләр, ай-һай, хәтәр,—
Бөтерелеп ага ак болыт;
Кошлар туа, күзли киңлекләрне,
Агач башларында атынып.

Анысы бар,—
Кош баласы канат белән туа,
Егыла да баса... җилпенә;
Очар кошлар каурый чыгар-чыкмас
Ташланалар җилләр иркенә.

Оча алар җилгә күкрәк куеп,
Гел биеккә, күккә талпынып.
Тукта, урман, тик бер генә минут,
Кошлар өнен тыңлыйк, тор тынып!

[1] Чаукалык — куаклык.

...Исә җилләр агач башларыннан,
Үзәннәрдә тынлык, «шым» да юк;
Мең тавышы белән гүли урман...
Шагыйрь җаны да бит шулай ук
Тына белми;
Алар тартым бераз
Оя корган кошлар халкына:
Алар да гел җилләр кочагында,
Гел биектә канат кагына.
(Урман җиле, иң беренче булып,
Биек агачларга кагыла.)

Исә җилләр агач башларыннан...

## Төш

Сәер төш иде ул... Тора идем
Кыя өстендә—диңгез ярында;
Беркемем юк иде тотынырга—
Дусларым да, сөйгән ярым да.

Мин әзер дә идем ташланырга
Кыя ярдан, түбән атылып,—
Ялгыз торна кебек бергәләнеп,
Ике кулым җәеп, атынып.

Шулчак
Кайдан тавыш инде?!
Жилме?!
«Тукта, егет? Сиңа иртәрәк!
Күрәсеңме: алда бер кыр ята—
Синең өлеш, куйган киртәләп.

Син чәчәргә тиеш анда орлык,
Таштан әрчеп, сөреп, йомшартып;
Агар гөрләвекләр, шытар үлән,
Нурга манылыр хәят кыш арты.

Тик тайчана күрмә буразнаңнан:
Язмышыңнан—исәрлегеңнән;
Олау-олау уңыш җыясың бар
Урылмаган кишәрлегеңнән».

Тыңладым да алдым кулыма каләм.

* * *

Таудан гына йөгереп төшәсе дә
Үргә генә сикереп менәсе;
Еракдагы алан, урман, кырлар—
Һымсындырып дәшә һәммәсе.
Баш очында гына якты Кояш,
Өзеп кенә ал—бәхет алмасын;
Хыял, өмет, сөю җилкендерә
Гомер бакый адәм баласын.
Киләчәк ул аргы ярда гына,
Басма аша гына чыгасы.

(Утка керәм, упкынын да үтәм,—
Тик йөрәгем генә чыдасын.)

## Арышлар шаулый

Бертуктамый шаулый арышлар
Мин үтәсе юллар өстендә;
Басу юлы—тузанлы юллар—
Балачактан калган танышлар.
Бертуктамый шаулый арышлар.

Арышларны сыйпап искән җил!—
Мине тагын сөендер әле.
Йөгереп-уйнап чапкан көннәрдән,
Бар, тиз генә хәбәр алып кил,
Арышларны сыйпап искән җил!

Алар ерак калдылар микән?
Беренче кат күрешкән көннәр,
Йөрәкләрне учларга куеп
Аерылмаска ант иткән төннәр,—
Алар ерак калдылар микән?

Аны эзләп таңнар аттырдым,
Күрмәмме дип юллар өстендә...
Сары чәчле шаян малайны
Әйтче, арыш, кая качырдың?
Аны эзләп таңнар аттырдым.

Бертуктамый шаулый арышлар—
Балачактан калган танышлар.
Арышларның башак шавында
Минем җаннан кучкән сагыш бар.
Шаулыйлар да шаулый арышлар.

* * *

Дулкыннар ярны кыйныйлар,
Җилләр бөгә талымны...
Исмә, җил, дулкын, бәрелмә!
Уйлыйм бергә чагымны.

...Ташкыннар ташып туктагач,
Ык төшкәч ярларына,
Безнең сөюнең ташкыны
Чыкты да ярларыннан,—
Таллары калды суларда
Күңелем болынының.
(Аклыдан күбәләк иде
Очында толымыңның;
Янмамын дип белдең микән?—
Утыма томырылдың.)

Күк гөмбәзен өскә ябып,
Дулкыннарда тирбәлдек;
Дулкында йөзә йолдызлар,
Без аларга тимәдек.

Җаныбыз айдан сирпелгән
Юл буйлап күккә табан
Ашты да—көмеш нурларда
Коендык бергә... Аннан

Атты таң... Алсу таңнарда
Зәңгәр томаннар инде.
(Синең дә ситсы күлмәгең
Нәкъ шулай зәңгәр иде.)

...Ташкыннар ташып туктагач,
Ык төшкәч ярларына,
Безнең сөюнең ташкыны
Чыкты да ярларыннан,—
Суларга калды күмелеп
Күңелем болыннары...
Күкләргә ашар идем мин,
Юл булса толымнарың.

Фәрит
Хатипов

# ӘСӘРНЕҢ ЭСТЕТИК ҖЕГӘРЕ

«Әдәби әсәрнең эстетик җегәре» гыйбарәсенә минем элегрәк тә мөрәҗәгать иткәнем бар иде. Ул чакта бу тәгъбир роман-повестьларның сыйфатын, камиллек дәрәҗәсен төсмерләтү нияте белән кулланылды. Әмма аңа нинди мәгънә салынганлыгы, ни-нәрсә аңлатканлыгы шәрехләп ачылмаган килеш кала бирде. Инде менә ошбу кәлимәнең эчтәлеге, мәгънәсе турында фикер йөртеп карау, кайбер якларын күздән кичерү ихтыяҗы туды.

«Җегәре», «энергия» сүзе гадәттә физик хәрәкәтне барлыкка китерү уңае белән әйтелә. Аның чыганагы, куәте ачык билгеле була. Поездда, машинада барганда без аны тәнебез, күңелебез белән тоябыз. Сәнгатьтә исә аны әсәрнең кешегә йогынты ясау, мавыктыру, үзенә җәлеп итү мәгънәсендә күз алдына китерергә мөмкин. Ләкин аның көч-куәте, механизмнардан үзгә буларак, күзгә бәрелеп тормый бит. Шулай булгач, әсәрнең үзенә тарту кодрәте хакында гәп кузгату урынлы булырмы соң? Минемчә, бик табигый булыр. Кояшның да куллары юк бит. Әмма бөтен планеталарны, ычкындырмыйча, үз тирәсенә тартып тора. Әдәбиятта да, әгәр без берәр әйбәт әсәргә юлыксак, төннәр буе аннан аерыла алмыйбыз, өчәр, дүртәр томлы романнарны йотылып укып чыгабыз. Тарту куәте булмаса, вакытыбызны, рухи көчебезне сарыф итәр идек мени?

Шулай да җегәр әсәргә каян килә соң? Әдәби әсәр—ул сүз ярдәмендә әдип тарафыннан төзелгән аерым бер дөнья. Шуны төзү барышында иҗатчы аңа биниһая күп, кайнар рухи энергиясен сала. Һәм шушы куәт эстетик кодрәткә күчә, әдипнең иҗат җегәре эстетик энергиягә әверелә.

Әмма моны укучының кабул итүе белән бәйләнештә карарга кирәк. Укылмаган чакта китап әле бернәрсә дә аңлатмый. Аның үзендә нинди серле, тылсымлы хәят яшерелгәнлеге бары тик укыганда, күңел һәм зиһен белән кабул иткәндә генә беленә. Димәк, «эстетик энергия» дигәндә әсәрнең мавыктыру, соклandыру сәләте, инсанны ышандыру, уйландыру, хисләндерү куәсе күздә тотыла. Бу процесста кешенең кызыксыну табигате дә әһәмиятле роль уйный булса кирәк. Димәк, иҗат барышында әдип персонажларының гына психологиясен күз уңында тотмый, укучыларның да рухи халәтен исәпкә алып эш итә икән. Чөнки укучы сюжетны пассив күзәтеп кенә калмый, ул аны бер үк вакытта күңеленнән кичереп, анализлап бара, ышандырмаса, эчтән бәхәсләшә. Әнә шулай вакыйгалар, бәйләнеш-мөнәсәбәтләр агышын күңеленә, зиһененә үткәрү, аларны анализлау, бәхәсләшү—әсәрне актив кабул итү дигән сүз ул. Укучы персонаж тойганны кичерә, гүя аның тормышы белән бергә яши.

## I

Һәрбер талантлы әдип үз әсәрен мавыктыргыч итәргә омтыла. Күп очракта моның өчен каршылыклар бәрелешен файдалана. Конфликтлар гаять күп төрле. Аларның исәбе-хисабына чыкмалы түгел. Шул ук вакытта каләм әһеле әсәренә үзенчәлекле, тапталмаган бәрелеш-бәхәсләрне алырга тырыша.

Жюльетта Бенцонинын «Марианна. Наполеон өчен йолдыз» дигән романында Марианна никахлашу кичендә, йокы бүлмәсенә кереп, ире Фрэнсисны көтә, әмма Фрэнсис әүәл кәрт уйнап алуны мәслихәт күрә... Ә төн уртасы житкәч, кәләш хозурына ире түгел, аның белән кәрт уйнаган Язон Бофор килеп керә һәм: «Ирегез сезнең бөтен байлыгыгызны, жир-суларыгызны, замогыгызны һәм ... Сезне оттырды. Беренче кичне Сезнең белән мин үткәрергә тиеш!»—ди. Күрәсез, ошбу гамәл төрле юнәлештәге конфликтларга, фажигага юл ача. Кияү егетенә ул артык кыйммәткә төшә.

Д. Х. Чейзның туксан дүрт романы да детектив жанрда язылган. Һәммәсе дә соң дәрәжәдә киеренке конфликтлы. Кайчак вакыйга хәтәр ноктага килеп житә дә, алга таба укырга куркып, тукталып каласың. Чөнки әсәрдәге психологик конфликт бик актив кабул ителә, аны персонажлар белән бергә кичерәсең. Шулай итеп, әсәрдәге рухи киеренкелек укучы күңеленә күчә, анда шундый ук диярлек киеренкелек хасил була.

Детектив әсәрләр гадәттә жинаятьне тикшерү, эзенә төшү юнәлешендә ижат ителәләр. Андый мәүзугъләр Чейзда да бар. Шуның белән бергә анда кылынган гөнаһ түгел, шул жинаятькә әзерләнү, ана бару юлларын чагылдырган әсәрләр дә очрый. Инде уй-ният соң дәрәжәдә камил төзелде, барысы да искә алынды дип уйлыйсың. Ләкин билгеле бер ноктада ул жимерелеп төшә, чәлпәрәмә килә. Шулай итеп киеренкелек һаман саклана бара.

Билгеле, зур тарихи вакыйгалар, кискен коллизияләр генә әсәрне мавыктыргыч итә дип уйларга ярамый. Мәсәлән, Әмирхан Еники әсәрләрен телгә алып китәргә мөмкин. Аның кайбер хикәяләрендә («Матурлык», «Туган туфрак», «Жиз кыңгырау» һ. б.) күзгә күренердәй ачык конфликтлар да беленми. Әмма алар да каршылыклардан азат түгел. Тик аларның характерлары башкача. Боларда эчке көрәш тасвирлана. «Туган туфрак» исемле хикәядә бабасының туган төбәгенә кайтыр алдыннан шәһәр кызы Клара күңелендә авыл турында бик беркатлы караш була. Әмма мондагы туганнары белән күрешкәч, аларның садә күңел байлыкларын тойгач, тирә-юнь табигате белән танышкач, теге карашны башка хисләр кысрыклый, туган туфракның хозурлыгын, тирән мәгънәгә ия икәнлеген аңлау тойгысы пәйда була аның яшь күңелендә. Әнә шундый әсәрләрне укучы ихлас яратып укый, хәтерендә саклый.

Тынгысыз каләм осталары сюжетның мавыктыручанлыгын арттыруда яңадан-яңа юллар эзлиләр. Чөнки беләләр: уңышлы табылган алым бөтен әсәрне нурландырып жибәрә ала. Майн Ридның «Башсыз жайдак» романында тасвирланган күренеш хәтсез вакыт дәвамында мистика кебек тоела: гайрәтле ат тегендә-монда чабып йөри, ә сыртына башсыз жайдак атланган. Тик ахырга таба гына моның билгеле бер бәрелешнең реаль нәтижәсе икәнлеге аңлашыла. Ләкин жайдак инде укучы дикъкатен жәлеп итеп өлгергән була. Әлеге алым драматик хәлгә кызыксындыру сыйфаты өсти.

Әгәр дә әдәби әсәрдә вакыйгалар үзара бәйләнешсез, бер-бер артлы гына теркәлсәләр, аларның эчке жегәре артык сизелми. Мондый энергия үзара бәйләнеш нәтижәсендә, эпизодлар нәрсәгә булса «тотынып» туганда гына барлыкка килә. Шуларның мөһиме—нинди дә булса бер ситуация эченә сыйган күренешләрне алып тасвирлау. Ситуация—әсәрне оештыруның бик мөһим чарасы ул. Әсәргә тотынып өчен тема сайлау гына житми. Күренешләрне берләштерердәй, үзара бәйләрдәй ситуация кирәк. «Ситуация» дигәндә без хәл-әхвәлләрнең чикләрен, аларның билгеле бер вакыйгалар белән каймалап, элмәкләп, «киртәләп» алынуын күздә тотабыз. Элегрәк, совет чорында, моның өчен еш кына берәр производство циклы хезмәт итә иде. Әмма классик әдәбият үзен гел моның белән генә чикләргә теләмәде. Әмирхан Еники, мәсәлән, мөнәсәбәт-кичерешләр өлкәсен үз итте. Аның «Гөләндәм туташ хатирәсе» Салих Сәйдәшевкә багышланган. Бу бөек зат гүзәл музыкасы белән халык күңеленә кереп калды. Әмирхан Еники моны бик яхшы белә иде. Алай гына да түгел, ул әле бу якты, тылсымлы ижатның драматик, үкенечле ягын да бар олылыгы белән тоя иде. Композитор турындагы әтрафлы, тирән эчтәлекле мәкаләсендә ул 1980 елда «Салих Сәйдәш бәхетле идеме?» диган

сорау куя һәм аның иҗатташ дусты Кәрим Тинчуринның илдән сөрелүе нәтиҗәсендә Сәйдәш музыкасының сәхнәдән төшүен, моның нечкә күңелле, күркәм холыклы композиторга никадәрле рухи газаплар китергәнен күрсәтә. Үтә киеренке психологик сюжет өчен менә дигән материал! Әмма Еники моны алмады. Хикмәт әлеге драманы язарга ярамауда гына да түгел иде. Әдип музыкант Салих хәятендәге тагын да ныграк поэтик янгырашлы ситуацияне алды. Ул Салих мәгыйшәтенең яшьлек чорын, мәхәббәт хисләренең бик матур бөреләнгән, чәчәк аткан, әмма җимеш бирә алмый калган дәверен сайлады һәм шушы ситуация эчендә Салих белән Гөләндәмнең сокландыргыч образын гәүдәләндерде. Әсәрдә гүзәллек, затлылык белән моңсулык аралаша.

## II

Күренешләрне әсәр композициясендә урнаштыру алымнары күп кенә. Шуларның иң актив кулланылганы хронологик эзлеклелек, мәгыйшәтнең үз агымына нигезләнгән тәртип. Билгеле, моның кыенлыклары да бар: эзлекле хәрәкәт дәвамында образны җанлы итеп күз алдына китереп бастырырдай, теманы камил ачардай төс бизәкләр, хәл-әхвәлләрнең житәрлек күләмдә булуы шарт. Уңай ягы шунда: укучының кабул итүе өзлексез бара, буталчыклар арасына кереп адашу хәвефе юк дәрәҗәсендә. Романнардагы аерым сюжет сызыкларының билгеле бер ноктада беразга тукталып торуы, аларны башкалары дәвам иттерүе эзлекле, ачык күренеп торган динамиканы юкка чыгармый. Чөнки алар, үзара үрелешсәләр дә, ахыр чиктә барыбер алга таба хәрәкәт итәләр. Бу җәһәттән Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» (икенче вариант) бераз үзгәрәк урын били. Анда әдип биниһая киң планлылыкка омтыла, әсәргә бик күп персонажлар кертә, роман мәйданында алар бер-берсен өзлексез алыштырып торалар. Һәр каһарман биредә ике-өч мәртәбә генә күренеп кала. Шулай итеп, биредә композиция киңлеккә җәелә. Чамадан тыш киң планлылык тулы канлы, калку индивидуаль образ гәүдәләндерү мөмкинлеген беркадәр чикли төшкән. Ошбу хасияте белән «Безнең көннәр» Г. Ибраһимовның үзенең кайбер әсәрләреннән дә аерыла төшә.

Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романының да композицион оештырылышындагы бер үзенчәлек күзгә ташлана. Әсәр үзендә ике романны берләштергән кебек тоела. Анда бар утызынчы еллардагы Иргали тормышы, анда бар Газинең катлаулы язмышы, нефтьчеләр эшчәнлеге. Шушы ягы белән ул гадәти романнардагы сюжет сызыкларының аралашуыннан аерылып тора. Гадәттә, әсәрләрдә сюжет сызыклары никадәр генә тармакланмасын, алар бер үзәккә тоташа. «Язгы аҗаган»да исә үзара бәйләнмәгән ике үзәк күзгә чалына. Иргали язмышын Мәхмүт Хәсәнов моңарчы күрелмәгәнчә рухланып, илһамланып иҗат итте һәм бик үзенчәлекле, җанлы образ тудырды. Әмма ошбу каһарман эргәсендә нефтьчеләр сызыгы бераз тоныкланыбрак кала...

Бәгъзе романнарда, хәтта ки күренекле прозаиклар иҗатында да, эпизодик чигенешләр хәтсез урын били. Билгеле, әгәр дә нинди дә булса серне чишүгә хезмәт итсә, алар үзләрен акларга да мөмкин. Әмма еш кына алар тема белән турыдан-туры бәйләнмәгән була, тик әсәр мәйданын нәрсә белән булса да тутыру өчен генә кертелгән кебек тоела. Билгеле инде, андый чигенешләр сюжет динамикасын туктатып торалар. Укучы исә тоташ хәрәкәтне кабул итәргә әзерләнгән була. Шунлыктан кирәксез чигенешләр аның күңелендә ризасызлык хисе уята.

Кайбер каләм әһелләре буталчык сюжет төзүне хуп күрәләр. Әмма күпчелек укучы психологиясе аларны югары бәяләми. Ул ачык, төзек сюжетны мәслихәт таба. Чөнки чуалчык сюжет укучы аңында да буталчык манзаралар калдыра.

## III

Инде әсәрнең инандыру тылсымына килик. Күренекле әдипләр моңа бик җитди әһәмият бирә, күренешләрнең тормышчанлыгына, уй-тойгыларның ихласлылыгына хилафлык кертмәскә тырыша. Чыннан да, кәгазьдә язылганны укучы берсүзсез кабул иткәндә генә әсәр яшәргә хокук ала. «Язучы алдында,—ди Фатих Хөсни, берөзлексез

сорау тора:—Тукта! Минем язганнарым тормыш чынлыгына хилаф түгелме? Укучы моны нәкъ тормышның үзе дип кабул итәрме? Тормыш чынлыгы, аның бөтен каршылыклары белән чәбәләнеп беткән катлаулылыгы, укучыны язганына ышандыру менә болар, ахыр чиктә, чын язучыны һавасыз бушлыкка очып китүдән саклый торган иң төп шартлар инде» *(Хәсни Ф. Карурманга керәм.—Казан: Т кит. нәшр., 1985.—22 б.)* Шул ук вакытта ул мона ирешүнең үтә катлаулы, газаплы булуын һәм ару-талуны белмәс эш икәнен дә искәртә.

«Иҗат иткәндә мин үз алдыма берничә максат куям,—диде миңа бер әңгәмә вакытында Әмирхан Еники.—Беренчедән, әсәр логик эзлекле, бәйләнешле булсын, икенчедән, укучыны ышандырсын, өченчедән, анда балласт, буш сүз булмасын». Әйе, классик әдипләрнең әсәрләрен укыганда күренешләрнең чынлыгына карата күңелдә бервакытта да шик уянмый. Аларны табигый хәл дип кабул итәсең. Әгәр инде чынлыкка хилаф картиналар әсәргә килеп керсә, укучыда сәерсенү, гаҗәпләнү барлыкка килә. Әйтергә кирәк, мотивлаштыру, сәнгатьчә нигезләү дәрәҗәсе безнең прозада еш кына авыр мәсьәлә булып кала бирә. Марат Әмирхановның «Тояк эзе» дигән әсәрендә Кәшшаф үз мәгъшукасына мәхәббәт хаты яза да, бичә дә укып кинәнсен дигәндәй, копиясен өстәлдә калдырып китә. Мондый хәл кискен коллизия тудырырга сәләтле, әлбәттә. Ләкин шулай да ярәшен гыйшык мәктүбенең күчермәсен алу һәм аны өстәлгә куеп китү кадәресе укучыны ышандырып җиткерми.

Вахит Имамовның каләме шактый үткен, җитез икәнлеге күпләргә билгеле. Ул эзлекле, дәлилле итеп яза белә. Шул ук вакытта аның «Утлы дала» сында сәер генә бер эпизод күренеп китә. Тимучин гаскәрләре бер вакыт бик мөшкел хәлдә кала. Шул чак Билгутай мондый тәкъдим кертә:

«—Тимучин! Бер мең җайдак бирсәң, мин әнә теге тау башына менәм. Шуннан мәркетләр өстенә бүрәнәләр илә ташлар очырамыз.

Тимучин кул астындагы чирүдән бер мең җайдак аерылып китүне шәйләп калсалар да, мәркетләр аларның кай якка юнәлүен аңламадылар. Ә бермәлне янда гына торган биек тау битендә йөзәрләгән җәяүле пәйда булды һәм шул минутта ук мәркет укчылары өстенә эре-эре ташлар, юан бүрәнәләр тәгәрәп төшә башлады. Орхон тамагында коточкыч зур гарасат кузгалгандай булды, сафлар буталышты, бар инкүлек өстен ачыргаланып һәм ярсып кычкырышкан тавыш каплап китте» *(«Казан утлары», 2000, № 3.—18 б.)*

Әмма ул бүрәнә, ташларны алдан кемнәр меңгереп куйган? Тәгәрәгән чакта, каршылыкка очрап, алар нишләп туктап калмаганнар? Әсәрдә мондый сораулар куелмаган, аларга җавап та бирелмәгән. Чынлыкта исә каршы як гаскәрләренең, бүрәнәләр тәгәрәтүчеләргә карап, «болар нишлиләр икән?» дип ваемсыз гына күзәтеп торган булулары да ихтимал.

Әдәби мотивлаштырудагы бәгъзе кимчелекләр еш кына халыкның әхлак нормалары, кардәшлек, туган-тумачалык кануннары белән җитәрлек исәпләшмәүдән килеп чыга. М. Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да» романында сурәтләнгәнчә, башкисәр Сирай ил-көн алдында консерватория студенты Зөлфиянең әтисен үтерә. Шул ук Сирайның улы Котбый әлеге Зөлфиянең сөйгән егетен кыйнап гарипләтә: «Котбый бар көченә ботинкасы белән егетнең аркасына типте» *(М. Хәбибуллин. «Сулар үргә акса да...» Казан: Татар, кит. нәшр., 179 б.).* Тимер башлы ботинкасы белән Котбый әлеге егетнең арка сөяген сындыра, аны йөри алмаслык хәлгә җиткереп имгәтә. Зөлфия шушы вәхши манзараның шаһиты була. Реаль яшәештә мондый зобани, җинаятьчел нәселгә мөнәсәбәт ике төрле була алмый. Әмма Зөлфия башкача карый: ул кансыз Котбыйны үзенә яр итеп сайлый. «Дүрт елга якын йөрдек бит...» *(297 б.),*—ди ул сеңлесе Кәримәгә. Шулай итеп, әсәрдә рәхимсезлекне, гаиләгә китергән фаҗигане хуплау кебек килеп чыга. Билгеле инде, Зөлфиянең явыз егетне үзенә иш итүе, мөнәсәбәт-бәйләнешләрдәге талымсызлыгы укучыны чиркандыра, кәефен кыра.

«Илчегә үлем юк» әсәрендә дә яшәешкә хилаф шундыйрак күренеш тасвирлана: вәзир Исхак Сәлим ханга, аз да түгел, күп тә түгел, «кала торгызыласы төбәккә хан нәселеннән ир бала корбан итәргә» киңәш бирә *(М. Хәбибуллин. «Илчегә үлем*

*юк»,—Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.—20 б.).*

Әгәр реаль тормышта берәрсе хан тикле хан нәселенә әнә шулай кизәнсә, хан моның өчен кинәш бирүченең үзенең башын чаптырыр иде. Әмма әсәрдә Сәлим хан башкача хәл итә, бернинди нигезсез, тик вәзир коткысына гына бирелеп, үз токымын корытырга җыенгандай, ул язмача шундый фәрман бирә: «Вәзир Исхак, Чияле тауда Гали белән Булат оныкларыма җирәбә салдыр. Кайсына җирәбә чыга, шуны яңа кала сарае салынасы төбәккә корбан иттер. Болгар ханы Сәлим. Милади белән 1167, һиҗри белән 562 елдыр» *(107 б.)* Ягъни ике оныкның берсен үтерергә боера.

Безнең халыкта баланың баласы балдан татлы дигән гыйбарә бар. Бу юлларны укыгач, «автор үз алдына чиктән тыш рәхимсез ханны гәүдәләндерү максатын куйды микәнни?» дигән сорау туа. Әгәр шулай икән, ул чагында аны бөтен әсәр буенча әлеге юнәлештә сурәтләргә, ерткычлыгын күрсәтеп барырга тиеш иде. Әмма шул ук Сәлим хан М. Хәбибуллинның «Шайтан каласы» романында нечкә хисле, шәфкатьле кеше итеп бирелә. Ул бер орыш вакытында кан коюдан—энесе Мөхәммәтгалим бәкне үтерүдән—баш тарта.

Димәк, «Илчегә үлем юк» романында Сәлим ханның үз оныгын үтерергә фәрман бирүе аның ерткыч характеры белән мотивлаштырылмый булып чыга. Алайса ул нәрсә белән нигезләнә соң? Моңа, тавык чалган кебек, вак нәрсә дип каравы беләнме? Ләкин онык үтерүгә әһәмиятсез гамәл дип карау мөмкин мени?

Шулай да чын сәнгатьчә әсәрдә унай персонажлар хәятендәге үкенечле хәлләр сурәтләнә аламы? Сурәтләнә, әлбәттә, ник сурәтләнмәсен? Әмирхан Еникинең «Вөждан» повестенда төп герой Хәбиб Юлдашев киеренке бер психологик ситуациядә, аңлашмыйча-нитмичә, өзелеп сөйгән кызы Хафазаны ташлап шәһәрдән китеп бара һәм гомер буе ямансулап яши. Фатих Хөсни егетнең мондый адымы белән килешми, Хәбиб Хафазаны күреп сөйләшергә тиеш иде, дип саный. Бу очракта Фатих Хөсни укучы буларак фикер йөртә. Саф күңелле ике яшь йөрәкнең кушыла алмавы, күркәм мәхәббәтнең моңсу финалы аның күңелендә, барчабызга да хас булганча, кызгану хисе тудыра.

Ләкин мәсьәләнең хикмәтле ягы шунда, Фатих Хөсни, язучы буларак, үзе дә шундыйрак хәлне тасвирлый. «Йөзек кашы» повестенда сурәтләнгәнчә, туй вакытында Айдар, мәсьәләнең асылы турында уйлап-нитеп тормыйча, сөйгән кызы Вәсиләне ташлап китә, мәкер корбаны була.

Бу повестьларның икесе дә—гүзәл әсәрләр. Аларда яктыртылган үкенечле күренешләрне дә кимчелек дип әйтеп булмый. Егетләрнең мондый адымы аларның характерлары белән нигезләнә, укучыларны озак вакытлар уйланырга мәҗбүр итә.

## IV

Реалистик сәнгать тә, романтик язучылар да тормышны чагылдыра, аның кануннары, логикасы буенча эш итә, поэтик бизәкләрне дә шушы чыганактан ала. Тик шулай да иҗатчы чынбарлыкка охшаш сурәтләр белән генә чикләнми. Кайбер әсәрләрдә, эстетик ихтыяҗ белән, мәгыйшәт формаларыннан ераклашу үрнәкләре дә очрап тора. Моның башлангычларын без фольклорда да күрәбез. Бер мәкальдә болай дип әйтелә: «Кеше ат дагалаганда, бака ботын кыстыра». Чынында бит бу җан иясе тимерче шөгыленә килеп керми. Ул биредә тик чагыштыру максаты белән генә алына. Андый чагыштыру, чыннан да, ситуацияне бик ачык итеп, җанлы төстә күз алдына китереп бастыра.

Язма әдәбиятта, бигрәк тә поэзиядә, иҗатчы сурәтле бизәкләр белән шактый иркен эш итә, күренешне төгәл сыйфатлаудан да бигрәк укучы күңелендә билгеле бер хис калдырырга омтыла. «Өзелгән өмет» шигырендә Габдулла Тукай, мәрхүмә әнисенә мөрәҗәгать итеп, болай ди:

«Барча күңелләрдән җылы, **йомшак** синең **кабрең ташы**». Монда «җылы» эпитеты туры мәгънәсендә килгән. Мин биредә ташның йомшаклыгын белдергән гыйбарәгә игътибар юнәлдермәкче булам. Таш—таш инде, ул йомшак була алмый. Ләкин берәү дә әлеге поэтик сурәтне туры мәгънәсендә аңламый. Көчерелмә сүз ул.

Шагыйрь әнисе истәлегенең никадәр кадерле, газиз булуын тойдырыр өчен шундый чагыштыруга мөрәҗәгать иткән. Ләкин моның өчен бер дә җисемле предмет сайламаган, абстракт күренешне мәгъкуль күргән. Җанлы сөйләмдә «йомшак күңел» тәгъбире актив кулланыла. Ташның йомшаклыгын шагыйрь әнә шул күңел йомшаклыгына тиңли. Шуның нәтиҗәсендә төшенчәләрдә бераз авышу барлыкка килә, ташның йомшаклыгы хакындагы сурәтнең шактый өлешен әлеге «күңел» үзенә тартып алгандай була. Шуңа күрә сыйфат белән сыйфатланмышның логик ярашмавы шигырьдә әллә ни сизелмичә үтә. Әсәр тойгылар динамикасын катлаулы ассоциацияләр аркылы бәян итүгә корылган. Бирегә бөтен хикмәт—рухи халәттә. Лирик геройга кабер ташы да йомшак булып тоела. Аерым телбизәк чарасының хәят күренешеннән ераклашуы шагыйрьнең әнисенә олы мәхәббәтен гаҗәеп зур поэтик көч белән әйтеп бирүгә хезмәт итә.

Куллана белеп кулланганда көтелмәгәнлек тә әдипкә мул уңыш китерергә мөмкин. Мона новеллалар бик маһир. Бездә аның танылган остасы Фаил Шәфигуллин иде. Бу җәһәттән ул дөнья классикасы, татар әдәбияты традицияләрен уңышлы дәвам иттерде. Аның әсәрләрендә көтелмәгәнлек юмор белән аралашып бара. Көлке хәл гадәттә нормадан тайпылу, шуны норма дип дәгъва кылу җирлегендә туа. Автор үз новеллаларының берсен «Ерак якларда» дип атаган. Бу исем чит җирләрдәге хәл-әхвәлләрне хикәя кылуны вәгъдә итә. Персонажларның җитди әңгәмәләре дә башта шуны сиздерә. Туфан Миңнуллин вагон тәрәзәсеннән карлы кырга карый да, үз алдына сөйләнгәндәй, әйтеп куя:

—Семьялар ни хәлләрдә икән инде безнең?

Аяз Гыйләҗев та, башкортның «Ирәндек» җырындагы кебек, шундыйрак рухта өстәп җибәрә:

—Ни күрмәгәнне ат башы белән язучы хатыны башы күрә.

Зөлфәт проводниктан сорап белешә:

—Простите, ресторан кайсы вагонда монда?

Шул рәвешле гәпләшеп алганнан соң автор нәтиҗә ясап куя:

«Казан—Арча» поезды Биектауга якынлашып килә иде».

Бусы инде үзенең мәгънәсе белән теге сөйләшүләрдән нык кына аерылып тора. Баксаң-күрсәң мосафирларның сәфәр чыгуларына күп дигәндә ярты сәгать узган, егерме чакрым тирәсе җир киткәннәр. Алдагы әңгәмәнең эчтәлеге белән соңгы җөмләнең ярашмавы әсәргә юмористик аһәң бирә. «Ерак якларда» дип аталуының да елмаю уяту өчен сайланганлыгы аңлашыла.

## V

Һәр сәнгать төренең үзенә генә кулай сурәтләү предметы була. Шуның белән бергә аның затлылыгы да мөһим роль уйный. Дөнья әдәбиятындагы күренекле әсәрләр кеше яшәешенең тирән мәгънәле, кызыксындыручан, үзенчәлекле якларын яктырту җирлегендә пәйда булганнар, шуның аркасында үлемсезлек яулаганнар.

Тагын монысы да бар: әдәби әсәр үз табигатенә ярашлы күренешләрне үз итә. Без гадәттә прозага, эпик төргә вакыйгалылык хас дип сөйләргә яратабыз. Ләкин вакыйга белән вакыйга арасында да аерма бар. Роман, повесть, хикәя теләсә нинди күренешне үз итми.

Шамил Усмановның «Легион юлы» әсәренең эчтәлеге исеменнән үк төсмерләнә. Автор монда, рапорт биргәндәге кебек, хәрби берләшмәнең көрәш тарихын яза, ягъни коллектив башкарган гамәлләрне хикәяли, ә аерым шәхес онытылып тора, кешеләрнең үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтләре, тойгы-кичерешләре игътибардан читтә кала. Нәтиҗәдә индивидуаль образ барлыкка килми. Әсәр очерк табигатенә туры китеребрәк язылган.

Вахит Имамовның «Утлы дала» әсәре матур әдәбият кануннарына ярашлы рәвештә языла башлый. Тора-бара әдәбилек белән тарихи язма аралашып китә, еш кына тарих өстенлек ала. Автор аны да әдәбиләштереп бирергә омтыла. Әсәрнең буеннан-буена киеренке көрәшләр бәян ителә. Драматик бәрелешләр бер дәүләт кысасына гына сыеп калмый. Бирегә Русь иле, Болгар, Монголия дәүләтләре

тасвирлана. Әсәрнең географик масштабы бик нык киңәя. Әмма, кызганыч, төрле мәмләкәтләрдәге вакыйгалар арасындагы бәйләнеш ачык сизелми.

«Атилла» әсәрендә Мөсәгыйт Хәбибуллин да сәнгатьлелек белән фәннилекне берләштерергә омтыла кебек. Бу—шактый сирәк күренеш. Әдәбият тарихында тәүге тапкыр күзгә чалына. Анда автор хикәяләвенә гыйльми хезмәтләрдән алынган күпсанлы белешмәләр кушылып бара. Аларның нинди характерда икәнлеге түбәндәге мисалдан аңлашыла:

«Рим. Июль, 403 ел. Аларих король чигенсә дә Римне яулау ниятен ташламый. Ул кыш узуга, таулардан кар китүгә, Берннер күчеше аша Рециягә узарга, ахыр Галлиягә үтәргә җыена. Ул шымчылар аша белә, империянең андагы гарнизоннары сыек. Стилихон да тик ятмый, Аларих корольнең ниятен сизеп, ул хәрәкәт иткән Амесис елгасы буендагы тарлавыкка юнәлә һәм готлар короленең артына төшеп, көтмәгәндә һөҗүм итә. Аларих король зур югалтуларга дучар ителә, әмма төп гаскәрен саклап кала—көнчыгышка таба чигенә. Стилихон аны куа барырга кыймый һәм король белән солых төзергә мәҗбүр була. Бу вакытта Рим императоры Гнория башкаласын Миланнан яхшы ныгытылган, тирә-яклары сазлыклы булган Равеннога күчерә. *«Сугышлар тарихы» китабыннан*».

Цитаталар һәммәсе бертөрле: Кытай, Иран, Рим, Византия, Британия дәүләтләрендәге, ягъни әлеге әсәр темасына катнашы булмаган төбәкләрдәге сугышларны хәбәр итә. Әсәрдә шундый 62 цитата теркәлгән. Әмма аларның берсе дә хәтердә калмый һәм кирәклеге дә сизелми.

Әсәрнең уртасында гына баш герой булырга тиешле персонаж—Атилла—мәйданга чыга. Ләкин ул бик аз күренә. Шунда ук автор чит мәмләкәтләр турында сөйләүгә күчә. Стиле белән автор хикәяләве дә теге цитаталарга якын тора: «Парфәннәр нәселеннән тәхеттә утырган шаһиншаһ Артабанны соңгы орышта каһин Сәсәннең оныгы Арташир үтерә. Милади белән 224 елда була бу. Әнә шуннан соң каһин Сәсән Иран тәхетенә оныгы Арташирны утырта. Арташир үлгәннән соң Иран тәхетенә аның улы Шапур утыра. Шапур чорында Фәрүз каласында туган һәм шунда мөбәтләр хәрәкәтен кузгатып җибәргән каһин Мани күтәрелә».

Грекларның София храмы турында гына да әсәрдә әллә ничә бит языла. Ләкин ул мәгълүматларның берсе дә Атилла образы, әсәрнең темасы белән бәйләнмәгән. Аларның берсендә дә Атилла исеме телгә алынмый.

Шулай итеп, аерым әсәрләрдә фәннилеккә таба авышу күренә. Яхшымы бу, начармы? Ә бит табигатьтә, үсемлекләр, җәнлекләр дөньясында төрнең сафлыгын саклау тайпылышсыз канунга әйләнгән. Бик сирәк кенә ике җенесле җан иясе—гермофродит—туа икән, ул яшәүгә, тормышка сәләтле булмый. Тарихи әсәр дә—тарих сөйләү түгел. Моның өчен аның үз фәне бар. Тарихи роман исә үткән дәвердәге аерым шәхесләрнең яшәешләрен: эш-гамәлләрен, бәйләнеш-мөнәсәбәтләрен, уй-кичерешләрен бәян итә, анда тарихи күренешләр үзмаксатка әйләнми, алар конкрет персонажлар хәяте аркылы белдереләләр, аерым шәхесләр мәгыйшәтен тасвирлау процессында чагылалар. Моның күркәм мисалы—Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары. Без аларда билгеле бер чорда инсаннарның ничек яшәгәнлекләрен, ничек көн күргәнлекләрен беләбез, тарихи атмосфераны тоябыз, әмма бер җирдә дә коры тарих сөйләүне, персонажлар мәгыйшәтеннән аерылып, фәнгә кереп китүне очратмыйбыз.

Монда, әлбәттә, әдәбиләштерелгән тарихны тыю хакында сүз бармый. Әгәр, әйтик, Вахит Имамов үзен шул өлкәдә көчле сизә икән, аның фикер агышы шул якка тарта икән, ул әлеге юнәлештә иҗат итсен. Әмма бу очракта фәнни-популяр әсәрнең жанрын төгәл билгеләү сорала.

Совет чорында, социаль детерминизмның ролен артык күпертеп, һәр әсәрдә, теманың нинди булуына карамастан, зарури рәвештә иҗтимагый вәзгыятьне яктырту таләбе куела иде. Күп кенә очракларда ул сәнгатьлелек сыйфатын киметүгә китерде. Тәнкыйть бу юнәлештә әдипкә конкрет күрсәтмәләр дә биргәләде. Мәсәлән, Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романы уңае белән язылган мәкаләсендә Хәсән Хәйри «тарихи проблемаларның әдәбиятта киң реалистик чагылышын күрергә» теләи. Ул әдәби әсәрдә дәүләтләрнең килеп чыгышы, аерым алганда, Болгар

дәүләтен төзү, Биләр, Сувар, Болгар калалары һәм, гомумән, шәһәр төзелеше турында, ислам динен кабул итү, Болгарда елга флоты, һөнәрчелек, «тарихи-иҗтимагый, политик процесслар» турында бәян итүне, «фактларга тарихи-философик бәя бирүне» кирәкле саный. «Билгеле дәрәҗәдә культура булуын күрсәткән шәһәрләр, таш, тимер осталары, Этил һәм Чулман суында хәрби, сәүдә һәм балыкчы көймәләре йөрүе һ. б.—экономик һәм рухи культурага караган бу факторларны ничек исәпкә алмаска мөмкин икән?» дип сорый *(Хәсән Хәйри. Язучы һәм тормыш.—Казан: Татар, кит. нәшр., 1979.—195–196 бб.)*, тарих, фәлсәфә, экономика, социология фәннәре бурычларын бер әдәби әсәр алдына китереп куя. Әмма моны әдәбият турында профессиональ сөйләшү дип әйтеп булмый. Андый мәгълүматлардан фәнни хезмәт кенә килеп чыгарга мөмкин. Әгәр дә аларны әсәр тукымасына сипли башласаң, дынгычлап тутырсаң, композиция әле бер җирдән, әле икенче яктан бүселеп чыга, сюжет киеренкелеге бетә, персонажлар әлеге «тарихи-иҗтимагый, политик процесслар» астында күмелеп, югалып-тоныкланып кала, әсәр җыйнаклыгын, төзеклеген югалта.

Гомумән, классик әсәрләр күрсәткәнчә, аларда вакыйга үзмаксат буларак тасвирланмый. **Әдәби әсәрдә персонажларның үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтләреннән, язмышларыннан килеп чыга торган вакыйгалар бәян ителә.**

Әйе, һәр сәнгать төренең үзенчәлекле табигатен нечкә тою, кануннарын төгәл үтәү, мөмкинлекләрен бар куәтенә файдалану уңышлы иҗатның төп шарты ул. Күпчелек житешсезлекләр исә матур әдәбиятнең хасиятен, асыл сыйфатларын санга сукмаудан, алар белән исәпләшмәүдән килеп чыга.

* * *

Җыеп кына әйткәндә, эстетик җегәр—ул әсәрнең укучыны мавыктыру, сокландыру көче, тойгыга, зиһенгә тәэсир итү сәләте. Әнә шундый эчке куәт җирлегендә иҗат җимеше үзенә карата мәхәббәт яулый. Эстетик энергия югары сәнгатьлелек җирлегендә барлыкка килә. Әсәрнең бөтен өлешләре шуна хезмәт итә. Талант иясе моны ачык тоя һәм бөтен рухи, иҗат сәләтен шундый камиллеккә ирешүгә җигә. Үз нәүбәтендә эстетик җегәр әсәрнең сәнгатьчә кыйммәтен тоярга ярдәм итә. Үткән гасырда күренекле әдипләребез, идеологик һәм сәяси чикләүләргә дә карамастан, артык шауламыйча гына, югары сәнгатьлелеккә ирешүдә үзара ярышалар иде кебек. Хәзер дә иҗади камиллек юнәлешендә ирешелгән биеклекләрне күрәсе килә.

---

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

Илшат
Вәлиулла

# РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН ШИГЪРИЯТЕНДӘ МОҢ ҺӘМ САБАНТУЙЛЫК РУХЫ

*Гавамга мирас—моң, сагыш,*
*минә калган байлык.*
*Шулай да әле халыкта гамь,*
*байтак Тукайлык.*
(«Гөмбәзләре—кояшмыни!..»)

*Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга*
*җитә сирәге!*
(«Бәйрәмнәр күп...»)

*Бүген көрәшәбез әле!*
*Җирнең пакьлеге өчен,*
*Илнең аклыгы өчен!*
(«Карт һәм Шагыйрь»)

## Сабантуйлык—Ир-егетлек, Көрәшчелек фәлсәфәсе

Һәркемнең дә үз газиз халкы-милләте турында уйлана башлавы кинәт кенә түгел, ә тирәннән, бәгырь төбеннән үк сызлана башлаган чоры була... Безнең буын өчен ул әле генә хәрби хезмәттән кайтып төшкән 1980 еллар ахырына туры килде. Нәкъ шул үзгәртеп корулар башланып киткән елларда, ерак ил-җирләрдән (кем—Әфганстаннан, кем—Алманиядән, кем—Тын океаннан) әйләнеп кайткач, милләттәшләребезнең үз тирәлекләрендә туган тел мәсьәләсендә күпмедер мескенчәрәк тотулары игътибарны җәлеп итә иде. Шунысы күзгә ачык ташлана иде: кардәш-милләттәшләр җәмәгать урыннарында татар телендә ничектер кыенсыныбрак, оялып, пышылдап диярлек аралаштылар. Телгә мондый мөнәсәбәт күңелдә төрле каршылыклы, сагышлы уйлар, сораулар уятты.

Ни генә булмасын, безгә—әле генә хәрби хезмәттән кайтып төшкән егетләргә—ул чакта милләттәшләребезнең үз (!) калаларында шулай мескенчәрәк тотулары гаҗәбрәк тоела иде. Чөнки ул чорда без, Совет Армиясендә хезмәт иткәндә, башка халык улларының гаҗәеп көчле милли горурлыгын күреп кайттык...

Бәлки, армиядән хезмәт итеп кайткач, 1985 елдан соң җәмгыятьтә ирек җилләре исә генә башлаган чорда тугандыр ул безнең күңелдә татар яшәешенең сәламәт үк булмаганлыгын, «яраланганлыгын» аңлау. Башкалар—өлкәнрәк зыялыларыбыз—моны күптән инде тойган-аңлаганнар иде. Хәер, ни генә дисәң дә, сөендерми иде бу: татар яшәешенең сәламәт үк булмавы, күпмедер бетәшкәнлеге, алман фәлсәфәчесе Фридрих Ницше терминологиясен кабул итеп әйткәндә, декадентлыгы.

Әмма татар яшәешенең яраланганлыгы, декадентлыгы күптән инде олы бер мәдәни-фәлсәфи-рухи күренеш булган Моң культында чагылыш тапты. Чыннан да, «Чура батыр», «Идегәй» ләр иҗат ителгәннән соң, татар мәдәнияте Моңлылыкка таба гаҗәеп бер үзгәреш кичергән! Кайчандыр барыннан да элек бөеклеккә, көчлелеккә омтылган, Ир-егетлекне беренче урынга куйган халык, аның милли

Бәйсезлеге, Дәүләтчеллеге тартып алынгач, моңлыланган, озак гасырлар дәвамында Моң белән «авырган».

Әйе, Татар Күңеле өчен Моң күренеше гаҗәеп мөһим иде... Чөнки Моңлылык ул кешенен төрле эчке һәм тышкы сәбәпләр нәтиҗәсендә (кайгы-хәсрәттәнме, сагыштанмы, хискә бирелгәннәнме, эчке рухи эзләнүләрдәнме...) Илаһилыкка Алгысуын, Сыгынуын, Юатылуын тирән анлата. Ул кеше эчендәге «мин»нен саф телен, анын Әрнү, Зарлану, Өметләнү, Шатлану кебек хис-тойгылар аша «яхшырак», «бәхетлерәк» яшәешкә омтылуын белдерә иде. Сүз дә юк, Моң искиткеч кыйммәтле, бөек күренеш булып кала бирә.

Әмма, гел Моң гына (әгәр дә ул синен яшәешенә тәэсир итүче бердәнбер, абсолютлашкан күренешкә әверелеп калса яки әгәр ул үз эчендәге хис-тойгылар бөтенлеген, гармониясен югалтып түбәнгә тәгәри башласа, мескенләнсә) туйдыра да башларга мөмкин.

Белмим, кемгә ничектер, әмма мина XX гасырнын торгынлык елларында матбугатта дөнья күргән татар шигырьләре вакыты белән артык монсу, сагышлы тоела иде... (Монда революцион-социалистик оптимизм белән бәйле шигырьләр керми, билгеле.) Ниндидер бер тулылык, оптимизм, яшәешкә, үз көченә ышанганлык житми иде кебек безнен шигърияттебезгә... Хәер, бәлки, бу монсулык-сагыш торгынлык елларынын сәяси атмосферасыннан да, милли яшәешебезнен әкрен генә сүнә-сүрелә, бетәшә баруын анлаудан да тугандыр. Ни әйтсән дә, милли яшәешебезне күзәтүдән туган өметсезлек көчле иде ул чорда. (Шәһәрләрдә милли мәктәпләр ябыла, милли югары уку йортлары юк, яшьләр маңкортлаша бара һ.б.)

Ни генә булмасын, нәкъ шушы торгынлык елларында күпләр Равил Фәйзуллин шигъриятенә тартылдылар! Чөнки анын шигъриятендә оптимизм да, киләчәккә якты өмет тә, ныклык та, тормышнын унай якларына ышану да бар иде!

Беренче чиратта Равил Фәйзуллин шигърияте фәлсәфилеге, фәлсәфи көче, һәрбер шигырьдә фикер булуы белән аерылып торды. Әмма нинди фәлсәфилек, нинди шигъри фәлсәфә хас иде соң анын шигъриятенә? Җавабы болай: Ир-егетлек, Көрәшчелек, Ныклык; Хакыйкатькә, Хөрлеккә, Гаделлеккә һәм башка изге кыйммәтләргә хезмәт итәргә омтылу...

Билгеле, һәрбер шагыйрьдәге кебек, Равил Фәйзуллинда да Моң, Моңлылык бар. Ләкин анын Моңы Ир-егет Моңы, көчле кеше Моңы, көрәшеп арыган кеше Моңы кебек, һәм житмәсә андагы Моң—Моң рухынын илаһи каршылыгы булган Сабантуй рухы белән һәрчак гармониядә булды.

Асылда, шагыйрь Равил Фәйзуллин, татарнын «бетәшү», декадентлык халәтен шул чорда ук (1970 елда) яхшы тоеп, кыю рәвештә язып чыкты!

*Безнең якта—борынгыдан*
*хәрабәләр генә.*
*Чын тарихны азлар белә,—*
*хәбәрдарлар гына...*

*Гавамга—моң, сагыш,*
*менә калган байлык.*
*(«Гөмбәзләре—коямымыни!..»)*

«Гавамга—моң, сагыш, менә калган байлык». Ни өчен болай? Нигә Моң, Сагыш аерым бер дәвердә безнен «сәер» байлыгыбызга әйләнгән икән? Шагыйрь бу турыда да тирәннән уйлана, фикер йөртә. Ул яхшы белә: болар бит биш гасырга якын колониализмнын бинһаза зур кайтавазы иде:

*Гөмбәзләре—коямымыни!*
*Сары алтын—чиркәү.*
*Бабайларның күз яшьләре*
*менә кайда икән!*

*Төссез түгел күз яшьләре,*
*сары төстә икән!*
*Ничек ялтырыйлар тәреләр!*
*Акыл—көчтә икән...*
*(«Гөмбәзләре—кояшмыни!..»)*

Гаҗәп, ачы күз яшьләре сары төстә дә, алтын төсендә дә була ала икән. Татар Моңының тирән тамырларын, аның каян килгәнлеген, кайсы катламнардан күтәрелгәнен яхшы тоя шагыйрь, һәм үзенең шигъриятендә кыю рәвештә ачып-сурәтләп тә бирә. Аннары аның үзенә дә, татар баласы буларак, Моң, Моңсулык та хас бит.

*Куып тереклек итүнең*
*мең башлы мәшәкатен,—*
*куеп бер якка көннәрнең*
*каһәрен һәм шәфкатен,—*
*үз хозурында җанны бер*
*рәхәтлеккә талдырып,*
*керфек эрерлек яшемдә*
*кояшны чагылдырып,*
*килә елыйсы кайчакта,*
*килә өзгәләнәсе!*
*Ярый нечкәрә беләбез,*
*юкса*
*нишләр җирнең бәндәсе?—*
*(«Куып тереклек итүнең...»)*

дип яза ул яшәешнең аерым бер моңсу мизгелендә. Менә шулай «нечкәреп», хисләр аша «өзгәләнеп»-моңлыланып кеше «мин»е авыр чакларында Илаһилыкка эченнән генә сыгынадыр да.

Ә күпкә соңрак язылган бер шигырьдә кешенең бәгырь төбендә яшәгән, җанын яулаган Моң турында мондый шигъри юллар бар:

*Җанымдагы үзәк өзгеч бер Моң*
*күмә барын:*
*кул чабулар,*
*җиз торбалар тавышларын...*
*(«Кемдер «дымлап» киткән көлдә күрәм...»)*

«Үзәк өзгеч Моң». Аның башы—язмыштадыр. Бер генә кеше гомере дә фани дөньяда Мәңгелек Дингезенә таба туры гына акмый, ә төрле каршылыклар аша, боргаланып, тармакланып юнәлә...

*Санама, күке, санама*
*гомерем елларын!*
*Күңелем тулар да*
*йә үксеп елармын...*
*(«Санама, күке, санама»)*

Шул ук вакытта Моң искиткеч милли дә!.. Татар халкының җиңел булмаган чорлары чагыла анда!.. Бәхет эзләп китеп шахталарда үз язмышын, инкыйразны тапкан милләттәшләре турында шагыйрь болай дип әрнеп яза:

*Күмер базларында күмелеп калган*
*күпме татар моңы, күпме сүз!..*
*(«Күмер базларында күмелеп калган...»)*

Әйе, Моңның ерак тамырларын ачык тоеп була... Әмма шул ук вакытта Равил

Фәйзуллин Монның Илаһи каршылыгы—Сабантуйның да татар өчен нинди бәя биреп бетергесез мөһим, калерле күренеш, фәлсәфә икәнлеген аңлый!

Сабантуй... Аның Олуг Рухы, билгеле булганча, Ир-егетлек, Көрәшчелек, Көчлелек, Ныклык, Житезлек һәм Гаделлек кебек сыйфатлар сорый. Шунысы да мәгълүм: фани яшәештә кешенең ошбу күркәм сыйфатлары Сабантуй бәйгеләренә, җәйге көрәш мәйданнарына гына кайтып калмыйлар, алар—тормышта, яшәештә еш очрыйлар. Шулай да ни өчен без кешенең Көрәшчелек, Җиңүчелек белән бәйле сыйфатларын Сабантуй рухыннан чыгып карарга кирәк дип табабыз?

Чөнки нәкъ менә язгы кыр эшләре тәмамлангач уздырыла торган татарның бөек бәйрәме Сабантуй фәлсәфәсендә кешенең шушы унай сыйфатлары аеруча калку, тирән чагылыш таба да бит! Нәкъ менә Сабантуйның тормышчан фәлсәфәсендә ачыла татарга хас булган бар Ир-егетлек, Җиңүчелек фәлсәфәсе! Сабантуйның олуг фәлсәфәсе, билгеле, җәйнең берничә көненә генә кайтып калмый. Ул татарның Рух-җанында гасырлар буе яшәп килгән Көрәш-тартыш фәлсәфәсе.

Равил Фәйзуллин шушы хакыйкатьләрне яхшы аңлый һәм аның Ир-егетлек фәлсәфәсе (шигырьләрендә, мәкаләләрендә, иҗтимагый эшчәнлегендә...), асылда, нәкъ менә Сабантуй рухына тугры калган килеш шәкелләшә. Шуңа күрә дә аның шигъриятендә калку чагылыш тапкан Ир-егетлек, Көрәшчелек, Җиңүчелек һ.б. сыйфатларны нәкъ менә гүзәл Сабантуй рухы белән бәйләп карау табигый һәм дөрес булыр иде.

Әйе, Сабантуй фәлсәфәсе—татарның чорлар аша килгән үзенчәлекле бөек тормыш фәлсәфәсе булып кала ул. Ул кешене, милләтне Кояш астында, Яшәеш кырларында нык, көчле булырга; гадел көрәшергә, бирелмәскә; җиңелгәннәргә миһербанлы булырга өйрәтә. Шуңа күрәдер дә фани яшәеш-чынбарлыгы никадәр «яраланган» булса да, татар халкы дөнья мәйданыннан кысрыклап чыгарыла алмаган, ә Күк астында үзенә лаеклы урынын даулап, яулап, табып яши килгән! Болай ди шагыйрь:

*Кипкән инеш тә*
*ташу чакларда*
*бер гөрләп ала!*

*Халык рухы да*
*сабантуйларда*
*бер дөрләп ала!*
*(«Кипкән инеш тә...»)*

Билгеле булганча, декадентлык заманында, торгынлык чорында, тулы канлы яшәешкә шартлар булмаган дәвердә тормыш һәм көрәш бәйрәме узгач, янә бөтен барлыгың белән Моңлылыкка әйләнеп кайтасың.

*...Аннан—кайтыла*
*иске эзләргә:*
*кипкән ташларга,*
*моңлы күзләргә...*
*(«Кипкән инеш тә...»)*

Икенче бер урында исә шагыйрь болай ди:

*Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга*
*җитә сирәге!*
*(«Бәйрәмнәр күп...»)*

Чыннан да, өстән тагылган рәсми «бәйрәмнәр» искә төшә: алар кичә бар, бүген инде юк... Ә Сабантуй? Ул исә халыкның үз бәйрәме—мәңгелек бәйрәме! Чөнки анарда аның үз, табигый рухы чагылыш таба.

Сорау туарга мөмкин: ни өчен Равил Фәйзуллин шигъриятендә Ир-егетлек, Көрәшчелек кебек Сабантуй рухына бәйле сыйфатларга игътибар көчле? Ни өчен

алар аның бай шигъриятендә киң чагылыш табалар?

Мөгаен, Равил Фәйзуллин шигъриятендә, «Идегәй», «Чура батыр» дастаннары чорыннан соң, колониализм дәверендә, фани дөньяда торгызыла алуга юллар ябык булу сәбәплеме ничектер югалыбрак калган, заманында татарга хас булган Ир-егетлек, Көрәшчелек фәлсәфәсен өр-яңадан татар яшәешенә, татар тереклегенә алып кайтырга теләү чагылып үтә.

Үзенең бер шигырендә кардәшенә, милләттәшенә болай дип эндәшә ул:

*Гел-гел мескенләнмик әле!*
*Үткәннәр безнең яклы.*
*Каныбызда—хезмәт сөю,*
*Җыр-дастаннар ничаклы!*

Сүз дә юк, үзенең шушындый Ир-егетлек, Көрәшчелек фәлсәфәсе белән Равил Фәйзуллин XX гасыр татар әдәбиятында ялгыз түгел. Мәсәлән, мондый Ир-егетлек фәлсәфәсе тагын икенче бөтендөнья сугышында катнашкан татар шагыйрьләре иҗатында чагыла. Аларның Ир-егетлек фәлсәфәсен барыннан да элек Туган җирне фашизмнан азат итү идеясе нигезли. «Яшәешне яклар, саклар өчен чын ир-егет булырга кирәк!» дигән фикер аларның шигъриятендә ап-ачык күзаллана...

Билгеле инде, мәсәлән, Равил Фәйзуллин үз иҗатында исемен телгә яратып еш алган герой-шагыйрь Муса Җәлилдә түбәндәге юллар бар:

*Ирлек сорый көрәш егеттән,*
*Ирешер өчен бөек өмиткә.*
*Ирек китәр, качсаң ирлектән.*
*Ирлек белән иреширеккә...*
*(«Батырлык турында»)*

Шагыйрь Равил Фәйзуллин исә Ир-егетлек, Көрәшчелек фәлсәфәсен, күпмедер башкарак яссылыкка күчереп, яңа дәвердә дәвам итә һәм аны үзенчә үстерергә, камилләштерергә омтыла.

Алда шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатында Көрәшчелек фәлсәфәсе тамырлары күренә дигән идек. Бу турыда уйлансак, шуны да искә төшереп узарга кирәк: бу фәлсәфә белән сугарылган шигырьләрне барыннан да элек коммунистик идеология белән бәйләп карауaчылар да булды. Билгеле, шагыйрь әдәбиятка килгән, иҗаты шәкелләшкән дәвердә хөкем сөргән рәсми идеологиянең аның иҗатына булган азмы-күпме тәэсирен дә (бәлки күбрәк яхшы яктан: чөнки бу идеологиянең яхшы яклары да бар, аның да чишмә башында дөньяны Галеллеккә алып чыгу идеясе ята) инкяр итеп булмый. Эзләсәң, эзләнсәң, Галеллеккә, Тигезлеккә чакыручы идеология белән монда нинди дер аваздашлыклар да табарга булыр иде... Әмма шунысы да хак: Равил Фәйзуллин шигъриятендә «кызыл» шигырьләр бөтенләй юк! Шул ук вакытта ул Көрәш төшенчәсе белән бергә Сабантуй турында еш искә алып яза. Юк, аның Көрәшчелек фәлсәфәсе күпкә тирәнрәк, олырак...

Минемчә, Көрәшчелек, Ир-егетлек фәлсәфәсе Равил Фәйзуллинда халыкның рухыннан, аның рух-җанында яшәгән Сабантуй фәлсәфәсеннән килеп чыга. Чөнки чын шигърият вакытлы вазгыятьтән, сәяси идеологияләрдән киңрәк ул (мәсәлән, Муса Җәлил шигърияте)! Һәртөрле вазгыять-идеологияләр (күпме булды алар!) тарихи борылышларда банкротлыкка очрагач та, чын шигърият яшәвен дәвам итә. Бу очракта, мәсәлән, шагыйрь иҗатындагы Сабантуйлык рухы белән бәйле Көрәшчелек фәлсәфәсе. Ул хәзер дә сорала, яши, чөнки ул тормыш-хәят тарафыннан даими соралган олуг тормыш фәлсәфәсе булып кала.

Әйе, тәнкыйтьчеләр тарафыннан күптән инде әйтелгән фикер болайрак: Равил Фәйзуллинның лирик каһарманы—көрәшчеләрдән! Бу шагыйрь шигырьләрендә еш кына көрәшкә, көрәшергә чакыра! Аның яшьли язылган «Көрәшчеләр кирәк!» дигән шигъри юлы бик күпләрнең хәтеренә чигелгән.

Гомумән, Р. Фәйзуллин өчен «Көрәш» сүзе «Тормыш» сүзе кебек кадерле, тансык, ахры. «Тормыш ул еш кына—көрәш» дигән фәлсәфә аның шигырьләрендә ярылып

ята. Үзенен 1966 елны язылган икенче бер поэмасында (23 яшьтә!) ул болай дип икърарлап язган иде:

*Чолгамыйча туры әйтәм:*
*бәхетем ташкан түгел.*
*Хәтта тулы бәхет миңа*
*кирәк тә түгел бүген!*

*Ә бүген?*
*Бүген көрәшәбез әле!*
*(«Карт һәм Шагыйрь»)*

Күнелдә исә урынлы сорау туа: каян килә соң Равил Фәйзуллинда көрәшкә тартылу? Аны күпмедер дәрәҗәдә яшәүнең стиле, рәвеше итәргә теләү? Көрәш үзмаксат була алмый лабаса.

Җавабы түбәндәгедән гыйбарәт: бәлки, һәрбер чын шагыйрьдәге төсле, дөньяның камил түгеллеген, аның Кешелеклелектән, Хакыйкатьтән күпмедер ераклашканлыгын аңлаудан торадыр.

*Кеше җаны өчен көрәш бара,*
*Иң нечкә ау,*
*Сәнгатьле ау—кеше аулау.*
*.............................*
*Иң кыйммәте—Кеше җаны!*
*(«Көрәшчеләр»)*

Шагыйрь монда эффект, матурлык өчен сүз уйнатмый, ә Яхшылык һәм Яманлык арасында кеше рух-җаны өчен барган катлаулы көрәш турында ихлас сүз алып бара.

Әйе, кешелек җәмгыяте әле камиллектән ерак тора. Үзе төсле үк бәхеткә омтылып яшәгән башка берәү исәбенә үз шәхси «бәхетләрен» «төзергә» омтылучылар алар түбәндә—гавамда да, югарыда—хакимияттә дә житәрлек әле. Шагыйрь әйтмешли, монда методлар гына төрле. Кичә яманлык тоталитар дәүләт сурәтендә, ГУЛАГ концлагерьлары булып күз алдына басса, бүген инде ул вакыт-вакыт криминал рәвешендә изге төшенчәләрне инкяр итә, яшәешнең ямьлелеген, сафлыгын кире кага.

Гомумән, кешеләрнең кешелеклерәк юлга кайтырга ашыкмавы гаҗәпләндерергә дә мөмкин. Югыйсә бөтенесе дә ачык бит: кешеләр изге төшенчәләрне сайласалар, күпкә яхшырак, бәхетлерәк яшәрләр иде! Әмма һәр кешенең күнел-җанында тамыр җибәрергә омтылган явызлыкның, күрәсең, үз тозәлмәс кануннары. Шуңа күрә Җиргә килгән һәрбер кешенең күнелендә бара бу Ак һәм Караның көрәше.

Ахыр чиктә һәркемгә дә үзенә сайларга кала: нинди кыйммәтләргә күнел капкаларыңны ачып куярга. Шагыйрь исә дөньядагы катлаулы бу көрәштә мәңгелек рухи кыйммәтләр ягында кала.

Кешелеклелек, Ирек-Азатлык, Хакыйкать—болар бит иң мөһиме. Мәсәлән, Хакыйкатькә хыянәт иткәннән соң, үз-үзеңне хөрмәт итәргә, үз юлың буенча ныклы адымнар белән атлап барырга, яшәешне бөтен тулылыгында, сафлыгында, ләззәтлелегендә кабул итәргә мөмкинме икән? Чын яшәешкә хыянәт иткәннән соң, салават күперенә караганда, дингезнең мәңгелек шавын тыңлаганда, үзеңне бәхетле итеп тоярга буламы? Юктыр...

1961 елда шигърияткә ишегеп кыю рәвештә кагучы яшь шагыйрь болай дип белдергән иде:

*Барыр юлым—аклык,*
*күңелемдә сафлык.*
*(«Миңа унсигез яшь»)*

Ә 1970 елны әдәбиятта инде җитди адымнар ясарга өлгергән, анда үз урынын да яулап алган шагыйрь түбәндәгечә икърарлап яза:

*...Вакытны, Хакны, Халыкны*
*танырга безнең исәп.*
*(«Азмы синдә байлык, кодрәт...»)*

Менә нindирәк кыйммәтләр, төшенчәләр аның Шигърият мәйданына килүенең асыл сәбәпләре булып кала!

Дөньяда гаделсезлекләр дә, яманлыклар да, тигезсезлекләр дә җитәрлек әле. Кеше рух-күнеле белән бәйле мәңгелек рухи кыйммәтләрне яклау-саклау исә һәр дәвердә дә, һәр вазгыять чорында да актуаль булып кала. Шигъриятнең төп илаһи миссиясе дә шундадыр.

Әнә шуның өчен дә бит яшәеш мәйданының уртасына чыккан шагыйрь Равил Фәйзуллин шигъриятендә көрәшкә тартыла икән:

*Бүген көрәшәбез әле!*
*Җирнең пакьлеге өчен,*
*Илнең аклыгы өчен.*
*(«Карт һәм Шагыйрь»)*

Әйе, вакыт-вакыт салкын җилләр, давыллар, зилзиләләр уйнаган тормыш үзәннәрендә күп нәрсә еш кына көрәшсез бирелми: Азатлык та, Гаделлек тә, Тигезлек тә, кайчак Яшәеш үзе дә... Равил Фәйзуллинның лирик каһарманы, дөньядагы гаделсезлекләргә очрагач, кайбер шагыйрьләрнең лирик каһарманнарыннан аермалы буларак, үз эченә ябылмый, ә дөньяны яхшырту хакына көрәшә. Ә бу шагыйрьдән көрәшчегә хас сыйфатлар сорый.

Чыннан да, изге кыйммәтләрне яклап чыгарга була (әйтик, Гаделлек, Азатлык идеясен), әмма көрәшә белү, көрәшкә әзерлек (нык тору, кыю булу, бирелмәү, җиңүчелек һ.б.) бармы синдә?

*Вакыт ныгырга,*
*катыланырга!*
*Бу дөньяда атың алырга!*
*(«Вакыт»)*

Яки:

*Усал дисәләр дисеннәр,*
*тик мескен димәсеннәр!*
*(«Усал дисәләр дисеннәр...»)*

Шагыйрь укучыларының үзләрендә дә көрәшчегә хас асыл сыйфатлар тәрбияләргә тели. Чөнки дөньяны яхшыртыр өчен аның авыр вакытларында чын көрәшчеләр кирәк икән.

*Беләкләләр җитә,—*
*йөрәкләләр кирәк!*
*(«Көрәшчеләр»)*

Ерак гасырлардан килүче яшәешкә кагылышлы Көрәш фәлсәфәсе исә бик төрле, бер-берсеннән аерылып торган үзгә яссылыкларда, хәтта төрле драматик кимәлләрдә дә чагылыш табарга мөмкин. Шушы унайдан күнелгә шагыйрьнең 1983 елны язылган «Коррида» исемле эссе-мәкаләсе дә искә төшә. Ул анда, бу мәшһүр драматик тамаша турында ихлас фикерләп, тирәннән үк уйланып яза.

Эссе-мәкаләдә шунысы игътибарга лаек: көрәшче шагыйрь монда испан халкының шушы тамашада чагылыш тапкан Көрәш фәлсәфәсен анларга омтыла, аның тормыш белән бәйле нигезе, ерак тарихи тамырлары турында фикер йөртә.

Сүз дә юк, кан һәм үлем белән бәйләнешле коррида тамашасын һәркем кабул да итә алмый. Уйласаң, бик бәхәсле тамаша ул. Әмма Көрәш фәлсәфәсе турында еш уйланучы шагыйрь, үзенең яшәеш принципларыннан чыгып, тормыш фәлсәфәсеннән этәрелеп («Яшәеш ул еш кына—көрәш...»), аны кире кагарга ашыкмый. Менә ни дип фикерли ул:

«Татар халкын сабан туе бәйрәмнәреннән тыш күз алдына китерү кыен булган кебек, испан халкының тарихын һәм холкын корридаларсыз тулы белеп булмастыр шул.

Гомумән, шат күнелле, тормышның бар тәмен тоеп яшәргә омтылган испан халкының үлемгә үзгәрәк мөнәсәбәте бар шикелле. Ирек тойган зат өчен үлем дә яшәүнең бер өлешенә әверелә бугай»[1].

Әйе, һәр халыкның гасырлар, дәверләр аша килгән үз Тормыш һәм Көрәш фәлсәфәсе. Әмма шагыйрь шулай да аңлый: Коррида фәлсәфәсе азмы-күпме бәхәс уята алса да, Сабантуй фәлсәфәсе бу яктан иң гармонияле Көрәш фәлсәфәләренең берсе булып кала! Гарсиа Лорканың мәшһүр сүзләрен аз гына үзгәртеп болай дип тә әйтергә мөмкин: «Сабантуйны аңламаган кеше татар халкының җанын да аңлый алмый». Сабантуй фәлсәфәсендә бит Мәхәббәт тә, Шәфкатьлелек тә, Яхшылык та бар. Сабантуй җитәрлек дәрәҗәдә якты идеаллар өчен көрәшергә өйрәтә! Һәрхәлдә, вак, тар, эгоистик амбицияләр өчен көрәшергә өйрәтми ул! Анда җиңелүчеләр дә бүләкләнә, тормыш бәйрәменнән читкә тибәрелми. Бары тик Сабантуй фәлсәфәсе «тормыш ул еш кына көрәш» дигән хакыйкатьне исбатлый һәм көрәшкә, җиңүгә өнди.

Ни генә булмасын, бер нәрсә ачык: Равил Фәйзуллин өчен Ир-егетлек, Көрәшчелек, Җиңүчелек кебек сыйфатлар барыннан да элек Сабантуй рухында чагылыш таба.

Шагыйрь менә шул Сабантуй рухына тугры калып иҗат итә дә! Ә Сабантуй рухы сораган Ир-егетлек, Көрәшчелек фәлсәфәсе исә төрле шигъри-фәлсәфи яссылыкта ачылып китәргә мөмкин. Мәсәлән, Олы җанлылыкка, Намуслылыкка чакыруда:

*Җанының ваклыгын*
*сылтама заманга.*
*Куркырга, өркергә*
*җай бар ул һаман да.*
*(«Җанының ваклыгын...»)*

Яки:

*Вөҗданың рәнҗемәсен. Аның*
*хөкеме каты.*
*Ирме соң без, акламасак*
*исемебез хакын?!*
*(«Дусларга»)*

Шәхси Хөрлеккә, гомумән, Ирек дигән бөек изге төшенчәгә тугры калуда:

*Әйдә, сүзем, кылган эшем*
*урләтсен хөрлегемне!*
*Шәхесемдә барын ачыйм да,*
*раслыем ирлегемне.*
*(«Хөрлектән башлана кеше...»)*

Нинди генә каршылыкларга, киртәләргә очрауга карамастан, яшәештә үз-үзенә таянуда:

[1] Фәйзуллин Р. Җырларда—ил гаме // Әдәби-публицистик мәкаләләр һәм юл язмалары.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

*Башың имә, җилләр*
*иссәләр дә каян!*
*Киләчәккә карап,*
*үткәнеңә таян!*
*(«Үз-үзеңә таян!»)*

Сайлап алынган Максатына тугры калуда, унга-сулга каерылмыйча, аңа таба өзлексез баруда:

*Тугансың икән, дөньяның*
*сиңа өлеше була.*
*Фәкать сиңа гына тигән*
*башкарыр эше була.*

*Шуны яшьли аңлаган җан,*
*гомер буе, икеләнмичә,*
*максатына баралган җан—*
*бәхетле кеше була.*
*(«Тугансың икән»)*

Хакыйкатьне сатмауда, аңа хыянәт итмәүдә:

*Яшәп кара бер маяксыз!*
*Йөз җыерып Хаклыктан!*
*Фикереңилтсәң сатлыкка—*
*кол булырсың ваклыкка.*
*(«Яшәп кара...»)*

Хаклык хакына фидаилектә:

*Дөнья—фидаи җаннарның*
*януында тора!*
*(«Сөйли. Җитди. Хак эш өчен...»)*

Яшәеш, дөнья, җәмгыять өчен үзеңне җаваплы тоюда:

*Якты утларны кем дә күрер,*
*үрләтә бел үз учагың!*
*(«Алдындагын кем дә күрер...»)*

Һәм, ниһаять, Ил-халык, Милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуда, шулар хакына жан атуда:

*Мин бүген сөйләшмим әле,*
*уйлана торган көнем.*
*Белмим бит нигә әйләнер*
*Илем, Телем һәм Динем...*
*(«Мин бүген сөйләшмим әле...»)*

Монда шуны да әйтеп узу фарыз: югарыда китерелгән шигъри өзекләр калейдоскобы һич тә үзмаксат түгел. Аларда шагыйрь иҗатына хас фәлсәфәнең—Сабантуйлык (Ир-егетлек, Көрәшчелек...) фәлсәфәсенең—олуг квинтэссенциясе.

Әйе, Сабантуйда соралган сыйфатлар тормыш бәйгеләрендә дә сорала. Кыюлык, Ныклык, Көчлелек, Каһарманлык рухи тормышта да кирәк икән! Нәкъ менә Ирек-Азатлык, Гаделлек, Кешелеклелек кебек кыйммәтләр өчен көрәштә сорала алар. Дөньяны яхшырту хакына, аны ямьлерәк, бәхетлерәк ясар өчен кирәк ошбу гасырлар аша килгән камил Көрәш фәлсәфәсе. Иртәме-соңмы Яхшылык—Явызлыкны, Ак—Караны жинәр дигән идея ята анын нигезендә.

Шунын өчен Сабантуй фәлсәфәсе гүзәл фәлсәфә булып кала да.

*Көрәшче шул—*
*матурлыкны арттыручы.*
*Җир йөзендә һәм кешеләр күңелендә*
*илаһи хис—Мәхәббәтне*
*Кояштан да биеккәрәк күтәрүче.*
*(«Көрәшчеләр»)*

## Көрәшчеләр һәр катлаулы дәвердә дә сорала

Сабантуйлык, Көрәшчелек фәлсәфәсе Равил Фәйзуллин иҗатының башыннан алып ахырына кадәр кызыл җеп, төп лейтмотив булып уза.

Еллар узган саен, ошбу фәлсәфә аның иҗатында үсә, калкулана гына төшә. Мәсәлән, «Ажаган» исемле икенче китабы (1966) белән «Монологлар һәм диалоглар» дигән өченче китабын (1967) чагыштырсаң, бу күзгә ап-ачык ташлана.

Әйе, торгынлык, татар яшәеше зур кыенлыклар кичергән чорда Равил Фәйзуллин Сабантуй байрагын, ана хас Җинүчелек рухын биек күтәреп барган кыю шагыйрьләрнең берсе булды. Уйлап баксаң, шушы шигърият татарның сәламәт яшәеше, тулы канлы тормыш итүе өчен үзенчәлекле көрәше дә иде бит!

Тагын бер кат искә төшерергә була: мәсәлән, милли мәсьәләләргә кагылышлы үткен, бәлки, үзе әйтмешли, «башың Себер китәрлек» шигырьләрне Равил Фәйзуллин әле татар халкының яшәеше деградацияләнә барган торгынлык елларында да язган иде. Бу факт замандашлары игътибарыннан да читтә калмады, һәм болар турында шактый язылды да.

Билгеле, Равил Фәйзуллин, кабул ителгән гомуми билгеләмәләрдән чыгып караганда, диссидент шагыйрь түгел. Әмма аның шигъриятендә үзгә бер диссидентлык—Ркаил Зәйдулла сүзләре белән әйткәндә («Идел бит ул киң бит ул» мәкаләсендә), милләтнең фикерләү үзенчәлеген үзгәртергә теләү (кыюлыкка, бәйсезлеккә, үз-үзеңә ышануга, җиңүгә таба һ.б.) күренеп китә!.. Халык күңелендәге Сабантуй рухына тугры калган шигърият ул. Шуна күрә дә, мөгаен, Равил Фәйзуллин торгынлык елларында күпләрнең шигъриятгәге яраткан кумирына әверелә алды.

Бу җәһәттән сорау туа, СССР дигән илдә үзгәрешләр башланып киткәч, җәмгыятьтә демократик җилләр исә башлагач, соңгы унбиш-егерме елда Равил Фәйзуллин Сабантуйлык, Көрәшчелек фәлсәфәсен тагын да югарырак кимәлдә дәвам итә ала иде түгелме? Ул вакытта рухи яктан сынмаганнар бүгенге заманда тагын да зуррак мөмкинлекләр алдылар.

Әйе, көрәшче шагыйрь, яна чор килгәч тә, үз шигъри фәлсәфәсенә тугры калды. Әмма... әллә инде бу болгавыр заманда күренекле татар шагыйрьләре сәяси идеологияләрнең чагыштырмалыгын, кыска гомерлеген аңлагангамы, әллә инде үткән чор белән киләчәк чор арасында чын мәгънәсендә хакыйкый күперләр салырга теләгәнгәме йә булмаса көрәшү сораган чын, изге кыйммәтләрне тагын бер кат барларга омтылгангамы, азга гына тынып тордылар, яки инде Сөю-Мәхәббәт төсле традицион булган мәңгелек темаларга кереп киттеләр...

Ә шулай да Сабантуй, Көрәшчелек фәлсәфәсе нииндирәк әверелеш-үзгәрешләр кичерде соң? Әллә инде тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин «Чорлар чатындагы үзгәрешләр» («Казан утлары», 2004, № 5) мәкаләсендә хаклы иде:

«Тоталитаризм чорында язучы бердәнбер тугры сүз, кыю фикер әйтүче булса, демократия чоры килү белән, гади бер авторга әйләнә».

Ни генә булмасын, Иреклелек, Хәбәрдарлык чоры килгәч, күп кенә кардәш-милләттәшләре «Көрәшчеләр кирәк!», «Бүген көрәшәбез әле!» дип ихлас инанып (кайчак, бәлки, беркатлырак та!) эндәшүче көрәшче шагыйрьне сагындылар. Чөнки заманалар үзгәрү белән, көрәшүне сораган кыйммәтләр юкка чыкмаганнар, бәлки әле тагын да калкарак төшкәннәр иде бит! Госман Садәнең 1993 елда Равил Фәйзуллинга багышлап язылган шигырендә шул кәефне чагылдырган түбәндәге юллар бар:

*Кайтарасы иде кабат,*
*Их! торгынлык елларын!*
*Яза иде курыкмыйча*
*Усал шигырь юлларын.*

*Каһарманнар югалмады...*
*Каһарманлык шигырьдә.*
*Чор кавыша чорлар белән*
*Шагыйрь салган күпердә.*
*(«Кайтарасы иде кабат...»)*

Бәлки, социаль системалар, вазгыятьләр, маяк-ориентирлар кискен алышынган дәвердә азга гына булса да тынып калу, уйлану, фикерләрне тәртипкә китерү кирәк булгандыр үзалдына изге максатлар куеп яшәргә омтылган, «көрәш» сүзен «тормыш» сүзе төсле үз иткән шагыйрьгә?!

*Син миңа, аргансың, дисең,*
*әйе, мин арган идем.*
*Дөньяның күзенә карап,*
*бер тынып калган идем.*

*Үткән еллар баскычына*
*гүя менеп утырып,*
*Үткән белән Киләчәкне*
*тоташтырмакчы булып*
*уйга тардым.*
*(«Халәт»)*

Шагыйрь 1988 елда язылган бу шигырендә үткән көрәшле елларга күз ташлый, аларны янә күнеленнән кичерә, андагы эшләнгән эшләргә, ирешелгән шигъри-рухи биеклекләргә ихлас бәя бирә:

*Девиз иде: сынатмаска*
*Дөнья сабан туенда!*
*(«Халәт»)*

Сонрак киләчәккә уйлану, борчылу, хәтта шом тулы карашын төби:

*Бихисап сораулар тулы*
*билгесезлек тора алда...*
*(«Халәт»)*

Чыннан да, нәрсә күрәбез киләчәктә? Мәңгелек рухи кыйммәтләр, милли мәнфәгатьләр күзлегеннән чыгып карасаң да, жиңел булмаган көрәшле еллар. Тормыш дигән олы көрәш мәйданы көрәшчеләр, ир-егетләр өчен һәрвакыт ачык кала.

Асылда, XX гасырның 90 нчы еллары татар шагыйрьләре өчен ачыктан-ачык Дәүләте, Ватаны, Милләте, Дине турында зур, каршылыклы уйланулар чоры, күпмедер дәрәжәдә милли романтизм чоры да булды. Уйласаң, менә нинди кыйммәтләр хакына, ниләр хакына яшәргә, көрәшергә, Ир-егетлегеңне күрсәтергә була икән! Тарихтан искә төшерсәк, Азатлык бер халыкка да көрәшләрсез бирелмәгән!

Әйе, Сабантуй рухына тугры калган, бәйлелекне түгел, ә бәйсезлекне үз иткән чын ир-егетләр һәрвакыт үз Дәүләт-Йортын төзү турында хыялланганнар. Равил Фәйзуллин да үзен шушы чорда Дәүләтчелек, милли Бәйсезлек өчен жан атучы шагыйрь сыйфатында күрсәтә.

*Өннәремдә*
*гомерем буе җиһан буйлап*
*сүзләр җыям күңелемә.*
*Бәгырьләргә утәрдәйләреннән*
*оран салам!*
*Милләттәшләр, кан кардәшләр*
*җыелыр дигән өмет белән*
*Дәүләт дигән Сабантуйга.*
*(«Минем таралган салларым бар...»)*

Моның белән шагыйрь тагын бер кат Дәүләт, Сабантуй кебек төшенчәләрнең үзе өчен никадәр мөһим, изге булганлыгын ассызыклый.

Дәүләт дигән Сабантуйга чакыру... Безнең көнелләрдә йөргән Дәүләтчелек, Азатлык идеясе әнә шундый тансык, кадерле образ-сурәт тә алырга мөмкин икән. Нишлисен, нәкъ менә татар шагыйренә халкы кичерә килгән метаморфозалар, олы югалтулар турында даими уйланырга, кардәшләрен берләшергә чакырып оран салырга язгандыр. Чыннан да, озын-озак вакыт милләтебез Хансыз да, Илбашысыз да калган болгавыр елларда татар әдибе төп кайгыртучысы, төп җан атары иде бит татар яшәешенең, татар чынбарлыгының. Әгәр шагыйрь дә уйланмаса, кем уйланыр иде милләткә кагылышлы гасырлар аша килгән ачы дәресләкләр турында.

*Мин бүген сөйләшмим әле,*
*уйлана торган көнем.*
*Белмим бит, нигә әйләнер*
*Илем, Телем һәм Динем...*
*(«Мин бүген сөйләшмим әле...»)*

Сабантуй фәлсәфәсенең Ватан, Дәүләтчелек, Милләт фәлсәфәсенә барып тоташуы табигый. Чөнки батыр, каһарман, фидаи ир-егет гомер-гомергә Ил токкасы булган.

Ә милли Азатлыкка омтылган татар күңелендә Өмет, Ышаныч ялкыны беркайчан сүнми. Чөнки татарга ничә гасыр инде инкыйраз юрап киләләр. Ә ул һаман юкка чыкмый, бирелми, яши бирә. Тарих-яшәеш упкыннарын сикереп чыгып яки урап чыгып киләчәккә юл яра, башка халыклар арасында үз лаеклы урынын табарга омтыла. Аның бит мәңгелек Сабантуй фәлсәфәсе бар. Шуңа күрә Гаделлек, Ирек, Хөрлек дигән изге кыйммәтләр өчен дә көрәшә ул бүген.

Ирек сөюче халыкны киләчәктә дә халыкара мәйданда җиңел булмаган көрәшләр көтә түгелме? Дөнья, тормыш үзе бит вакыт-вакыт Сабантуй... Ә Равил Фәйзуллин «Азатлык ул еш кына—көрәш» фәлсәфәсен бүген генә аңлаган шагыйрь түгел! Искә төшерсәк, әле 1974 елда, рәсми даирәләр «милләтләр бетәчәк» дип аз санлы халыкларның күңелен төшереп сөйләнгәндә, ул кардәшләренә-милләттәшләренә эндәшеп болай дип язды:

*Заманга иш булыйм дисәң—*
*кем бер янса—*
*ун яшьнәргә,*
*ун янарга кирәк безгә.*
*Тормыш дигән халыкара сабантуйда*
*батыр булып*
*калалырга*
*кирәк безгә!*
*(«Кирәк безгә!»)*

Әйе, тормыш-яшәеш дигән халыкара Сабантуйда татарга үзен чын-чынлап күрсәтәсе бар әле.

Үз халкының халыкара мәйданда батыр булып калуын, сынатмавын ихлас

теләгән шагыйрь, билгеле, моны аңлый: дөньяда Гаделлек, Кешелеклелек, Яхшылык кебек идеаллар җиңмичә торып, аның халкына да алга бару авыр булачак.

...Уйласаң, мәңгелек рухи кыйммәтләр—Хөрлек, Яхшылык, Сафлык һ. б.—ни өчен бүген дә, кешелек инде өченче меңъеллыкка кергәндә дә, яклау-саклауга мохтаҗлар икән? Ни өчен бүген (бигрәк тә соңгы унбиш-егерме елда) аларның кешеләр күңелендә, җәмгыятьтә бәяләре төште икән? Югыйсә дистә еллар буе күпләрнең күңелендә яшәгән хыял-өмете тормышка ашты: җәмгыятьтән кешелеклерәк тормыш хакына тоталитарлык богаулары алып атылды, ГУЛАГлар турында күз яшедәй ачы дөреслекләр кайтты. Юк, Ирек кешеләрне бәхетлерәк ясамады әле. Әллә инде алар табигатьләре, менталитетлары белән аңа рухи әзер дә, рухи лаек та түгел иделәрме?! Ирек бит ул—дөнья өчен олы җаваплылык та.

Үз вакытында изге төшенчәләргә, идеалларга ышанып-инанып Шигърияткә килгән һәм Көрәшче дигән исем алган шагыйрь әнә шуна да уйланып калды түгелме? Чөнки шагыйрь үз вакытында күпме рухи янды! Хакыйкать, Хөрлек, Кешелеклелек хакына ул кабатланмас елларда күпме шигырьләр язылды! Сабантуй, Көрәшчелек Ир-егетлек рухы астында яшәешнең изге максатлары хакына күпме шигъри юл узылды...

Ул вакытта җиһанда якты идеаллар җиңәр төсле иде. Тормыш тора-бара тагын да матураер, ямьләнер кебек. Әйе, ул кабатланмас чорда камил җәмгыять төзүгә өмет тә, ышаныч та шактый зур иде. 1961 елны яшь шагыйрь болай дип ялкынланып язды:

*Миңа унсигез яшь!*
*Мин—давылга тиңдәш,*
*Беләгемдә—көчем.*
*Күңелемдә дәрли,*
*зур эшләргә өнди*
*тыелгысыз хисем.*
*(«Миңа унсигез яшь!»)*

Ә менә 1989 елны (28 елдан соң!), үзгәрешләр чорында, язылган шигырь күпмедер моңсу да яңгырый:

*Яшәдең, эшләп җан аттың...*
*Йә, үзгәрттеңме бераз*
*Дөньяны, Илне?*

*...Сизәме тау—очып төшкән*
*тәмәке көлен?*
*(«Яшәдең, эшләп җан аттың...»)*

Кайчакта шулай да була икән: син дөньяны, кешеләр күңелен күпмедер үзгәртергә, яхшырак якка борырга телисең, ә ул һаман шул ук ярларда кама. (Кем белә, бәлки, шагыйрьҗаннар булмаса, ул тагын да авыррак хәлдә булыр иде?!) Бу парадокс башка шагыйрьләр иҗатында да чагылып үтте. XX гасыр ахырында—XXI гасыр башында иҗат иткән күп кенә шагыйрьләргә ачарга, аңларга, кичерергә туры килде ошбу ачы хакыйкатьләрне!

Кешелеклелеккә, Гаделлеккә чакырып язган шигырьләрнең җиһан өчен, җәмгыять өчен бер файдасы да булмадымы икән?! Алар кешеләр күңелен аз гына булса да яхшырак, изгерәк якка алып чыга алмадыларммы?! Әллә инде җәмгыятьтә шигъриятнең, рухи тормышның ни икәнен дә белмәгән битараф җаннар, рухи гариплэр өстенлек алдыларммы? Менә җәмгыятьтә башланып киткән һәм баручы кискен үзгәрешләр кайчак шундыйрак сәеррәк сорауларга этәрәләр. Чөнки бу үзгәрешләр кайбер кешеләр өчен аерым бервакытта җитәрлек тискәре төсмер алдылар...

*Көтмәдекме безне баскан*
*басымның басылуын?*

*Җанга, рухка, хөр фикергә*
*юлларның ачылуын?—*
*(«Көтмәдекме безне баскан...»)*

ди шагыйрь XX йөз ахырында җәмгыятьтә барган үзгәрешләргә кагылышлы рәвештә. Аннан болай дип әрнеп дәвам итә:

*Көттек. Көттек... Ниһаять,*
*күзләр шәрран ачылды.*
*Күз алмасына шәп-шәрә*
*чынбарлык кереп тулды.*

*Канүннар шартлап ярылды,*
*Ил-җирләр тетрәнде.*
*Әтрәк-әләмнәр көрәйде,*
*хезмәтле—бөкрәйде...*
*(«Көтмәдекме безне баскан...»)*

Менә шундый яшәеш метаморфозасы. Рухка, хөр фикергә юллар ачылды, ә кешеләр, асылда, бәхетлерәк яшәешкә ирешмәделәр?! Ни өчен икән? Кешеләр кайчак Ирекне джунглилар законы сыйфатында аңлаудан югарырак аңлауга сәләтсез булып чыктылар түгелме?!

Равил Фәйзуллин иҗаты элек тә төрле контраст буяулар, антитезалардан тора иде. Әмма җәмгыять капиталистик системага юл тоткач, тирә-юнь яшәешебездә гаҗәеп контрастлар пәйда булды! Гомумән, шундый чор килде: хак белән нахакны вакыт-вакыт зур авырлык белән генә аерасың.

*Шундый итеп сөйлиләр!—*
*торасың шаккатып.*
*Ялганнарын аңлаганга—*
*еларлык ятып.*
*Хакимияттә—тозаклар,*
*богаулар, бикләр...*
*Матур сүзләргә оялый*
*иблислекләр.*
*...........................*
*...Сөйлиләр! Алганнармыни*
*Күкләрдән вәхи...*
*Бу дөнья Чын-Ялганнан*
*тора, билләһи!*
*(«Шундый итеп сөйлиләр!..»)*

Чыннан да, гаҗәп тискәре күренеш бу: син изге төшенчәләр хакына җан атасың, рухи янасың, борчыласың, ә башка кайберәүләр, шул изге төшенчәләр хакына дигән булып, үзләренең эгоистик, ә бәлки кешелексез эшчәнлеген җәелдерәләр. Алар кеше яшәешенең нindирәк кыйммәтләргә нигезләнергә тиешлеге турында, ул кыйммәтләрнең бакый асылы турында уйланырга да сәләтсезләр сыман.

*Ике-өч катлы коттеджлар витражында*
*юксылларның, сабыйларның күз яшьләре...—*
*(«Белая горячка»)*

ди шагыйрь кинаялы шигырендә, беренче чиратта хәрәм, талап алынган малны хәләл малдан, изге төшенчәләрдән югарырак куючыларга ишарәләп. (Югыйсә, коттеджлар витражында сабыйларның елмаюы да чагыла ала!..) Әйе, яшәештә очраган ачы дөреслекләрне искә төшерү, алардан качмау—намус эше. Ул үзенне яшәеш кырларында Кеше, Шагыйрь буларак исбатлау...

Р. Фәйзуллин аңлый: бүген дә кеше һәрвакыттагыча тормышның олы сынавы

алдында тора. Моннан күп гасырлар, меңъеллыклар элек булган төсле, ул олуг мәсьәләне үзе чишәргә тиеш. Кемгә хезмәт итәргә, күңел-җан капкаларыңны ачып куярга: Яхшылыккамы, әллә инде Яманлыккамы?

*Әче төтене заманның*
*күзләрне ачыттыра!*
*Яхшыга да, Яманга да*
*капкалар ачык тора.*

*Ә Вакыт ашыктыра...*
*(«Көтмәдекме безне баскан...»)*

...Гомумән, көрәшче шагыйрьнең иҗатын игътибарлырак укып чыксаң, шул күзгә ташлана: үзгәртеп кору еллары башланып киткәннән соң, аның иҗатындагы Сабантуй рухына хас дәртле шигъри юлларны («Көрәшчеләр кирәк!», «Бүген көрәшәбез әле!») үзгәрәк планда язылган фәлсәфи уйланулар алыштыра төште. Аларда—кырыс, хакыйкатьләрне бөтен барлыгында ачып-сурәтләп бирергә омтылу, яшәеш-хәятның кайбер парадоксларын, метаморфозаларын анларга алгысу. Әйтерсең лә шагыйрь дәверләр алышынган елларда яшәеш-хәятның никадәр катлаулы икәнен, мантыйкка сыеп бетмәвен тагын да яхшырак төшенеп алган. Бәлки, көрәшеп, сыналып олыгаю да шагыйрьгә яшәеш кырларына бүтән яктанрак карарга ярдәм итәдер...

Сүз дә юк, көрәшү сораган кыйммәтләр һәрвакыт кала. Әмма инде шагыйрь хәзер көрәш мәйданнарына күпмедер дәрәҗәдә беркатлы рәвештә ташланмый. Ул яшәеш кырларында изге төшенчәләр кичергән үзгәреш-әверелешләр турында да уйлана.

Әйткәнебезчә, элек тә шагыйрь антитеза, контрастлар белән эш итәргә ярата иде. Ә хәзер алар аның шигъриятендә ешрак очрый.

Тормышның парадоксальлеге бит гаҗәеп төрле яссылыкларда ачылып китәргә мөмкин. Кеше яшәешенең катлаулыклары, драмасы белән бәйләнешле рәвештә монда гаҗәеп төрле тема-идеяләр табыла!

Мәсәлән, яшәеш барышында аерым вакытта сиңа очраган тормыш парадокслары турында да:

*Берәүгә икмәк сузасың—*
*ә ул сиңа таш ата...*
*Гавам җаным пакьлим дисең,*
*ә ул—күзен акайта.*
*(«Парадокс»)*

Чынлыкны анламыйча фани «биеклекләргә» ябышып ятучылар, Аллаһы Тәгалә биргән олы сынауны—бердәнбер гомерләрен—бушка әрәм-шәрәм итүчеләр турында:

*Ярминкәләр! Ярминкәләр!*
*Кайсы Хөрмә тәгәрәп төшәр*
*бу Кызыл Кәрҗинкәдән?*

*«...Чын гамәлең ни?» дип, беркөн*
*сорар бит Җир-әнкәләр!*
*(«Ярминкәләр! Ярминкәләр!»)*

Ә менә монысы, яшәешнең кайчак күзәтелгән вакытларын бөтен кинлегендә-парадоксальлегендә-кырыслыгында анларга чакырып, тагын да фәлсәфи үзгәрәк кимәлдә янгырый төсле:

*Шакал корбанын ботарлады да,*
*лакыл булгач, канлы бугаз белән*
*Күккә карап сузып улады...*

*Ә Ай—*
*болыт арасыннан*
*нур сибеп карап тора.*

*(«Төн»)*

Әмма, ни генә булса да, яшәешнен котылгысыз агышында аның игелегенә, изгелегенә ышану яши, кала:

*Үз вакыты җиткәч—имән ава,*
*йолдыз арып сүнә, рух какшый...*

*Нихәл итмәк кирәк: кемдер чынлап*
*Яшәештә мәңге калмакчы!*

*...Була кайчак. Дөньяны баскан*
*явызлыкны җиңә бер Яхшы.*

*(«Үз вакыты җиткәч—имән ава...»)*

Кайчак ошбу уйланулар эчке фикри Моң булып күз алдына баса ала. Чөнки, әнә шундый фәлсәфи шигырьләр калейдоскобы аша «яраланучан», эзләнүчән шагыйрь жан-күңелен күреп-тоеп алырга да мөмкин түгелмени?!

Үз вакытында Сибгат Хәким Равил Фәйзуллин шигърияте турында: «Бик күп шагыйрьләр чирләгән сентиментализмның анда эзе дә юк»,—дип язган иде. Бәлки, Равил Фәйзуллин шигъриятенең яшьлек чорына кагылышлы рәвештә, бу күпмедер дәрәҗәдә дөрес тә булгандыр. Әмма менә шагыйрьнең яшәеш-хәят катлаулыкрын парадоксларын еш сурәтләвендә кеше «мин»енең Чынлыкны эзләп бәргәләнүләре дә ачык күренә бит. Бу—күңелләрдә үзенчәлекле теләктәшлек, фикердәшлек, симпатия уята.

Әйе, шагыйрь табигате, бәлки, миссиясе белән дә көрәшче булса да, ул бит нәфис фильмдагы робот-терминатор түгел! Асылда бит җирдәге төп көрәш кеше күңелендә бара. Ә кеше жаны таш түгел.

Р. Фәйзуллин исә—моны үзе дә шактый яшьли аңлаган бер жан. Менә ни дип язган иде ул мәшһүр поэмасында көрәшчеләр хакында:

*Аларның да кан йөгерә тәне буйлап,*
*аларның да һич кипмәгән хис чишмәсе,*
*аларның да кешегә хас*
*бер-бер йомшак ягы була.*

*(«Көрәшчеләр»)*

Менә ни өчен аерым бер мизгелдә Сабантуй рухын Моң дәрьясы алыштыра ала. Менә ни өчен кояшлы Сабантуй мәйданнарыннан соң моңлы күзләргә кайтыла.

Сабантуй рухына тугры калып иҗат итәргә омтылган шагыйрьнең бер шигырендә Татарник үләненә игътибар итүе очраклы түгел, билгеле. Татарник—көрәшү, бирелмәү символы!..

*«Шайтан таягы» яки*
*«Татарник» диләр,*
*Идерә алмый аны*
*давыллы җилләр!*

*(«Татарник»)*

Әмма Татарникның яшәү өчен көрәшендә үҗәтлек, бирелмәү, җинүчелек кенә түгел, ә Моң да сизелеп китә. Каян килә соң ул? Дөньяга хөр булып туган, илаһи кыйммәткә ия «мин»нең бирелмәскә теләвен аңлаудан. Аны сыталар, таптыйлар, юкка чыгаралар. Ә ул барыбер бирелми! Көрәшә, исән кала, томыш ямен табып яши бирә! Бу олы яшәеш вакыйгасы, ямьле, гүзәл тормышның җинүе күңелдә теләктәшлек тә, Моң да уята. Әйе, татар күңелендә, яшәеш кырларында Сабантуй һәм Моң янәшә калалар.

Ни генә булмасын, Сабантуй рух-фәлсәфәсе тормыш мәйданнарында, яшәеш көрәш-бәйгеләрендә даими сорала торган рух-фәлсәфә булып кала. Шуна күрә көрәшче шагыйрь иҗатында ул беркайчан да юкка чыкмый, һәрвакыт яши. Билгеле, тормыш үзәннәрендә сыналып олыгайгач, күңелгә яшәеш, катлаулыклары турындагы уйланулар ешрак та киләдер. Әмма бу бит көрәшү сораган кыйммәтләр кыйммәтсезләнде, юкка чыкты дигән сүз түгел! Сабантуйның рухына тугры калган шагыйрь (үзенең көрәшче табигатеннән дә, миссиясеннән чыгып та!) изге төшенчәләр хакына (Милләт, Хөрлек, Гаделлек, Кешелеклелек һ.б.) көрәшүдән туктый алмый. Чынлыкта Сабантуй рухы, чын ир-егетләр, көрәшчеләр һәр катлаулы дәвердә дә сорала икән:

*Атлантида, калкып чыгып,*
*күтәрсен иде Аңны!*
*Күңелдә йөргән Дәүләт бар—*
*саклыйк Республиканы!*
*..........................*
*Татар кайда яшәсә дә,*
*Казан—аның бакканы...*
*Өзмик кардәшләр өметен—*
*саклыйк Республиканы!*
*(«Саклыйк Республиканы!»)*

Яшәеш, алгарыш еш кына көрәшүләр аша да дәвам итә...

Татар халкы, асылда үзенчә бәхетле халык. Чөнки яшәешкә кагылышлы рәвештә аның бер-берсенә охшамаган, бер-берсен тулыландырып торучы ике бөек Рухи-Мәдәни Тәҗрибәсе бар. Якты Татар Рухының бер канатында—Сабантуй, икенчесендә—Моң.

Татар шигърияте исә шушы ике Рухи-Мәдәни Чынбарлык белән тыгыз мөнәсәбәттә яши, яшәргә омтыла. Әйтик, Мөдәррис Әгъләм кебек шагыйрьләр татарның Моңын бәгырьләрендә йөртсә, сакласа, Равил Фәйзуллин төсле шагыйрьләр татарның Сабантуй рухын үз шигъри рухлары белән баеталар, саклыйлар.

...Ә төпсез кеше күңелендә исә Шигъриятнең дөньяны яхшырак якка алып чыгасына Хыял-Өмет һәрвакыт яши, сүнми! Гасырлардан гасырларга якты идеаллар өчен җан атучыларның, көрәшүчеләрнең бу Өмете, Ышанычы, Хыялы көчеп килә.

Көрәшче шагыйрьнең соңгы поэмаларының берсе якты оптимизм белән түбәндәгечә тәмамлана:

*...Бер яшь егет шигырь яза!*
*Күңелендә—мәңге яшәү,*
*йөзләрендә—таң нуры!*
*(«Иҗат»)*

## Мәңгелеккә юллар бар...

Равил Фәйзуллинның 1987 елны язылган «Мин яшәдем» шигырендә түбәндәге юллар бар:

*Мин яшәдем—*
*җир җимертеп хезмәт иттем.*
*Чөнки тойдым илнең якты күзен,*
*ишетеп тордым кешеләрнең хуплау сүзен.*
*(«Мин яшәдем»)*

Шагыйрь иҗатын хуплау ни-нәрсәләргә нигезләнгәнен яхшы беләбез. Равил Фәйзуллин шигъриятенә хас Сабантуй рухы аның иҗатын популяр ясады, илгә танытты. Үзенең яшәешендә тарихи зилзиләләргә очраган, җиңү шатлыгына сусаган татар халкына нәкъ менә шундый көрәшче рухлы шигърият кирәк булган. Шагыйрьнең иҗатын хуплап, татар җәмгыяте үзенең җиңүчән рухын, үз-үзенә ыша-

нычын, хөрлеккә булган ихтыярын хуплады, үстерә килде.

Әйе, максатчанлык, ныклык, жинүчелек, хезмәтчәнлек дөньяда кеше өчен кирәкле күркәм сыйфатлар. Әлбәттә, Жиһан-Галәм баласы буларак, нәкъ менә Кеше өчен... Равил Фәйзуллин шигъриятенә хас антропоцентризм, ягъни кешеүзәклек турында әдәбият галимнәре яздылар инде. Кеше һәм Вакыт, Кеше һәм Галәм, Кеше һәм Намус һ. б. темаларга кагылышлы уй-фикерләр Равил Фәйзуллин шигъриятенең асылында ята.

Әмма иртәме-соңмы Алла бәндәсе Кеше Жир планетасында үз миссиясен тәмамлый. Калганы—Тәңре кулында. Шуна да микән Кешенең еш кына трансцендентальлеккә—без белгән яшәештән кинрәк булган, аннан «чыгып киткән» чиксез Яшәешкә—күнел офыклары ачык кала. Кеше күнеле илаһи бакыйлыктан килгән.

Дөреслек шунда, Равил Фәйзуллин фәлсәфи шагыйрь булганга, аңа фани чынлык турында гына түгел, ә вакыт-вакыт бакый Чынлык турында да уйланулар хас. Уйлансан, һәр чын шагыйрьнең дә бит трансценденталь офыклары була.

Яшәешнең үзгә бер мизгелендә Кеше, бигрәк тә Шагыйрь, үз яшәешенең бакыйлыктан килеп чыкканлыгын искә төшерә. Ахыр чиктә, югары жан иясе буларак, ул иртәме-соңмы уйланырга, төшенергә тиеш бит: каян килгән ул һәм кая китәчәк?.. Ә бу үз чиратында Яшәү һәм Үлем турындагы олуг фәлсәфи уйлануларга этәрә. Бөек акыл иясе Әфләтун фәлсәфәнең асыл мәгънәсе турында болай дигән: «Кешеләр өчен бу сер: әмма фәлсәфәгә чынлап торып бирелүчеләр бакыйлыкка «күчү»гә әзерләнүдән башка берни белән дә шөгыльләнмиләр».

Фәлсәфәченең бу сүзләре, билгеле, тормышка карата пессимистик караш түгел, ә киресенчә, Бакый Тормышның бөтен чиксезлегендә танып беленә алынуын аңлаудан туган олы оптимизм булып тора.

Мәсәлән, шул ук Көрәш темасы. Нәрсә ул Мәңгелек алдында? Бакыйлыкка күчкәннән соң, ошбу тема актуаль кала ала микән?!

Әмма иң игътибарга лаеклысы шунда: Сабантуйлык фәлсәфәсе фани яшәеш өчен Көрәш идеясен генә түгел, ә Мәхәббәт, Гаделлек, Сафлык, Миһербанлык кебек мәңгелек кыйммәтләр өчен, димәк, бакыйрак тормыш өчен көрәшү идеясен дә үз эченә ала. Шуна күрә Сабантуй рухына тугры кеше Мәңгелек белән дә, иксез-чиксез Хакыйкать белән дә очрашудан курыкмаячак.

Асылда, фани яшәешебездә һәр мизгел Мәңгелек Тормышка кагылышлы уйланулар яссылыгына этәрә ала. 1969 елны язылган бер шигырендә шагыйрь болай яза:

*Кабатланмас бу мизгелнең,*
*бу халәтнең*
*мәгънәсе ни*
*гомеребездә,*
*Мәңгелектә?!*

*Кеше—бөек, дип уйлама, төнбоек!*
*Мин уйда гына...—*
*(«Бөек дип уйлама син, төнбоек!..»)*

ди шагыйрь Равил Фәйзуллин, яшәешнең аерым серләренә төшенергә теләп. Алдагы елларда аның бу темага карата уйланулары тагын да киңәя генә төшә...

Чыннан да, аерым мизгел Мәңгелек яссылыгында нәрсә ул? Мәңгелек өчен Вакыт төшенчәсе, гомумән, ят түгелме? Алар бер-берсен аңлыйлармы? Әйтүе кыен. Тик монда бер нәрсә ачык: Кеше өчен Бакыйлык дигән билгесезлеккә «күчү» «үлем» дигән серле төшенчә белән бәйле. Иртәме-соңмы инсанга Туу-Яшәү-Үлемнең изге бәйләнешен аңларга кирәктер! Чөнки синең яшәешеңнең сере шушы хакыйкатьләргә бәйле бит...

Менә нәрсә ди фәлсәфи шагыйрь шушы турыда:

*Жил ул нәрсә?*
*Ул—юк, һава күчеше бар.*

*Ә мәхәббәт?*
*Тәңгәллеге кайбер җаннарның...*

*Олы Чынлык тик шул:*
*Туу,*
*Үлем,*
*Мәңгелек Хәят.*
*(«Җил ул нәрсә?..»)*

Олы Чынлык—безнең өчен серле, без аңлап бетерә алмаган Мәңгелек Хәят. Үлем исә Яшәешнең чиксезлеген тәэмин итүче сер булып кала. Джидду Кришнамурти (1895—1986), мәсәлән, бу турыда түбәндәгечә язган иде:

«Безнең җиребездә, гүзәл җиребездә булган һәммә нәрсә дә үлә, дөньяга килә һәм аннан соң тәссезләнә, шинә. Тормыш хәрәкәтен аңлар өчен акыл, фикер, укыганлык, белем түгел, ә ярату акылы, сизгер мәрхәмәт хисе булу зарур... Вакытыннан алда өзелеп төшкән яфракның матурлыгына, төсенә карап, кеше, мөгаен, үз үлеменең, гомер азагында түгел, ә башындагы үлеменең нидән гыйбарәт икәнен аңлый, төшенә торгандыр. Үлем ул—куркып кача торган яисә кичектереп була торган нәрсә түгел, ул көннән-көнгә кичерелеп баручы бернәрсә. Чамасызлык, чиксезлек хисе белән каян барлыкка килә».

Бу турыда шагыйребез үзе дә болай дип язып үтә:

*Төбенә төшеп уйлап баксаң,*
*бернәрсә дә куркыныч түгел.*
*Туу-үлү дигән ике чикне*
*котылгысыз үтү һәркемгә.*
*Мәңгелекнең, фанилыкның да*
*мохтаҗы юк безнең хөкемгә.*
*Ахыр чиктә*
*бернәрсә дә куркыныч түгел,*
*бернәрсә дә...*
*(«Төбенә төшеп уйлап баксаң...»)*

Фәлсәфи шагыйрь уйлана, фикер йөртә. Чөнки еллар узган саен, ул моңа тагы да ныграк төшенә: яшәеш серләрен аңлау бик катлаулы икән. Ул һәрвакыт «кача», «ераклаша», «шуып кала» кебек. Гомумән, уй-фикер ярдәмендә генә танып белеп бетереп була микән чиксез Яшәешне? Хәтергә Иоганнес фон Икскюль сүзләре килә: «Тормыш ул—югары һәм үз-үзенә тиң чынлык, аны физика яисә химия терминнары аша сурәтләп бетерергә мөмкин түгел».

Тормыш итүнең аерым бер мизгелендә шагыйрь дә шушы хакыйкатьне аңлап яза.

*Җитсәң дә Акыл тавының*
*биектәге читенә,—*
*Яшәү дигән Бөек Серне*
*аңламыйча кителә.—*
*(«Әй, бу Яшәү!..»)*

ди ул, фикри гаҗәпләнеп.

Үзенең шигъри-фәлсәфи уйлануларында шагыйрьгә Мәңгелек Хәятны танып белергә омтылырга, Илаһи Тынычсызлык кичерергә кала. Чөнки кеше башка җан ияләреннән шуның белән аерыла ки: ул еш кына Хаклыкны эзләү хакына Илаһи Тынычсызлык кичерә, һәм бу—Хакыйкатькә илтүче юл җинел түгел. Үзенең тынгысыз фикри эзләнүләрендә шагыйрь кайчак, якынына эндәшкән кебек, үзен дөньяга яраткан Раббысына эндәшә:

*Көч бир Син миңа, мәдәд бир!*
*И Аллам—Бөек хуҗам!*

*...Ник тыныч түгел бу күңел,*
*Ник тыныч түгел бу җан?*
*(«Көч бир Син миңа...»)*

Сүз дә юк, кеше Мәңгелек Яшәеш турындагы сорауларына җавапны төп диннәрдә, рухи укуларда таба ала. (Без, татарлар өчен, Ислам динендә.) «Барысы да Алладан, һәм барысы да Аңа кайтачак» диелгән анда. Кеше шушы хакыйкатьне аңлап, фани яшәешен дә Бакыйлыкка яраклы итеп төзи ала. Үз тереклеген Мәңгелек белән үлчәгән кешегә илаһи кануннарга гына буйсынырга кала.

Философ шагыйрь аңлый: илаһи кануннар, диннәр синнән рухи тормыш, рухи үсеш таләп итәләр. Чөнки рухи кыйммәтләр матди кыйммәтләрдән өстен калганда гына дөнья, кеше имин калачак. Чөнки рухи кыйбласына тугры калганда гына кеше ахыр чиктә үзен борчыган мәңгелек сорауларга җавап табачак, Хакыйкать белән бәйләнешкә керә алачак.

Шуңа күрә шагыйрь, бакый кыйммәтләр һәм заманның атмосферасы турында уйланып, болай дип тә яза:

*Машиналар хәзер югарыда!*
*Көч, Тизлек һәм Дәһшәт аларда!*
*Ә Мәгънә?*
*Ә Мәгънә—*
*робагыйларда!..*
*(«Машиналар хәзер югарыда!..»)*

Шушы яшәеш богжрасында кешегә кайта-кайта уйланырга һәм үз яшәешен фәлсәфи кичерергә кала. Тормыш исә гел алга бара: даими туып торган якты һәм гүзәл Моңнары белән, ел саен яшәешне данлаган шатлыклы Сабантуйлары белән...

*Таш уала... Чәчри тамчы...*
*Империяләр таркала...*
*Шәһәр булып күтәрелә балчык-комнар...*
*Агач тамырлары, тармакланып, ерагая*
*үзгеннән...*
*Атлый Кеше яшәү-лабиринттан*
*үзенә генә язган юл белән...—*
*(«Таш уала...»)*

дигән иде Равил Фәизуллин, кешенең җиһандагы язмышы турында уйланып.

Кешенең гомер юлы исә Алла сызган серле лабиринтлар аша чиксез Мәңгелек Хакыйкатькә генә илтә аладыр.

*Күп серләр мәңге ачылмый,*
*һәм кирәкмидер дә...*
*Алар, ахры, Күккә ашадыр*
*Җан рухы белән бергә.*


*Карагыз Күк гөмбәзенә!—*
*Йолдызлар—тоташ тылсым!*
*Уртак сер булмаса аларда,*
*ул берлек каян килсен?*
*(«Очкычлар ватылгач, җирдән...»)*

*2003, 2005-2006*

# ТОЙГЫЛАР САФЛЫГЫ

## МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАП ЧЫГАРЫЛГАН «БЕЗНЕҢ АВЫЛ КЕШЕСЕ» ИСЕМЛЕ ҖЫЕНТЫКНЫ УКЫП УЙЛАНУ

Балачагымның якты хатирәсе булып күңелемдә бер китап саклана. Инде күп еллар үтсә дә, ул ни өчендер онытылмый—бик еракта калган кадерле истәлекләргә алып китә. Бу якты хатирә—«Батыр исемле малай» дигән әсәр иде.



Узып киткән гасырның утызынчы еллары ахырында безнең гаиләгә «Пионер каләме» дигән журнал һәм «Яшь ленинчы» исемле газета килә иде, ә мин һәр икесен дә бик көтеп ала идем. Укып бетергәндә күңелне ике сүз әллә нишләтә—ымсындыра, канатландыра: «дәвамы бар»... Ул заманда күләмле матур әдәбият әсәрләрен журналлар гына түгел, атнасына өч-дүрт тапкыр чыга торган газеталар да бер саннан икенчесенә күчерә-күчерә басалар иде. Һәм безгә—яңа гына хәреф таный, укый белә башлаган балаларга—кызыклы әсәрнең бер сандагы өлешен тырышып-тырмашып укып бетергәч, «дәвамы бар» дигән гыйбарәне күрү күңелгә искиткеч бер шифа, алдагы очрашуга өмет һәм ышаныч ләззәте бирә иде. Әйе, бу гадәти хәбәр итеп кую гына түгел—«көтегез, кадерле балалар, дәвамы бар, сезне алда әле нинди кызыклар, яңа мажаралар, яңа очрашулар көтә бит» дип күңелләрне кытыклап, алгысытып торучы сихри мәгънәле сүз булган. Телевизорсыз, сериалсыз заманнарда үскән яшь буынга мондый нәрсәләр зур куаныч иде.

Менә шул чакларда «Батыр исемле малай турында хикәяләр» дәвамлы әсәр буларак басылды. Бу малай безнең якын дустыбызга, китапчарак итеп әйтсәк, идеал героебызга әверелде. Без аны, чыннан да, каядыр яшидер ул малай дип йөргәнбез, ә аны бер язучы уйлап чыгарган икән! Әнә шулай Мирсәй Әмир безне, сиздермичә генә, үзенең иҗат биләмәләренә генә түгел, ә олы әдәбият дөньясына алып кергән икән!

Чыннан да, мавыктыргыч иде ул хикәяләр—исемнәре генә дә ни тора: «Калку кырга кар ява», «Калку кырда кар беткәч», «Калку кырда карак бар», «Калку кырдан Казанга»... Авыл малае Батырның күргән-кичергәннәре, кыланышлары кайчагында безгә үзебезнеке булып тоела, ә кайчагында аның кебек буласыбыз да килә иде. Бер карасаң, ул башка малайлардан бик аерылып та тормый кебек. Әтисе белән әнисе генә Батыргәрәй дип йөртәләр, ә иптәшләре ана «Батыр» дип кенә дәшәләр... «Чәче өрәңә бакыр акча төсле. Түп-түгәрәк бите сипкелләр белән чуарланган. Кеп-кеченә курнос борыны яз җиту белән тиресен коя башлый». Аны «усал малай» дип тә йөртәләр. Дөресендә бу усаллык та түгелдер, андыйларны бүген «тынгысыз», «әйдәп баручы», лидерларга хас характер иясе» дип әйтерләр иде. Батыргәрәйнең олыларга булышып, башкаларны да ияртеп, күмәк хуҗалык кырларында мул иген уңсын дип кырларга күп итеп кар яудырырга тырышып йөрүләре, халык милкен урлаучы каракларны фаш итүе һәм саксызрак кыланып, язгы ташу суларына агып китеп, чак кына исән калуы,—болар барысы да галәмәт тә кызыклы, дулкынландыргыч, гаҗәп һәм аңлаешлы булып тоела иде. Белмим, бүгенге балалар мондый хәлләрне, мондый геройларны үз һәм якын итә алырлар микән? Юктыр, мөгаен. Әмма уз-

Мирсәй Әмир. Безнең авыл кешесе. Повестьлар. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2007.

ган гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында дөньяга күзләре ачылган буын Мирсәй Әмирнен Батырлары, Аркадий Гайдарның Тимурлары, Жюль Верннын капитан Грант балалары рухында тәрбияләнде һәм аларның бик күбесе ил мәнфәгатен яклаучыларга, җәмгыять өчен кирәкле кешеләргә әверелеп гомер итте.

Әдәби эшләнешләре, эстетик әһәмиятләре ягыннан төрле дәрәҗәдәрәк булган бу образларны бер киштәгә янәшә тезеп карамавымның үз мәгънәсе бар—аларны үзара бер нәрсә, бер фикер, бер идея якынайта—бу китапларның нәни геройлары меңләгән, миллионлаган укучыларны намуслы булырга, чынны ялганнан аера белергә өйрәткәннәр, «нәрсә соң ул кешелеклелек?» дигән сорауга җавап биргәннәр, яшь кешенең тормыш дәрьясына чыгып килгән мизгелләрендә угы Гаделлек һәм Дөреслек дигән изге төшенчәләргә юнәлтелгән компас вазифасын башкарганнар.

Шулай да, хәтеремә нык уелып калса да, әлеге Батыр Мирсәй Әмир иҗат иткән күп санлы геройларның берсе булып кына калды. Әдип үзе аны бик уңышлылардан дип санамады да ахрысы—әсәр әдипнең сайланма җыентыкларында урын алмады да бугай. Әмма Мирсәй Әмир балаларны, яшьләрне тәрбияләү мәсьәләсен беркайчан да онытмады, күңеленә иңгән балачак сафлыгыннан беркайчан да аерылмады—аның күләмле «Кичә турында бүген» дип исемләнгән соңгы зур әсәре дә—тәмамланып житмәгән автобиографик трилогиясе дә балаларга, яшүсмерләргә багышланган иде.

Әдипнең 100 еллык бәйрәмен әдәби җәмәгатьчелек матур гына билгеләп үтте. Ана карата булган олы ихтирам һәм хөрмәт язучы әсәрләренең ике тупланмасында да чагылды[1]. Без бу мәкаләбездә шул китапларның икенчесенә—янарагына—«Безнең авыл кешесе» исеме белән дөнья күргән повестьлар җыелмасына иркенләбрәк тукталырга уйлыйбыз. 500 биттән торган саллы гына шушы басмага урнаштырылган әсәрләр арасыннан нибары берсен генә күпчелек укучыларга яхшы таныш һәм әдәбиятыбызның классик фондына кертелгән дип әйтеп була—ул «Агыйдел» повесты. Ә башкалары? Алары да милли хәзинәбезнен түренә урнаштырырга лаеклы лабаса.

«Пар күгәрчен», «Хикмәтуллиннын маневрда күргәннәре», «Балыкчы ялганнары», «Җан көеге». Боларны күргәч, күңелне бер борчулы сорау биләп ала: сыйфатлары, эшләнешләре, тәрбияви тәэсир көче ягыннан караганда да башка әсәрләреннән һич тә кайтыш булмаган бу әсәрләр ни өчен җәмәгатьчелек игътибарыннан гел читләштерелеп килделәр икән?Җавап бик еракта да түгел ахрысы: чөнки байтак еллар дәвамында иҗади казанышлар мәгълүм рәсми идеология рухына туры килүенә карап бәяләнгәннәр. Нәкъ шул мөнәсәбәттә аларның кыйммәтләре, әһәмияте билгеләнгән, ә әдәби эшләнеш, иҗат рухы, үзенчәлекләре белән бәйле яклар искә дә алынмаган диярлек.

Ә әдипнен үз сүзен үзенчә әйтергә тулы хокукы барлыгын, һәм дә нәкъ шул хокукы булганга күрә, әдәбиятта үзенчә, үз исеме белән яши алуын Мирсәй Әмир инде 1928 елда ук «Пар күгәрчен» исемле повестенда исбат итәргә тырыша. Әсәрдәге вакыйгалар гади авыл егете исеменнән сөйләнә. Повестьның үзәгендә авыл яшьләре Камалетдин һәм Шәрифәнең пар күгәрченнәрдәй матур гаилә тормышы башлап җибәрүләре тора. Әмма ул заманда, «Чын бәхет» дигән төшенчәне башкачарак үлчәү яисә билгеләү хакимлек иткән икән. Бик еш уздырыла торган җыелышларның берсендә «һәрбер яшь йөрәк совет властен якларга тиеш. Совет власте—безнең власть, аны чын күңелдән яклаучы икәнеңне күрсәтер өчен, бөтен яшьләргә « коммунистический союз молодёжи» дигән оешмага керергә кирәк» дигән ялкынлы сүзләрне ишетеп, болар комсомолга язылалар, кызыл туйлар үткәреп, Алласыз, никахсыз яши башлыйлар. Үз исемнәрен яңа революцион исемнәргә алмаштыралар: Камалетдин Ревалгә, Шәрифә Лирага әверелә. Игезәкләре туа—берсенә Сәлим, икенчесенә Сәлимә дип кушалар. Бу исемнәр «Союз ленинской молодежи» дигәннең татарчалаштырып кыскартылганы дип аңлатыла.

Тора-бара гади генә кешечә көн итү белән «яңача» яшәү омтылышы үзара каршылыклар да китереп чыгаргалый:

«Лирочкам тенкәмне корытты.

---

[1] Мирсәй Әмир. Сайланма әсәрләр. «Мәктәп китапханәсе» сериясе. 35 т. Казан, «Хәтер» нәшрияты. 2005.

Әнисе авырып, Алласын бик еш кабатлый башлагач, колагыма килә дә пышылдый:

—Ревал, жаным, аллә кешегә белдермичә генә никах укытыйкмы? Әни рәнжер бит,—ди.

Яшь кәләш дип тормадым, ачуланып ташладым үзен:

—Комсомолка башың белән шуны сөйләп тору оят,—дидем.

Ул мина жинелде:

—Ярар инде алйса,—диде».

Мондый Камалетдин-Ревалләргә кәләшләрен генә түгел, үз-үзләрен кумәк эшләргә тарту да зур эш булып тоела:

«Мин кәләш алгач та ячейканы ташламадым. Аны үз өем кебек якын күрдем. Жәмәгать эшләренә дә үз бәрәнге бакчама караган кебек карадым. Кәләш тә шулай итте.

Үзен Алласызлык тарафдары дип ышандырасы килсә дә, Камалетдинның тормышка сөенеп, «Аллага шөкер» диясе килә, кендек әбисе дә совет акушеркасы түгел, ә Нәфига әби булып чыга, ә ике игезәк имчәк балаларын «әзрәк клуб төтененә иялэнсеннәр» дип жыелышларга-кичәләргә йөртә торгач, чир йоктыралар—ул бичаралар, шуннан арына алмыйча, якты доньядан китеп тә баралар. Мона карамастан, Ревал һәм Лира әсәр ахырында үз хәсрәтләрен онытып, яңадан ячейкага килеп, күңел тынычлыгы табалар.

Әнә шулай әсәр барышында тормыш табигыйлеге белән яңа режим догматикасы ярымфажигале, ярымкөлке рәвештә үзара бәрелешәләр, Әсәрнен нигезенә беркатлырак, әмма яңалыкка омтылучан авыл яшьләренең дөньяга, яңа тормышка күзләре ачылуы дигән схематик тезис салынса да, геройның сәеррәк кыланышлары, авторның бик мулдан сипкән юмор-сатира бизәкләре астында төп идея—сүтелә», пародиягә әверелә. Яшь һәм тәҗрибәсез автор бу хәлне ул чакта үзе бигүк аңлап та житмәгәндер, әмма вакытлар уза төшкәч, мондый әсәрләрнең, заман жәмгыяте тегерменәнә су коймаганлыгы сизелә башлый. Шуннан өч-дүрт ел элек Фатих Әмирхан да яңа тормыш тәртипләренең формаль демагогик догмаларга корылуын сатирик образлар аша күрсәтеп, үтергеч тәнкыйть уты астына алган иде бит...

«Пар күгәрчен»—чорга оппозиция рәвешендә түгел, киресенчә, илгә килгән яңалыкны бик мактап язган әсәр. Әсәрнең сюжеты һәм бигрәк тә героеның наданнарча чикләнгәнлеге, аңындагы демогоглык чире белән Камалетдин да Шәфигулланы хәтерләтә. Капма-каршы ике максаттан чыгып язылган ике әсәр ахыр чиктә бер яссылыкка килеп чыгалар: «Пар күгәрчен» әсәрен укыгач, күңелдә «яңа тормыш алып килүче совет власте нинди әйбәт» дитән фикер түгел, «теге ике баланы яңа тормыш дип юкка харап иттеләр бит» дигән үкенечле кызгану тойгысы уяна.

Ахыр чиктә «Пар күгәрчен» әсәре дә «Шәфигулла агай»дан ерак төшмәгән алма булып чыга. Фоат Галимуллин Мирсәй Әмир әсәренә дә шул заманның тәнкыйтен күрсәтү йөзеннән болай яза: М. Максуд М. Әмирнең «Пар күгәрчен» әсәренә бәя биргәндә, сүзнең мөмкин кадәр усалрагын сайлый: «Пар күгәрчен» хикәясе уң оппортунистлар теориясенең матур әдәбияттагы чыкылдап торган бер үрнәге булып чыккан»,—ди.

Инде бүгенге көн күзлегеннән, сәясәтче түгел, китап сөюче буларак карасаң, яшь-яшь Мирсәй Әмирнең хәзер дә рәхәтләнеп, көлә-көлә укырлык әсәр язуына сокланырга гына кала. Без, ни өчендер, Мирсәй Әмирнең ижаты турында фәкать житди әсәрләре буенча гына фикер йөртергә гадәтләнгәнбез—аның чын классиклар рәтендә торырдай юмор һәм сатира остасы икәнлеген онытып жибәрәбез. Яисә шуны күрмәмешкә салышабыз. «Пар күгәрчен» исемле әсәрнең дә әнә шундый онытуоныттыруның бер корбаны икәнлеге аңлашыла.

Игътибар белэнрәк баксаң, Мирсәй Әмир ижатының кимендә яртысы юморсатира нурларына манчылган икәнлеген күрергә була. Кем әйтмешли, ул әдип ижатының буеннан-буена кызыл жептәй сузылып килә. Хәтта драма әсәрләрендәге диалогларга да ул энже-мәржәннәр мул сибелгән. Без карый торган китапта «Безнең авыл кешесе» драмасы юк югын. Әмма анда урнаштырылган алты повестьның өчесе—юмористик әсәрләр.

Тәнкыйтьчеләр карашыннан мәхрүм калган әсәрләрнең икенчесе «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре» дип атала. Монысына да сюжет жебен Мирсәй Әмир тормыш чынбарлыгыннан суырып ала. Бу әсәрендә дә герой үз исеменнән сөйли. Әдип бу юлы да юморның табигатен, хасиятен бик дөрес аңлаганлыгын раслый. Авторның үз-үзенә карата юнәлтелгән юмор һәм сатира уклары гадәттә бик үтемле һәм нәтижә-

ле була: беренчедән, ул әдип белән укучы арасындагы табигый элемтә-контактларны тиз урнаштырырга булышса, икенчедән, үз-үзеннән көлүләреннән курыкмаган андый геройга табигый ихтирам-хөрмәт һәм ышаныч та уяна.

Хәсрәт солдат Хикмәтуллин үзенең булдыксызлыгы, ялкаулыгы, алдакчылыгы аркасында бик күп көлкеле мажараларга юлыга. Әсәр ахырына таба ул кимчелекләреннән аз-азлап арына башлый. Авторның юмор күренешләрен үзенә бер ләззәт белән язуы әллә каян сизелеп тора.

Әдипнең үткен телле, төгәл сюжетлы, образ гына чәнечкеле юмор белән сугарылган хикәяләре һәм повестьларының тамырлары, мөгаен, кайчандыр «Чаян» журналында эшләгән елларына ук килеп тоташа торгандыр. Ә инде «Кысыр хәсрәт» (1954) исеме җыентыкка кертелгән әсәрләре, бигрәк тә «Биш пот Гали», «Мөстәкыйм карт йокысы» кебек хикәяләре җыйнак, җылы һәм үткен юморның иң матур классик үрнәкләре булып саналалар.

«Балыкчы ялганнары» (1971) исемле повестенда әдип кешенең үзенчә ирken яшәүнең ләззәтен, дөньяның кайберәүләрне аеруча мавыктырган якларының берсен гаҗәеп бер бик табигый һәм кызыклы итеп сөйләп бирә. Әсәр геройларына балык тоту җене кагылган. Менә шундыйларның берсе турында: «Балык дигәндә Азатыбыз җил дип тә тормый, давыл дип тә тормый. Яңгыр да юк аның өчен, салкын да.. Төн дә юк, көн дә юк, яз да юк, көз дә...», «Балыкчы өчен балыкның эләккәне генә түгел, ычкынып киткәне дә бик кадерле һәм истәлекле икән, чөнки ул синең бөтен кан тамырларыңны дулкынландырып, күңелеңдә гомер буена, сагынып сөйләрлек матур истәлекләр калдырып ычкына икән».

Күренә ки, бу өлкәдә дә, үзенчәрәк итеп әйтсәк, әдибебез үзен суга, җибәрелгән балыктай тоя. «Балыкчы ялганнары» һәм «Мыжык карт язмалары» (1976) әсәрләре мажаралы һәм юмористик алымда эшләнүләреннән тыш, табигатькә, әйләнә-тирәгә мөнәсәбәттә кешенең рухи дөньясы һәм әхлакый йөзе, чынбарлыкка карашы кебек мөһим мәсьәләләрне күтәрүләре белән дә әһәмиятлеләр.

Татар әдәбият гыйлеме озак еллар дәвамында үзенең укучыларын үтә җитди, кырыс реализм рухында язылган әсәрләрне генә чын әдәбият була ала дип тәрбияләргә тырышты. Бу хакта турыдан-туры әйтелмәсә дә, әлеге өлкәдәге чынбарлыкка күз салсаң, хәл бик тиз ачыклана: татар әдәбиятындагы юмор һәм сатира күренешләре турында фәнни хезмәтләре аз языла, иҗатларыннан юмор-сатира чәчрәп-ташып торган Әхмәт Фәйзи, Фатих Хөсни, Шәйхи Маннур, Мөхәммәт Мәһдиев, Фаил Шәфигуллин кебек әдипләрнең шушы өлкәдәге иҗат эшчәнлекләре тиешенчә яктыртылмый. Тик чыгарма рәвешендә, классикларыбыздан Шәриф Камал һәм Галиәсгар Камал иҗатларындагы юморга гына вакытында игътибар булганлыгын әйтергә мөмкин. Әмма бүгенге әдәбият фәнендә Ибраһим Нуруллин, Абдулла Сайганов, Әхәт Нигъмәтуллин, Искәндәр Абдуллин кебек сатираның һәм юморның нинди көчле эстетик чара икәнлеген аңлаучылар һәм аңлатучылар кимеде, хәтта бетеп бара сыман. Әдәбият фәне дөньясын ясалма җитдилек, кирәгеннән артык җитди булып күренергә теләү галәмәте басты. Нәкъ менә шуна күрә дә әдәбиятны дустанә, якын, үз итеп, киңәшче, сердәш буларак кабул итәргә гадәтләнгән укучылар да үзләре яраткан әсәрләрне анализлаган фәнни мәкаләләрдә аңлаешсыз, авыр, катлаулы, терминнар чытырманлыгына эләгеп, буталып бетәләр, шуларга карап, дөрес юнәлешне, хәтта элеккеге эстетик кыйблаларын югалталар.

Туган халкыбызның бүген иң хәтәр җилләргә дә бирешмичә, сынмаска, сыгылмаска тырышып, үз күнелен үзе күтәреп, ачык һәм җор күңеллелеген югалтмыйча, мәгънәле, горур, шаян һәм зирәк акыллылыгын саклап яшәп яткан көне. Җор сүзнең кадерен, кыйммәтен аңлаучы, вакытында күңел күтәрерлек сүз әйтә белүче әдипләре дә күп аның. Кайберләренең генә исемнәрен санап үтик: Камил Кәримов, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт Хәким, Рабит Батулла, Фәнзаман Баттал, Ләбиб Лерон, Тәлгать Нәҗмиев, Алмаз Гыймадиев кебек талантлар хәзерге әдәбиятыбызның әнә шул күтәренке рухлы, таза, чиста, әмма һаман да югарыда әйтелгән мәгънәдә тиешле гадел бәясен алып җиткермәгән канатын тәшкил итәләр.

Сүз башыбыз шурәле дигәндәй, төп темабызга әйләнеп кайтабыз. Әлбәттә, китап укучыны гел унай, гел матур мисалларда гына тәрбияләү әдәбият-сәнгатьнең бердән-бер юлы түгел.

Мирсәй Әмир каләме начар, ямьсез, күнелгә ятышсыз хәлләрне сатира уты аша тәнкыйтьләргә, хәтта көйдерергә дә сәләтле иде. Язучы «Җан көеге» (1969) исемле повестенда ил өстенә килгән авыр сынау елларында шәхси мәнфәгатен генә алга куйган куркак җанлы бер бәндәнең гыйбрәтле һәм җирәнгеч фигурасын реаль нигездә күрсәтә алды.

«Сугышның авыр чагында... хәрби эшелоннан качып, үз йортына кайткан, шунлыктан башта сарайда печән астында, ә соңыннан үз йортының базында яшеренеп тере мәеткә әйләнгән Кәмәретдин Абдуллин кызгану түгел, ә чиркану хисе тудыра» дип язды әсәргә иң беренчеләрдән булып бәя биргән Гыйлемдар Рамазанов. Аннан соң ул повестьның һәм гомумән Мирсәй Әмир иҗатының бик әһәмиятле тагын бер ягына игътибарны юнәлдерә: «Шунысы әһәмиятле һәм куанычлы—бу кечкенә повестьның төп герое һич кенә дә дезертир Кәмәретдин түгел. Аның фаҗигасе Кәмәретдиннең әнисе Сабира апа һәм аның яшь, чибәр хатыны Хәтирәнең чын-чыннан саф йөрәкле, тирән тойгылы чын совет кешеләре булуларын ачу өчен күнелсез бер фон гына ул. Повестьның төп геройлары саф намуслы, фидакарь кешеләр». *(Рамазанов Г. Исәндәме, солдат?—Кызыл таң, 1973, 21 февр.)*

Әдәби осталык, стиль камиллеге мәсьәләсендә иң маһир язучы Хәсән Сарьянның фикерләре аеруча кызыклы: «Образларның төгәл эшләнүе, һәммәсенең ышандыруы җәһәтеннән «Җан көеге» повесте күпләргә үрнәк була ала. Анда—кереп тә, сүз әйтергә онытканы, яки сүз әйтеп тә, чыга алмый буталып йөргән бер генә персонаж да юк... Күлкүл су җыелып торган калын романнар белән чагыштырганда бу кечкенә повесть бик тыгыз. Ул—Мирсәй Әмирнең өзлексез камилләшә килгән осталыгы нәтиҗәсе. Монда ул «Саф күнелендәге озынлык чирен җинеп, сюжетның җегәрле агышына, композицион бөтенлеккә ирешкән... Җыеп әйткәндә, «Җан көеге» повесте—йодрыктай йомарланган, пружинадай, кысылган, кирәкмәгән бар детальдән арчылган, бер сулыш белән укыла торган әсәр ул».

Миңа калса, әсәргә моннан да төгәл, ачык, тулы һәм гадел итеп бәя бирү мөмкин түгел. Ә бит бу повестьның дөньяга чыгу юлы бигүк җиңел булмады: әсәрнең рухын-юнәлешен аңларга теләмичәме, әллә башка сәбәпләр аркасындамы, ул укучысына язылып беткәннән соң байтак еллар узгач кына барып җитте. Иң аянычлысы шунда: әсәр бүген дә уку йортларында яисә башка әдәби чаралар үткәргәндә әдипнең иң яхшы әсәрләре рәтендә тәкъдим ителми яисә бөтенләй игътибардан читтә кала. Бу хәлнең үзгәртелергә тиеш икәнлеген аңлап, әлеге «Безнең, авыл кешесе» җыентыгын төзүчеләр аны тупланманың иң алдына, беренче әсәр итеп куйганнар һәм бик дөрес эшләгәннәр.

Мирсәй Әмир бик катлаулы елларда да татар әдәбиятының мәгърур олылыгын бөтен илгә күрсәтергә теләп, зур оештыру эшләрен башкарган шәхес. Аның 1934—1980 еллар арасында СССР, РСФСР, Татарстан язучыларының барлык корылтайларында (РСФСР язучыларының II съездын исәпкә алмаганда) катнашуы факты үзе генә дә күп хакта сөйли. Ул 1937, 1961—1968 елларда Татарстан язучылары оешмасын җитәкләгән элегрәк эшләнгән библиографик белешмәләрдә бу дата ялгыш—киметеп күрсәтелгән).

Тормыш юлындагы фаҗигале хәлләр дә (аны 1937-39 елларда кулга алып, төрмәдә тоталар), әдәби эшчәнлегенә ясалма киртәләр кую да (мәсәлән, «Җан көеге» һәм «Миңлекамал» әсәрләренә аерым елларда ялгыш, тискәре мөнәсәбәт булу)—болар берсе дә аны тормышка, кешеләргә, иҗатка мөнәсәбәтендә төп юлыннан авыштыра алмады. Әдипнең якты, киң колачлы һәм бер үк вакытта җитди иҗаты бүген дә бик күпләрне сокландыра.

**Рифат СВЕРИГИН**

**Редакциядән:**

***Күренекле галим һәм әдәби тәнкыйтьче, Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты, журналыбызның даими авторы Рифат Хәсән улы Сверигинга бу айда 75 яшь тула. Юбилее уңаеннан аны кайнар котлыйбыз һәм исәнлек-саулык, яңа иҗат уңышлары телибез!***

# БЕРЕНЧЕ ТАТАР БАСМА КИТАБЫНА НИЧӘ ЕЛ?

Китабы басыла башлау теләсә кайсы халыкның рухи һәм, гомумән, иҗтимагый тормышында биниһая зур әһәмияткә ия вакыйга. Ул шушы халык вәкилләренең электән үк файдаланып килгән үз язуы, үз графикасы булуын, укый-яза белүнең тиешле дәрәҗәгә җитүен, әдәби традицияләрнең һәм уку-укыту эшенең киң таралуын, ягъни басма китапның үсеше өчен тиешле шартлар һәм ихтыяҗ өлгереп җитүен дәлилли.

Күчмә шрифтлар җыеп китап басу XI гасырда Кытайда туа, ә Европа бу эшкә XV гасыр уртасында гына керешә. Европада китап басуның барлыкка килүе Иоһанн Гутенберг исеме белән бәйләнгән, наширлек 1445 елда чыгарылган «Библия»дән башланган. Русиядә беренче басма китап 1564 елда барлыкка килә, ул Иван Федоров чыгарган «Апостол» була.

Татарларда хәрефләр җыеп китап басу эше барлыкка килү вакыйгасын һәм датасын ачыклаганчы, Болгар дәүләте чорында ук бабаларыбыз тормышында кулъязма китапларның киң таралганлыгын, китап язып көн күрүче хаттатлар яшәгәнлеген, мәктәп-мәдрәсәләр эшләгәнлеген, илләр гизү, дөнья халыклары казанышларын үзләштерү, үз ачыш-табышларын да күп халыклар арасында таныту кебек гамәлләрнең чит булмавын искәртү урынлы булыр.



Татар басма китабының без белгән тарихи үткәне Татарстан Фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, күренекле китап белгече Әбрар Кәримуллин хезмәтләре нигезендә торгызылды. Хәреф җыеп басылган беренче татар китабын ачыклау, барлау максатында эзләнә торгач, ул 1612 елда Лейпцигта татар телендә басылган бер китапка тап була. Әлеге китап татар теле грамматикасына керешне, татарча-латинча, латинча-татарча сүзлекне эченә алган әсәр булып чыга. Авторы — Лейпциг университетында төрки-татар телен укыткан профессор Иероним Мегисер (1555—1618). Бу китапның яртысы өлеше татар телен өйрәнү өчен басылган татарча текстлардан тора, алар һәм андагы сүзлекнең татарча өлеше гарәп хәрефләре белән татарча басылганнар. Ләкин Ә.Кәримуллин моны беренче татар басма милли китабы дип санау ягында түгел. Чөнки китап чит илдә басылган, авторы да чит ил кешесе. Ул Европада татар телен өйрәнү өчен чыгарылган, Европа укучылары арасында гына таралган. Дөрес, аның сүзлеген төзүдә татар кешесе дә катнашкан. Әмма, моннан чыгып кына, аны татар милли китабы дип атау бик үк дөрес булмас, дип саный галим.

Академик Ә.Кәримуллиннан аермалы буларак, нәкъ менә шул Лейпциг басмасын беренче татар китабы дип карарга кирәк дип исәпләүчеләр дә бар. Соңгы елларда матбугатта бу хакта язмалар күренгәләде. Һәрхәлдә, бу мәсьәлә үзенең фәнни нигездә тәфсилләп өйрәнүче һәм дәлилләп аңлатучыларын көтә. Кызганыч ки, Ә.Кәримуллиннан соң китапчылык тарихыбызны өйрәнү юнәлешендә җиң сызганып эшләүчеләр юк диярлек. Шунлыктан хәзергә татар җәмәгатьчелеге беренче басма татар китабының 285 еллыгы турында сүз алып бара.

Татар теле Киев Русе довереннән башлап рус дәүләтенең Шәрык илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләрендә кулланылган, әле XVIII йөздә дә бу шулай дәвам иткән. Руслар Персия, Кавказ, Урта Азия, Һиндстан, Кытай халыклары һәм идарәче даирәләре белән татар телендә аралашканнар. Россиядә беренче гарәп шрифтлары

да Кавказ төркиләре белән аралашу максатларында кулланыла башлый.

Россиядә беренче татар китабы 1722 елның 15 (хәзерге стиль белән 26) июлендә Әстерхан шәһәрендә Петр I нең «йөзмә» басмаханәсендә (суднога урнаштырылган поход типографиясендә) хәреф җыю ысулы белән басыла. Ул – Петр I нең Фарсы походы белән бәйле, җирле халыкларга бу походның сәбәпләрен алдан белдерүне, аңлатуны максат итеп куйган Манифесты. Петр патшаның әмере буенча бу Манифест Кавказда һәм Иделнең түбән агымында яшәүче халыклар арасында таратыла. Бу эш белән Әстерхан губернасында губернатор Волынский, Шәмаха һәм Дәрбәнт шәһәрләре тирәсендә поручик Лопухин шөгыльләнә, соңгысына ярдәмгә 15 татар солдаты да бирелә. Татарча тиражы 1000 данә булган Манифест шул ук типографиядә немец телендә дә басылган, ә рус телендә аерым рәвештә беркайчан да басылып чыкмаган. Озак еллардан соң гына аның тексты Фарсы походына караган тарихи хезмәтләрдә китерелә.

Манифестны бастыру өчен гарәп шрифтларын Петр I нең якын киңәшчесе, чыгышы белән кырым татары Дмитрий Кантемир ясаган хәреф рәсемнәренә карап эшлиләр, алар Россиядә беренче гарәп шрифтлары була. Поход басмаханәсен оештыручы да, аның белән җитәкчелек итүче дә – Кантемир үзе. Патша кушуы буенча Манифестның текстын да ул яза.

Петр патшаның ярәннары арасында татарлар да була һәм Фарсы походында 30 меңгә якын татар солдаты катнаша.

Рус дәүләтенә аның көнчыгыш сәясәтендә күрсәткән хезмәтләре өчен соңыннан генерал-майор дәрәҗәсе алган Котлымөхәммәд Тәфкилев тә Яшерен Советның өлкән тәрҗемәчесе булып походта катнаша. Манифест татарчага аның тарафыннан тәрҗемә ителгән дип санала. Ә текстны җыю һәм бастыру эшен татар солдатлары башкарган.

Югарыда әйтелгәнчә, «Манифест»ны татар кешесе тәрҗемә итә, аның текстын басмаханәдә татар кешесе җыя, шрифтның рәсемнәрен дә кырым татары Д.Кантемир ясый, типографиядә бастыручылары да татарлар була. Басылып чыккач, аны татар солдатлары төрки һәм мөселман халыклары арасында тараталар. Димәк, «Манифест» татар укучысына да барып җиткән. Шуңа күрә әлеге «Манифест» басмасы төрки-татар басма сүзенең беренче үрнәге дип санала. Петр I нең йөзмә басмаханәсендә татар телендә башка китаплар басылуы хакында да мәгълүматлар бар, ләкин ул китапларның хәзергә кадәр табылганы юк әле.

1722 елгы төрки-татарча Манифестның бер нөсхәсе хәзерге вакытта Россия Фәннәр Академиясенең Азия һәм Африка халыклары Институты китапханәсендә, тагын берсе Россиянең борынгы актлар дәүләт архивында саклана.

Милли басма китабыбыз, халкыбыз тарихының елъязмасы булып, өч гасырга якын тарихи юл үтте, зур каршылык һәм киртәләргә юлыгып торуына карамастан, октябрь инкыйлабына кадәр генә дә 15 мең исемнән һәм 3 миллион нөсхәдән торган, аннан соңгы бер гасырга якын дәвердә тагын меңнәрләп һәм миллионлап өстәлгән бай мирас тупланмасы барлыкка китерде.

Мәдәниятебезнең, әдәбиятыбызның, фәнебезнең, мәгърифәтебезнең, иҗтимагый фикер тарихыбызның көзгесе булган милли китабыбызның тарихын өйрәнү бүген дә иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә.

Татар басма китабына ничә ел тула соң дигәндә, 1722 елгы «Манифест»тан исәпләгәндә быел 285 ел, ә Лейпциг басмасына 395 ел тула. Бу ике датаның берсе дөрес, икенчесе ялгыш дигән карашта тормыйбыз. Һәр икесе дә безнең татар халкының теленә, басма сүзенә бәйле олуг тарихи вакыйгалар. Моннан 395 ел электәгесе татар китапчылыгының дөньякүләм әһәмиятен күрсәтсә, 285 ел әүвәлгесе Россия эчендәге тарихи шартларның бер дәлиле.

Хәзер фән дөньясының мөмкинлекләре чиксез зур, чит илләрдәге архивлар, китапханәләр һәм музейларга да юллар ачык вакыт. Гайрәтле яшь галимнәребез җитди әһәмият белән зур тырышлык куйганда беренче татар китабы басылуның иң төгәл вакытын ачыкларлар дип ышанабыз. Ихтимал, ул әйтеп үтелгән даталардан да элеккерәктер.

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ХӘТТАТ*** *г.* — Матур (күркәм) язу остасы, каллиграф; матур язарга өйрәтүче.

Гарәп язуының иң беренче үрнәге булып *куфи язуы* (куфи хаты) санала. Хәттатлар гарәп язуын камилләштерә килеп, аның йөздән артык өлгесен иҗат иткәннәр. Тора-бара традицион ситтә — алты стиль (*ситтә* — "алты" дигән сүз): *мухәккак, рәйхан, нәсх, сөлс, тәуки, рика / рокъгә* өлгеләре барлыкка килгән. Боларга фарси язу стильләре килеп өстәлгән. Гарәп язу шәкелләренең яңалары иҗат ителгән, болар: *тәгълыйк, нәстәгълыйк* (нәсх һәм тәглыйк төрләре кушылган) һәм *шикәстә*. Иң еш кулланыла торган язу шәкелләре *куфи, нәсх, рокъгә, нәстәгълыйк, ди(й)вани* һәм *шикәстә* дип атала. Гомумән, XIX гасырга язу өлгеләре саны 70 тән дә артып киткән. Шартлы рәвештә куфи язуына карата нәсх өлгесен курсив дип атарга мөмкин, ә тәгълыйк исә нәсхнең үзенә карата курсив (тизрәк, җиңелрәк языла).

Җитди эчтәлекле текстлар — Коръән һәм дини китаплар ачык, төгәл һәм ансат укыла торган нәсх белән, документлар һәм шәхси хатлар курсив рокъгә, тәглыйк, шикәстә белән, ә рәсми актлар катлаулырак һәм тантаналы эре өлгеләр кулланып — сөлс, тәуки һәм дийвани стильләрендә язылган. Куфи язуы архитектурада, коелма металл эшләнмәләрне бизәүдә кулланылган.

Коръәнне күчереп язуның Шәрыктә гаять зур осталары булган, аларга илдә хөрмәт белән караганнар. Мәс., Төркиядә Шәех Хәмдуллаһ (1437-1519), Госман әфәнде (1642-1698), әл-Хаҗ әс-Сәед Хәсән Риза (1849-1920) бу өлкәдә аеруча уңышлы эшләгәннәр. Шоһдә әл-Кятибә исемле хатын үзенең матур язуы һәм хәдисләр сөйләү осталыгы белән тарихта дан казанган. 1460-1470 елларда эшләгән хәттат Хаҗи-Корбан-хафизның исеме Ибраһим хан ярлыгында теркәлгән.

Мөселман хәттатлары сүзләрне алма һәм груша шәкеленә, кошларга һәм арысланга әверелдереп, язма телне визуаль йогынты ясау белән тулыландыралар.

Мәхмүт Кашгарыйда *"уч"* — язу каләмнәре ясауга китә торган агач төшенчәсе очрый ("Древнетюркский словарь"да: "название дерева, из которого делают перья для письма, трости и т.д."). Шулай да монда *камыш* (тростник) күздә тотыла булса кирәк ("Каләм" сүрәсенең рус теленә "Письменная трость" һәм "Тростниковое перо" дип тәрҗемә ителүен искә төшерик).

Һәр язу шәкеле өчен камыш каләмне очлауда махсус алымнар кулланылган. Мәс., нәсх белән язганда (ә Коръәннең күпчелек күчермәләре нәсх шәкелендә язылган) каләмне чак кына кыйгачрак очлаганнар. Каләм очлый торган пәке йөзе артык озын да, кыска да булмаган, киңлеге дә пәке каләм очында борыла алырлык итеп эшләнгән ("пәке" сүзе үзе дә фарсы-таҗик чыгышлы). Каләмне ашыкмыйча, бик җентекләп очлый торган булганнар. Каләм очын кискән вакытта махсус аскуймадан *(гайкат)* файдаланганнар. Гайкат пластинкасы чиста һәм ялтырап торырга тиеш булган. Каләмне шул аскуймага куеп, пәке белән кыеклап кискәннәр. Шуннан соң каләмне сынау өчен нокта куеп караганнар. Нокта дөрес чыкса, яза башларга мөмкин дип санаганнар.

Эрмитажда саклана торган экспонатлар арасында Алтын Урдага нисбәтле бронза каләм дә бар.

Язу әсбапларын *каләмдан* дип атала торган махсус пеналда саклаганнар. Әсбаплар

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

комплектына кечерәк кенә капкачлы металл кара савыты, камыш каләмнәр, кәгазь кырыйларын тигезләп кисү өчен кайчы, пәке һәм гайкат пластинкасы кергән. Табылдыкларга караганда, кара савытлары бронзадан яки фаянстан ясалган, кызыл балчыктан ясап, глазурь белән коелганнары да булган.

“Начар вә килешмәгән каләм ата вә анасын рәнҗетүче бала кебектер вә һәм бәгъзе гадәвәт итүче карендәш кебектер, димешләрдер.” Каюм Насыйри.

Борынгы Болгарда һәм Казанда хәттатлар камыш каләмнәр (килек) белән "хушхат" (күркәм, матур язу) стилендә язганнар. “Килек” сүзен Дәрдмәнд тә кулланган әле.

Тора-бара безнең якларда язуда *хамә*, ягъни каурый каләм куллануга күчкәннәр, аның өчен каз канатының иң эре каурые (*шаһбал*) алынган. Электә каурый йоны булмаган камыш каләмне *фәрештәсез каләм* дигәннәр, чөнки каурый каләмнең һәр төге саен бер фәрештәсе була дип ышанганнар. Каурый каләмне очлау да үзе бер осталык сораган. Нәкый Исәнбәт элекке Казан дәүләтендә диванханә һәм базарларда язу-күчерүчеләр рәте булып, кара савытларын (дәватләрен) муенга тагып, каурый каләмнәрен колак артларына кыстырып торганнар дип яза.

Карл Фукс Казан шәкертләренең каләм өчен күркә каурыеннан файдаланулары, ә караны суда тушь җебетеп ясаулары турында хәбәр итә.

Европада уйлап табылган корыч каләмне тимер каләм, рус каләме дип тә атаганнар. Түбәндәге бәеткә карап фикер йөрткәндә, корыч каләмнәргә кадәр җиз каләмнәр дә булган дип уйларга кирәк. XIX гасыр ахырына инде каурый каләмне “тимер каләм” алмаштыра.

*Каләм бәете*

Кара савыты тора, көмеш башлы җиз каләм,
Каләмнең хезмәте илә агарды бөтен галәм.

И каләмем, каләмем, сәңа булсын сәламем,
Сәнең кылган хезмәтеңә юктыр һичбер кәлямем.

Күз өстен каралттың, дөнья йөзен агарттың,
Ничә миллион нөсхәләрне җир йөзенә тараттың.

Китаплар килерме иде, адәмләр белерме иде,
Әгәр каләм булмаса, хөкемнәр йөрерме иде.

Диңгез кичергән каләм, җиһан гиздергән каләм,
Ярны ишеп, тауны тишеп, ташны ваттырган каләм.

Тупны аттырган каләм, шәһәр ваттырган каләм,
Дау чыгарса—солых кыла, шул каләмгә йөз сәлам.

Язу өчен кәгазьне алдан эшкәрткәннәр: башта аңа крахмал нигезендә ясалган махсус катнашма (*ахар*) сеңдергәннәр, аннары кәгазь битен әйбәтләп тигезләгәннәр, шома чуерташ, пыяла шарчык яки кабырчык белән ышкып ялтыратканнар. Габделҗәббар Кандалый үзенең мәхәббәт хатларын саргылт һәм кызгылт төсләрдәге *афтаби* дигән кәгазьгә язганлыгын әйтә.

Кәгазьгә юл сызыгын механик ысул белән төшергәннәр. Линейка (*мистар*) буенча каты, ләкин кисми торган нәрсә (мәс., без) белән сызып эз салганнар, кайчагында юка тигез катыргыга киереп юл-юл тарттырылган ефәк җепләр өстенә кәгазь битен каплап, шуның өстен кул белән сыпырганнар да кәгазьдә нәзек эзләр (юл-юл сызыклар) калган.

Язу карасына (*сийаһ*) килгәндә, аларны әзерләү ысулы Солтан-Гали Мәшһәдинең һәм Казый-Әхмәднең хезмәтләрендә сакланган. Солтан-Гали рецепты асылда ике катнашмадан: корым белән чия чәереннән ясалган туштан һәм ачуташ белән кара чикләвегеннән ясалган язу карасыннан гыйбарәт. Шушы ике эремәне катнаштыргач, чыдамлы һәм куе төсле язу карасы хасил булган. Казый-Әхмәд рецептына исә анар

кабыгы, кара чикләвеге һәм купорос кергән. Хан исемнәрен язу өчен язу карасына алтын оны куша торган булганнар. Кызгылт-сары төстәге караны зәгъфран үсемлеге оныннан ясаганнар һәм *зәгъфран кара* дип атаганнар. Гомумән, мөселман илләрендә бик күп төсләрдәге язу карасы кулланганнар. Мәс., XI гасырда төзелгән бер белешмәдә кызыл, ал, яшел, сары, зәңгәр һ.б. төсләрдәге язу каралары санап кителгән.

Г.Ишмухаметов сүзлекчәсендә "язу карасы" мәгънәсендәге гарәби *хибер* сүзе теркәлгән.

Хәттатлар хатасыз язарга тырышканнар, хата төзәтү хупланмаган. Ләкин хаталар барыбер киткәләгән, аларны каләм белән төзәткәннәр (пәке белән кырмаганнар).

Язу-сызуга карата татарда кызыклы гына табышмаклар чыгарганнар. Мәс.: "Аузы бер, теле ике, җаны юк, сөйләгән сүзенең һич саны юк" (кара савыты, каләм, язу); "Бохарадан килгән пел (*фил*-А.Т.), уртасында тасма тел, җанныдан җансыз туар, ул ни булыр, аны бел (кара савыты, каләм, язу)"; "Әгәр киссәң башыны, йөрәге һәм алына; аз-аз гына эчерсәң, сөйләшергә салына" (каурый каләм). Бу табышмаклар Н.Ф.Катановның "Матеріалы къ изученію казанско-татарскаго наречія" (Часть первая) китабыннан алынды.

Китап күчереп язучылар китүе ихтимал булган хаталар өчен китап ахырында укучыдан гафу үтенгәндә түбәндәге гыйбарәне еш кулланганнар:

*Хат хатадыр, хатасын орма йөзгә,*
*Хатадан хали ирмәс хакъдин үзгә...*
*Хата ирсә-каләм илә сийаһы,*
*Фәкыйрь язгучының күпдер гөнаһы...*

"Күчереп язучыларның хыянәте" (*хийанәт әл-вәррақин*) гыйлем өчен зур бәхетсезлек саналган һәм күп кенә галимнәр үз китапханәләрен үзләре күчереп язуны артык күргәннәр.

Татар мәдрәсәләрендә *хөсне хатка* (матур, күркәм язуга) аерым дәресләр билгеләнгән.

Татарлар арасында да гарәп язуының осталары үсеп чыккан. Казан һәм Петербург университетларында шәрык телләре укыткан һәм каллиграфия дәресләре биргән Ибраһим Хәлфин, Ибнеәмин Әминов, Казан университеты мөгаллиме Мәхмүдов Мөхәммәдгали, Рәхмәт Әмирхан, М.Чутай, Хөсәен Фәезхановларның гарәпчә язу үрнәкләре камиллек һәм зәвык үрнәкләре булып исәпләнә. Мөхәммәдгали Мәхмүдовның хәттатлык осталыгы турында сәнгать белгече П.М.Дульскийның махсус мәкаләсе бар *(П.М.Дульский. Казан каллиграфы Гали Мәхмүдов. Казан, 1930-рус телендә)*. 1861 елда ул Мәрҗанинең "Болгар вә Казан тарихы" китабын күчереп язган. Ул нәсх, шикәстә һ.б. стильләренең гүзәл үрнәкләрен калдыра. Шиһабетдин Мәрҗанинең бабасы Габделкәрим дә хәттат булган. Китап күчерү белән даими эш иткән хәттатлардан Оры авылыннан Иванай Арсай улын (XVII гасыр азагы), XVIII гасырның беренче яртысында Арча төбәгендәге Түбән Оры авылында яшәгән һәм 90 Коръән күчереп язуы белән мәшһүр булган Алма абыз углы Габдеррәзак хәзрәтне, Ташкичү авылыннан Илми Үтәмеш улын (1700-1740 еллар), шагыйрь Мәнди Котышны (1761-1849), Оренбург губернасыннан Тайсугани Габдрахман Туймөхәммәд угылын (1690-1762 елдан соң), Ашыттан Сәйфелмөлек Зәйнетдин улын (XVIII гасыр уртасы), Кыснадан Собхан Мәрҗанине (ул үзе генә дә 60 томнан артык китап күчергән) атап күрсәтергә мөмкин. Балтач районы Сасна авылы имамы Таҗетдин Иштирәкинең (1788-1841) 40 тан артык китап күчергәнлеге турында Ризаэддин Фәхреддин яза. Габденнасыйр бин Сабит әл-Әчкенинең (1746-1841) 200 дән артык татар китабын күчереп язганлыгы билгеле. Казанда литографиядә гравер булып эшләүче Лотфи Өммәти күчергән китапларын шәрык орнаментлары белән бизәгән. Исмәгыйль Рәмиев үзенең хатирәләрендә халык телендә "Удивительный Закир" дип исеме чыккан каллиграф Закирне искә ала. Каюм Насыйри сөйләвенчә, Зөя өязе Югары Шырдан авылыннан Хөсәен баба Әлмөхәммәт улы (1805 елларда Шырданда вафат) Коръән язучы булып танылган, аны үз гомерендә берничә йөз китап язгандыр дип сөйләгәннәр. Бөгелмә өязе Әлки авылыннан Хисаметдин Мөслим улы 1828 елда ике җилдле (2253 битле) "Мәдарик әт-тәнзил вә хакаик әт-тәнвил" китабын күчереп язган. XVII гасырда кабер ташларына язучы оста Ашман бине Бикмөхәммәд билгеле.

Исмәгыйль Рәми XIX гасыр ахыры-XX гасыр башларында оста куллы хәттатлардан

Казанда-мәгърифәтче әдип Габрахман Мөхәммәтәмин улы Ильясины, Мөхәммәт Идрисине, Кавам Зөлфаккаровны, Галиәсгар Камалны, Котдус Фәхретдиневны, югарыда телгә алынган "Удивительный Закир" кушаматлы Зәкир хәттатны, Усман Салиевны, Оренбургта—Госман Акчокраклыны, Сәлах Камалны, Петербургта—Ильяс Бораганскийны, Уфада—Баһаветдин Максудовны күрсәтә.

Соңгырак чорда Татарстан халык рәссамы Бакый Урманче оста хәттат буларак та танылган иде. Гарәп хоруфаты гомумкулланылыштан чыккан чорда белем алган буыннар килгәч, хәттатлыкны сагынып сөйләргә генә калды, ләкин өметле генә каләм осталары хәзер дә юк түгел, аларга ихтыяҗ да сизелә башлады. Матур гына язылган шамаилләр, тугралар күренә, әмма, кызганычка каршы, алар хатадан хали түгел, чөнки бүгенге хәттатларыбыз тиешле әзерлекне үтмәгәннәр.

Дөньякүләм мәшһүр хәттатлардан Истанбулдагы Айя-Суфия мәчетен гадәттән тыш зур һәм матур язулы герблар белән бизәгән төрек каллиграфы Бичаки Задә Мостафа Чәләбине аерым билгеләп үтәргә кирәктер.

***ХӘЧТЕРҮШ***—"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә кыяфәтсез, шыксыз, ямьсез кеше дип аңлатылса да, кайбер галимнәр бу сүзнең туры мәгънәсе "Тәре (хач) йөртүче" дип уйлыйлар ("Тәре сугышлары"нда катнашкан христианнар).

***ХӘШӘБ / ХӘШӘП*** *г.*—1.Мәнсез, аңгыра кеше турында әйтелә (мондый кешегә карата "агач" дип әйтү дә бар). 2.Агач (бүрәнә, такта кебек материалга карата). // *Чабата хәшәп*—табанына такта куелган юкә башмак.

Күплек саны шәкеле-*әхшаб*.

***ХӘШИШ*** *г.*—**1**.Чүп үлән; гомумән үлән. //*Хәшиш әл-бәхер*—диңгез үләне. **2**.Киптерелгән һинд киндере чәчәгеннән ясала торган наркотик матдә—*гашиш*. Хәшишне тәмәке кебек тарталар, чәйниләр яки иснилә, кайчак таблетка рәвешендә кабул итәләр.

Юридик әдәбият сәхифәләреннән күренгәнчә, Ислам дөньясында хәшиш IV/IX гасырларда гына кулланылышка кергән булырга тиеш. Аны куллану шафигыйларда рөхсәт ителгән, ә хәнәфиләрдә тыелган була. Хәшишне еш кына суфилар да кулланган. Ул организмны агулый, тотрыклы һәм аермачык күренә торган галлюцинацияләр тудыра. Хәшиш кулланучы наркоманнарны *хәшишиннәр* дип атаганнар.

Хәшиш Азиядә борынгы заманнардан бирле кулланылып килгән. Бу наркотикның Мексикадагы исеме—*марихуана*.

***ХИҖАБ*** *г.*—**1**.Пәрдә, йөз өреткеч; пәрәнҗә, никаб. Мәс., Мөхәммәд Пәйгамбәрнең җәмәгатьләре хиҗаб киеп йөргәннәр (Һиҗрәнең бишенче елыннан башлап). Сөнгатулла Бикбулат: "Хиҗаб Рәсүлуллаһ хатыннары өчен горурлык, өстенлек һәм башкалардан аерылып тору өчендер,"—дип яза. Чыннан да хатын-кызга йөз каплау тиешлеге турында Коръән- кәримдә һәм хәдисләрдә бер сүз дә юк. "Нур" сүрәсенең 31 нче һәм "Әхзәб" сүрәсенең 59 аяте чәч вә муеннарны каплау тиешлеген генә күрсәтәләр. Ләкин бүген хатын-кызларның гаурәтләрен күрсәтеп, ярымшәрә йөрүләрен берничек тә аклап булмый. //*Кальб хиҗабы*—гыйлем-мәгърифәттән ерак калу.

Кеше белән Аллаһ арасында җитмеш мең хиҗаб бар, болар-кешенең нәфесе, эгоистик тойгылары.

**2**.Оялу, тартыну. **3**.Бөти, амулет (бу мәгънә "Шәрык алынмалары сүзлеге"ндә теркәлгән).

***ХИЛКА*** *г.*—**1**.Алка, балдак, боҗра. **2**.Түгәрәкләнеп утырган кешеләр, түгәрәк, даирә. Русчадагы "кружок"ка туры килә. //*Хилкаи тәдрисе*—дәрес бирү түгәрәге. *Ишаннар хилкасы*.

Суфичылык истиляхы, суфиларның берлек, кумәклек, туганлык символы. Суфилар алачыгында күмәкләшеп зикер әйткәндә дәрвишләр, хилка ясап утырышалар, уртага шәехне алалар һәм, күзләрен йомган хәлдә, экстаз (җәзеб) халәтенә керәләр.

"Суфичылык серләре" китабында бу термин *халка* рәвешендә алынган.

***ХИСАР*** *г.*—Курган, ур; ныгытылган җир, кальга, ныгытма, форт, русча—острог.

*//Хәрәм хисары* – Изге җир (Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә чикләре билгеләнгән изге урыннар). *Ун көн каланың нигезен берничә микъдар эшләгәннән соң, кич белән эштән бушагач, хан сорады: "Каланың хисары астына берәүне-берәүне салдыгызмы?" – диде.* "Бу Яңа Казанның гыймарә кыйлынганы." "Риваятьләр һәм легендалар" китабыннан. *Сакласа һәркемне дошмандин Ходай, ләм-йәзил Хаҗәт ирмәсдер аңа кимәк зарра гали хисар.* Кол Шәриф.

***ХОЗЫР ИЛЬЯС КӨНЕ*** *тар.* – Төрекләрдә 6 майга (иске стиль буенча 23 апрельгә) туры килгән мөбарәк дата. Христианнардагы изге Георгий көненә тәңгәл. Шушы көннән кышка туктатып торылган сугыш хәрәкәтләрен яңартырга мөмкин булган.

***ХОРАФАТ*** *г.* – Искелек калдыклары, буш әкиятләр, ялган ышанулар; юк-барга ышану.

"Хорафат гакыл белән хакыйкать арасында пәрдә булып тора, – дип яза Р.Фәхреддин. – Сәфәргә чыккан вакытларында юллары аркылы бер нәрсә үтеп китү яки карга вә саескан кебек кош тавышы ишетелү, тән тарту вә төш күрүдән шомланучылар шушындый гакыллары пәрдәләнгән кешеләрдер".

"Җәвамигуль кәлим шәрхе" китабында Ризаэддин Фәхреддин дин бөркәнчеге ябынган һәм әле бүгенге көннәрдә дә дини әдәбиятта хакыйкать сыйфатында сөйләнгән төрле хорафатларның шактый тулы исемлеген китерә. "Дини әсәрләрдә вә тәфсир исеме белән язылган китапларның күпләрендә, – ди ул, -гүя (дөнья) шушы үгез өстендә, үгез балык сыртында торганлыгы вә иртә белән үләнләргә төшә торган "чык"ның шушы үгез сулышыннан хасил булган "бу" булуы; хәзрәте һава Адәм пәйгамбәрнең сул кабыргасыннан ясалып та, шуның өчен сул кабырганың саны ким иканлеге; яңгырларны фәрештәләр чиләкләр белән диңгезләрдән ташып яудырулары; әсхабе кәһаб этләре булган Кыйтмир, Ибраһим пәйгамбәр тәкәсе, Салих пәйгабәрнең дөясе, Гозәер пәйгамбәр ишәгенең җәннәткә керәчәге; аяклары җир астында торган хәлдә кикрикләре гарешкә терәлеп тора торган зур бер әтәч тавышын ишетүләре белән бөтен җир йөзендә булган әтәчләрнең кычкырулары; бөтен җирне уратып алган вә яшел зөбәрҗәттән булган "Каф" исемле бер тау булып, шуның төсе күкләргә төшеп торуы; шул Каф тавы артындагы шайтанлар адәм балалары алдансынлар вә сәхәр ашамый калсыннар өчен яктысы бөтен җир йөзенә төшәрлек рәвештә ут яндырып ятулары; хәҗәре әсвәднең якуттан булып та, гөнаһлы адәмләрнең куллары тию сәбәпле каралып калуы; Бәйтелмөкатдәстәге сәхра җиргә тимәгән хәлдә һавада торуы вә шул сәхрада Рәсүлулланың аяк эзләре калуы; Гуҗ бине Гоныk исемендә коточкыч зур гәүдәле бер кеше булып, туфан суы бары тезләренә генә җитүе, туфан суындан балыклар тотып, кояшка күтәреп кояш кызуында пешереп ашавы вә соңыннан Муса пәйгамбәр тарафыннан үтерелүе; Шаддад исемле падишаһ бер кирпечне алтындан вә бер кирпечне көмештән итеп Гадән сәхрасында җәннәт бина иттереп вә шул җәннәт бу көндә дә сәламәт булса да, адәм балаларына күрелми яшерелеп торуы, һәр ай өчен яңа бер ай вә һәр көн өчен яңа бер кояш чыгып, фәрештәләр кояшны алтын арбага салып тартып барулары; Әбелхәят исемле чишмәдән су эчүче кеше мәңге вафат итми торуы вә шул судан эчкәне сәбәпле Хозыр Ильяс пәйгамбәрнең һәмишә җир йөзендә халыклардан яшеренеп сәламәт йөрүе мисалында асылсыз сүзләр вә хорафи хәбәрләр язылып тора".

"Кеше гакылы инде бер килешкән нәрсәсен (ул нәрсә гомум кабул ителгән булсын яки аның үзенә генә ошасын – барыбер) яклау өчен бөтен чараларны эшкә куша. Капма-каршы фикерне раслаучы дәлилләр никадәр күп яки көчле булмасын, гакыл аларны күрми яки күрмәмешкә салыша яисә аларны кире кага, теше-тырнагы белән карышып, үҗәтләнеп инкяр итә, баштагы инануларының дөреслеге кагылгысыз булып калсын дип тырыша." Бу сүзләрне 1620 елда философ Френсис Бэкон әйткән. Гомумән, хорафатларның психологик асылы алдынгы фикер ияләренә бик ерак заманнарда ук билгеле булган.

Тагын шуңа игътибар итик: кичә өстенлек иткән карашлар һәм тәгълиматлар бүген тормозга әйләнергә мөмкин. Мәс., бүген коммунистик карашлар әкияти хорафаттан башка нәрсә түгел.

***ХОРШИД*** *ф.* – Кояш, көн (татар телендәге "көн" сүзе дә элек кояш мәгънәсен белдергән).

***ХОТБӘ*** *г.* – **1.**Җомга намазы вакытында, корбан бәйрәмнәрендә һәм махсус көннәрдә сөйләнә торган нотык; никах вакытында укыла торган вәгазь. Аны хатиб (кагыйдә буларак, имам) мөнбәргә басып гарәпчә укый (вәгазь ана телендә укыла). Кайчагында хотбә рифмалаштырылган проза-нәсер рәвешендә булган. Хотбәнең мөслимнәргә йогынтысы зур булган һәм еш кына аны дәүләт чиновниклары язып биргәннәр.

"Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хотбәләре гел бер төсле генә булмыйча, ул мөселманнарның хәлләренә күрә вәгазь сөйли иде" (Сөнгатулла Бикбулат). Хотбә сөйләгәндә аны икегә бүлеп, утырып та алуы билгеле. Хотбә вакытында сәхабәләре сорау бирсә, ул хотбәсен өзеп, аңа җавап бирә, аннары хотбәсен дәвам итә торган булган. //*Никах хотбәсе.*

**2.**Гомумән, халык каршында сөйләнгән сүз, нотык, чыгыш, речь. //*Гаяз әфәнде адреска каршы хотбәсендә артистларның мөхәррир мөсәүвиден тәшхыйс итүче булганлыкларыннан тәкъдиргә иң лаек затлар икәнлекләрен бәян итте.* "Кояш", 1917, 16 апрель.

***ХӨҖҖӘТ*** *г.* – Дәлил, аргумент; факт, ышандыргыч документ. Синонимнары – *дәлил, борһан* (фәлсәфәдә һәм мантыйкта), шулай ук *шәһадә, икрар* һәм *бәйинә* (фикъһедә). Коръәндә фәкать Аллаһның гына ышандыргыч дәлилләргә ия булуы турында берничә тапкыр әйтелә (6:83, 149/150). //*Хөҗҗәт әл-хакк*-хакыйкать дәлиле (әдәбиятта Әбу Гали ибне Синаны шулай дип атау очрый). *Әл-Хөҗҗәт әлә-л-халык*-халык өчен Аллаһның дәлиле ("кырый" шигыйлар Мөхәммәд Пәйгамбәрне шундый дәлил дип санаганнар). *Хөҗҗәт әл-Ислам* – Ислам дәлиле (аеруча абруйлы дин галимнәренә, мәсәлән әл-Газалигә, шундый хөрмәтле исем бирелгән).

Ислам хокукында "хөҗҗәтлек" дигән төшенчә бар. Мөхәммәд Пәйгамбәрдән садир булган, ягъни башланган һәрбер сүз, гамәл яки тәкърирләр безгә чын (сахих) һәм ышанычлы риваятьләр белән килеп ирешкән булсалар, хөҗҗәт дип хисап кылыналар. Мөҗтәһидләр шулар нигезендә шәргый хөкемнәрен чыгара алалар.

Күплек саны шәкеле – *хөҗәҗ.*

***ХӨКЕМ*** *г.* – **1.**Уй йөртү, фикер йөртү. **2**.Мәхкәмә карары, суд карары. **3**.Режим, дәүләт төзелеше. //*Шәригать хөкемнәре. Шәргый хөкем. Тәҗвид хөкемнәре.* Бу мисалларда "хөкем" сүзе "кушуы буенча", "кагыйдәсе буенча" мәгънәләренә ия.

Шәргый хөкемнәрне *тәклифи хөкем* һәм *вәзгый хөкем* төрләренә бүлеп карау кабул ителгән. Теге яки бу эшне эшләүне таләп итүче яки берәр эшне тыючы яисә берәр эшне кылу һәм кылмау уртасында ихтыяр булган хөкемгә тәклифи хөкем диләр.

Мәс., "Тәүбә" сүрәсенең 103 нче аятендә: "Мөселманнарның малларыннан зәкят ал" диелә. Бу – мөкәлләфтән үтәү таләп ителгән хөкем була. "Хуҗурәт" сүрәсенең 11 нче аятендәге "Бер каум башка бер каум өстеннән көлмәсен, аны мәсхәрә кылмасын" дигән хөкем исә кылмау таләп ителгән хөкем. "Җомга намазын укыганыгыздан соң таралыгыз" *("Җомга" сүрәсе, 10 нчы аять)* хөкеме исә ихтыяри хөкем: эше булган кешеләр таралышырга, ә эштән бушаган кешеләр икенче намазны көтеп мәчеттә утырырга да мөмкин.

Әгәр берәр хөкемне үтәү өчен теге яки бу шарт һәм сәбәп булырга тиеш икән, андый хөкемне вәзгый хөкем диләр. Әйтик, "Маидә" сүрәсенең 6 нчы аятендәге хөкем – "Әй, мөэминнәр, әгәр намазга бассагыз, иң элек йөзләрегезне һәм кулларыгызны терсәккә кадәр юыгыз" сүзләре вәзгый, ягъни шартлы хөкемгә мисал була. Чөнки намазның мөкәммәл булуы өчен шарт итеп тәһарәтнең фарызлыгы куелган.

Төрле мәзһәбләрдә хөкемнәрне тагы да нечкәләбрәк төрләргә аеру барлыгын әйтергә кирәк.

Татарча "Коръән тәфсире"ндә "*хөкмий*" сүзе очрый (98:3).

*Дәвамы киләсе саннарда*

Рәфыйк
Шәрәфиев

# БЕР АВЫЛНЫҢ КҮРГӘННӘРЕ

*Карадуган кебек булырмын мин,—*
*Дошман алларында бөгелмәм.*
Илдар Юзеев.

Себер салкыннарын ияртеп көнчыгыш ягыннан искән җил, авыл читенә җиткәч, икегә аерылган урамнарның кайсына керергә белмәгәндәй, басыла төшә. Авыл башындагы зират та җилне исәр юлыннан тоткарлап тынычландырадыр. Шулай да кайвакыт җил куәте борынгы бу зиратның карт каеннарын сындырырга җитәрлек була, ел саен язгы чистарту вакытында юан-юан бер-ике каенны йә тураклап яндырырга, йә зират читенә тарттырып чыгарырга туры килә. Гаҗәеп зур ябалдашлы, колач җитмәслек юан нарат кына җил-давылларның берсенә дә бирешмичә горур басып тора. Хәер, горурлыгы картларчарак инде, аның да гомер азагы җитә бугай. Зиратның иң карт агачы икән диләр иде шул аны. Бәлки ул авылның яшьтәшедер һәм заман зилзиләләренә карамый әлегәчә исән-имин яшәп, шул авыл язмышын гәүдәләндерәдер. Наратның асылынып үскән түбәнге ботаклары җиргә тигәч, заман ахыры җитәчәк, дип тә юрыйлар иде авыл картлары. Тора-бара ул ботаклар яшәүдән һәм үсүдән туктап корый башладылар, тик җиргә әллә ни якынаймадылар. Инде без, бүгенге өлкәннәр, бу легенданы балаларга сөйли калсак та, чынга алучы булмас иде, мөгаен. Тик барыбер, заман ахыры якисә гомер азагы киләчәген искәртү өчен генә булса да, сөйләргә кирәк булган. Кабатлый торгач, шунда бу «ахыр»га үзебезне дә ышандырган булыр идек, бәлки. Һәркемнең «дөнья»сы бер бетәчәк бит. Авыл кешеләренең әллә ничә буыныннан бирле килгән легендаларны өзүче булу ни үкенеч!

Зиратның түбәнге итәгеннән аз гына көнчыгыштарак тагын бер каберлек бар иде. Анысын керәшен зираты дип йөрттеләр. «Керәшен» атамасын телгә алырга теләмәгән олылар аны «яналар зираты» дия иде. «Яналар» дигәне яңа керәшеннәрне аңлаткандыр, бәлки. Шундый төшенчә дә бар икән бит. XVIII гасырдан соң чукындырылганнарны яңа керәшеннәр дип атаганнар. Ләкин Карадугандагылары борынгырак булганга охшый. Кайбер тарихи язмалар да монда иске керәшеннәр яшәгәнлеген күрсәтеп тора. Бер елны күмәк хуҗалыкның ипсез бер рәисе, кайдандыр килгән мелиораторларга кушып, каберлекнең агачларын төбе-тамыры белән йолкытты. Җирен болынга кушарга теләгәннәрдер, күрәсең. Табигый, ягъни, «кыргый» болыннарны сөреп «культуралаштыру» заманы иде шул. Каберлекнең карт каеннары бу тирәне сөрергә комачаулагандыр, мөгаен. Әмма сөрү борынгы каберлекнең дә печәнен яхшыртмады, ә болынның кайчандыр төрле-төрле чәчәктән генә торган, «Карадуган болыны печәне» дип аерым макталып йөргән үләне картлар истәлегендә генә калды.

«Яңалар зираты»нда төп зираттагы нараттай карт агачлар юк иде. Шуннан чыгып, зират үзе дә «яшьрәк» булган, димәк, керәшеннәр монда авылга нигез салган мөселман татарлардан соңрак килеп урнашканнар дип уйларга нык сәбәп бар.

Ике зират арасындагы бушлыкка да кеше мәетләре күмелгән булып чыкты.

Илдә кукуруз игү шаукымы күтәрелгәч, булачак силоска зур итеп чокыр казучылар шундый билгесез каберлеккә тап булдылар. Аннан бала сөякләре дә чыкты. Траншеяга, әлбәттә инде, силос салынмады. Бирегә кемнәр мәете күмелгәнлеге исә сер булып калды. Бөек акыл иясенең: «Жиргә баскан һәр адымың—кеше йөзенә» дигән сүзләре тагын кайсы авылга шушылай тәнгәл килә икән?

Хәзергә кадәр билгеле булган тарихи истәлекләрдә Карадуган авылы /କородован/ беренче тапкыр Иван Болтин төзегән «Казан өязенең 1602-03 елгы Язу кенәгәсе»ндә /Писцовая книга Казанского уезда 1602-03 г.г./ телгә алына. Шушы документка нигезләнеп булса кирәк, «Татар исемнәре энциклопедиясе» Карадуган авылына XVII гасыр башында нигез салынган дип белдерә. Ләкин авыл, һичшиксез, элегрәк төзелгән. Чөнки әлеге Язу кенәгәсендә элекке авыл урыны /пустошь/ турында гына сүз бара. Аңа кадәрге Карадуганның төгәл тарихын инде мәңге белә алмабыздыр. Ә шулай да авылны «пустошь»ка калдырган сәбәпләр һәммәбезгә мәгълүм диярлек. Явыз Иван яуларының буйсындыру сугышлары Казан ханлыгының үзеген тар-мар итү белән генә төгәлләнмәгән әле. Халык үзе дә җинелүе, иреген, дәүләтен югалтуы белән килешергә теләмәгән, шунлыктан ханлыкның әле бер, әле икенче төбәгендә баш күтәрү чуалышлары чыгып торган. Мәскәүнең яулап алынган милләтләрне көчләп урыслаштыру-чукындыру сәясәте дә зур ризасызлыклар китереп чыгарган. Билгеле, урыс гаскәрләре мондый «фетнә»ләрне рәхимсез төстә бастыра килгәннәр, халкын кырып, фетнә үзәге саналган авылларны тар-мар иткәннәр. Тарихчылар 1552-57 елларда гына да Казан арты төбәгендә һәм Кама буенда 250 татар авылыннан көл генә калганлыгын язалар. Мәгълүм Иван Болтин да, төбәктәге Салауч /Салавыч/, Елгулова /Янгул/ авылларын язган чакта, «күптән түгел булган сугыш»ны телгә ала, чөнки сугыш әлеге авылларны да беркадәр вакытка кешесез калдырган була.

Карадуган авылы урынын да буш хәлдә озак тотмыйлар, аның печән әзерләрлек җирләрен Денис Колчуринның тол калган хатыны яңа керәшен Пелагея Денисовна белән Шабулат Шачюрингa бергәләп файдалану өчен бирәләр, төгәлрәге, ниндидер хезмәтләре өчен бүләк итәләр. Шабулатка, шулай ук Колчуринның Митька һәм Олешка исемле ике улына казнадан әйбәт кенә хезмәт хакы да түләнә. Колчуриннар белән Шачюрин Шушма /Язу кенәгәсендә Тошма/ елгасының ике ярыннан, Ширә инеше буеннан һәм Чәткәнә /Шаткана/ үзәненнән 55Ошәр чүмәлә печән чабып алалар. Болар хакында да Иван Болтин язмалары хәбәр итә. Бу вакытта Карадуган игенчелегенең тәмам рәте киткән булган, күрәсең, монда сөрелгән урыннар телгә алынмый. Ә менә Салавычта 78 чирек сөрелгән җир барлыгы һәм 17 «чуваш» хуҗалыгы яшәгәнлеге әйтелә.

Карадуган тарихының «керәшенле чор»ы , язма истәлеккә карагандa, шушы Колчуриннардан башланса да, чынлыкта Пелагея Денисовна белән Шабулат Шачюрин бу авылга нигез салучылар да, хәтта анда төпләнеп яшәүчеләр дә түгел. Пелагеяның төп җир биләмәсе Арча юлының Казанбаш авылында, Шабулатныкы Түбән Мәтәскәдә булган. Алар шул якның авылларында кабаклар, Казансуның югары агымында һәм Ия инешендә тегермән тотканнар. Әйе, Мәскәүнең урыс хакимияте халыкның рухын сындыру әмәлләрен яхшы үзләштергән, ханлык үзәген туздырганнан соң, Казан арты авылларына үзенең динчеләре белән генә түгел, кабаклары белән дә һөҗүм итеп килгән. 1885 елгы авыллар исемлегеннән күренгәнчә, Карадуганда да ике кабак /питейное заведение/ эшләгән. Ул яктан вәзгыятьнең әллә ни үзгәргәне дә юк: авылда дүрт кибет тәүлек буе диярлек исерткеч сату өстенә, тагын да мәһабәтрәк бишенчесе төзелеп бетте. Әмма бүгенге кибет хуҗалары христиан динендәгеләр түгел инде, аракы сату-алуга үзебез бик остардык.

Россиядә 1719-22 еллардан башлап 1858 елга кадәр барысы ун тапкыр халык исәбе алынган. Карадуган халкының кабаттан оешып, авыл булып яши башлавы өченче ревизия чорларына—1762 елларга туры килә. Исемлеккә нибары алты хуҗалык теркәлгән: 1700 елда туган Исәкәй Кадыйровлар, 1711 елгы Арыслан Кәдрәков, 1703 елгы Ибраһим Юнысов гаиләләре, 1712, 1716, 1719 елларда туган

Гали, Гомәр, Госман Йосыповлар. Хуҗалыкларның алтысы да күп балалы ишле гаилә булып яшәгән, шуна күрә аларның яна буыннары заман зилзиләләрен имин кичеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Кадыйровлардан хәзер авылда яши торган Шәриповлар, Шакиржановлар, Хәкимовлар нәселе тармакланган. Кызганыч, бу шәҗәрәдән Сәфәргалиевлар һәм Гыйззәтуллиннарның авылда беркеме юк инде. Егерменче гасырның утызынчы елларында гына да күп балалы Гыйззәтуллин Фатих абзый гаиләсе иң таза тормышлылардан саналган. Исәкәй Кадыйровның бишенче буын оныклары бертуган Габсәләм һәм Гыйлемҗан Мәҗитовлар да сәүдә кәсебе белән шөгыльләнгән. Егерменче гасыр башындагы бер документта әйтелгәнчә, Габсәләм бабайның /әниемнең әтисе/ еллык товар әйләнеше 1600 сум булган, авылда бүтән кәсептәшләре аннан шактый калышкан. Аларның Минлебай атлы энеләре Казанда яшәп сәүдә иткән. Минлебайның Габдулла исемле улы сугыш корбаннарының «Хәтер китабы»нда бар, гаилә язмышы хакында башка хәбәрләр ишетелми.

Борынгы шәҗәрәсенә караганда, үзе бер зур авыл булырлык Арыслан Кәдрәков токымы да, кечерәя-кечерәя, авылда Мифтахов-Нәбиевлар һәм Латыйповлар буларак кына егерме беренче гасырга килеп җиткән. Ибраһим Юнысовның нәсел тармаклары булган Кәримовлар һәм Фәхертдиновлар да егерменче гасырда юкка чыгып бетә язган. Исән тармагы—Сәгъдиевләр генә. Бүген Сәгъдиевләр нәселенең дүрт кешесе Татарстанның атказанган хезмәткәре исемен йөртә.

Бик гаҗәп һәм гыйбрәтле хәл: Карадуганда халык санының кискен кимүе, кайбер гаиләләрнең тәмам юкка чыгуы һәм авыл хәтереннән җуела баруы без әлегәчә аңлап җитмәгән егерменче гасырга, бигрәк тә аның беренче яртысына туры килә. Бәхетсезлегебезгә күрә, бер Карадуган язмышына гына туры килгән бәла түгел бу.

Ревизия исемлегендә Йосыпов Гали, Гомәр, Госман гаиләләренең Ахман (Балтач?) авылыннан күчеп килгәнлеге әйтелә. Бу вакытта гаилә башлары үлгән була. Әтисез калган күп балалы гаиләләрнең тиктомалдан җайлы гына чит-ят авылга килеп урнаша алуы бик ышандырмый, билгеле. Мөгаен, сугыш вакытында китәргә мәҗбүр булган гаиләләрнең, дөньялар бераз тынычлангач, әтиләре яисә бабалары корган үз авылларына кире кайтып төпләнүе турында сүз барадыр монда. Бәлки әтиләре дә үлмәгән, ә һәлак булгандыр. Йосыпов Гали нәселен хәзер авылда Хафизовлар, Шәрәфетдиннекеләр, Гомәр токымын—Булатовлар, Госман шәҗәрәсен—ике «оя» Нәбинекеләр дәвам иттерә. Ә Йосыповлардан тармакланып кайларгадыр китеп югалган һәм бүгенге авыл хәтереннән бөтенләй җуелып бара торган «оя»ларның исәбенә дә чыгарлык түгел. Хәсбиулла Әһлиуллин, Сәләхетдин Камалиев, Фәйзулла Төхфәтуллин, Габделхәй Баһаветдинов, тагын ниндидер шактый ишле Салаватныкылар, Исмәгыйль Исхаков, Сөләйман Габсәләмов гаиләләре... Күбесенең исемнәре үк ят инде. Унтугызынчы гасырның соңгы унъеллыкларында тутырылган мулла метрикәләренә күз салсаң, яңа туган балаларның күплегенә исләрең китәр. Кечкенә генә Карадуганга шуның кадәр кеше ничек сыйган дип хәйран калырсың. Хәер, егерменче гасыр сыйдыра алмаган аларны, күче-күче белән юк иткән.

Авыл үзенең Карадуган дигән исеменнән әлегәчә уңмады дияргә була. Бәлки ул зур мәгънәле исем булгандыр да, авыл аны күтәрә алмагандыр. «Бөек» урыс иләндәге татар авылларының байтагына хас язмыш бу. Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хокукый әгъзасы И. А. Износков 1886 елгы «Казан өязенең торак урыннар исемлеге»ндә Карадуган атамасы татарча «кара» һәм «туган» сүзләреннән ясалган, дигән имеш-мимешне телгә ала. Ә үзе авыл исемен «Карадуван» шәкелендә яза, ләкин «туган»ның ничек итеп «дуван»га әверелүен аңлатып маташмый. Билгеле инде, «кара» төшенчәсе монда «пычрак» сүзе белән тәңгәлләштерелә. Янәсе, бу авылның беренче кешеләре керәшен татарлар булган да, күрше-тирә мөселманнары алардан көлеп, кара туганнар / грязным родился/ дип йөрткәннәр. «күрше-тирә» дигәндә Арбаш һәм Таузар авылларын күз алдында тотарга кирәктер, чөнки аларда Карадуганның керәшенле

тарихын кинаяләп телгә алучылар әле дә очраштыргалый. Димәк, Износковның үз диндәшләрен дә аямыйча «пычратуы» кирәкле рольне уйнаган, ике диндәге бер үк халык арасына озын гомерле «кара мәче» җибәреп калдырган диган сүз.

Әмма авылга керәшеннәр нигез салган диган юраманы И. А. Износков язмасыннан башка берни белән дә раслап булмый, киресенчә, моңа шикләнеп карарлык сәбәпләр байтак. Е. И. Чернышовның «Вопросы этногениза тюркоязычных народов Среднего Поволжья» исемле китабында /Казань,1971/ Казан ханлыгы чорындагы Шушма буе авыллары картасы бар. Анда, хәзерге район үзәге Балтачтан, мәгълүм Марат Әхмәтовны, атаклы Васил Минһаҗевны, Камил Исхаковның әнисе Илһамия ханымны биргән Хәсәншәехтан да элегрәк, Карадуган авылы да кергән. Шулай булгач, Казан ханлыгы авылына каян килеп керәшеннәр нигез салган, ул чакта татарларны кем чукындырган, дигән урынлы сораулар туа, ләкин аларга беркем дә ачык җавап бирми һәм бирә дә алмый. Чөнки чукындыру-урыслаштыру элекке Казан ханлыгы өстеннән Мәскәүнең канлы хакимияте урнашкач кына актив төс ала. Аннары, мантыйкча фикер йөрткәндә, әгәр авылга керәшеннәр нигез салган булса, русларның яулап алу һәм буйсындыру сугышларында Карадуганны беркем дә «пустошь»ка калдырмас, ул җирне читтәге ике керәшен гаиләсенә бирү ихтыяҗы да тумас иде.

Соңрак бу авыл егетләренең солдатка күп алынуы да властьларның ниндидер сәбәп белән Карадуганга «аерым игътибар» бирүеннән түгел микән? Бер нәселне генә күздән кичерик. Минем бабай олылар хәтерендә «Солдат Шәрәфи» булып саклана. Аның әтисе Габдерәшит, ревизия исемлегендә әйтелгәнчә, 1843 елда, Габдерәшитнең бертуган энесе Шәрәфетдин 1855 елда рекрутлыкка алынган. Боларның әтиләре мулла метрикәсендә «билетлы солдат Шәмсетдин» дип язылган.

Авылдан ерак түгел, иске Казан юлы өстендә, борынгы әүлия кабере бар. Кабер турындагы мәгълүмат С. М. Шпилевскийның «Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии» китабына (Казань, 1877, стр. 485, «Древняя могила в д. Карадуван на р. Шошме»), шулай ук уникe томлы «Татар халык иҗаты»ның «Риваятьләр һәм легендалар» китабына кергән. Менә легендаларның «Кисек башлы әүлия» исемлесе (игътибар итик, ике чыганакта да авыл атамасы Карадуган дип бирелә, ә ниндидер «кара туган»га бернинди ишарә юк):

«Карадуган авылыннан ерак түгел, почта юлы буенда иске язулы бер кабер ташы бар. Бу ташны ике йөз еллар элек Вятка губернасындагы Бәрәскә авылы сәүдәгәрләре куйган, дип сөйлиләр. Бу кабер ташы турында шундый хикәят сакланган: Бохарадан өч кеше чыгып бөтен җирдә ислам дине таратып йөргәннәр. Бервакыт Казаннан Карадуганга бара торган юлда, хәзер Фонглен урманы дип аталган урманда, ниндидер юлбасарларның олаучыларга һөҗүм иткәннәрен күрәләр һәм олаучыларны якларга ташланалар. Әмма бу сугышта юлбасарлар бер изгенең башын кисәләр. Изге, башын култык астына кыстыра да, алга таба китә. Иптәшләре аннан башын алырга телиләр, ләкин ул бирми. Шуннан алар аның ике кулыннан тоталар да юл буйлап китәләр. Алар шулай сигез чакрым үтәләр, аннан соң башсыз кеше юлдан читкә өч адым атлый да егылып үлә. Иптәшләре аны шул урында күмәләр, ә үзләре кире Бохарага кайтып китәләр».

Күршедәге Шубан авылы мулласының кызы Нәкыя Мәгъсүмова, әтисе Мәгъсүмҗан хәзрәттән ишетеп калып, әүлия каберенә Хәсән улы Искәндәр хаҗи күмелгән дип хәтерли иде.

Кабернең борынгы ташы гасыр җилләрендә таралып бара инде. Бик тирән батырып язылган гарәп хәрефләре танымаслык булып тигезләнә. Шулай да филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов 1994 елда бу таштан «Бар дөньяның хакиме Аллаһе әйтте: бер сәгатьлек дөньяга алданып иманыңны онытма» дигән сүзләрне укый алды. Ул шулай ук «тарих тукыз йөз кырык икедә» дигән сүзләрдән чыгып «таш һиҗри 942, руми 1536да куелган, дигән нәтиҗәгә килде. Димәк, кабернең «яше» легендада әйтелгәннән дә өлкәнрәк булып чыга. Керәшеннәр нигез

салган кара исемле авыл янына бер мөселман да үз изгесен җирләп, берничә гасыр торырлык язулы таш куеп калдырмаган булыр иде. Димәк, авыл атамасының килеп чыгышы хакында Износков язып алган юраманың ышандырырлык төпле нигезе юк. Диннәр борын-борыннан янәшә килешеп кенә яшәгәннәр дип уйласак, нык хаталанган булырбыз. Тәре походларын, көч белән чукындыруларны, чукынганнан соң ислам диненә кире кайткан өчен җәзалауларны онытмыйк. Мондый җәза кылычы Карадуган өстендә дә ялтырап-ялтырап алган.

Социализм чорында Карадуган атамасының килеп чыгуын ниндидер «кара таган»га бәйләп аңлату хәтта рәсми төс алган иде. Янәсе, авыл башында, Себер тракты буенда, кара буяулы таган торган, Себер юлы буйлап сөргенгә озатылучы каторжаннар, качарга омтылсалар яисә бүтән яманлык кылсалар, шул таганга асып үтерелә торган булганнар. 1956 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм республика лекторлар бюросы чыгарган «Карадуган авылы лекторлар берләшмәсе» исемле китапчыкта нәкъ шулай дип язылды. «Шушы юл буенда /Себер тракты турында сүз бара.—Р. Ш./ хәзерге Татарстан, Балтач районы авылларыннан берсе Карадуган авылы урнашкан. Картлар сөйләве буенча, авылның исеме дә әнә шул каторжаннар юлына бәйләнгән. Әби патша /Екатерина II/ заманында качарга омтылучы тоткыннарны асар өчен кара буяулы таган эшләнеп куелган бу авылда. Ошбу кара таган каторжаннарны гына түгел, бәлки хокуксыз, атсыз-җирсез, наданлык коллыгында яшәгән авыл халкының котын алып, мораль яктан изеп торган»,—диелә анда. Себергә сөрелүчеләрне ни өчен нәкъ менә Карадуганда асарга кирәк булган, дар агачын нилектән таган дип атаганнар, андый «таган», гомумән, авылда булганмы, булса, кем күргән һәм кайда язып калдырган—мондый сораулар беркемне кызыксындырмады. Кызыксынучы, төпченүче булса, бирәдә «каторжаннар юлы» салынудан йөз еллар элек үк авылның Карадуван дип аталуын белер иде. Бу авыл аша, күргәннәрен яза-яза, русның атаклы сәяхәтчесе П. П. Семенов-Тянь-Шанский, патшабикәгә баш бирмәгән хөр фикер иясе А. Н. Радищев узган. Тик аларның сәяхәтнамәсендә авылның дар агачы хакында бер сүз дә юк. Радищев биредән 1790 елның ноябрь аенда, уникесе белән унөче арасында үтә. «Чуашларның һәм чирмешләрнең өйләре кара, ләкин, мал абзары белән тоташ салынган урыс өйләреннән аермалы буларак, һавасы чиста... Татарларның өйләре ак»,—дип яза ул бу яклар хакында. «Вяткага житкәндә Г. Юшковның урыс авылы бар, мужиклар ярлы, өйләре сәләмә»,—дип дәвам иттерә арырак киткәч. Татар җирләрен яулап алу да аларны бәхеткә коендырмаган, күрәсең.

Бу юлдан П. П. Семенов-Тянь-Шанский үтеп киткән чорда һөнәрчелек, җиңел сәнәгать җанланган була инде. «Казаннан 70 чакрымдагы почта станциясе Мәтәскәне узгач, 95нче чакрымда тракт Карадуган станциясенә килә... Бу авылда XIX гасырның 60 нчы елларында кытат һәм комач фабрикасы булган, хәзер Якуповның зур булмаган сумала кайнату заводы гына бар,—дип язып уза ул. Туку фабрикасының юкка чыгуын монда бүтән һөнәр—йомран мехы эшкәртүнең күтәрелеп китүе белән аңлатырга буладыр. Сонрак шушы гап-гади һөнәрчелек тә авылга шактый бәла китергән.

«Татары Среднего Поволжья и Урала» исемле китапта XVIII йөз азагы—XIX йөзнең беренче яртысында бу төбәктә Әтнә, Мәңгәр, Алат, Карадуган, Җөри , Түнтәр, Сосна, Ор, Саба, Мәчкәрә кебек шактый нык экономик үзәкләр барлыкка килүен хәбәр итә /сүз җаеннан әйткәндә, Кытай җирендә туган академик Миркасыйм Госмановның әнисе ягыннан бабасы сату эшләре белән шул якларга барып җиткән Ор сәүдәгәре була/.

И. А. Износковның 1885 елгы «Исемлегендә» теркәлгәнчә, Карадуган халкы 797 дисәтинә җир тоткан, 241 дисәтинә «буш җир» өченче гильдия купец Муса Якуповныкы саналган. Авылның почта станциясе, 3 харчевнясы, 2 кабагы, 2 тимерчелеге, Муса бай җирендә ике кытат фабрикасы һәм бер су тегермәне булган. Халык уртача муллыкта яшәгән. 1878 елгы «Исемлек»тә исә Казан мещанины Козминның һәм отставкадагы солдат Предконың каралтылары, сәүдәгәр Якуповның

туку фабрикасы һәм мал абзарлары телгә алына. Урыслар, бәлки, мондагы ике тимерчелектә эшләгәннәрдер, чөнки татарларны, урыска каршы корал ясау ихтималы бар дип, бер авылда да тимерчелек эшенә якын китермәгәннәр.

Казан тирәләре, элекке татар биләмәләре, урыс дәүләте өчен тынычсыз, хәтта хәтәр җирләрдән саналганга, әүвәлге Себер юлы бу якларны читтә калдырып, әйләнечтән салынган була. Карадугандагы «Себер юлы тарихы» музеена тупланган материаллар «Әби патша юлы»ның салыну тарихына шактый ачыклык кертә. 1735 елда Себер рудниклары идарәчесе В. Н. Татищев юлны Казан аша үткәрү кирәклеген, аннан үтсә, 409 чакрымга кыскарачагын һәм уңайлырак урыннардан узачагын белдереп Сенатка хат яза. Билгеле, Татищев мондый фикерендә ялгыз булмый. Һәм 1762 елда патшалык итә башлаган Екатерина II бу ниятне гамәлгә ашыра. Петербургтан Казан—Арча—Карадуган аша Себергә илтә торган әлеге тракт беренче категорияле башкала юлы дип йөртелгән һәм Россиядә иң әһәмиятлеләрдән саналган.

1780-1790 еллар арасында авылда почта станциясе ачылган, ул якын-тирәдә иң зурлардан булып, транспорт һәм почта элемтәсенең әһәмиятле төенենә әверелгән. Кеп-кечкенә авылда соңрак өч харчевня, ике кабак ачылу да шушы станциягә, юл йөрүчеләрнең күплегенә бәйледер. 1808 елда станциядә 32 ат тотылганлыгы мәгълүм. Нәкъ йөз елдан авылга телеграф килә. Россия Эчке эшләр министрлыгының почта һәм телеграфлар Баш идарәсеннән Казандагы почта-телеграф округы начальнигына 1908 елның 5 июнендә махсус күрсәтмә җибәрелә. Аңда Карадуган почта бүлеген почта-телеграф бүлеге итеп үзгәртергә, аның штатына бер начальник, Түбән окладлы ике надсмотрщик, елына 120 сум хезмәт хакы белән бер каравылчы билгеләргә кушыла. Шулай итеп, Себерне үзләштерү, ә дөресрәге, аның байлыкларын талау, халкын буйсындыру-изүгә Карадуган да катнашып киткән булып чыга.

Кайбер галимнәр Карадуган атамасының килеп чыгышын авылга иң элек нигез салган кабилә кешеләре исеменә бәйләү ягында торалар. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков аларны табын /кара табын/ кабиләсе дип атый. Галим карашынча, табыннарның бу якларга күченүе «XV йөзнең 70 нче елларыннан да соң булмаган дип уйларга урын бар... Табын кабиләсе вәкилләре Казан артына ук үтеп кергәннәр... Балтач районындагы Карадуган авылы исеме дә очраклы барлыкка килмәгән / дуван-дуан этнонимы шул ук табыннар белән бәйле/. Шулай ук Кече Әтнә авылы янында 1524 елгы кабер ташында «Ябынчы табын Акбулат» исеме игътибарга лаек» /*«Татарстан» журналы , 2 сан, 1993/*.

Филология фәннәре докторы Фирдәвес Гарипова исә бу авыл исеме дуван кабиләсеннән калган дип уйлый. «Дуван кабилә—кавемнәре күп төрле халыкларны формалаштыруда катнашкан... Каспий диңгезе ярына урнашкан Карадуван бистәсе—нугайларның элекке башкаласы. Тарихи чыганакларда 1664 елда Казан юлы өстендә Дуван өязе теркәлә»,—ди ул. Аның язуынча, Пермь өлкәсендә Дуван суы һәм Дуван авылы, Молдовада Дуван өязе бар икән. Филология фәннәре докторы Фәрит Йосыпов дуваннарны борынгы кыпчак токымыннан дип фараз итә, аларны гайәр, затлы татарлар дип атый. Карадуганга килеп урнашкан кешеләрнең «затлылыгы» кайбер борынгы язмалар белән дә раслана. 1795 елда Казан межа конторасы эшләгән Карадуган харитасына аңлатма язуында авылның халык саны да китерелә. Дүртенче ревизия вакытында, ягъни 1782 елда Карадуганда морзалар нәселеннән булган йомышлы татарлар 48 кеше яшәгән, хәзер 64 кеше; иске керәшеннәр һәм ясаклы татарлар 25 булган, хәзер 32 кеше, диелә анда. «Экономические примечания к Генеральному межеванию» дип аталган 1790—1803 елгы документ та Карадуганда /Карадуван/, морзалардан булган 18 йомышлы татар хуҗалыгында 27 ир-ат, 45 хатын-кыз, ә 10 ясаклы керәшен татар хуҗалыгында 7 ир-ат, 33 хатын-кыз яшәгәнлеген хәбәр итә. Бу язма истәлек авылның кара туфраклы, балчыклы һәм ташлы җирләрендә арыш, солы, бодай, арпаның яхшырак уңыш, печәннең бик әйбәт үсүен белдерә. Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов Карадуган атамасының һәм анда яшәүчеләрнең килеп чыгышын Нугай

Урдасы татарларына һәм морзаларына бәйләп анлата *(«Шәһри Казан», 16 февраль, 2007 ел).*

Карадуган атамасында «кара» компоненты да Износков язган «пычрак» төшенчәсен белдерми икән. Үзебезнен галимнәр дә шундый фикердә, күптән түгел Казанга килгән бик зур мәгълүматлы төрки кардәшебез шагыйрь Олжас Сөләйманов та «кара»ны тәмам «аклап» сөйләде. Заманында бу сүз «мул» һәм «олуг» мәгънәләрен белдергән икән бит. Олжас туганыбыз Кара дингез атамасын «Олуг» дингез дип шәрехли, тарихи төрки риваятьтәге «кара каным агыздым» сүзләрен «бик күп каным агыздым» дип анлата. Чынлап та, кайсы риваять каһарманы үз канын «пычрак» дип атар, нинди халык үзе нигез корган авылга ямьсез мәгънәле яисә шомлы исемябыштырып калдырыр икән?

Авылда керәшеннәр белән мөселманнарның янәшә гомер итүе 1881 елга кадәр дәвам итә, ләкин, тирә-як авылларда да күпчелеге мөселманнар яшәгәнлектән, аларның йогынтысы көчлерәк була. Ничектер җай китереп, Карадуган халкы мәчет салдыруга да ирешә, ә керәшен катнашкан авылларда бу шактый читен, аерым очракларда закон нигезендә тыелган була.

1881 елның 23 июлендә керәшен авылы Апазның христиан динчесе Александр Миропольский, Казан губерна идарәсенә рапорт язып, Балтач волосте Карадуган крестьяны Тихон Григорьевнын, татарча Мостафа исеме белән, диндәшләрен мөселманлыкка кайтырга өндәп йөрүе хакында хәбәр итә. Ул инде, куркыту һәм ялган юлы белән, күпчелек керәшеннәрне мөселманлыкка кайтырга күндергән, дип белдерә поп. Аның язуынча, әлеге Тихон Григорьев патша галиҗәнапләренең үзенә яла ягудан да тайчанмый икән. Янәсе ул «патша ислам динен христиан диненнән яхшырак дип саный һәм һәркемне мөселманлыкка күчәргә чакыра» дип сөйләп йөргән, шуна охшаш кеше ышанмаслык әкиятләрен таратып инде Апаз, Шомбашы, Сәрдәбаш кебек керәшен авылларында булган, хәтта Вятка губернасына да барып житкән. Мин баш коткычы һәм Галиҗәнап шәхесенә яла ягучы Григорьевны каты җавапка тартуыгызны сорыйм, шулай булмаса, Казан һәм башка губерналарның керәшеннәре мөселманга күчеп бетәчәк, шулай итеп, христианнарның һәм Россия Хөкүмәтенең дошманнары көчәячәк, Мөхәммәт өммәтендәгеләр мона күптән омтыла инде, аларның Рус Хөкүмәтенә буйсынуы, урыс башлыкларына хөрмәте дә мәжбүри вакытлы гамәл генә, беренче җай чыгу белән каршы күтәреләчәкләр, дип кисәтә Александр Миропольский.

Нәкъ шул чорда Казан Дини консисториясе дә губерна идарәсенә хат язып, Карадуганда яшәгән ун иске керәшен хуҗалыгының мөселманлыкка кайтуын хәбәр итә, моның сәбәпләре итеп, беренчедән, христиан диненнән баш тарткан Әзәк кешеләренең ireккә чыгарылуы, икенчедән, Карадуганда законсыз төстә мәчет салынуы күрсәтелә. Консистория губерна идарәсеннән әлеге мәчетне тиз арада юк итү турында боерык бирүне сорый.

Властьлар каршында бик тә мөһим саналган бу гаугалы эшкә тора-бара Казан хөкем палатасы, губернаның жандарм идарәсе һәм дәүләт полиция департаменты катнашып китә. Әмма бу вакытта Александр «кардәш»нең /ул үзе дә керәшен татары булгандыр, чөнки татарчаны яхшы белгән/ «поезды киткән» була инде. Казан өязенең полиция идарәсе кушуы буенча Карадуганга килеп тикшерү уздырган пристав бу авылдагы җәмигъ мәчетенең күптәннән эшләп килүен, хәзерге мәчет бинасының тузган элекке мәчет урынына 1865 елда ук салынуын, мулла Мифтахетдин Хәсәнов Йосыповның да 1857 елдан бирле шушы вазифаны башкаруын, монда мөселман татарларның Александр Миропольский язганча «йөздән аз гына артык» түгел , ә бәлки шактыйга күбрәк—җәмгысы 136 ир-ат булуын ачыклый. Эчке эшләр министрлыгының Казан губерна идарәсе, шушы тикшерү нигезендә, инде ничә еллар эшләгән мәчетне ябу мәгъкуль булмас, бу эшнең мөселманнар арасында рәнжү һәм чуалышлар да чыгаруы бар, дигән унай карарга килә. Чөнки ирексезләп чукындыруга, ислам диненә кире кайтучыларны төрлечә җәзалауларга каршы ризасызлык дулкыны тирә-якта әлелән-әле күтәрелә торган

була. Ә вакыт агымы әкренләп революцияләр чорына якынлаша.

Мәгълүм тарихчы Илдус Заһидуллин тапкан һәм Татарстан телевидениесеннән сөйләгән бер хәбәргә караганда, шушы 1881 елда Карадуган керәшеннәре ислам диненә кайтып бетә. Заманында губерна хакимияте дәрәҗәсендә олы бәхәскә сәбәп булган һәм могҗиза белән диярлек сакланып калган мәчет исә большевиклар хакимлеге чорында барыбер ябыла, манарасы киселеп, бүтән максатларда файдаланыла, ахырдан бөтенләй сүтелә. Таузар авылыннан килеп урнашкан Рубис, Рәис, Фәнис Хөсәеновлар соңгы елларда гына нәкъ шул урынга шәп кирпечтән мәһабәт яңа иман йорты төзеттеләр.

Россия Эчке эшләр министрлыгының губерна идарәсе документларына кереп калган Мифтахетдин хәзрәтнең дәвамчысы Минһаҗетдин мулла, ярты гасыр чамасы ара узгач, билгесез сәбәпләр белән кулга алынып юк ителә. Хәер, сәбәп бөтенләй үк билгесез дә түгел бугай. Кызының кызы Мөнирә ханым аны, әнисе сөйләве буенча, берәүләргә никах укыган өчен кулга алганнар дип хәтерли, чөнки атеист хакимият хәзрәтне мулла вазифасын башкарудан тыйган була инде.

Әйе, егерменче гасырның «яңа типтагы» үзгә хакимнәре дә электән «кыңгыраулы» Карадуган белән рәхимсез эш итәләр. Бу авыл халкы белән сак булырга, башларына баскалап торырга кирәген аларга патша чоры түрәләре өйрәтеп калдырган диярсең. Революциядән соң монда хәтәр ВЧК бүлекчәсе оештырыла, мулрак яшәүчеләрнең мал-мөлкәте һәм йорт-җирләре тартып алына. Халыкны хәерчеләндереп «тигезләү» сәясәте шул кузгалудан соң ун еллар дәвам итә. Балтач район башкарма комитетының 1932 ел, 6 марттагы утырышы авылларның кулак хуҗалыклары исемлекләрен карап тикшерә. «Кара исемлек»ләрнең иң зурлары Карадуган һәм аның күршесе Арбаш авылларыннан төзелә. Карадуганнан Галимов Ибени, югарыда телгә алынган, талану һәм коточкыч җәберләрдән акылына зәгыйфьлек килеп вафат булган Мәҗитов Габсәләмнең улы, авылның беренче колхоз рәисе Габсәләмов Закир, Кәримов Низаметдин, Мәҗитов Гыйлемҗан, әлеге Мәҗитовлар кияве Ибраһимов Нәби, Шәрипов Гариф, Һадиев Гали, аның абзасы Гыйззәтуллин Фатих, Әхмәтҗанов Даутлар кулак хуҗалыгы исемлегенә кертелә, алар сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. Тырышып эзләгәннәр, күрәсең, инде бер кат таланып беткән авылдан да әнә никадәр кулак таба алганнар. Бердәнбер «гаепләре»—властьлар күзенә карап тормыйча, үз көннәрен үзләре күрергә тырышулары. Язмышның бер каһәрләнгәч, хакимнәренә тегеләй итеп тә, болай эшләп тә ярый алмыйсың икән шул. Бирелә, яңа икътисадый сәясәт шаукымы белән, бер гасыр ярым элегрәк Мөхәммәд Рахмандеев нигез салган һөнәрчелек кабаттан җанланган була. Хәллерәк кешеләр бик ераклардан йомран тиресе алып кайталар да, аны эшкәртеп, ярминкәләрдә саталар. Билгеле, күпләп кайтарылган тирене теләге булган чит кешеләргә, Таузар кебек якындагы авыл халкына да биреп эшкәрттерәләр. Гали Һадиев Себер якларыннан ат алып кайтып саткан. Җәяүләп чыгып китеп, бишәр-алтышар ат житәкләп кайта иде, диләр аның хакында. Эше дә, атлары да авыл кешесе өчен бик кирәк, фәкыйрь игенчелек белән генә көн күреп булмый, әмма тәкәббер түрәләр иле боларны аңлый алудан мәхрүм.

Тугыз «кулак» хуҗалыгының өчесеннән калган нәсел генә бүген авылда яшәвен дәвам иттерә, бүтәннәренең тамыры шул елларда бөтенләйгә киселә, нигезләре корый. Чөнки җәза чаралары аларны район башкарма комитетының «кара исемлегенә» кертү белән генә төгәлләнми. Татарстан АССРның ОГПУ өчлеге 1932 елның 9 маенда Закир Габсәләмовны, Фатих Гыйззәтуллинны, Даут Әхмәтҗановны, Нәби Ибраһимовны, Низаметдин Кәримовны өчәр елга концлагерьга, Галимов Ибенинең олы улы Галимҗан Ибениевны 2 елга хезмәт белән төзәтү лагерына җибәрергә дип хөкем карары чыгара. Аларга ягылган гаепләрнең ниндие генә юк! Колхоз төзелеше һәм Совет властена риза булмау, дини коткы тарату /илле еллар элек авылдашларына поп Миропольский таккан гаеп/, хәтта... контрреволюцион төркемдә катнашу. Гаепләнүчеләрнең иң өлкәне Фатихка бу вакытта 62 яшь, иң кечесе Закирга 36 яшь була. Шушы ук көнне нәкъ шушы хөкемдарлар авыл мулласы

Хәсәнов Билал Хәсән улын, уйлап чыгарылган гаепләре өчен, 5 елга концлагерьга озаталар. Билал хәзрәттән элекке мулла, Йосыф Минһаҗ Мифтах улы исә 1937 елда кулга алынып, Казанда атыла. Авылның ике катлы, чарлаклы йортлары бер катлыга калып тәбәнәкләнә, кешеләре ваклана, алардан борынгы затлылык, рух хөрлеге әкрен-әкрен кысып чыгарыла. Монда хәзер беркем дә диярлек үзенең ерак морзалар нәселенең дәвамчысы икәнлеген белми, хәтта моңа ышанмый, тамырлары белән кызыксынмый. Авыл мәктәбе, өйгә эш биреп, балалардан үз шәҗәрәләрен төзеттерә башлагач кына аларның әти-әниләренә аз-маз уй керде. Әмма әле дә үзләренең ерак бабалары исемен сер итеп сакларга тырышучылар, шул хакта сорашучыларга шикләнеп караучылар бар. Чөнки гыйбрәтле һәм шомлы үткәннәре шулай өйрәткән. Габсәләм Мәҗитовның Мәннән атлы улын сугыш вакытында мәҗбүри урман эшенә җибәрәләр. Шунда, бәхетсезлегенә күрә, аның ат азыгын һәм үз ризыкларын урлыйлар. Атының һәм үзенең ачыгуына түзә алмыйча авылына кайткач, «азыкларын үзе юк иткән ул, житте инде кулак калдыгына, күптән вакыт иде» диләр дә ун елга төрмәгә илтеп тыгалар. Биш ач бала белән калган хатыны да, гаиләсен җыештырып, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр була. Элекке герман сугышында катнашкан, биш баласы булган Хафиз Ибениев, яңа сугыш башлангач, имештер, «немецләрнең бәдрәф юлына кадәр асфальт» кебегрәк сүз ычкындыра һәм аны да Галимҗан абыйсы юлыннан, тик тагын да озаккарак озаталар. Мәннән белән Хафиз—ике яшьтәш һәм авылдаш, ике «кулак калдыгы»—ачлыктан бетерешеп, Казан төрмәсендә вафат булалар. Сугыш чорының «Хуҗалык кенәгәсе»нә күз салсаң, бу авылдан тагын берничә кешенең төрмәдә булганлыгы күренә. Сәбәпләре—билгесез. Исмәгыйль Садыйков кына үзенең «коточкыч гөнаһ»ларын хәтерләп сөйли ала. Сугыш алды елларында дуңгыз фермасы мөдире була ул. Балтачның милиция башлыгы Ибраһим Габдерахманов аннан ничәдер дуңгыз баласы алып китә, ләкин алардан бет табыла. Ул арада ферма чучкалары ачтан кырыла да башлый. Киләләр, тикшерәләр һәм Исмәгыйльне, корткычлыкта гаепләп, ике елга Колыма җәһәннәменә илтеп тыгалар. Колыма шартларындагы ике ел—чиксезлеккә тиң, бирегә сезон башында миллионлап китерелгән тоткын сезон азагына кадәр кырылып бетә. Ә Исмәгыйль, гайәр татарлар токымының бер баласы, ике елын исән-имин кичүе өстенә, ирекә чыгарылгач та, Колымада ялланып эшләргә кала. Токымыннан «киткән», бабаларының холкын җуйган хәзерге «Исмәгыйльләр» исә әтиләре йөреп урнаштырган университетларда да берике елдан артыкка түзә алмый.

«Гаепле»ләрнең байтагын соңыннан аклаган булдылар. Ләкин фаҗигале тәмамланган язмышлар кабаттан язылмый, корган нигезләр җанланмый. Авылның да властьлар алдында кара тамгадан котылып беткәне юк. Әле ел башында гына Карадуганга килеп, район җитәкчелегенең хисап җыелышын уздырдылар. Бирелә эш таба алмыйча йөри торган яшьләр башка урыннардагыдан да күбрәк икән. Аларны элеккечә хакимиятләргә салынуда гаепләү сүзләре дә ишетелгәләде. Ә кемгә «салынырга» тиеш иде алар? Эшсезлекне кем тудырды?

Карадуган белән Арбаш борынгыдан тире иләү, мех эшкәртү кәсебе белән танылганга, үткән гасырның утызынчы елларында ике авыл арасына «Кызыл мехчы» артеле корып куялар. Сонрак ул мебель фабрикасына әверелде. Тулай торагы, фатирлары да булгач, монда эшләргә һәм яшәргә дистәләгән авылдан кеше агылды, цехлар өч сменада эшләде. Хакимиятләрнең аңлаешсыз хуплавы белән фабрика әкрен генә бөлеп эштән туктагач /әйтерсең, халыкка бернинди мебель кирәкми/, ярты Карадуган белән Арбаш та, килгән гаиләләр да эшсез калды. Әнә фабриканың өсте-өстенә өстәп салынган, бервакыт нигезенә кадәр янгач та эштән туктамаган галәмәт зур цехлары, ел буе яшелчә үстерә алырлык җылы теплицасы, миллионнарга төшереп соңгы елларда гына төзелгән һәм бер еллап кына файдаланылган газ котельные, никадәр җирне бушка биләп, күз алдында таралып ята, ә кемнәрдер аларны кулдан-кулга сата-сата үз кесәләренә миллионнар көри. Ләкин мондый «эшсез»леккә Карадуган кешеләре гаепле түгел, алар, киресенчә,

бу хәлдән күп зыян күрүчеләр генә. Чөнки фабрика белән беркайчан да алар житәкчелек итмәде. Алай гынамы, авылның борынгы токымнарыннан шушындагы күмәк хужалыкка рәис тә куелмады, хәтта район советы депутаты да сайланмый иде. «Акларга-каралларга» бүленеш һәр эштә сизелә. Авылның читтән килгән түрә-каралар һәм яна байлар нигез корган яңа урамнарына тиз арада асфальтка кадәр җәелә, ә элекке Габсәләм тыкрыгында—«контрреволюцион төркем» дәвамчылары яши, мәшһүр Тукай исемен йөртә торган борынгы урамда бер тапкыр вак таш та салынмаган урыннар бар. Анда яз-көз түгел , хәтта жәй уртасында да яңгырдан соң машина белән урам очына күтәрелеп булмый, урам кыш көне кардан чистартылмый. Жир пайлары бүлгәндә дә иң зур өлеш гомер-гомергә шушы жирне тоткан, беренче тапкыр эшкәрткән, аны ихтыяри-мәжбүри колхозга биреп күмәкләшкән, шул жир өчен кулак итеп сөрелгән, концлагерьларга озатылган, оялары хаксыз тузгытылган шәжәрә «яфрак»ларына түгел, башлыча соңгы елларда килеп урнашканнарга «тиеш» булып чыкты. Гаепсездән гаепләнүләрне чып-чын аклау, аларның рухлары алдында гафу сорау нәкъ шушы гамәлдә күренергә тиеш иде, югыйсә. Быел гына Яңа ел кичәсендә дүрт кызның эчкән баштан Карадуган мәдәният йортында гауга чыгаруы газета аша бөтен районга таралды. Баксаң, аларның берсе дә авылның үз токымыннан түгел, фабрика исән чакта читтән килеп оялаган гаиләләрдән икән.

Борынгы Себер юлының көньякка караган борылышыннан Карадуганга таба бер кеше атлый. Бу юлның «кала юлы», үрнең дә «кала тавы» дигән исемнәре онытылып килә инде, чөнки яңартып төзелгән Казан—Пермь юлы Карадуган борылышын читтә калдырып уза. Юлдан атлаучы кеше үзен чакырып торган матур һәм бай кибеткә дә күз салмаска тырышып, монда автобус көтеп торучыларга да илтифат итмичә һаман баруын белә. Әле яшь кенә диярлек булса да, авылның 150 ел элекке кабагында озак утырып чыккандай арыган-талчыккан ул. Үзенең нинди затлы нәсел кыйпылчыгы икәнен белсә әгәр... Ә бит Кәлүнекеләр кайчандыр Карадуганда иң гаярьләрдән йөргән. Көрәш батырлары, эш уңганнары, кызлар күзен яндыручылар! Бертуган Әхмәдулла, Әхмәтгәрәй, Каһарман, Әсхәдулла, Дәүләтхан, Гыйльмулла, Хаммат... Иген эшенә дә, чорына күрә техникага да оста булганнар, авыл тормышын бөтәйтү өчен әллә ниләр уйлап чыгарганнар. Аларның атлы сугу машинасы ярты авылның игенен сугып биргән. Күмәкләшкәч тә ай-вайлап тормаганнар, гөрләтеп эшләгәннәр. Хаммат ашлык сuktырганда аңа иген китереп, саламын читкә ташып өлгертү бик читен булган. Бригадир Гыйльмулла колхозчылар белән кояшка каршы тау битләренә киң-киң террасалар уеп, күмәк алма бакчасы ясаган, атлы чарыклар ярдәмендә инештән су күтәртеп, яшелчә үстерүне көйләп жибәргән. Хәзер ул урыннарда—«пустошь». Бер елны Әхмәтгәрәй эшли торган сугу машинасының барабан теше сына. «Корткычлык» өчен утыртасыларын әйбәт аңлаган оста игенче төн эчендә Петропавловск шәһәренә чыгып кача. Бүтән туганнары да берәм-берәм авылдан китеп югала. Петропавловскида Әхмәтгәрәй гаиләсен күреп кайткан Арбаш егете Мәгъфүр аларның чын татар булып яшәүләрен, татарча гармун уйнаучы очратсалар, аерыла алмауларын сөйли. Дәүләтгәрәй дә шунда яшәгән. Инде өлкәннәре мәрхүмнәрдер. Барысын уйлыйсың да, булдыклыларны, үз тормышын үзе көйләүчеләрне кирәксенми, планлы төстә зимагурлар һәм сукбайлар үрчетә торган нинди ил булды соң әле бу дип хәйран каласың. «Пустошь»ка калдырылган жирләребезне, фабрикаларыбызны астан-астан сатып кемнәрдер үзләренә акча да эшләр, тик менә рухи тамырларыннан өзеп хәтерсезләндерелгән кешеләрнең күңел бушлыгы белән ни кылырга җыендылар икән алар?

❀

Фәрит
Баттал

# САЛИХ АБЫЙ ТУРЫНДА УЙЛАНАМ...

Мин—Салих Баттал энесе Фуатның улы Фәрит; Казан телестудиясендә инженер булып эшлим (ТНВ).

Алтмышынчы елларда Салих абый Бутлеров урамындагы 20 нче өйдә тора иде. 1961 елда без дә шул урамга күчкән вакытта ул опера театры артисткасы Мәдинә апа белән өйләнешеп, Гагарин урамына күченде. «Яңа» өебез дә утын ягып җылытылгач, без мунча урынына еш кына аларга, барлык уңайлыклары булган фатирларына юынырга йөри идек. Барыбыз да юынып, ашап, чәйләр эчеп алганнан соң өлкәннәр сөйләшеп китәләр, ә безнең өчен Салих абыйның уенчык үлчәве әзер иде: җылыткыч торбасына уртадан бәйләп асылынган таякчыкның очларына эленгән шырпы каплары. Мондый «үлчәү» безгә уйнарга озакка җитте.

Ул тагын шундый кызык шөгыль уйлап тапкан иде: миңа массажны кем ясар икән дип, урынына ятып, өстеннән йөрергә тәкъдим итә. Без җинел булсак та, тере кеше өстеннән йөрү аңа авырттыру мөмкинлеген аңлап, акрын, сикермичә, стенага тотынып гәүдәсе-аякларыннан йөри идек. Әти, әни карап, безне мактый иделәр, ә Салих абый ләззәтләнгән булып: «Уф, рәхәт!»—дип кабатлап торды. Шундый «массаж» ясауны без «Салих абыйны таптау» дип атый идек. Әлбәттә, без үсә төшкәч, аны таптавыбыз туктады. Әмма үсеп житкәч, бу функцияне кайсы бәндәләр, хәтта житди оешмалар янадан башлаганнарын белдек: болар күбесе яшьләре буенча Салих абыйга уллары кебек булган, аның хәтле авырлыкларны күрмәгән, нәкъ балалар шикелле «өстән» дәртләндерелеп, Салих абый «файдасына» кайгыртуларына нык ышанып, аны тырышып таптаганнар.

Салих абый архивында аның 1980 елда Литфонд директорына язылып куелган гаризасы бар. «Батый ханга мөрәҗәгать» поэмасы аркасында күргән авырлыкларын телгә алып, ул биш йөз сум акча сорый һәм шулай яза: «...Ә инде мораль яктан күргән газапларны бертөрле үлчәү белән дә күрсәтеп бетерерлек түгел. Ничә мәртәбә үземә кул салу чигенә життем, ләкин «немец шпионы» яласы тагылган һәм Каплан агулы пулясы белән яраланган бөек Ленин үрнәге мине коткарды...».

Сенелем белән таптавыбызның шундый куркыныч нәтижәләрен күз алдына китереп була идеме? Киресенчә, аны файдалы дип тә таба алам: бәлки, дөреслек өчен көрәшкән шагыйрьгә без чыныгырга булышканбыздыр; әнә, Ленинның да файдасы тигән икән...

*...Таптаучылар никадәрле үчексәләр,*
*Шулкадәрле мине күбрәк үрчеттеләр.*

Ә инде Советлар Союзы таркалганда Салих абый кебек кешеләрне жәберләү «программасы» юкка чыккач та, аның өстеннән миңа тагын бер мәртәбә йөреп алырга туры килде. Бу болай булды.

Салих абыйның табутта күмелүен белепме, кабер казучылар ләхетне ясамаган иделәр. Ләхет такталары әрәм булмасын өчен аларны барыбер куярга хәл ителгәч, кабергә мин төштем, әмма ләхет булмаганга такталар кыска булып чыкты. Шуңа күрә табутның бер ягына жирне сиптеләр, ә мин, урын биреп, аның өстендә тегендә-

монда кучәнеп тордым—Салих абыйның соңгы мәртәбә «таптап»...

Салих абыйлар мине сеңлем Фәридә белән чиратлап үзләренә кунарга алып тордылар. Бер мәртәбә мин Фәридәгә кызыгып калдым, чөнки Мәдинә апа аны «Евгений Онегин» операсына алып барган. Фәридә, әлбәттә, анда йоклап киткән дә, «дуэль»да пистолет «аткан» тавыштан уянган.

...Бутлеровка кучкәннән соң өч ел узгач, безгә су белән газ үткәрелгәч тә, Салих абыйларга кунакка еш йөрүебезне дәвам иттек—шәһәрдәге «кышкы квартиралары»на да, бакчаларына да. Безнең белән бергә күп чакта Салих абыйның улы Виктор абый килә иде; тагын энесе Мөбарәк абый да килгәндә, сугыштан исән кайта алган өч бертуган җыелгач, вакыт бик күңелле уза иде.

Бакчасында Салих абый күп нәрсәне үз кулы белән ясый иде. Дачаның бер почмагында фонарь баганасына беркетелгән столяр верстагы урнаштырылган иде; өе алдында—чарлау станогы; бакча үзәгендә—эссе көннәрне чумып алыр өчен эченә пленка җәелгән кечкенә бассейн. Өйләрендә ике кешелек кенә урын булгач, без башта палаткада куна идек; соңыннан Салих абый искесенә янәшә гипсолит плиталарыннан зуррак өйне, ә өйләр каршында тактадан кечкенә мунчаны үз кулы белән төзеде. Мунчаның алты почмагы булгач, әти аны АКШдагы бишпочмаклы «Пентагон»га охшатып, «Алтыгон» дип атады. Иске өй янында яшен үткәргеч тора иде, шуңа күрә яңгырлы төннәрдә яшен яшьнәп өйне яктыртканда, күк күкрәгәндә әни, мин, Фәридә озак йоклап китә алмый интектек.

Бакчада йә өлгергән җиләк җыю, йә җирне казып чыгу, йә су ташу кебек эш булмаганда, мин рөхсәт алырга ашыгып, Салих абыйның язу машинкасында башыма теләсә нәрсә килгәнне басарга ярата идем (хәзер бу машинка Олы Тигәнәле музеенда). Ә дүртенче сыйныфта мин Жюль Вернга ияреп, «Серле утравы»ннан берничә персонаж исемнәрен алып, роман язам дип игълан иттем. Бу «бөек» әсәрне



*«Казан утлары» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Шамил Маннапов, Рәдиф Гаташ, Салих Баттал, Тәүфикъ Әйди, Рашат Низами, төрек язучысы Яхъя Акынгөн, Ринат Мөхәммәдиев. 1991 ел.*

мин Салих абыйдан алган, дүрткә киселгән кәгазь битендә кулдан яза идем; көлгәнен күрсәтмәскә тырышып, ул миннән вакыт-вакыт: «Йә романны язу эшең ничек бара?»—дип сорап, төп геройның язмышы белән кызыксына иде. Ул «роман»ым хәзер дә иске блокнотлар арасында ята әле...

Шул вакытта мин шигырьләр дә язып маташтым. Әти, әни моны күреп, аларны Салих абыйга күрсәтергә күндерде. Минем белән бергә үзенең берничә юлын Фәридә дә күрсәтергә булды; аның әсәре якынча шундый иде:

*Без абыем белән югалттык*
*сары саплы мылтык;*
*аннары аны таптык.*

Минем бөтен язганым уникe битле мәктәп дәфтәренең яртысын тәшкил итте, ә мәгънәсе сеңел язганныкы белән бертигез иде—Куба башлыгы Фидель Кастро, ошаган уенчык, песи, бәлеш пешерү турында... Салих абый минем шигырьләремне мактады, язуымны дәвам итәргә киңәш бирде (хәтта бер шигыремне тыңлап көлгәч, архивында калдырачак дип, җыеп куйды), ләкин Фәридә югарырак бәягә лаекланды, чөнки аның бу кыска «шигыре» татарча язылган булган. Аныкын тыңлап бетерүгә үк Салих абый елмаеп: «Моны, мәсәлән, шулай дәвам итеп булыр иде: «...Булды шундый шатлык, без алдык та, аттык!»—дип, өстәп куярга тәкъдим итте.

Салих абый әтигә, әнигә яңа чыккан китапларын бүләк итеп барган, әти үзе дә аларны алып торган. 1959 елда Фәридә белән мина бүләк ителгән китабы Пушкинның «Руслан и Людмила»; соңгысы—1982дә хатыным Кадрия белән мина—«Тылсымлы балдак». 1971 елда әти Салих абыйдан Магадан нәшриятендә басылып чыккан китапны алып кайтты—аны 1930 елларда Салих абый белән бергә махсус конструкторлык бюро каршындагы очу отрядында самолетларны сынап очкан Михаил Николаевич Каминский язган; берничә биттә автор Салих абыйның төгәл психологик портретын биреп, аны мактап уза. Виктор абый да безгә килгән саен букинистик кибетеннән берәр китапны алып килә иде, шулар арасында мин телгә алган Жюль Верн романнары да бар иде.

Кайвакыт дачадан поездда кайтканда мин барысына үзем төзегән кроссвордымны чишәргә тәкъдим итә идем, бигрәк тә Салих абый алдында мактанасым килде. Салих абый җавапны шул ук вакытта бирә алмаганда, акрын-акрын үз биографиясеннән чираттагы очракларын сөйләп китә иде дә, кроссворд Казанга кайтып җиткәндә дә чишелмичә кала иде. Ул вакытта минем мона бик тә кәефем кырыла иде, хәзер аңлыйм: шатланып, ишеткәнемне яза барырга кирәк булган икән! Шундый олы яшьтәге, бигрәк тә сиңа тарих дәресләкләре аша гына таныш булган дан казанган шәхесләрне үз күзе белән күргән кешене тыңлау бик мавыктыра бит. Менә вагон көпчәкләренең рельслар тоташкан урыннарында шакылдаган тавышы сезгә нәрсәне булса да хәтерләтәме? Колхозлар оештырылган заманнан ук Салих абыйга ул шакылдау «Кол-хоз-га кер! Кол-хоз-га кер!» дигән агитация сүзләрен исенә төшергән икән.

Салих абыйның хәтере шәп, зиһене үткен иде. Оренбургтагы хәрби мәктәп курсантларыннан берсе халык иҗатының бер үрнәген—«Гоп со смыком»ны—яттан белгән, ди (Салих абый «Гоп»—түгел, «Губ» дия иде); маршта баруларын җиңеләйтер өчен барысы аннан шул «Гоп со смыком»ны сөйләргә үтенәләр. Бу курсант сөйләвен туктатмасын өчен иптәшләре аннан берәмләп-берәмләп әйберләрен алып бетерәләр дә, ул кул селкеп, кычкырып сөйләп, бөтен колоннаны көлдереп барган. Өч дистә ел узгач, Салих абый ул «Губ со смыком»ның озын-озын өзекләрен инде безне көлдереп яттан сөйләде—әлбәттә, килешә торганнарын гына.

Салих абый үзе атеист булса да, әти сораганда Коръән сүрәләрен баштан гарәпчә укып, мәгънәләрен безгә аңлата иде. Сорауларга җавап биргәндә ул сиңа карамыйча, күзләрен ярым йомып, бүлдермичә тыңлап бетерә иде, шуннан инде ашыкмыйча, нык уйлаганнан соң, тема буенча бөтен белгән нәрсәне сөйләп бирә иде.

Ә атеист булып китүгә ике сәбәп иде, дип яза Салих абый. Берсе шул: алты-җиде яшендә ул, әтисе күрше Урта Тигәнәле авылы базарына җыенганда аннан чана

сораган да, үтенече тормышка ашсын өчен догалар укыган. «Ләкин теләгем кабул булмады. Алып кайтмау гына түгел, әти каршына чана турында сорашып баргач, ул мине берсүзсез сугып тәгәрәтте...». Ярты битен бәйләп кайткан әтиләреннән соңыннан нәрсә булганын ишеткәннәр. Ошаган комганның тишеге юкмы икәнен тикшерер өчен ул аның эченә өреп караган да, кышкы салкында иреннәре тимергә ябышкан. Комганнан аерылгач, авыртудан чананы эзләү турында уйларгамы!

Элек «дингә ышанам» диюнең күнелсез хәлләргә китерүе мөмкин иде, хәзер исә «атеист» дию начар характеристика кебек кабул ителә. Динле булмаса да, Салих абый дин тотучыларга ихтирам күрсәтте. Бүтәнчә мөмкин дә түгел иде: әтисе, әнисе, Ләйлибәдәр апасы, Галимжан абые, минем әни ягыннан дәү әти, дәү әни динле иделәр. Ул намаз укуын файдалы эш, дия иде: укыганда кеше физзарядка ясый бит! Салих абый хәмер белән дә мавыкмый иде; ул иң авыр, кыерсытылган елларда, исеме аклануга ышанычы шикле булганда гына салгалады. Галәттә, ул бакчасында карлыган, кура җиләген шикәр белән изеп, берничә көннән килеп чыккан төнәтмәне генә эчә иде.

*Мин—кунакта якын бер дустымда.*
*Якын тоелды ул тагын да,*
*чөнки исерткечнең тамчысын да*
*ул куймаган иде табынга.*

Сала торган кеше шундый юлларны яза алыр идеме? Киресенчә, Гомәр Хәйям шикелле шәрабка мәдхияләр иҗат итеп торыр иде...

Салих абыйның элек тәмәке тартканын мин белә идем, әмма бер мәртәбә генә күргәнем бар—ул безне ресторанга чакырып утырганда, төтенне божра иттереп чыгаруы белән мине гаҗәпләндерде. Шул очрак соңгысы да булып калды.

Бакча өен талаучылардан саклар өчен Салих абый аның ишеген бикләп тормаган. Теләсәләр барыбер ватачаклар дип, ул аны җил ачмасын өчен генә эчтәге бигенә бикли иде, ә бигенә бәйләгән бауның бүтән очын стенадагы тишек аша чыгарып, кыска язу калдыра иде: «Товарищи воры! Просьба дверь не ломать, она не заперта. Чтобы открыть её, потяните за верёвочку». Өйне ватмасалар да, кайсы караклар барыбер тәртипне бозып, буяп китә иделәр; лампалы зур радиоалгычны да урлаганнар. Шуңа күрә Салих абыйның аларга каршы соңгы уйлап тапкан чарасы—җиңел җыела торган карачкы: җиң очлары яшерелгән җылы фуфайка; аның якасын ярым каплап куелган киң кырыйлы эшләпәсе; фуфайка итәге белән өсләре капланган ике күн итек; янәшә балта—эшләпә тирәсендә идән кебек, «кан»ны белдерә торган вареньега буялган. «Карачкы»ны җыю гади булып күренсә дә, кеше гәүдәсе пропорцияләрендә төзелгәч, аны чын мәеттән аеру авыр иде; моны Фәриләнең кечкенә кызы Гүзәл күреп: «Анда абый ята!»—дип куркып йөгереп чыккан иде.

Салих абыйның безгә яна музыкаль инструментта күрсәтте: «Менә, курай ясадым; «Галиябану»дан беренче өч нотаны да уйнарга өйрәндем, бүтән барып чыкмый әле...». Ул өч нотаны ике мәртәбә безгә уйнап күрсәтте дә, кураен җыеп куйды. Салих абыйның музыка белән шөгыльләнгәнен бүтән күргәнебез булмады.

1973 елның августында әти белән Салих абыйны туган көне белән тәбрикләргә дачасына килгәндә, ул күчәргә утыртылган җайланманы көйли иде. Безне күреп, «Мин дулкыннар көче белән хәрәкәт итә торган механизм ясадым,—дип аңлата башлады.—Дулкыннар рычаг очындагы калкавычны күтәреп, күчәргә беркетелгән винтны боралар да, бөтен җайланма кузгалып китәргә тиеш. Мин моны «Волноход» дип атадым». Сөйләп бетергәч, ул безгә бу әйберен сынап карау өчен су буена алып барырга тәкъдим итә башлады. Без аннан көч-хәл белән котылдык.

Салих абый туган көннәренә әһәмият бирми иде. Аны чын күңелдән ихтирам итеп, ел саен бишенче августта туган көне белән котларга бара идек тә, кайсы вакытта өендә туры китермичә кайтып китә идек, соңыннан исә аның үз йомышлары белән чыгып киткәне ачыклана иде.

Самолетлар турында сүз чыкса, әти: «Абый! Сиңа хәзер шундый ук самолетны биргән булсалар, очып китә алыр идеңме?»—дип сорады. «Ник оча алмаска?!» Чыннан да, менә бу юллар нык ышанып язылган бит:

*...Әйләнәсем килә Җир шарын.*
*Тик гомерем калды бик кыска...*
*Очыр, илем, мине космоска!*

Үзенен ачуын китергәннәр белән Салих абый бәхәсләшергә, араны бозарга ашыкмый иде. Бакчаларынын чикләрен билгели торган буразнаны күршесе биләп алгач, ул ана да бернәрсә әйтмәгән. «Ник күршенә бернәрсә әйтмисен?»—дип сораган әтигә Салих абый: «Әйтмәвем мина файдалы»—дип җавап бирде. «Монда нинди файда булуы мөмкин?»—«Минем честный икәнем күренә...». Без анын күршесе белән бәйләнәсе килмәгәнен аңладык.

Салих абыйның «титуллары» ничек алмашынып торган! «Совет язучысы»ннан соң—«милләтче», аннары—«диссидент». Ә 2004 елда «Татарстан» журналының ноябрь чыгарылышында язучы Рафаэль Мостафин тарафыннан ихтирам белән, Солженицынга ияреп—«Казан үгезе» дип атала ул.

*...Мин үткен булуымны*
*теләде әнкәй үзе.*
*Юаш булсам, ул кисәтеп:*
*—Бозау булма!—ди иде...*

*Үстем. Шул ук тешләрем. Тик*
*күпләр моны белмиләр:*
*тешләсәм, «сатира» диләр;*
*елмайсам—«юмор» диләр...*

Салих абый үз күзе белән күргән, очраткан мәшһүр кешеләр арасында космонавтлар гына булмагандыр, ләкин анын заманындагы беренче очучылар алтмышынчы еллардагы беренче космонавтлар дәрәҗәсендә иде. Ул мәгариф һәм сәламәтлек саклау беренче наркомнарының Луначарский белән Семашко; Ленин хатыны Крупская; испан революционеры Долорес Ибаррури; Болгария коммунистлары башлыгы Георгий Димитров; Арктиканы өйрәнүчеләрнең берсе—Иван Папанин; Ерак Көнчыгышка тукталышсыз очып житкән Осипенко белән Раскова чыгышларын тыңлаган. Дөньяда танылган, Төньяк полюс аша Америкага житкән очучы, «һава хулиганы» Валерий Чкалов өенә дуслары белән кунакка йөргән; Чкаловтан ким түгел сынаучы Владимир Коккинаки белән бер очу мәктәбендә укыган. Бервакыт Салих абыйдан: «Мәскәүдә Горькийны тыңларга йөри идек...»—дигәнне ишеткәч, аңламыйча калдым: Алексей Горький күптән үлгән, аны мәктәпләрдә «узалар», ә Салих абый—менә минем алдымда, исән-сау тора; ничек ул аны күреп тыңлый алган? Бу соравымны Салих абый «Ничек ул Горькийны күрә алган» түгел, «Ник Горькийны тыңларга йөргән»—дип аңлап, гади хәлләр турында сүз барган кебек: «А как же, классик бит!..»—дип җавап бирде. Казанда ул Һади Такташ белән очрашкан. Замандаш язучылардан күбесе Салих абый белән Мөбарәк абыйнын танышлары булган, ә Муса Җәлил аларның якын дуслары иде. 1957 елда Кави Нәҗми үлгәч, Хәсән Туфан болай язган:

*Таянырга минем кем бар тагы*
*Нәҗмидән соң дәвам итешли?*
*Талантлы да, дус та, ләкин кырыс,*
*металл хисле Баттал что ли?*

Сибгат Хәким 1979 елда Салих абыйга язган хатында шундый юллар җибәргән:

*Шигырь ул колын ташлаган*
*гаепле байтал кебек,*
*яки ул кире һәм үҗәт*
*баш бирмәс Баттал кебек.*

Горький турында ишеткән кебек, Салих абыйдан тагын бер данлыклы кеше исемен ишетеп мин шаккаттым. Әендә әти белән сөйләшкәндә ул: «Мина Девятаев килеп китте...»—диде. Әсирлектән немец самолетында качкан очучы турында мин белә идем инде; хәзер без әти белән яшәгән урында Советлар Союзы Герое Михаил Петрович Девятаев нәкъ үзе булып, чынлап та Салих абый белән сөйләшкәнме?! Мона унай җавап алып, бу хәлне мин утыз елдан артыкка онытып тордым да, 1998 елда исемә төшереп, уйга баттым: күп хезмәт күрсәткән ике очучының очрашу сәбәпләрен ничек белергә? Хәзер Салих абый да булмагач, моны Девятаевның үзеннән генә сорарга кала, кыюлыгым гына җитми... Фамилиясе сирәк булгач, белешмәләр китабыннан аның телефон номерын табып, кыюлыгымны җыйдым да, шул елның өченче маенда өенә шалтыраттым. Үземнең исемемне әйтеп, җитеп килә торган Җиңү бәйрәме белән котлап, Салих абый турында исенә төшердем дә, аның турында нәрсә әйтә ала, дип сорадым. Михаил Петрович: «Әйе, мин аның өендә кунакта булганым бар, тик бер мәртәбә генә... Фронт турында сөйләштек. Бер-беребезне белмәгәч, бүтән бернәрсә әйтә алмыйм»—дип җавап бирде.—«Рәхмәт; гафу итегез...»—«Пожалуйста.»—һәм трубканы куйды. Бер елдан соң Девятаев тугызынчы апрельдә Милли музейда мәктәп балалары белән очрашырга тиеш дигән хәбәрне алгач, мин дә шунда барып, Салих абый белән очрашу сәбәпләрен, мөмкин булганча вак-төякләрен исенә төшерергә яңадан үтендем. Җавабы былтыргыдан аерылмады: «Хәзер инде бернәрсә хәтерләмим. Ничектер очраштык та, ул мине кунакка чакырды». Шуның белән үзе кулын сузып, минекен кысты. Балалар аңа «Тәмугътан качу» дигән китабына автографын куярга сораганнарын күреп, мин дә җавабын язар өчен алган кәгазьне чыгарып, автографын алдым. Тарихны вакытында теркәп куймасаң, танылган кеше кулынны кысу белән автографын бирү турында гына бүтәннәргә сөйләргә кала...

Салих абый атаклы композитор Салих Сәйдәш белән дус булганын мин әтидән һәм Мөбарәк абыйдан ишеткән идем инде. «Салих Баттал минем әтинең иң якын дусты булган»—диде бөек композиторның улы Альфред абый да.

Сара Садыйкова кызы Әлфия апа Айдарская да әнисенә Салих абый хат язган, ул хат Садыйкова архивында ята, диде.

...Мәшһүр кешеләрдән кайсыларын Салих абый күргән, аралашкан дигән темага язып бетердем генә, икенче көнне танылган композиторның улы—телестудиядә музыкаль режиссер булып эшләгән Эмиль Александрович Ключарёв очрады: «Карале, мин радио фонотекасында Салих Батталның әтием белән сөйләшкән язманы таптым; ул сезнең туганыгыз түгелме?». Җавабымны ишеткәч, Эмиль Александрович инде таныш булып киткән фразаны әйтте: «Син беләсеңме, Салих Баттал белән минем әти якын дуслар булган!». Мин чын күнелдән рәхмәт әйтеп, Салих абыйның тиздән җитәчәк юбилее турында хәбәр иткәч, саубуллаштык.

Салих абыйның өч баласы бар иде: беренче татар хатынынnan Виктор һәм икенчедән—марҗадан—Вячеслав белән Долория. Мөбарәк абый сөйләгәнчә, Виктор абый туганда әтисенең Виктор Гюго романнары белән мавыккан чагы була, шуңа күрә улына француз исемен куштырган. Виктор абый безгә шундый күп йөри иде, әйтерсең, ул Фәридә белән минем бертуган абыебыз булган. Килгән саен ул безгә йә нинидер вак-төяк уенчык, йә тундырма; без үсә төшкәч—китапларны алып килә иде; тимердәй мускуллары белән безне сокландыра иде.

Салих абыйның икенче хатыны—комсомол Үзәк Комитеты әгъзасы, парашютчы Ольга Николаевка Яковлева иде. Ул сугыш алдыннан үлә (кызлары Долория сөйләгәнчә, Ольга Николаевна самолеттан сикергәндә сазлыкка эләгеп суык тидереп, терелә алмаган). Салих абыйга сугышка китәргә туры килгәч, ике балаларын Ольга Николаевнаның туганнары Мәскәүдә тәрбияләп үстергән. Вячеславның суворов училищесында укыганын беләм; ул фәнни эше белән дә шөгыльләнеп алган. Язып та карарга тырышкач, Салих абый аның өчен шатланып, бергә төшкән фото артына шаярып: «Дюма-отец и Дюма-сын»—дип язган. Әмма фәндә дә, әдәбиятта да «Дюма-улы»ның әллә ни казанышлары күренмәде. 1982 елда Мәскәүгә белем арттыру курсларына барсам—ул йончыган кыяфәттә йөри иде; «Крокодил»

журналында күптән бастырылган юмористик булырга тиеш мәкаләсен миңа күрсәтеп мактанган булды. Вячеслав 1991 елда илле өч яшендә үлгән. «Нәшриятта аның романы калган», дип безгә хәбәр итте хатыны Люба. Бәлки, ул минем мәктәп елларымда язылган «роман»ым кебегрәк бер «әсәр» булгандыр инде...

Салих абыйны соңгы күрүем 1994 елның 25 августында булды. Билгеле булганча, бу җәлилчеләрне җәзалап үтерелүләренә илле ел тулу, шул уңае белән Җәлил иптәшләренә барельефлар ачу тантанасы иде. Тантанага килгән Салих абый белән исәнләшкәч, ул миңа: «Туганнардан икәнеңне аңлыйм, танымыйм гына»—диде. «Фәрит, Фуат малае»—дип җавап бирдем.—«Ә-ә, искә төшердем. Үзгәрден». Чыгыш ясарга Салих абыйга сүз бирелгәч, ул кереш сүзсез җәлилчеләр батырлыкларына багышланган кыска шигырен укыды да, рәхмәтле саубуллашу сүзләре әйтеп вакыт әрәм итмичә, микрофон янынннан китте. Тантана озак баргач мин Кремль янына барып чүгәләп тордым—һаман басып торган ветераннар ничек түзгәннәр икән? Ләйлибәдәр апаның улы Рәшит абый белән Салих абыйның музейга киткәнен күрдем. Тантана беткәч, Салих абыйга студия автобусында өенә кайтырга тәкъдим иттем (ул студияга якын тора иде); шул вакытта язучы Рафаэль абый Мостафин аны Җәлилнең музей-квартирасына барып чәй эчәргә чакырды. Чәй турында ишеткәч, Салих абый миңа җавап бирмичә Мостафин белән китте.

2000 елның 12 мартында Салих абый үлгән дип ишеттек. Эштән өенә барганда Мөбарәк абый белән Рәисә апаны очраттым; квартирасының ватык ишегендә милиция суккан печатьле кәгазь ябыштырылган иде. Күршеләрдән белдек: өйләрендә төтенне сизгәч, янгын сүндерүчеләрне чакырганнар—төнлә Салих абый йоклап яткан бүлмәсендә ут чыккан икән. Салих абыйны тәрәзә янында яткан килеш тапканнар, куллары-аякларына ут тигән. Милициядә безгә «мәет моргта», диделәр. Соңыннан Виктор абый сөйләгәнчә, салкын төннәрдә әтисе туңып, бер розеткага кабызган күп электр җылыткычларын тирә-ягына куйган да, көчәйгән токтан розетка кабынып киткән. 14 мартта мәетне күмәр өчен Язучылар берлегенә алып килделәр. Берлек рәисе Ринат Мөхәммәдиевтан соң саубуллашу сүзләре белән язучылар Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Рабит Батулла, Локман Бадыйкшан, хәзрәт Харис Салихҗан чыктылар. Туганнардан—Мөбарәк абый, Рәисә апа. Мәчет аша Яңа Бистә зиратына җитеп, Салих абыйны моргтан китергән табутта нәкъ әнисе (минем дәү әни) янына күмдек; шуңа күрә соңыннан кабер ташлары да ике язулы, икесенә бер булган. Урыннары Тукай каберенә якын булгач, Салих абый үзенең яраткан Тукаена мәңгегә якынлашты...

Партиядән куылган һәм дистә еллар буена кыерсытылган елларда Салих ага болай дип язды:

*Нидә мәгънәсе яшәүнең?*
*Җавап бар минем дә бер—*
*һәркемнең туткан урнында*
*һәм туган илендәдер.*

*Әйе, уен түгел яшәү.*
*Шушындый чаклар була—*
*күз йомасың—йокы алмый,*
*ачасың—кошмар була.*

Салих абыйга тагын ничек уйларга кала иде? Бервакыт аның өенә, ишеген ничектер ача алып, таныш булмаган җирән сакаллы егет килеп кергән, дип сөйләде әти. Керү максатын аңлатмагач, Салих абый аны боргычлап, милициягә тапшырган. Ә 1983 елда телевизорларын төзәтер алдыннан бушаган розетканы стенага беркеткәндә дивар куышыннан бер-берсенә паять ителгән ике транзистор килеп чыккан. Мин боларның радиоприборларда куллана торган детальләр икәнен Салих абыйга аңлаттым. Ләкин берничә көннән телефонын тикшерергә дип килгән монтерга Салих абый: «Минем өйдә сөйләгәнемне тыңлар өчен дәүләт акчасын әрәм итмәгез, мин сезнең өчен кызык нәрсәне сөйләмим бит»—дип әйттем, дигән.

Әлбәттә, шундый очракларны Салих абый КГБ казынулары дип санаган. Бәлки, теге монтерның килеп чыккан транзисторларга катнашы булмагандыр да, ләкин «үзгәртеп кору» елларында шикле кешеләр фатирларында яшерен тынлап тору җайланмаларын кую турында мәкаләләр басылды. Шуңа күрә Салих абыйның шикләнүен анларга да мөмкин.

2005 елның 30 сентябрендә Алексеевский районында Салих Батталның тууына йөз ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп үттеләр. Казанда исә матбугатта Салих абый турында «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин язганын гына күрдем, тагын «Эфир» телеканалында һава торышын әйтүче Н. Куранов матур гына сөйләп алды. Ренат Харис 2005 елда «Ватаным Татарстан» газетасында «Салих Баттал «һ. б.» түгел» исемле мәкаләсен бастырды...

Салих абый тантаналарны, үзен мактаганны яратып бетерми иде. Әмма утырышлар уздырылмаса да, аның юбилееи үз вакытында дәүләт телевидениесе, радио аша телгә алып, чын биографиясен сөйләп бирсәләр әйбәт булыр иде бит. Салих абый турында элек чыккан мәкаләләрдә хаталар, уйдырмалар аз түгел, хәтта татар энциклопедиясендә дә аның үлгән көне дөрес күрсәтелмәгән. Шуңа күрә менә бу юлы Салих Баттал турында үзем язарга булдым да...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

## Хәсән Туфан

(1900—1981)



Поэзиябезнең күренекле шагыйре Хәсән Туфан Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында 1900 елның 27 ноябрендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Әтисе Фәхри, тумыштан крестьян углы буларак, бик күп һөнәрләргә ия була һәм балаларын да хезмәткә өйрәтергә тырыша.

Яшүсмер Хәсән 1914 елны Тобол ягына, абыйлары янына китә һәм бакыр руднигында эшли. Абыйлары аны Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Шунда ул Г. Ибраһимовтан әдәбият дәресләре тыңлый, Ш. Бабич оештырган әдәбият түгәрәгенә йөри.

Төрле төбәкләрдә, төрле урыннарда шахтер, сәгать төзәтүче, токарь, укытучы булып эшләгәндә ул бай тормыш тәҗрибәсе туплый. 1924 еллардан соң ул татар шигъриятенә эчтәлек һәм форма җәһәтеннән яңа аһәң, яңа сыйфатлар алып килгән үзенчәлекле шагыйрь буларак таныла, поэма жанрында зур иҗади уңышларга ирешә. «Урал эскизлары» (1926), «Ике чор арасында» (1927), «Башлана башланды» (1927) кебек лиро-эпик әсәрләрендә шагыйрь үз заманы турындагы фәлсәфи уйлануларын колоритлы картиналар, яңа кеше характерлары аша ачып бирә.

1928 елны шагыйрь Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүле сәфәргә чыгып китә. Ул анда төрле халыкларның тормышы белән якыннан таныша, халык иҗаты әсәрләрен өйрәнә. Сәяхәттән кайткач, Татарстан радио комитетында «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») редакциясендә төрле вазифалар башкара.

1940—1956 елларда аңа Себердә булырга, Сталин репрессияләрен үз җилкәсендә татырга туры килә.

1966 елда шагыйрьгә Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде. Х. Туфанның рәсемдәге бюсты скульптор А. Әбдрәшитовның шәхси остаханәсендә саклана.

## Җәүдәт Фәйзи

(1910—1973)



Булачак композитор Җәүдәт Харис улы Фәйзи 1910 елның 4 гыйнварында Оренбург шәһәрендә укытучы гаиләсендә туа. Бала вакытларында ук әтисенең дусты, язучы Шакир Мөхәммәтовлар гаиләсенә барып йөри һәм шунда фортепиано дәресләренә өйрәнә.

Аның музыка белән кызыксынуына, иҗат эшенә бирелеп китүенә абзыйсы—классик драматург Мирхәйдәр Фәйзи зур йогынты ясый. Ул—15 яшендә үк инде «Күз яшьләре» исемле драма яза һәм бу драма Оренбургтагы татар драма театрында куела.

Башкалабызга күчеп килгәч тә ул Казан дәүләт университетының юридик фәннәр факультетында укый. Ләкин әдәбият һәм музыка белән шөгыльләнү аның профессиональ эшенә әверелә. 200-ләп җырлар, романслар, дүрт комедия—бигрәк тә сәхнәләрдән төшмәгән «Башмагым» комедиясе авторы буларак күздән кичерсәк, аның иҗатының колачын чамалау кыен түгел.

Ж. Фәйзинең халык көйләрен җыеп эшкәртү, өйрәнү эшендә дә хезмәте зур. Аның эшкәртүендәге күп кенә татар халык көйләрен Татарстанның җыр һәм бию ансамбле, үзешчән хор коллективлары башкара.

Ул—Россия һәм Татарстанның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, үз заманының җәмәгать эшлеклесе.

Аның рәсемдәге сурәте скульптор А. Әбрәшитов тарафыннан 1975 елны эшләнгән, Татарстан Дәүләт музеенда саклана.



# Габдулла Галиев

## Күңелемдә яңарган хатирә

Беркөнне шулай мәрхүмә әниемнең дини китапларын барлап утырганда, тышлыгы күзгә яфрак кебек саргайган, битенең читләре өтелеп, таушалып беткән китап килеп чыкты. Кызыксынып кулыма алдым. Чү... «Кыйссаи Йосыф» түгелме соң бу? Кара, шул үзе бит! Үзлегемнән берничә ел элек гарәп әлифбасын өйрәнгән идем, тышлыгыннан дулкынланып «Кол Гали, Кыйссаи Йосыф» дигән сүзләрне укып чыктым.

И үткән гомерләр! Уйларым кинәт шул хөрмәтле китап белән бәйле хатирәләргә барып тоташты.

...Алты-җиде яшьлек малай чагым. Атнакич җитте исә, әни: «Улым! Уенның белән мавыгып әллә кая китә күрмә! Бәдәрттән мунчага дәште»,—диеп, мине кисәтеп куя торган иде. Мунчага дигәч, китәмме соң! Югары оч малайлары чүрәкәй уйнарга чакырганнар иде, үпкәләсәләр үпкәләрләр, анда да бармыйм. Уен куян түгел, урманга качмас әле.

Менә кич җитә. Кояш кемнәндер оялган сыман кызарып безнең йортыбыз каршындагы тупыллар артына төшеп яшеренә дә, бераздан бөтенләй юкка чыга. Тәрәзәләрдә утлар алынгач, без әнием белән алдан ук әзерләнеп куелган чиста күлмәк-ыштаннарыбызны култык астына кыстырып, Бәдәрттәйләргә китеп барабыз. Мин кинәт кенә тукталып калам да, әнидән: «Йосыф» китабыңны онытмадыңмы?»,—дип сорыйм. Әни алъяпкычы күкрәкчәсен кулы белән капшап: «Онытмадым. Менә бит биредә»,—ди.

Без, ниһаять, «Вәли урамы» дип аталган урам очындагы шомырт агачлары артында утырган Бәдәрттәйләрнең такта түбәле йортына килеп җитәбез. Ишектән күренүебезгә үк безне елмаеп, ачык йөз белән каршы алалар. Әниемнең якын кардәше булгангамы, Бәдәрттәй әнием янында нишләргә белмичә йөгереп кенә йөри. Ә йортта искитмәле хәл! Биредә зур кунакларны каршы алырга җыеналар диярсең. Өстәл өстендә бер чиләк су сыешлы ялтырап торган җиз самавыр җырлап утыра, шунда ук кипкән кура җиләге, карлыган, миләш каклары. Чәйнектән җир җиләге яфрагы белән чамасын белеп кенә мәтрүшкә салып пешерелгән чәй исе бөркелә, өй эче, әйтерсең лә, хуш исле урман аланы!

Инде мунчада юынып чыгарга өлгергән Бисәттәй белән Наһарттәй, җилкәләренә салган сөлгеләре белән алма кебек кызарган битләренә бәреп чыккан бөрчек-бөрчек тирләрен сөртә-сөртә, рәхәтләнеп чәй эчәләр. Бәдәрттәй: «Бәдерниса белән Камал әлерәк кенә мунчага киттеләр. Бар, артларыннан йөгер!»,—дип, әнине мунчага ашыктыра.

---

Габдулла ГАЛИЕВ (1928)—*прозаик; «Үкенеч», «Кичер мине, Сүрия», «Минем бабай умартачы» һ. б. китаплар авторы. Әгерҗе районының Кырынды авылында яши.*

Безгә чират житми әле. Бәдәрттәйнең төпчек улы Жәүдәт белән мунчага без сонрак барачакбыз. Көндезен үк ягып томаланган мунча бер минут та буш тормый, берәүләре юынып чыгуга, икенчеләре керә тора. Мунчадан ун-унбиш адым гына читтәрәк сиртмәле кое. Яз, көз айларында әйләнәсен ромашка, бөтнек үләне баскан бу бәрәкәтле коеның суын бөтен урам эчә. Юыну өчен дә аның суы йомшак, шифалы диләр. Әйткәнемчә, берәүләре юынып чыгуга икенчеләре керә тора. Мунчадан чыкканы берсе Бәдәрттәй белән Габдрахман жизнигә: «Бу игелекләрегез гамәл дәфтәрләрегезгә савап булып язылсын. Аллаһының рәхмәтенә ирешегез»,—дип, кулларын күтәреп дога кылалар. Алар кылган догадан Бәдәрттәйнең йорт эчләре тагын да яктырып, нурланып киткәндәй була. Бәдәрттәй аларның берсен дә чәй эчерми чыгармый, өстәлендә булганын кыстый-кыстый ашатып сыйлый. Торганы белән гаҗәеп киң күнелле, кунакчыл инде ул безнең Бәдәрттәебез!

Ниһаять, безгә дә чират житә. Алдан әзерләнеп куелган күлмәк-ыштаннарыбызны алып Жәүдәт белән мунчага йөгерәбез. Ашыга-кабалана юынабыз. Бигрәк тә Жәүдәт ашыктыра: әйдә, әниең жырлап укый башлаганчы чыгып өлгерик, ди. Жырлап түгел, көйләп укый ул, дип, мин аны төзәтәм.

Без мунчадан чыкканда инде эчәсе чәйләр эчелгән, ясига намазлары укылган, әйтеләсе рәхмәтләр әйтелгән була. Камалттәйләр тезелешеп сәкегә утырып әниемне көтәләр. Әни түш кесәсеннән катыргы тышлы кечкенәрәк китап алып, жиделе лампа янына якынрак килеп утыра. Тиешле битен ачкач, йомшак кына тамак кырып ала да, сузынкы, моңлы көйгә салып укып китә. Йорт эче кинәт тынып кала, колаклар сагая, күзләр әнигә төбәләләр.

Газиз Йосыф тәмам унбер яшәр иде,
Йагъкуб сәүче тезләрендә йоклар иде.
Йоклаганда бер гажәп төш
Йосыф күрде,
Юралышын атасыннан сорый инде...

Иагъкуб, улы Йосыфның төшен юрап: «Сиңа олуг мәртәбәләр булыр. Зур мөлкәтнең хуҗасы, хан-солтан булырсың, тәңгере сиңа пәйгамбәрлек рәхим кылыр. Кардәшләрең унбере дә сиңа хезмәт итәр»,—ди. Әмма моны берәүгә дә әйтмәскә куша. Ләкин Йагъкубның үги кызы Динә моны тыңлап торып, Йосыфның кардәшләренә житкерә.

Юк, бу болай гына үтми. Сәкедә утырган хатыннар бер-берсенә карашып куялар. Бисәттәй түзми: «Ий, үги кызы бигрәк явыз булган икән. Ходаем! Әләкчеләрдән үзең сакла»,—диеп уфылдап ала. Кайсысыдыр берсе эхелдәп куйгач, янадан тынып кала. Инде барчасының да игътибары әнидә, ә ул сузып-сузып көйли:

Кардәшләре моны иштеп мәкер кылды,
Көнчелек һәм мәкерләре өстен булды.
Барчасының күңеленә кайгы тулды,
Бергәләшеп бозык чара уйлый имди.

Йосыфның кардәшләре яннарына чакырып елашкандай итеп: «Нинди төш күрдең, сөйләп бирче»,—дип үтенәләр. Йосыф башта атасының сүзен тота. Әмма ныклыгы озакка бармый. Бераздан кардәшләренең ялваруларына бирелеп тегеләргә барсын да сөйләп ташлый.

Йорт эче кинәт шомланып калгандай була. Хатыннар астындагы сәке шыгырдап куя, бичара Йосыфтан берсе дә моны көтмәгән. «Ихма! Кара инде, атасына биргән вәгъдәсен бозып, серен ачып салды бит бу»,—ди Камалттәй. «Әйтмә дә, бигрәк беркатлы икән, балакаем»,—диешәләр хатыннар.

Көнчелек Йосыфның кардәшләренә тынгылык бирми...Төрлечә алдап-

юлдап, алар Йосыфны үзләре белән сәхрәгә алып китәләр. Агалары Йосыфның чәчләрен йолкый-йолкый кыйнарга керешкәч, тыңлаучыларның күңел кыллары артыгын түзә алмый. Яше дә, карты да яулык очлары белән күз яшьләрен сөртеп, пышык-пышык борын тартып еларга керешәләр...

Әнием беразга хәл алырга, чәй йотарга туктала. Шул арада тагын утырган урыннар шыгырдый... «Ихма!»—диеп ингерәшеп куйгач, һәркем китапта язылган явызлыкка үз карашын белдерергә ашыга. Бигрәк тә Бисәттәй, Камалттәй, Наһарттәй ялганны күтәрә алмыйлар. Йосыфның агаларына карата кабынган нәфрәтләре хәтта йөзләренә бәреп чыга. Бәдәртттәй: «Ий, Раббым, безнең балаларыбызга хәерле тәүфыйк бир! Аларны көнчелекләрдән, явызлыклардан сакла! Үзебезгә аларны дөрес тәрбия кылырга күркәмлек, үрнәк сыйфатлар, хәерле гомер насыйп ит!»—дип дога кыла. Өйдәгеләр барысы да Бәдәрттәйгә ияреп «Әмин!»—диеп битләрен сыпырып куялар.

Шөкер, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының азагы әйбәт тәмамлана.

770 ел элек язылган бу гүзәл поэманы тыңлап үскән Бисәттәйләр, Наһарттәйләр, Бәдәрттәйләр чын әхлаклы, намуслы балалар үстерделәр. Газиз уллары Әкмәлетдиннәр, Сәетмөхәммәтләр, Галимуллалар сугыш кырларында туган илләре өчен башларын салдылар.

Кышкы озын кичләрдә «Йосыф кыйссасы»н ихлас күңел, күз яшьләре белән тыңлап утырган ул апакайларның берсе дә юк инде. Кыйссаны җанны тетрәтерлек моңга салып укучы әнием дә күптән мәрхүмә.

Бүген Кол Галинең буыннардан-буыннарга күчеп баручы мәңгелек дастанын кулыма алгач, мин аларны тагын бер кат күз алдыма китердем дә, сагыштан йөрәгем кысылып куйды. Кыйблага карап: «Гүрегездә дә Ходайның рәхмәтендә булыгыз, изге җаннар!»—диеп дога кылдым.

## Туган як сагышы

*Йөгереп китәрдәй булам да,*
*Кайтып җитәрдәй булам.*
*Күзге ачы җилләрдә лә,*
*Туган - үскән илләргә.*
(Халык җыры)

Бу вакыйганы язарга мин берничә тапкыр омтылып карадым. Әмма кәгазьгә төшерү төрле сәбәпләр аркасында һаман сузыла килде. Бер көнне шулай су астында калган бер авыл картының туган нигезенә, дулкыннар уйнап торган авылы кырыена кайтып вафат булуын сөйләделәр. Бу хәбәр бөтен авыл халкын тетрәндерде. Шунда мин, үз күзләрем белән күргән Гарифә карчыкның шул картка охшаш язмышын язып калдырасым килеп, кулыма каләм алдым.

...Түбән Кама сусаклагычын күтәреп Кама, Иж елгалары буенда гомер кичерүче авыл халкын күчереп зар елаткан сиксәненче еллар иде. Туган авылым Кырындыда фельдшер булып эшләгән чагым.

Беркөнне шулай иртән медпунктка миңа таныш булмаган, уртачадан калкурак буйлы, бераз шадрарак битенә көзге яфрак кебек сары иңгән, моңсу карашлы өлкән яшьтәге бер апа килеп керде. Исәнләшкәч, унайсызланып кына каршымдагы урындыкка утырды да, тирән итеп көрсенеп алгач:

—Бу нинди чит апа керде диясездер инде, апаем. (Безнең якларда үзеңнән кече яшьтәгеләргә апаем диеп дәшү гадәте бар.) Олы Баржыдан мин, Гарифә апаң булам.—Ул куеныннан кагәзь төргәге алып алдыма куйды.—Баржы брачы моны сиңа тапшырырга кушып җибәрде. Нит, берәр җиреңә урнаштырып куй, апаем. Анда минем бөтен авыруларым язылган булырга тиеш.

Бу аның амбулатория картасы иде, битләрен ачып, күз йөртеп чыктым.

—Кан басымы белән интегәсез икән...

—Интегәм шул. Менә бу күченү хәсрәте бөтенләй бетереп ташлады, апаем.

—Кече урамга ялгызак бер карчык күченеп килде дигәннәр иде, ул сез буласыз инде алайса.

—Мин булам ул, апаем. Шул кече урамдагы Салыйк картның тавык кетәге кадәр генә йортын сатып алдым, хәерлегә генә булсын!

—Барсы да әйбәт булыр, Гарифә апа. Калган гомеренне шул йортта исән-имин үткәрергә язсын!

—Изге теләгенә рәхмәт, апаем.—Бераз тынып торгач, Гарифә апа уфылдап авыр итеп сулап куйды да, сүзен дәвам итте. - Иии, апаем, бигрәк авыр хәлләр икән ул гомер иткән нигезенне ташлап китүләр... Бик тә авыр икән шул. Кузгалып чыгып киткән вакытларым күз алдыма килә дә... үзәккәйләрем өзелә дә китә. Ии, Ходаем, кемнәрнең каргышлары тотты икән безнең Баржы халкын диеп үксеп елыйм.

—Баржылар Кичкетан авылына күчәләр бит. Ә син нигәдер безгә күчәргә уйлагансың икән.

—Баржыдагы күршеләрем Гәрәйләр: «Әйдә, безнең белән Кырындыга күч»,—диеп үгетләгәч, күндем шул. Гәрәйнең балалары үз балаларым кебек булдылар. Бигрәк тә малайлары тыпырдашып минем йортымда үстеләр.

Мин үзем дә сизмәстән кинәт сорап куйдым:

—Үзеннең балаларың юкмени, Гарифә апа?—Ул сискәнеп киткәндәй булды, йөзенә кинәт кызыллык йөгерде, унайсызланып китеп, башын түбән иде, аннан керфекләрен түбән төшереп, башын күтәрде дә: «...Балалар табарга насыйп булмады шул мина»,—диде.

Мин артыгын сорарга базмадым. Бераз тынып торгач, мәсьәләгә ул үзе ачыклык кертте.—Сазаган кыз мин, апаем. Кияүгә чыга алмадым шул.

Безнең арабызда тагын авыр тынлык урнашты. Тынлыкны беренче булып мин боздым: «Гарифә апа, урынсызрак сораулар биргәнем өчен гафу ит. Ачуланма, тагын бер нәрсә сорыйм әле. Яраткан егетен дә булмадымени?»

—Ник булмасын, үземә күрә минем дә яратканым бар иде, апаем. Бер башлагач, сөйләп бирим инде алайса. Без аның белән көзгә кавышырга җыенган идек. Тик каһәр төшкән сугыш барсын да чәлпәрәмә китереп ташлады. Бәгырькәемне муенынннан кочып елый-елый сугышка озаттым. Бер бәхетсезнең бәхете булмый икән ул. Китнәненен дүртенче аенда ук теге Смалински дигән жирдә вафат булуы турында кара кәгазь килеп төште. Сугыш ачылган көннән үземнең кулыма дилбегә тоттырдылар. Юлдан кайтып керә алмадым, районга икмәк ташыдым. Мадьяр, Шаршады урманнарында атым белән агач чыгардым. Ул арык, хәлсез атлар белән юлларда ничек газап чиккәнемне бер Ходаем үзе генә белә. Кеше колачы житмәс агачларны берьялгызым чанага салганда көчем житмәс иде дә, чанама капланып үксеп елар идем. Ирләр күтәргәнне күтәрдем, ирләр бушатканны бушаттым. Башымда бүрек, өстемдә сырма, чалбар булды. Әкренләп күнелем тупасланды, юк-юк та авызымнан сүгенү сүзләре ычкына башлады. Әнә шулай жанымдагы нечкә тойгылар, наз дигәннәре еллар белән бергә югала барды. Сугыш безне явыз сихерче сыман иратша кызларга әйләндерде. Сугыштан кайткан егетләр безне түгел, чәчәк кебек яшь кызларны сайладылар. Ә без, кырышкан чәчәкләр, үтмәс тауар шикелле бер читтә торып калдык.

Мин Гарифә апаның язмышын тетрәнеп тыңладым.

—Мин сөйләгәннәр инде әкренләп онытыла баралар. Иң авыры, апаем, картаймыш көнендә туган нигезенне ташлап чит жирләргә китү икән ул. Ии, Ходаем! Минем кебек бәхетсезләргә сабырлыклар бир, мәрхәмәтеннән ташлама—Гарифә апа яшьле күзләрен мина күрсәтмәскә тырышып, башын читкә борды.

Мин аны җентекләп тикшердем, сәламәтлеге нык кына какшаган булып чыкты. Ул, сагышлы-моңсу күзләрен миңа төбәп, куркып кына сорады:

—Ничегерәк соң? Яшәрлегем бармы әле, апаем?

—Кан басымың шаяра икән, апа. Сине һәрдаим күзәтеп торырга кирәк. Медпунктка ешрак килеп йөрергә туры килер.

Гарифә апа минем киңәшләремне тотты, һәр атна башында медпунктка кан басымын тикшертергә йөрде. Яныма килгән саен Барҗысын сагынуын, колхозлары кечерәйтеп төзеп биргән шул «уймак кебек кенә» кечкенә йортын төшләрендә күреп йөрәге әрнүен елый-елый сөйләр иде. Мин авыруы турында әйткәннәрне дә Барҗысына кайтарып: «И, апаем, Барҗымда яшәсәм мин болай ук авырмас идем, туган якның бит аның чишмә сулары да, кояшы да, хәтта җилләре дә шифалы»,—дип әйтә торган иде. Бер атнаны Гарифә апа медпунктка елмаеп килеп керде.—И, белсәң икән, апаем, бүген шундый матур төш күрдем, янәсе, йортыма кайтканмын икән, ишек алдым тулы ямь-яшел бәбкә үләне өстеннән кечкенә йомгак кебек ап-ак чебиләрем йөгерешеп йөриләр. Мине күрү белән каршыма җыелдылар да чеп-чеп килеп җим сорый башладылар. Йортыма кердем дә, ярма эзләргә керештем, таба алмыйм гына, ярма тутырган тартмаларым да бушап калган икән. Ул арада кулыма буш чиләк күтәреп ярма эзләргә чыгып киттем. Кортлык тавында ярма эзләп йөрдем, тау астында тал-тирәкләргә күмелеп Иж җәйрәп ята. Башымны сулга борсам, Барҗымның урамнары тезелеп киткән. Куанычымнан түзә алмыйча: «Барҗыбыз исән икән бит, әнә бит, әнә!»,—дип кычкырып җибәрдем. Уянгач, ничектер рәхәт булып китте.

Гарифә апа һәркөн иртән кибеткә икмәккә йөрер иде. Пекарнидән икмәкне көттеребрәк китерсәләр, ул гел бер сүзне сөйли башлый: «Безнең Барҗыбызда халыкны болай тилмертмиләр. Безнең Барҗыбызда бервакытта да мондый хәл булмый. И, безнең Барҗыбызда... безнең Барҗыбыз...»

Бер сабырсызы шунда: «Барҗың алай бик әйбәт булгач, нигә монда күченеп килдең? Бар, юлыңа ак җәймә!»—диеп ычкындыра. Бу тел угы Гарифә апаның иң авырткан җиренә барып кадала.

—Барҗым исән булсамы? Барҗың үз урынында утыра дисәләрме? Артыма да борылып карамыйча тыным капланганчы йөгерер идем авылыма!—Гарифә апаның хәтере калудан тавышы калтырана.

Хатыннарның да кәефләре кырыла. «Бар, Барҗыңа кайт»,—дип ычкындырган хатынны төрле яктан нык кына шелтәләп ташлыйлар. Гарифә апаның Барҗысын сагынуы, җирсүе көннән-көн көчәя барды. Кан басымы күтәрелде, бик еш йөрәге чәнечте. Ябыкты, күз төпләре эчкә батып калды. Бер көнне эшемнән кайтып килгәндә бакча киртәсе янында кулын кашы өстенә куеп, күзләрен еракка төбәп басып торучы Гарифә апаны күреп, янына килеп туктадым. Ул бер кулын алга сузып:

—Әнә теге тау буендагы чикләвекле Балтач чаганлыгын күрәсеңме?—диде.—Әнә! Әнә! Күрәсеңме?

—Күрәм...

—Әнә шул тау артында гына бит инде минем Барҗыкаем! Бәбкә үләнле минем яшел чирәмле ишегалдым! Минем бер якка янтайган бәләкәч йортым! Минем туган туфрагым! Чит-ят җирләрдә үләм бит инде, бәгырькәйләрем!

Мин аны күпме генә юатырга тырышсам да ул ике бите буйлап аккан күз яшьләрен сөртә-сөртә елады да елады.

Бер атнадан соң без аны җирләдек. Төрдәле зиратында сагыштан җирсеп үлгән Гарифә апаның кабере барлыкка килде.



Лирон
Хәмидуллин

# ӘЙ, ГАРМУНЫМ, ГАРМУНЫМ!

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Һәр җирдә тансык кунак

Мәшһүр гармунчы артист Фәйзулла Туишевны, үз вакытында сәхнәдә күрмәгән, һич югы аның бик тә үзенчәлекле, дәртле, моңлы итеп уйнавын радио аша ишетмәгән бер генә татар кешесе дә юктыр, мөгаен. Ник дисәң, илле елдан ашып киткән иҗат гомерендә бу тынгысыз музыкантның концерт белән бармаган җире, төрле зурлыктагы чеңгелдәп торган үз гармуннарын уйнамаган сәхнәсе калмагандыр! «Фәйзулла Туишев милләтебезнең горурлыгы, халык арасыннан чыккан чын талант»,—дип язды аның турында күренекле язучыбыз Фатих Хөсни.



*Фәйзулла Туишев. 1910 еллар тирәсе.*

СССР дип исемләнгән дәүләт оешканчы ук әле ул көмеш телле гармуннарын иңенә асып Каф таулары артындагы Баку, Тифлисләрне дә, Мәскәү белән Петербургларны да, ерак Себер шәһәрләрен дә йөреп, урап чыга. Йөри-йөри җир читендәге Владивостокка да барып җитә, чит мәмләкәт шәһәре булган Харбинда да торып кайта. Болар белән генә чикләнмичә, Европаның мәдәни үзәге саналган Парижның үзендә зыялы тамашачы алдына чыгып, татар белән рус халыкларының моңкөйләрен уйнап дан ала. Анда ул икенче бер мәшһүр якташыбыз Федор Шаляпин белән бергә, бер сәхнәдә чыгыш ясау бәхетенә ирешкән артистларның бик сирәгедер. Фәйзулла Туишевны һәр җирдә ихлас теләп, яратып кабул иткәннәр. Ул җитәкләгән артистлар бригадасы Татарстанның һәм аңа чиктәш өлкә һәм республикаларның барлык татар авылларында булып кайткан диярлек. Әйе, аның җитез бармаклары күңел түрендәге халкы моңын, сагышларын бик мул өләшкән. Аның уйнау осталыгына соклануларын милләтебезнең бик

---

Лирон ХӘМИДУЛЛИН (1932)—*язучы, тәрҗемәче; «Юлда», «Дала иртәсе», «Офыктагы рәшәләр» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

мәгълүм шәхесләре Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һ. б. бик күпләр әйтеп һәм язып калдырган.

Чордашларының искә алуларына һәм сакланып калган афишаларга таянып, Фәйзулла Туишевның кайсы зур шәһәрләрдә һәм кайчан булганлыгын күз алдына китерә алабыз. Үзе туып-үскән төбәктәге Сембер, Самара, Казан, Түбән Новгород һәм Идел буендагы башка барлык шәһәрләрне ул иң беренче гастрольләре вакытында ук йөреп чыга. Аңа ул вакытта әле егерме яшь кенә була. (1910 еллардагы артист кыяфәтен күзаллардай фото сакланган. Артист гитарада уйный, янәшәсендә гармуны чират көтеп тора.) Ә туган-үскән җирләреннән ерак-еракларга таралышып көн күрергә мәҗбүр ителгән милләттәшләребез исә сөекле музыкантны һәркайда да сагынып каршы алган. Мәһабәт буй-сынлы, көләч йөзле артистның шат елмаеп сәхнә түренә чыгып басуын, шундагы өстәл өстенә тезеп куелган эреле-ваклы гармуннарның берсен алып уйный башлавын түземсезләнеп көтеп торганнар. Концертны алып баручы:

—Фәйзулла Туишев уйный!—дип белдерүгә үк гөрләтеп кул чабулар башланган.



*1914 елгы концерт программасы.*

Хәер, Фәйзулла Туишевның гармунда уйнавын татар тамашачысы гына түгел, башка халык вәкилләре дә бик яратып тыңлаганнар. Аның уйнавы аша татар халкының эчке рухын үз итеп, күңелләренә сеңдерә торган булганнар. Моның шулай икәнлеген без матбугат битләрендә теркәлеп калган истәлек язмаларыннан да укып беләбез. Мәсәлән, танылган артистның илле еллык юбилеена багышланган бер мәкаләдә Муса Җәлил болай дип язган: «Фәйзулла ага төрле милләт көйләрен өйрәнүгә һәм аларны оста уйнап бирүгә күп игътибар куя. Ул казакъ, үзбәк, әзәрбайҗан, кавказлы, чуаш, чегән һ. б. азчылык милләтләрнең хәзерге композиторлары әсәрләреннән һәм халык көйләреннән күп кенә үрнәкләр уйный. Шунлыктан Фәйзулла аганың музыка өлкәсендәге хезмәте интернациональ төс ала...»

Совет хакимияте урнашуының ун еллыгы көннәрендә, 1927 елда, Мәскәүдә СССР халыкларының сәнгать фестивале үткәрелә. Илнең төрле төбәгеннән килгән театр коллективлары үз осталыкларын, ә концерт бригадалары үз һөнәрләрен баштa таләпчән комиссияләргә күрсәтергә, шуннан соң халык алдында чыгыш ясарга тиеш булалар. Татарстаннан килгән концерт бригадасына композитор Салих Сәйдәшев, танылган җырчылар Гөлсем Сөләйманова белән Газиз Әлмөхәммәтев һәм төрле халык көйләрен бер дәрәҗәдә оста башкаручы Фәйзулла Туишев керәләр.

1940 елның мартында классик әдибебез Шәриф Камалның иҗат итә башлавының утыз еллык бәйрәме Мәскәүдә билгеләп үтелә. СССР Язучыларының мәдәният сараенда уздырылган ул кичәгә Казаннан әдипнең иҗатташлары Афзал Шамов, Тажи Гыйззәт, Гази Кашшаф һәм күренекле артистлар бара. Алар арасында Ш. Камалның якын дусты, яшьтәше Фәйзулла Туишев та була. Мәскәүдә яшәүче мәгълүм язучылар һәм СССР Язучылар берлеге рәисе Александр Фадеев та ул кичәдә катнаша.

Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗанов, мәшһүр гармунчы белән бергә, байтак кына концертларда катнаша. «Озак еллар чит җирләрдә йөргәч, ниһаять, сөекле, дәртле, моңлы Казанга кайтты. Татар дәүләт академия театрында Фәйзулла аганың Казанда беренче концерты булды. (Бу очракта сүз, әлбәттә, совет хакимияте чорына караган беренче концерт турында бара. Л. Х.) Миңа бу

концертта Туишевны тамашачылар белән таныштыру һәм кичәне алып баручы вазифасын үтәргә туры килде. «Хәзер сезнең алдыгызда Фәйзулла ага Туишев»,— дип белдерүгә, залдагы алкышларны язып та, сөйләп тә аңлатуы кыен. Тамаша залы гөр килде»,—дип яза артист, оста гармунчы белән беренче очрашу кичәсен искә алып. Һәм болай дип дәвам итә: «Шул заманда ул иң зур баяннан алып, шырпы тартмасы кадәр генә гармуннарда уйнаучы бердәнбер артист иде. Беренче бүлектә ул татар егете кыяфәтендә ыспай итеп киенгән. Чиккән кәләпүш, камзул, читектән—матур сынлы, соклангыч булып күз алдына килеп баса. Бу бүлектә фәкать татар көйләрен башкарды. Ә икенче бүлектә русча киенеп, рус халык көйләрен уйнады. Гармунда уйнау белән генә чикләнмичә, бик оста итеп биеп тә җибәрә иде. Минем аңа кадәр һәм аннан соң да Фәйзулла абзый кебек виртуоз башкаручыны очратканым булмады».

Хәким Сәлимҗановка соңрак та берничә мәртәбә Фәйзулла ага белән бергә концертларда катнашырга туры килә. Ә Мәскәүдә 1941 елда узарга тиешле татар әдәбияты һәм сәнгатенә әзерлек көннәрендә ул башкаладан килгән кабул итү комиссиясе вәкилләре белән аралаша. «Мәскәү комиссиясе алдындагы смотрда Фәйзулла ага да катнашты. Башкала вәкилләре аның иҗатына иң югары бәяне бирделәр. «Мондый оста башкаручы безнең рус дөньясында да сирәк», дигән фикергә килделәр»,—дип искә ала Хәким ага. Сугыш башлану сәбәпле, әлеге декада булмыйча кала. Шул сәнгать бәйрәмендә катнашырга дип сайлап куелган артистлар, аерым бригадаларга билгеләнеп, яу кырындагы сугышчыларны рухландырып, концерт куеп йөрергә мәҗбүр булалар. Алтмыш яшенә житеп килүче Ф. Туишев та шундый төркемнәрнең берсен житәкли. Аның «фронт бригадасы»на Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая да керә. Останың көмеш чыңлы гармун телләрен тибрәтеп уйнавы сугышчыларның күңелләрен, һичшиксез, җилкендереп җибәргәндер. Туган-үскән якларыннан сәлам буларак кабул ителгәндер. Сәхнә ветеранының ике зур чемоданга тутырылган төрле зурлыктагы гармуннарын күтәреп, Бөек Ватан сугышы фронтларына барып чыгуы, туп гөрселдәүләре тынып торган минутларда сугышчылар өчен ялкынланып уйнавы бик күпләрнең хәтерендә сакланып калган.

Әйе, кайларда гына уйнамасын—фронт шартларындамы яисә кечерәк бер авылның клубындамы, аны һәрчак үз итеп, якын күреп кабул иткәннәр, уйнавын бирелеп тыңлаганнар. Үзен яратып калганнар. Аның моңлы да, дәртле дә итеп оста уйнавы кешеләрнең күңелләрен юаткан, тормышның гүзәллекләрен тоярга ярдәм иткән, сагышларын тараткан.

Кайларда, ничегрәк башланган соң олы дан-шөһрәт казанган бу артистның тормыш юлы? Кем аны шулай тәрбияләп үстергән? Кайсы төбәк җир-суының баласы ул? Истәлек язмаларда бу сорауларга әлегә төрлечә җавап бирелә. Аңа багышлап 1939 елда «Гармунчы» повестен язган күренекле әдип Фатих Хөсни артистны Мәләкәс шәһәрендә туып-үскән дип бәян итә. Соңрак дөнья күргән кайбер башка язмаларда да, «Гармунчы» авторына ияреп булса кирәк, Ф. Туишевның туган җире итеп шушы шәһәр күрсәтелгән. Ә бит Ф. Хөсни повестеның беренче бүлегендә үк, бу әсәр артистның тулы биографиясен чагылдырмый, дип кисәтә. Татарстан китап нәшриятында 1980 елда басылып чыккан күләмле «Народные артисты» китабында да: «Родился в поселке Мелекес ныне Ульяновской области», дигән сүзләр язылган. Һәм иҗади-биографик белешмә урынына әлеге повестьтан кыскача өзек китерелгән. (Ул китапта башка төгәлсезлекләр дә байтак. Мәсәлән, танылган җырчыбыз Рәшит Ваһаповны да анда биш елга иртәрәк гүр иясе итеп күрсәткәннәр.)

Дөрес, кайбер очракларда артисит үзе дә, мөгаен, оста гармунчы булып китүенә бәйле рәвештә, яшүсмер чоры Мәләкәсен ешрак телгә ала торган булгандыр. Әйе шул, Олы Чирмешән елгасы буендагы нәкъ шушы шәһәрдә ул беренче булып кулына гармун ала. Музыкант буларак шушында «туа». Икенче бер мәшһүр якташыбыз, рус әдәбияты классигы Максим Горький да бит әнә, Түбән Новгородта дөньяга килүенә карамастан, «шәхес буларак мин Казан шәһәрендә тудым» дип яза.

## Ямьледер Чирмешән буйлары

Фәйзулла Туишевның беренче мәртәбә тәпи аяк баскан җире шул ук Олы Чирмешән елгасы янәшәсендәге Иске Төгәлбуга авылы була. Ул Мәләкәс (хәзерге Димитровград) шәһәреннән кырык чакрым чамасы үрдәрәк урнашкан. Артист туган вакытта авыл Самара губернасының Самара өязенә караган. (Югыйсә, Ф. Туишевны «Сембер губернасында туган» дип, хата язу очраклары да еш кабатлана.) Утызынчы елларда Иске Төгәлбуга, Урта һәм Иске Исәнтимер, Өчкаен, Әбдери, Алга, Төплистан, Зирекле Куак, Иске Җүрәй кебек бер төбәктә урнашкан татар авыллары Куйбышев өлкәсе карамагында булды. 1943 елдан алар Ульянов өлкәсенең Яңа Малыклы районына керәләр (Төплистан белән Иске Җүрәйдән кала). Иске Төгәлбугада туган кеше буларак, миңа артистның балачак биографиясе бик тә таныш. 1939 елның март урталарында гармунчы туган авылында зур концерт куйды. Мин дә анда тамашачы булдым. Җиденче яшьтә чагымда. Ул вакыйганың кайсы көндә барганын төгәл хәтерләмим. Аңа күрше-тирә авыллардан да бик күп кеше килгән иде. Урта Исәнтимердә эшләгән әтием һәм аның юлдашлары да ул кичтә, берничә олау төялеп килеп, Иске Төгәлбуга клубында Фәйзулла аганың уенын бирелеп тыңлаганнар.

1958 елда, җитмеш дүрт яшендә Казанда вафат булган авылдашым Фәйзулла Туишевны башка вакытта күрмәсәм дә, аңа багышлы истәлекләрне балачактан ук ишетеп үсәргә насыйп булды. Алтмышынчы-җитмешенче елларда исә олуг артист белән бергә уйнап үскән яисә соңрак якыннан аралашкан кешеләрдән язып алган каралама язмаларым да бар. Ул елларда әле Иске Төгәлбуга авылында «Курай урамы Фәйзүге»нең бала чагын яки туган-үскән төбәгенә «концерт куярга» кайтып йөргән заманнарны хәтерләүчеләр байтак иде. Сугышка кадәр мәшһүр артист туган якларына еш кайта. Ул елларда авылда әле аның якын туганнары да исән була. Олуг артистның бер кайтуында булачак тарихчы Җәмил Гыйльманов аңа пионер галстугы да тагып җибәрә. Ул вакыйга клубта булганмы, яисә мәктәп балалары белән очрашудан соңмы—ачыкламаганмын.

*Чирмешән буйлары ямьле,*
*Ял итәргә килегез;*
*Эштә уңган егетләрне*
*Безгә килеп күрегез,—*

дип җырлана халык җырында. Иске Төгәлбуга авылы да бик ямьле җирдә, Чирмешәнгә коючы елгачык буенда урнашкан. Ул елгачык Иске Җүрәй янәшәсендәге үрдә башлана да, күрше чуаш авылы аша үтеп, Иске Төгәлбуганың кыйбла башына килеп керә. Елга арьягы урамы буйлап бераз баргач, авыл эченә таба борылып ага башлый. Авылның төньяк очыннан Чирмешәнгә бер чакрым чамасы ара. Ул урында елга, дугаланып, бездән берникадәр ераклаша төшә. Елга белән ике арада күлле-баткаклы Чалу болыны, урман алды агачлыгы һәм урман колаксасы рәвешендә куерып үскән шомыртлык бар. Ә Чирмешәннән соң инде кинлеге егерме-утыз чакрымлы «Зур карурман» башланып китә. Әбиемнең Татарстан чигендәге туган авылы Пәрауга балачакта шул тоташ нарат урманы аша атта да, җәяү дә барганым хәтердә калган.

Үз төбәгендә Иске Төгәлбуга зур тарихлы авыл санала. Ул Казаннан элекке Нугай иленә һәм Самара каласына илтүче ол юл өстендә оешкан. Кайчандыр шунда булып киткән бер галим-сәяхәтче аның борынгы тарихлы авыл икәнлеген язып калдырган. Авылның исем-атамасында да борынгы кыпчак-мишәр чалымы чамалана. Ил, ыру башы булырдай ирләрне, нәсел үгезенә тиңләп, төрле сыйфатлы буга, шул исәптән төгәл буга (нәкъ үгез) дип атауларына тарихта мисаллар күп. Әйтик, урта гасырлар кыпчакларына нисбәтле «Кодекс команикус» китабында да Төгәлбуга исемен йөртүче зат булуы теркәлгән. Димәк, бу авыл да кайчандыр Төгәлбуга исемле бер шәхес тарафыннан нигезләнгән. Дөрес, хәзер яшьрәк буын вәкилләре, исем әйтелешен беркадәр җиңеләйтеп, авылны Төгәлбай дип тә атыйлар. Ләкин аның чын тарихи һәм рәсми исеме Төгәл+Буга. 1917 еллардан соңгы

үзгәрешләргә кадәр анда җиде йөз унбиш йорт исәпләнгән.

Авыл төньяктан кыйблага таба сузылган өч чакрымлы дүрт һәм берничә кыска урамнан тора. Аның як-якларында икешәр зират, Иске һәм Яңавыл дип йөртелгән оч-очлар аралыгындагы бушлыкта бишенче, иске зур зират бар. Зур һәм Курай урамнары арасыннан агучы елгачык, урталыктагы биек буага җитәрәк, Зур күл хасил итә. Шул күл янәшәсендә унлап йортлы Күл почмагы бар. Шунда элек бәләкәй Фәйзүк бер-ике кыш укыган Күл буе мәдрәсәсе булган. Без үскәндә ул мәдрәсә биналарында фельдшер бүлмәсе, китапханә эше оешмалар эшләде. Авыл советы, колхоз идарәсе йортлары һәм ике кибет тә шул тирәгә сыешкан иде. Зур урам белән Күл почмагы чатындагы Олы мәчет клубка әверелдерелде. 1939 елда, Фәйзулла Туишев концерт куйганда, ул клуб әле мәчет рәвешен саклый, фәкать манарасы гына юк иде. Ә Курай урамы мәчете манарасы, бала-чага өстенә ишелеп төшмәсен дип, җитмешенче елларда гына сүтелә.

Сугыш алды елларында Курай урамы мәчетенең буш бинасы шул оч балаларының олылардан качыбрак уйнау өенә әверелгән иде. Ябык тәрәзә капкачлары ярыгыннан сузылган яктылык сөңгеләре сихри дөнья тудыра. Шул нурлы сөңгеләр аша сикерә-сикерә малайлар иркен идән буйлап чабышып йөриләр, качыш уеннары уйныйлар. Куышып арыгач, текә баскыч буйлап манарага менеп китәләр. Өркетә-өркетә андагы күгәрченнәрне очыралар. Яки, Чапай батыр рәвешенә килеп, манара тәрәзәләреннән тирә-якны күзәтергә керешәләр иде. Иске Төгәлбуга бик тигез җирдә урнашкан. Якындагы дүрт-биш күрше авыл манзарасын шул мәчет манарасыннан күзәтеп торырлык. Зуррак малайлар, аннан алтмыш чакрымнардагы Нурлат элеваторы да елкылдап күренә, дип мактаныр иде. Ләкин аны күрү өчен бик иртә, кояш чыкканда ук торасы шул. Ә минә җилсез, тымызык көннәрдә мәчет манарасыннан ерак офык читеннән үтеп китүче поездларның куе-кара төтене бөркелүен шәйләп була иде. Курай урамына, классташым Өмид янына барганда малайларның ул уеннарында үземнең дә катнашкан чакларым хәтердә.



*Салих Сәйдәшев (сулда) һәм Фәйзулла Туишев. 1930 еллар.*

Бала чакта Фәйзүк абыйларга мәчет тирәсендә уйнау, манарага менеп, паровоз төтене бөркелүләрен күзәтеп тору тыелган була, билгеле. Хәер, ул вакытларда әле Сембер белән Бөгелмә арасында поездлар да йөрмәгән. Хәтта әле «чуен юлы»ның да салынмаган чагы. Ул чор малайларының бирелеп уйнаган урыннары— урам чирәмендә һәм су буйларында... Тавык-кошны өркетә-өркетә куе әрекмән арасында бер-береңнән качкан булып йөрү дисеңме, хәтфәдәй җәелеп үскән чирәмдә мәтәлчек атынгалап, тәгәрәшеп алуларммы—берсе дә ялыктыра торган уеннар түгел. Урамда уйнап ялыксаң, кармак сабын күтәреп, су буена төшәсең. Кемнәрдер шунда су коена, кемнәрдер, бераз читкәрәк барып утырып, кармак сала. Зуррак малайлар исә, күлдә балык начар чиртә, дигән сылтау белән күнелне ымсындырып торган урман ягына карангалый башлый. Ике-өч малай бер фикергә килсә, ашкын сулы Чирмешәнгә таба китеп бара. Анда чыннан да балык—эре дә, еш чиртә дә. Кармакны салып, йөзеп баручы калкавычны күздән кичереп өлгермисең, ул бата да башлый. Бик уңган, җимне дөрес сайлый белгән оста балыкчылар кайвакыт берәр аршин буйлы җәен балыгын да каптырып ала. Әмма, андый бәхет һәркемгә дә эләкми. Җәеннең кайсы чоңгыл төпкелендә үз корбанын, үз ризыгын көтеп ятуын белү бик читен.

Фәйзүкнең дә керсез, ваемсыз-гамьсез бала чагы баштарак менә шулай узгандыр. Яңа әшнәсе Мөхәммәтша һәм агалы-энеле Биказаковлар белән бергәләп гамьсез

генә йөргән чаклары еш булган. Олыларның вак-төяк йомышын үтәүдән бушаган арада, әлбәттә. Олы мәчет янәшәсендә, Зур урамда яшәүче Мөхәммәтша белән Фәйзүк мәдрәсәдә укый башлагач дуслашалар.

Артист буларак танылa башлаган бер вакытта, егерме ике яшендә солдатка каралырга авылга кайткач та, Фәйзулла башлыча шушы дуслары белән некрут җырлары җырлашып йөри. Авылдан егерме биш чакрымдагы Зирекле Куакка каралырга барганда аларга җырчы Гүләй Шәфигулласы да кушыла. Соңрак туган якларга кайтканда да гармунчы Мөбәракша дусты белән күрешмичә китми торган була.

Фәйзулла ага туган елларда авыл халкы дүрт мәхәлләгә бүленә. Мәхәлләләрне Кизләү, Мәләкәс мәдрәсәләрендә белем алган муллалар җитәкли. Иске Төгәлбуганың ике зур мәчете карамагында мәдрәсәләр эшли, Яңавыл очында мәктәп була. (Ул 1934 елда, яңа зур мәктәпне төзегәч ябыла. Бинасында кече кибет—«лавка» ачыла.) Мәдрәсәләрдә кечләрен кычкырып китап уку, аларны күчереп язу үзенә күрә бер мәртәбәле, изге эш саналган. Иске Төгәлбугада борынгы китапларны күчереп язу белән мавыгучылар булганлыгын олы әдибебез Нәкый ага Исәнбәт тә бер әңгәмә вакытында раслаган иде. Утызынчы елларда ул, Татарстан биләмәсеннән көньяктарак калган авылларда булып, кешеләр кулында сакланган кулъязмаларны барлап һәм халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплап йөргән. «Сезнең Төгәлбугада да булдым. Ул авылның изге җаннары Гаделша, Гобәйдуллалар күчереп язып, тамга салган кулъязмаларны соңыннан архивларда да очратканым булды»,—дип әйткән иде ул.

## Курай урамы Фәйзүге

Авылның бу урамы башкаларыннан соңрак барлыкка килгән. Урам исеменнән үк чамаланганча, элгәре анда эре кура-сабаклы үләннәр котырып үсә торган урын була. Зур урам артындагы елга-күлгә янәшәдән генә агып төшүче инеш буе үзәнендә хәзер дә әле әрекмән, елан көпшәсе («елан курае») ише озын куралы үләннәр өер-өер булып утыралар.

Фәйзулла Кәбир улы Туишевнең туган йорты Курай урамы мәчетеннән ерак түгел. 1972 елда чордашы Фәтхи ага Биказаков белән ул урынны карап йөргән идек. Җиргә сеңеп баручы бер иске өй янына җиткәч ул:

—Кәбир абзыйның төп йортта калган Хөснетдин энесе яңартып төзегән ызба шушы була,—дип төртеп күрсәтте.

Хөснетдин Туктаров Беренче Герман сугышында, аның уллары Сәхаб белән Шәмси Бөек Ватан сугышында башларын салып, чит-ят җирдә ятып калган мәрхүмнәр. Әйе, артистның авылдагы нәсел-нәсәбе Туктаров фамилиясен йөрткән. Дөрес, монда андый фамилияле ике нәсел булган. Зуррак тармаклы икенче нәсел башында Шәкүр байның бертуганы Туктар карт торган. Ул нәсел варислары бүген дә авылда һәм авылга якын тирәлектә ишле санала.

Фәйзүкләрнең бәрәңге бакчалары авыл аша аккан елга буена төшкән. Курай урамы очына җитәрәк ул елга, капылт кына төньякка таба борыла да, Олы Чирмешәнгә таба ага башлый. Яз айларында, Чирмешәнгә кушылыр алдыннан болын буйлап җәелеп, эреле-ваклы күлләр хасил итә. Җәй урталарына үл күлләрдә маймыч балыклар үрчеп чыга. Ташу китүгә, авыл уртасындагы буа яңадан буыла. Күл суы әкренләп Фәйзүкләр бакча башындагы борылышка кадәр күтәрелә, җәелә. Элек ул күлдә бала-чага балык тота, ир-егетләр ат коендыра, хатын-кыз басмаларга басып кер чайкый, ул керне бәләкләп куя торган иде. Илленче еллар ахырларына чаклы совет чоры авыл тормышы да шул рәвешле барды. Күл буендагы алачыкта чаң-чоң китереп тимер сугалар, иртә-кичен ике яр тарафыннан су чыпырдаган, сырлы бәләк белән кергә йомшак кына суккан авазлар ишетелеп куя. Кыр эшеннән кайткан ир-егетләр атларын пошкырта-пошкырта суга кереп китәләр. Көндезләрен күл өстендә бала-чага чыр-чу килә. Курай урамы тарафындагы текә яр тирәсендә яр буе керәшәләре чыр-чулап баш очында бөтерелә. Кызгылт-кара балчыкка тирән итеп уеп тишелгән түм-түгәрәк ояларында ул кошларның чебиләре ишетелер-ишетелмәс кенә чикылдаша. Тәвәккәлрәк малайларның йомры учлары ул ояларга

үрелә башласа, керәшәләр, бер өер булып, андый батырның өстенә ябырыла. Баш очында җан өркеткеч чинау-чәрелдәү авазлары күтәрелә иде.

Фәйзулла агалар заманында да ул шулайрак булган. Ат та коендырганнар, бала-чага чыр-чу килеп күл өстендә йөзеп уйнарга да яраткан. Авыл гадәтенчә, Фәйзүкнең апа-сеңелләре дә, мөгаен, иртән дә, кичен дә күбрәк шул төнбоеклы күл буенда, зур-зур өянкеләр тирәсендә кайнашканнардыр. Тирәкләрдә кош сайраган, яр буйларында кыз-хатынның сабыр гына моңлану, җырлау авазлары ишетелеп торгандыр. Тар басмага басып алар юынып та алган, керләрен дә чайкаганнар. Утаудан яисә урактан кайткач, чабата белән тула оекны салып, аякны суга тыгып утыру да җанга-тәнгә рәхәт биргән.

Дөрес, Фәйзүкләр бакчасы башында су тирәнлеге, бәлкем, ат коендырырлык ук булмагандыр. Анда елга беркадәр саега һәм тарая төшә. Шул ук вакытта анда бала-чага рәхәтләнеп коенырлык иң шәп урын да иде. Чөнки язгы ташкын борылышның Курай урамы тарафына күп иттереп аксылсары ком китереп өя. Ул урынга Зур урам очы малайлары да бик теләп йөриләр иде. Ә борылыштан чак кына өстәрәк—Зур урам белән Аркылы урам башлары кушылган җирдә—күлгә саф, салкын сулы Сыза кизләве килеп кушыла. Сыза чокырында элек чишмәләр ишле була, авылның яшь киленчәкләре элек анда чәй суына йөриләр. Яшьрәк чакта артистның әнисе Гөлҗамал да, апа-сеңелләре дә якындагырак чишмәләрнең берсенә суга бара торган булган. Искеавыл очы бала-чагасы, хатын-кызлары ул заманда Сыза буендагы кече урманчыкка җиләк җыярга да йөргән. Авыл очында яшәгән Мокыч токымы да алардан калышмагандыр. Әйе, Фәйзүкнең бабасының халык телендәге исем-кушаматы Мокыч. Алар—Мокычныкылар.



*Өч дус: (сулдан) Ш. Камал, К. Нәҗми, Ф. Туишев.*

Без үскәндә инде Сыза буе урманчыгы беткән, тирән яр төбендә сабыр-салмак кына агып ятучы кизләү суын чыпчык атлап чыгарлык кына иде. Халык телендә Шалкан куагы дип йөртелгән урманчыкның булганлыгын раслап, авылның кырый урамнарындагы бәрәңге бакчалары ызаннарында анда-санда озын, төз нарат агачлары гына күренер иде.

Кечкенә Фәйзүкне дә, дан-шөһрәт казанган артистны да авылда иң яхшы белүче, ул чор вакыйгаларын яхшы хәтерләүче кеше—Фәтхи ага Биказаков. Курай урамы Туктаровларының элекке күршесе.

Иң әүвәл аның үзе белән чүт кенә танышып үтик. Ул Фәйзулла агадан ике-өч яшькә кечерәк. Шулай булса да, аның белән бик якыннан аралашкан кешеләрнең берсе. Чөнки аның абыйсы булачак гармунчы белән яшьтәш тә, сабакташ та була. Фәйзүк некрутлыкка каралырга кайткан көннәрдә дә бу ике яшьти берберсеннән аерылмый. Яшьтән чая, үткен булган Фәтхи энекәш тә һәрчак аларга ияреогә тырыша торган була.

Фәтхи ага какча гәүдәле, уртачадан кечерәк буйлы, җитез хәрәкәтле кеше. Хәрәкәттә бәрәкәт, дип олылар тикмәгә әйтмәгәндер. Берәр вакыйга турында сөйли башласа, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, шулай булды бит, әйе бит дип, үз сүзләрен раслатып торырга ярата. Аның яшьтән үткен, чая, һәм, үзе әйтмешли, чаманы белеп кенә усал да булганлыгын дәлилләүче мисаллар җитәрлек. Гражданнар сугышы чорында аңа атка атланып, кылыч айкап ярты илне гизеп чыгарга туры

кылә. Мәләкәс татар атлы эскадронында кече командир да, агитатор да була. Шул сугышта уң кулын гарипләтеп кайта. Колхозларга берләшү елларында берничә артельне оештыруда катнаша. Күрше Әбдери авылында колхоз рәисе булып та эшли. Кылыч яртылай өзгән уң кул чугы белән мылтыктан ата алмасын белгән хәлдә, 1941 елның көзендә үзе теләп сугышка китә. Илле яшьтә. Мәскәү тирәсендәге сугыш мәһшәрен, әсирлек газабын узаманларча күрәшеп кичерә. Без аралашкан 1970 еллар башында да әле ул, сиксәннән өстен яшьтә булуына карамастан, егетләрчә җиңеллек белән колхозның ревизия комиссиясе рәисе вазифасын үтәп йөри иде.

Әмма аңа иң зур дан китергән вакыйга 1920 елда Татарстан мохтариятен оештыру көннәренә бәйле. Булачак автономия чикләренә Иске Төгәлбуганың һәм аңа якын булган дистәләгән татар авылының кертелмәгәнлеге ачыклана. Яңарак кына иркле, тиң, тигез тормыш өчен дип төрле тарафларда сугышып, кан коеп кайткан узаман ир-егетләр мондый хәл белән килешергә теләмиләр. Берничә авыл халкы берләшеп, күкрәкләренә беренче Совет орденын тагып кайткан иң батыр ир-атларны Самарага озаталар. «Безнең авылларны да Татарстан биләмәсенә кертүгә ирешегез»,—дип наказ бирәләр. Ләкин халык теләге үтәлми. Губерна комиссарлары: «Декретка кул куелган, хәзер соң инде»,—дип акланалар. Ә җирле волость ревкомы рәисе Вечкомов «ходатайларны кулга алырга» дигән боерык бирә. Авылларда гауга чыга. Иске Төгәлбуга бунт үзәгенә әверелә. Атка атланып, кулына чалгы алган Фәтхи Биказак аның әйдәүчесе булып таныла. «Совет өчен сугышып йөргән батырларны кулга алырга әмер бирүчене томкарларга»,—дигән халык таләбен үтәп, җирле комиссарны авыл келәтенә китереп ябып куя. Халык белән аңлашырга дип Самарадан мөселман комиссары килгәнче, теге рәис шунда ике-өч тәүлек утыра. Менә шундый тәвәккәл, чая, тапкыр кеше була яшь Фәтхи Биказаков. Әйткән сүзендә торучан, туры сүзле булганы өчен дә авыл халкы аны үз итә иде.

—Фәйзүк абыйлар белән безнең ызбалар янәшә иде бит, беләсең инде,—дип сүз башлады ул беренче очрашу вакытында.—Минем абый белән яшьтәш алар. Ярты көнне аларда уйнасалар, тагын ярты көнне бездә үткәрерләр иде.

Курай урамы—кырый урам. Анда авылга яңарак килеп төпләнүчеләр дә ишле булган. Фәтхи ага әйтүенчә, Мокыч баба нәселе дә, Биказаковлар гаиләсе дә кайсыдыр күрше авылдан элегрәк елларда Иске Төгәлбугага күчеп килүчеләр була. Бер оя бала үстергән Биказаковлар да, «бер ызбага сыешмаган Мокыч баба токымы» да ярлылар чутында йөргән.

—Фәйзүк үскәндә алар да бик ишле булды,—ди дә Фәтхи ага, бармакларын бөгә башлый:—Мокыч баба карчыгы белән—рас, Кәбир абзый, хатыны, ике кызлары, Фәйзүк—ике булдымы, яңарак өйләнгән Хөснетдиннәре—өчме, Мокыч бабаның кияүгә китәргә өлгермәгән кече кызы—дүрт булдымы. Әһә, вәт, дүрт сандык кына бар бер ызбада. Ә тавыш-тын чыгармаганнар, сыешканнар бит. Никме? Йорт башының талканы коры булган, ни дисә—шуны эшләгәннәр,—дип сөйли әңгәмәдәшем.—Аннары бит ул заманда төп йорттан тиз генә аерылып чыгу да катлаулы иде. Авыл жыены урын бирсә генә ага-брат бүленеп чыга алды. Ә жыенда утыручы авыл картлары кайсы йортта ир заты күп, шуңа өстенлек бирә. Имана кишәрлеге ишлерәк булган кешеләрне иң элек йорт-җирле итәргә тырышалар. Чөнки алардан авылга файда күбрәк тия.

Җан башларын санарга керешәбез. Фәтхи ага исәпләвенчә, Мокыч баба йортында унтугызынчы йөзнең туксанынчы елларында уникe җан иясе була. Шулардан, Фәйзүкне дә санап, имана җиренә ия булырдай дүрт «душ»—дүрт ир заты чыга. Бик аз, әлбәттә.

—Староста Кумык бабаның, пример, унбиш жанның яртысыннан күбрәге ир затыннан иде. Туктар бай ызбасындагы нисбәт тагын да югарырак. Алар баемый кем баесын! Кырны тутырып иген игәләр, башак ашатып мал симертәләр. Кыш булды исә ярминкәдән ярминкәгә йөриләр. Мәләкәскә илтеп ашлык, Юхмачы базарында көр мал-туарларын сатып акча туплыйлар. Янчыклары тулгач, ярлы-ябаганың эшкәртерлек рәте булмаган җирләренә кул суза башлыйлар. Вәт бит ул ничек...

Иске өйне караганда Фәйзулла абыйларның авылдагы тормышын күзалларга тырышам. Урам якка өч, ишегалдына ике тәрәзә уелган кечерәк бура өй, иркен генә такта чолан. Юкарак бүрәнәләрдән сипләнгән сыер абзары ат араны белән тоташкан. Яз-көз һәм кыш көннәрендә хатын-кызга суыкка, кар-яңгырга чыгып йөрисе түгел. Ишегалды почмагында җәйге чорда һәм көзге-язгы аяз көннәрдә мал ашата торган урын. Ул озын, юка колгалар белән киртәләп куелган. Ул киртә янәшәсендә бәрәңге бакчасына, су буена илтә торган җил капка.

Фәтхи ага һәм башка картлар сөйләвенчә, авыл җыены Кәбир Туктаров гаиләсенә төп йорттан аерылып чыгарга урын билгеләгән була. Курай урамы очындагы бушлыкта. Ләкин, 1891 елгы зур ачлык башлану сәбәпле, Фәйзүкләр яңа бура корып, үзгәлеккә чыгарга өлгермичә калалар. Ә ике-өч елга сузылган ул хәтәр ачлык байтак кына кешеләрнең тормышын, яшәешен төптән үзгәртеп ташлый. Ачтан, хәерчелектән үлүчеләр дә күп була...

## «Чукынган, чучка көтә...»

Әйе, мәшһүр артист биографиясендә андый хәлләр дә бар, дип искә ала авылдашлары. Һәм, мөгаен, артист өчен иң авыр кичерешле, һич тә искә аласы килмәгән, хәтер төпкелендә генә яшеренеп ятучы бер үкенечле хатирә булгандыр ул.

Алда әйтелгәнчә, ата-бабадан килгән тәртип буенча, Мокыч бабаның төп йортының варисы кече улы Хөснетдин булган. Хөснетдиннән соң ул өй аның кече улы Шәмсетдингә кала... Сугыштан соңгы елларда ул өйдә балигъ булмаган улы белән Шәмсинең хатыны яши. Егерменче-утызынчы елларда Фәйзулла ага авылга җиңгәсе йортына кайта торган була. Унбиш чакрымдагы тимер юл станциясеннән ул һәрчак затлы тарантаста кайта икән дә, зур юлдан Курай очына борылуга:

—Бәнат тәчи, чәең куй!—дип көр аваз сала икән. Шул авазы аның тиз арада авылның аргы очына да ишетелеп, бар халыкка сөенеч өсти торган булган, имеш.

Рәсми биографиясендә теркәлгәнчә, Фәйзулла Туишев 1884 елның декабрендә дөньяга килгән. Ләкин кайбер авылдашлары аны бер елга алданрак туган дип исәплиләр. Чордашлары Мөхәмматша белән Фәтхи агалар да шул фикерне раслый. Узган гасыр башында писарьларча пөхтә киенеп, солдатка каралырга кайтканда да ул 1883 елда туган некрутлар белән бергә йөрде, бергә комиссия үтте, дип саныйлар.



*Рәссам П. Новичковның артистның 70 яшьлек юбилеена багышланган сурәте.*

Димәк, ачлык еллары башланганда Фәйзүккә җиде-сигез яшьләр була. Берәүләр раславынча, бу вакытта инде аның Хафиз белән Җаббар исемле энеләре дә туа. Ләкин ул балаларның язмышы тиздән туачак яңа гасырның икенче яртысында яшәгән авылдашларына мәгълүм түгел.

Җирсезлектән интеккән, җир-сулары күрше мукшы, чуашлар тарафыннан даими рәвештә дауланып, кысрыклана барган Иске Тогәлбуга халкының ул ачлык елларын ничек үткәреп җибәрүен күзаллау да кыен. Әйе, көтүлек җирләре юк дәрәҗәсендә, сөрү җирләре кысан. Берәрсендә ир бала туган саен авыл халкына бирелгән ул кысан җирне дә өстәмә имана-өлешләргә тагын бүләргә кирәк була иң. Бик зур авыл, халкы һаман ишләнә, арта тора, ә имана җирләре өлешләре елдан-ел кими,

кичерәя бара. Бу хәл исә еш кына авылдашлар арасында ызгыш-талашларга китерә. Күрше-күләннең яңа туган балага көнләшеп карау очраклары да еш була. Әйе, күлмәксез-ыштансыз ир баланың күршедә тупырдап уйнап йөрүен берәрсе күрсә, сөенәсе урында көенеп:

—Бу ыштансызы да имана дәгъвалап йөгерә, әнә,—дип сукраныр заманнар булган. Авылда ир бала туу ул заманда һәркемне: «Минем җир кишәрлегем кими»,—дигән хафага салган.

Шул ук вакытта һәр туган ир бала ата-анасына зур сөенеч-юаныч китерә, киләчәккә өмет өсти, әлбәттә. Бер-бер артлы ике ул тугач, Кәбир белән Гөлҗамалның да сөенеч-куанычларының чиге булмагандыр. Янәсе, артык кашык кына тумый, өстәмә сөрү-чәчү җирен дәгъвалаучы да туа бит! Әмма ләкин аларның бу өмет-шатлыкларын күк иясе генә ни сәбәпледер күрмәгән, изге догаларын кабул итмәгән икән шул. Авыл, ил өстенә зур афәт җибәргән...

Хак, нәкъ шул заманда, шул елларда Иделнең урта төбәге авылларында котычкыч ачлык башланып китә. Иске Төгәлбуга кебек кысынкылыкта утырган зур авылларда аның афәте бигрәк тә сизелерлек була. Хәллерәк авылдашларына булышкалап көн күргән, тормыш-яшәешен көч-хәл белән очын-очка ялгап килгән ярлырак катлам ул афәттән тәмам гаҗиз калган чак була. Ике-өч елга сузылган корылык, шуның нәтиҗәсе булган ачлык чорында бөтенләй җирсез калучылар да аз булмый. Андыйлар, үз өлеш-иманаларын сатып ашап бетергәннән соң, чит-ят җирләргә китеп, шунда сыену эзли башлый. Кайсыбер сабырсызраклары, мохтаҗлыкка чыдый алмыйча, иманасын гына түгел, иманын сату хәленә җитешә. Чукынып, күрше авылларда сыену эзли башлый. Иске Төгәлбуга тарихында да андый мисаллар бар. Ата-анасы вафат булгач, күрше чуаш авылына китеп, анда яшәп калган унҗиде яшьлек Әхсән язмышы—шундый фаҗигаларның бер үрнәге. Хуҗасы кызына өйләнеп, үз диненнән ваз кичүчеләргә өстәп бирелә торган җир өлеше алып, Карга Куак авылында ул Аксеновлар нәселен нигезләде, дип сөйли авыл картлары.

Кәбир абзый гаиләсе дә ул ачлык елларын бик авыр кичерә. Гаилә ишле, җир аз. Шул аз җирне эшкәртү, чәчү дә катлаулыга әверелә. Чәчүлек җитми, арандагы ике ат та аягында чак басып тора, өшәнгәннәр. Карчыгы үлгәннән соң кече кызы белән генә калган Мокыч баба бер көнне, бәхет эзләп, чуаш авылына күчеп яшәргә ният кыла. Күрше Иске Салаван авылына барып, көтүчелеккә яллана. Бераздан Кәбир абзый да үз гаиләсе белән аларга барып кушыла. Берсе анда сыер-сарык көтүен йөртсә, икенчесе өлешенә чучка көтүе кала. Кәбир абзый чучка көтмәсә дә, авылга кайткан араларда Фәйзүкне «чучка көтә» дип үртәр өчен сәбәп табыла. Шул рәвешле, Фәйзүккә тугыз-ун яшьләреннән рәхимсез мыскыллау сүзләрен ишетеп үсү дә насыйп була. Дөресе, ярлы, мохтаҗ йортта туган һәр авыл малаеның өлешенә нинди авырлык төшә торган булса, Фәйзүк тә андый кыенлыкларны үз башыннан кичерә. Юклык, мохтаҗлыклар белән янәшә үртәлү, кимсенү кичерешләре дә яши, алар котылгысыз. Шул ук вакытта бала чакка гына хас булган барлык сөенеч вә юанычлар да Фәйзүкне читләтеп үтмәгән. Бердән, ул—ата-анасының өлкән, сөекле улы. Ике кыз туганы булу өстенә, тиздән бер-бер артлы ике энесенең тууы да аңа сөенеч, шатлык кына өстәгәндер. Ышанычлы дусларың булу да зур бәхет...

Әмма Иске Салаванда булганда аңа үкенү, кимсенү хисләрен ешрак кичерергә туры килгән. Баштарак ул үз авылына, дуслары янына еш кайткан. Әмма кайткан саен күңеле сүрелә барган. Чөнки Иске Төгәлбуга бала-чагасы, аны күрүгә: «Чәч үстереп килгән монда Фәйзүк атлы чукынган»,—дип такмаклап үчекли торган була. Иске Салаван халкы да аларны үз итәргә, үз арасына кертергә ашыкмый, «килмешәк татарлар»—дип чагарга гына тора. Үз яшенә күрә эрерәк буй-сынлы булган, яшьләр уенына керәсе килгән Фәйзүкне дә, кыз туганнарын да чуаш егет-кызларының өнәп бетермәве үзен еш сиздергән.

Шулай, төрле яктан каргала-тиргәлә, алар бу авылда икеме-өчме җәй яшиләр. Кимсетү, кыерсытулардан тәмам гаҗиз булган Кәбир абзый гаиләсе, Мокыч бабаны җир куенына кую белән үк, бу авылдан китәргә була. Иске Салаванда атасы өлешенә тигән җирне, кирәкмәсрәк йорт-кура әйберләрен калдырып, ялгыз ат җигүле арбага төялеп, Мәләкәс каласына карап юлга чыгалар. Кәбир абзый инде

анда барып, кайларга борын төртәсен алдан ук чамалаган була. Чөнки көтүдән арынып торган араларда ул тик ятмаган, озын кыш айларында якындагы базар тирәсендә олаучы хезмәтен үтәп, байтак кына кеше белән танышкан, аралашкан була.

## Бәхет кошын эләктерү

Кайчандыр Иске Салаваннан аерылып чыккан, урман эченәрәк кереп, Чирмешән янәшәсенә үк сыенган Зур Салаван элек шау-шулы базары белән данлы иде. Кыш айларында Кәбир абзый әнә шул базар кешеләренә үз аты белән хезмәт итеп йөрүчеләрнең берсе булып китә. Базарда кибет тотучы алып-сатар сәүдәгәрләр өчен кирәгрәк була олаучылар. Кәбир абзый да күбрәк вакытта шундый кешеләр белән эш йөртә.

Халык телендә ул сату-алу җирен «урыс атнасы базары» яки «Салаван базары» дип кенә йөрткәннәр. Ул дәвердә бәлки берәр җирдә саф мөселман базары-җомга көн эшләүче базар да булгандыр. «Урыс атнасы базары» таң беленү белән башлана да, төштән соңгарак таралып бетә. Аңа якын-тирә авыл халкы гына түгел, егерме биш-утыз чакрымнардагы Әбдери, Лабит, Төплистан, Пәрау кешеләре дә, гаилә-гаилә булып, ат-арбаларга төялеп киләләр иде. Чөнки монда ашлык белән эре мал-туардан кала барлык кирәк-яракны да сатарга һәм сатып алырга була. Хатын-кыз биредә кемнәрдер бәйләгән әйберләрне, кемнәндер артып калган кием-салымны да, кулдан эшләнгән йөзек, беләзек ише бизәнү әйберен дә таба алган. Хак инде, авылча тормыш-көнкүреш өчен ни-нәрсә кирәксә, барысын да диярлек алып та, сатып та булган. Иләк, чиләк, гөбе, юкәдән үрелгән, агачтан юнып, чокып ясалган, кызыл яки сары балчыктан әмәлләп киптерелгән төрле-төрле савыт-саба—барысы белән дә сату итәләр монда. Бер почмактарак, әнә, үзе ясаган кашык, кәнди, коштабакларын шакылдаткалап, агач әйберләр остасы утыра. Аның күршесендә тимер кыршаулы күәс-камыр тәпәннәрен, төрле зурлыктагы гөбе, кисмәк ишеләрне ясаучы кисмәкче басып тора. Аның «арзанга сатам» дигән сүзләрен тагын да көррәк аваз белән кабатлаучы җәптәше дә якында гына. Монысының алдында ялтыравык ак калай белән бизәлгән эреле-ваклы сандыклар өеме тора. Бала учы чамасындагы кечкенәдән алып, беләк буедай зур чабаталар бәйләмен ике иңенә аскан сакаллы һәм сакалсыз, картузлы вә түбәтәйле юкә «каешы» осталары да халык арасында туктаусыз йөренә. Ара-тирә алар да: «Хан кызлары киярдәй матур чабаталар... патша уллары киярдәйләр...»—дип, үз хезмәт үрнәкләрен мактыйлар. Әйе, монда күпләр үз һөнәр җимешен күккә чөеп мактый-мактый сата. Хуҗалык кирәк-ярагын канәгатьләндерердәй әйберне эзләп тапкан кеше ала. Ата-бабаларыбыз әйтмешли, монда инде кемнәрдер алдый, кемнәрдер алдана. Мыжлап торган халык арасында чын жуликлар да буталып йөри, билгеле. Аларның төп кәсебе—икәү-өчәү берләшеп, затлырак әйбер чәлдерү. Яисә берәр ачык авызын төпсез кесәле итеп калдыру.

Карурман эченә кереп, мул сулы һәм балыкка бай Олы Чирмешән ягасына ук килеп утырган Зур Салаван халкы да урман һәм елга нигъмәтләре белән сату итәргә тәмам остарып беткән. Базарның бер кырыенда фәкать алар гына сәүдә итә торган ике-өч озын киштә-ләүкәләр бар. Авылның уңганнары буйдан-буйга сузылган ул ләүкәләрне һәр якшәмбедә яңа тотылган балык, яңа өзелгән җиләк, бөрлегән, карлыган, шомырт кебек ризыклар белән тутырып куярлар иде. Киштәләргә аркылы сузып салынган аршын буе җәен, беләк буе симез чуртан һәм башка төр балыклар, бармак төртүенә сискәндереп сикергәләп, әлерәк тотылганлыкларын сиздерәләр. Шул ук ләүкәләр янәшәсендә суйган тавык, өем-өем йомырка, йомарлам май, кызыл эремчек, сөт-катык ише көндәлек кирәк-яракны сатып торучы төрле милләт хатын-кызлары да кайнаша. Алар арасында башына алсу-күрән яулык бәйләгән, чуар алъяпкыч япкан, чулпы таккан Иске Тегәлбуга, Иске вә Урта Исәнтимер, Иске Җүрәй кебек якынрак авыл киленнәрен дә очратып булган.

Әйе, заманында бик данлыклы була Зур Салаван авылы базары. Аңа Самара ягы авылларыннан да, хәзер Татарстанның көньяк чик буенда урнашканнарыннан

да, Мәләкәс, Ставрополь (хәзер Тольятти) кебек шәһәрчекләрдән килеп сәүдә итүчеләр дә күп булган.

Авыл картлары сөйләвенчә, Салаванда Мәләкәстән килеп сату итүче кешеләр дә була. Алар, башлыча, базарны каймалап алган ларекларда эш йөрткәннәр. Кәбир абзый кебек олаучылар нәкъ шундыйларга хезмәт иткән. Киләсе базарда сатыласы товарны алар атна арасында ук ташып куя торган булган. Тумышы белән безнең тирәдәге авылларның берсеннән чыккан Алексей Федоров дигән кеше белән Фәйзүкнең атасы аеруча якынлашып китәләр. Ә ул Федоровның Мәләкәстә зур кунак йорты да бар икән. Атлы-арбалы бер-ике дистә кунакны кабул итәрдәй «Постоялый двор» тоткан ул. Шул кеше Кәбир абзый гаиләсен үзенә сыендыра, эш бирә. Яңа урында аларның төп бурычы: ишегалдын тәртиптә тоту, мич-учакны утыннан өзмәү, кирәк-ярак товарны үз вакытында җиренә җиткереп кую, алып кайту була.

Монда күчкән вакытта Фәйзүккә унике-унөч яшь тирәләре булган. Балалыктан чыгып, яшүсмерләр дөньясына аяк басу еллары. Һәр шәхес язмышында үзенчәлекле бер дәвер: дөньяга, тирә-як мохиткә, чынбарлыкка караш көннән—көн үзгәрә, үсә барган бик тә кызыклы бер чор. Һәм нәкъ шундый үсеш, яңарыш дәверендә барлык өмет-хыялларың белән бөтенләй бер үзгә мохиткә—шәһәр мохитенә килеп кер әле син!

Мәләкәс каласы ул вакытта Самара губернасының өяз үзәге санала. Аңа хәзерге Татарстанның көньяк биләмәләре дә керә. Унтугызынчы йөз ахырында Мәләкәс кырык көнлек ашлык ярминкәсе һәм өч зур тегермәне белән данлы санала. Агачтан һәм талчыбыктан өй җиһазы җитештерүче остаханәләр дә эшли. Машина куәте белән хәрәкәткә китерелүче өч тегермәннең берсе татар бае Әбдүш варисларыныкы була. Мулла кушкан исем Габдулладан Абдюшев фамилиясен тудырган бу нәсел шәһәрдә 1917 елгы үзгәрешләр башланганчы үз дәрәҗәсен саклый. Каланың татарлар яшәгән өлешендә мәчет, мәдрәсә эшли. Совет хакимияте вакытында мәдрәсә җирлегендә педтехникум ачыла. (Мәләкәс татар педучилищесы Хрущев фәрманы чыккач ябылды.) Бу мәдрәсәдә узган гасыр башында күренекле тел галимебез Латыйф Җәләй дә белем алган. Шуннан соң ул берничә ел Иске Төгәлбуга янәшәсендәге Иске Җүрәйдә балалар укыта. 1919 еллар тирәсендә кабат Мәләкәскә кайтып, әлеге укытучылар әзерләүче уку йортын нигезләүдә катнаша. Бу калада ул елларда татарча газета да берничә ел чыгып ала...

Атналарга сузылган ярминкә көннәрендә «Постоялый двор»ларда ишек-капкалар һич тә ябылып тормый, билгеле. Кемнәрдер килә, урнаша. Кемдер, гаиләсен арбасына төяп, саубуллашып китеп бара. Үз яшенә караганда буйчанрак, калкурак күренгән Фәйзүк тә эшсез тормый. Ишегалдына чыгып атасына да булыша, кирәккәндә кунакларның йомышын үтәргә дә өлгерә. Йөгереп йөргән күндәм авыл малае, таш каланың ак күмәченә авыз тидереп тамак туйдыргач та дәртләнеп, кушкан йомышларны карусыз үти. Самовар да куя, кунак бүлмәләренә аш-суын да, башка кирәк-яракны да ташып кына тора. Җитез, зирәк һәм күндәм бу кәләпүшле малайны, мөгаен, бик күпләр үз иткән, яраткандыр. Килеп урнашкан беренче кышында ук инде ул тирә-күршедәге малайлар белән дә, кунаклар белән дә дуслашып өлгерә, аралаша башлый.

Ә ул кунаклар арасында ярминкәне бизәп, җанландырып җибәрү өчен Россиянең төрле тарафыннан җыелган һәвәскәр сәхнә әһелләре һәм цирк артистлары да була. Халык күп җыелган җирдә кәмит күрсәтүчеләрсез буламы соң! Алар дөньяны ямьләндереп, күңелләргә рухи азык бирүчеләр ич. Ачлык афәтеннән арынып, тук тормышка йөз тоткан бервакытта аларның кирәклеге бермә-бер арта. Һәркемнең күңеле кәмит катыш җырлы-биюле уеннарга, карусельләргә тартыла.

Фәйзүк тә бөтен күңеле белән шул карусель уенын оештыручыларга, кәмитчеләргә якынрак торырга тырыша. Алар да йомышчы малайны үз итеп өлгерәләр. Чаршау корулы балаганнарына чакырып алгалыйлар, ара-тирә күмәк уенга да катнаштырып җибәргәлиләр. Монда цирк белән эстрада уеннары бергә, алмаш-тилмәшләп башкарыла торган була. Шунда ук җыр, бию, мәзәк сөйләү, акробатик күренешләр бер-бер артлы алышынып тора. Өздереп гармунда уйнаучылар да шул ук балаган артистлары рәтендә йөри.

Фәйзүк баштарак, гади тамашачыга күренмичә, бернича яшүсмер белән бергә эчтән карусель чыгырын әйләндерү хезмәтен башкара. Өстә, мәйданчыкта бәйрәмчә киенгән бала-чага чыр-чу килә, җил куып әйләнә, уйный. Фәйзүкләр, көч түгеп, аларга андый рәхәтне тудыралар. Узган җәйдә генә көтү көтеп көн үткәргән авыл баласының, шулай итеп, күк капусы көннән-көн ачыла бара. Тиздән аңа ачык сәхнәдә күренеп китәрдәй җиңелчәрәк рольләрне дә тапшыра башлыйлар. Шул рәвешле бер-ике сезон үтеп тә китә. Хәзер инде Фәйзүк кунакханәләрнең тар бүлмәләрендә атналап, айлап яшәүче, төрле һөнәргә ия булган балаган артистларының самоварчысы гына түгел, арага кереп китәрдәй һөнәрдәшләренә әйләнә бара. Ярминкә көннәрендәге бәйрәмчә уен карарга килүчеләр аны гадирәк акробатик номер башкаручы сыйфатында да, ярыйсы ук оста итеп, такмаклап русча һәм татарча биюче буларак та күрергә күнегәләр. Аның биографиясе белән таныш кешеләр: «Фәйзүкнең беренче артистлык адымы—баш очына самоварлы поднос куеп, русча бию була»,—дип язалар.

Билгеле, артист халкы Постоялый двор бүлмәләренә хәл җыярга кайткач та тик кенә ятмый. Берише биюнең яңа алымнарын үзләштерә, икенчеләре җырлый, мәзәк сөйли, уен коралларында уйнаучылар яңа көй өйрәнә яки элекке көен камилләштерергә тырыша. Шул исәптән гармунчылар да үз уеннарын камилләштерү белән мәшгуль. Биючегә дә, җырчыга да, фокус күрсәтүчегә дә гармунчының булышып, уен тембрын үзгәртә-үзгәртә уйнап торуы кирәк ләбаса. Ял вакытларында алар да, бер-берсе белән тәңгәл килеп, бербөтен образ тудыру өстендә эшлиләр. Шул сәбәпле ярминкә көннәрендә постоялый дворда һәрчак гармун чыңлавы яки моңлы бер көй уйналуы тынып тормый диярлек. Хәер, гармунны фәкать эч пошудан шыңгырдатып утыру очраклары да булгалый.

Гармунчыларның уйнауларына кызыгып карап торган әлеге кәләпүшле малайга да ара-тирә шул гармун сәдәфләренә баскалап алырга рөхсәт иткәләүчеләр була, әлбәттә. Тора-бара бик теләп үз һөнәрләренә өйрәтергә теләүчеләре дә табыла. Бу тормышта бит башкаларга карата хәерхаһ, ярдәмгә килергә әзер торучылар да еш очрый. Шулай булмаса, кешелек дөньясы яши дә алмас иде.

Фәйзүк зирәк шәкерт булып чыга. Көй-моңнарны да, аларны күңелгә ятышлы итеп уйнау рәвешләрен дә тиз отып ала. Озакламыйча инде ул өйрәтүчеләренә ияреп, иш-җәптәш булып уйнардай дәрәҗәгә җитешә. Өстәвенә әле аның җирле халык күңелен җилкендереп татарча һәм чуашча көйли алу сәләте дә ачыла.

—Ну, Фәйзүк, сиңа балаганнан һич аерыласы түгел,—дип, аны балаган хуҗалары башка шәһәрләргә үзләре белән гастрольләргә димли башлыйлар.

Оста гармунчы даны әнә шулай бөреләнергә керешә. Иске Төгәлбуга авылының ярлы Мокыч баба ызбасында туып-үскән яшүсмер Фәйзүкне, шулай итеп, Мәләкәс Постоялый дворында үзләштерә башлаган һөнәр-кәсебе олы дөньяга алып кереп китә. Очраклы бер хәл: Кәбир абзыйның мохтаҗлыктан качып, шул заман кунакханәсенә эшкә килеп урнашуы—улының киләчәк бәхетле язмышының тәүге терәге, этәргече була. Шул очраклы вакыйга Фәйзүкне тиздән олы сәнгать дөньясына алып чыга. Икенче бер очраклылык—Россия күләмендә танылган виртуоз гармунчы Уткинның нәкъ шул елларда Мәләкәскә килеп чыгуыдыр. Соңыннан Фәйзулла ага Туишев гомере буена шул остага рәхмәтле булуын белдерәчәк. Әйе, юклык, ачлык нәтиҗәсендә тук тормыш эзләп Мәләкәс каласына килеп эләккән татар гаиләсе гомердә көтелмәгән бәхетле язмышка дучар була.

Хак инде, армый-талмый эшләргә, хезмәт итәргә гадәтләнгән авыл баласы, ташны ярып чыккан язгы үлән кебек, әнә шулай һаман да яктыга һәм яхшыга омтыла бара.

Фәйзулла аганы язмыш туган авылыннан кумыйча, шул Иске Төгәлбугасында калдырган булса, ул кем булыр иде икән? Әтисе Кәбир абзый кебек бер олы җанлы гаилә башлыгы, имана җирен үз вакытында чәчеп-урып, төпле генә тормыш алып баручымы? Тырышлыгы, зирәклеге һәм яшьлегендә күргән-татыган мохтаҗлыклар аны авылдашлары арасында тырыш хуҗа буларак танытмый калмас иде, әлбәттә.

Атасының зирәк акылын, гайрәт-куәтен, эзләнүчәнлеген исәпкә алганда, Фәйзүк тә, һичшиксез, үз мохитендә танылганрак авыл кешесе—мәчет куштаны, җыен

активисты ише, үз фикере белән абруй казанганрак кеше булыр иде, мөгаен.

Дөрес, заманасына, чорына күрә Кәбир абзый да коеп куйган мәчет карты да, фәрештә дә түгел-түгелен. Аның да холкының кырысрак чаклары еш булгалап торгандыр. Үз даирәсе таләп иткәнчә, динен дә тоткандыр. Балаларының бозык юлга басуыннан куркудан, аларга карата кайчак кырысрак та кылангандыр, Фәйзүгең дә баштарак төрле ят уеннардан һәм ят уен коралында уйнаудан тыярга тырышкандыр. Ф. Хөсни «Гармунчы» документаль повестенда аны шулайрак итеп күрсәтә. Фәйзүкнең үз хезмәтенә алган беренче гармунын да атасы таптап изә, диелә ул әсәрдә. Ләкин авылдашлары башкачарак фикердә. Унбиш яшьләрдәге Фәйзүкнең гармунга чын-чынлап мөкиббән булуын аңлаганнан соң, улының ул уен коралында уйный алуына ышангач, Кәбир абзый беренче гармунны аңа үзе сатып ала, дип сөйли безнең авыл кешеләре.

Әйе, Фатих Хөснинең повестенда атаны артык диндар, томана итеп күрсәтергә тырышуын замана чире дип карарга кирәктер. Әсәр бит утызынчы елларда, динне каһәрләгән чорда иҗат ителгән. Әсәрдәге Кәбир абзый образы чынбарлыкка туры килми. Чөнки андый диндар кеше гаиләсен ачлыктан йолып калу өчен булса да башка диндәге күрше авыл халкына барып баш иярргә курыккан булыр иде. Кәбир абзый исә шуның киресен эшли. Атасы, Мокыч карт сүзенә буйсынып, чуаш авылына барып көтүчелеккә яллана. Шул рәвешле ишле гаиләсе белән авыр ачлык елларын уздырып җибәрә ала. Иске Салаванда да, Мәләкәс каласында да ул гади батрак кына түгел, үз кул көче белән көн күрергә омтылучы хуҗа буларак күзаллана. Көтү көтүдән бушаган айларда ул үз аты белән олаучы хезмәтен дә башкара. Мәләкәстә дә тик кенә, Постоялый двордан килгән ризыкны ашап кына ятмый. Базар-ярминкәләр булмыйчарак торган мәлләрдә Әбдүш тегерменәнә йөк ташый. Шул рәвешле, ике-өч йөкне тарта-тарта ул, озакламыйча үзе дә бер кешенең Постоялый дворын сатып ала, үз эшен башлап җибәрә. Мөселманнар өчен үз кунакханәсен ача.

## Сәяхәтләр, юллар...

Кәбир абзый үз кунак өенә хуҗа булу көннәренә ирешкәндә аның зур улы, беренче ярдәмчесе Мәләкәстән еракта була инде. Фәйзүк баштарак, уналты-унҗиде яшьләрендә, биюче һәм төрле мәзәк кыланышлар башкаручы сыйфатында Казаннан килгән төркем белән үзләрендәге уеннарда катнаша. Балаган җитәкчесе Анна Казаграндега аның чыгышлары ошый һәм ярминкә ябылгач та ул хатын аны үзләре белән алып китә. Казанда бастырылган яңа, матур афишаларда аның исеме дә «виртуоз артист Фәйзук Туишев» буларак беренче мәртәбә теркәлә. Шушы көннән соң «Туишев» аның псевдонимы булып китә, соңрак фамилиягә әверелә.

Алар төркеме Казанда бер кыш дәвамында эшли. Фәйзүк сәхнәгә күбрәк вакытта рус яшьләре кыяфәтендә чыгып бии, гармунда рус көйләрен уйный. Баш очына самовар беркетеп биюдә аеруча осталык күрсәтә. Шул сәбәпле бервакыт аны татар яшьләре урамда тукмап та китәләр. Яз башында бу төркем кабат Мәләкәс каласына юл тота. Шул ук вакытта монда Сембер каласыннан килгән цирк артистлары төркеме дә эшли. Ярминкә сезоны беткәч Фәйзүк икенче гастрольга шушы цирк төркеме белән чыгып китә. Алар биеп-җырлап, цирк тамашалары күрсәтеп, Идел буе шәһәрләрен гизеп чыгалар.

Шушы гастроль вакытында булса кирәк, Сембердә торып эшләгән бер вакытта, алар төркеме арендалаган цирк бинасы һәм күпчелек җиһазлары янып көл була. Күпмедер вакыт тулы хезмәт хакы алмыйча эшләгән артистлар акчасыз калалар. Төркем җитәкчеләре шәһәрдән чыгып кача. Иң авыр хәлдә калучылар арасында яшь артист Фәйзулла Туишев та була. Ачы язмышка дучар ителгән артистны фәкать кулында калган гармуны гына коткара. Шушы вакыйгадан соң инде ул кечерәк кенә үз төркемен оештыра, ил куләмендә дан, шөһрәт биеклегенә илтүче туры сукмагына юл яра.

Егерме ике яшендә, Сембердә цирк труппасы белән булган вакыйганың көзендә, Фәйзулла Туишев хәрби хезмәткә каралыр өчен дип туган авылына кайта. Иске Төгәлбугадан чыгып китүенә сигез-тугыз еллап вакыт үткән була. Ул заманда

кабул ителгән тәртип таләп иткәнчә, хәрби комиссиядә каралырга тиешле һәркем туган җиренә кайткан. Чордашлары хәтерләвенчә, Фәйзук авылга 1906 елның көзендә кайта. «Авыл писарьлары кебек киенгән иде»,—дип сөйлиләр. Өстендә затлы көзге пальто, аягында ялтырап торган күн итекләр була. Иңендә зур гармун иде, дип истә калдырганнар. Ул вакытта безнең төбәк авыллары некрутларын Иске Төгәлбугадан егерме биш чакрым көньяктарак урнашкан Зирекле Куак авылында комиссия аша үткәрә торган булалар. (Бу татар авылы рәсми документларда Елховый Куст аталып йөргәнлектән, артистның биографияләрендә дә шулай теркәлгән.) Өяз каласы Самарадан килгән рус офицерлары Фәйзулла Туишевны үзләре белән алып китә һәм күпмедер вакыт үткәч кенә «хәрби хезмәткә яраксыз» дип иреккә җибәрәләр. Ә Мөхәммәтша, Шәфигуллалар, солдат шинеле киеп, хезмәт итәргә калалар. Алар Фәйзук кордашлары белән кабат фәкать ике зур сугыш һәм 1921 елгы ачлык вакыйгаларын кичергәч кенә кавыша алалар. Бу еллар арасында Фәйзулла Туишев үзе туплаган артистлар төркеме белән Россиянең барлык төбәкләрендә гастрольләрдә йөри. Халык мәхәббәтен яулый.

Театр артисты Локман Аитов «Артист язмалары» китабында Фәйзулла Туишев белән Түбән Новгород шәһәрендә очрашуын түбәндәгечәрәк тасвир итә. 1909 елның җәе, ярминкә көннәре. «Шул көннәрдә Фәйзулла Туишев концертлары да барды. Аның белән дә таныштым. Безнең халыктан да шундый гармунчы чыгар икән дип, тәмам хәйран калдым. Чөнки мин бу көнгә кадәр Пермьдә гастрольгә килгән рус уенчыларыннан мәшһүр Петр Невскийны гына күргәнем бар иде. Фәйзулла Туишевның рус көйләреннән башка татар халык көйләрен дә кечкенә гармуннарда зур осталык белән уйнавы, шуның өстенә тагы үзе уйнап, үзе биеп җибәрүләре сокландыргыч булды»,—дип язды.

Казан милли музеенда Фәйзулла Туишев архивының бер өлеше һәм гармуннары саклана. Анда төрле елларга караган афишалар, концерт программалары да бар. Менә 1914 елның 17 апреленә караган бер программа. Ул рус һәм татар телләрендә аерым-аерым басылган. Анда Казан сәүдәгәрләре бинасының залында Фәйзулла Туишев катнашында концерт һәм спектакль буласы бәян ителә. Кичәнең администраторы Ш.Әбдиев диелгән. Бер пәрдәлек спектакльдә катнашучы Вәлишин, Исмәгыйлов, Ибраһимов, Саттаровлар янәшәсендә дә Әбдиев фамилиясе күрсәтелгән.

Озакламыйча башланган Беренче Бөтендөнья сугышы көннәрендә Ф.Туишевның Оренбургта, Мәскәүдә, Петербургта гастрольләрдә булуы мәгълүм. Бу көннәрдә «Ил» газетасында аңа багышлап мәкалә басылуы хакында да хәбәрләр бар.

Гражданннар сугышы тәмамланганнан соң артист Казанга кайтып төпләнә. Татарстанның халык артисты Хәким ага Сәлимҗанов гармунчының Совет Татарстанында оештырылган беренче концертын яхшы хәтерли. Бу концерт Фәйзулла Туишевның Себер белән Ерак Көнчыгыш гастрольләреннән соң Татарстанга 1923 елда бөтенләйгә кайтуыннан соң уздырыла. «Кабатланмас якты талант, чын мәгънәсендә профессиональ музыкант иде Фәйзулла ага Туишев. Аның репертуары гаять бай иде. Менә ул, берара чит җирләрдә йөреп, ниһаять сөекле, моңлы Казанына кайтты,—дип башлый ул аңа багышланган истәлеген.— Татар көйләреннән бигрәк тә «Ончы Фәхри» белән «Әллүки»не тирән эчке бер хис белән башкарды. Тамаша залы гөр килде».

Гармунда гаҗәеп оста уйнаучы гармунчының бөтен хәрәкәт-халәтен бик төгәл тасвир иткән ул истәлеккә инде ни дә булса өстәп тә, шуннан арттырып сөйләп тә булмастыр. Хәким ага Сәлимҗанов татар тамашачысының һәм, гомумән, татар халкының гармунчыга карата булган ихтирамын һәм мәхәббәтен бик тулы чагылдыра, минемчә. Фәйзулла Туишев концертлары, кайларда гына оештырылмасын, тамашачының ялкынланып кул чабулары белән ачылып китеп, аягүрә басып, артистны озаклап алкышлаулар белән тәмамланган. Сөйгән халкы аны һәркайда яратып кабул иткән, «Туишев, афәрин!», «Туишевка озын гомер!» дип кычкыра торган булган. Халыкның дәррәү хуплавын күреп торган кайбер шикләнүчәнрәк түрәләр дә сабырлык күрсәтергә, мәшһүр артистның элекке сәяси хаталарына күз йомарга булалар.

Казанга кайткач, артист үзедәй оста гармунчылар әзерләргә кирәклеген дә онытмый. Милли музей архивында аның яшь музыкантлар белән дәрес уздыру

вакытын чагылдырган бер фоторәсем дә сакланган.

Ерак Владивосток, Харбин якларында озаклап йөргәннән соң артист туган җирен, туган төбәген дә бик сагынып кайта. 1923—1939 елларда ул Иске Тегәлбугада гадәттәгедән ешрак була. Артист буларак, тәүге тапкыр туган авылына концерт куярга кайткан елны чордашлары төгәл хәтерләми хәзер. «Ачлыктан соңгы ел иде»,—дип кенә искә алалар. Әле Иске Тегәлбугада клуб булмый. Шәкертләрдән бушаган бер иркенрәк бинада—уку йортында концерт куела. Аның ул вакыттагы мөдире—«избачы» Нәкытдин бабай Миңлебаев җитмешенче елларда исән иде әле. Үзе дә авылның бер дигән җырчысы булган, «Сандугач Нәкый» кушаматын йөрткән карт гармунчының ул вакытта авылга кайту күренешен болайрак тасвир иткән иде. «Фәйзүк абыйның уйнавын карарга, тыңларга дип килгән кеше мәчет янәшәсендәге ул ызбага сыешып бетмәде. «Иртәгә дә килеп уйна», дип күндердек үзен. Ике-өч көн шунда ялыкмыйча уйнады».

Берничә көннән соң авылдашларын озатырга дип Курай урамына килгән халык:

—Адә, тагын кайт, Фәйзүк, шулай уйнап безне тагын сөендер!—дип, матур теләкләр теләп калалар.

Шуннан соң ул авылга тагын берничә мәртәбә кайта. Ул вакытта әле Бәнат җиңгәсе дә, аның улы Шәмси дә исән-сау. Артист һәр кайтуында үзе туып-үскән өенә төшә, Бәнат тәчиендә кунак була. Бары тик 1939 елда гына авыл түрәләре Ләлә ханым белән икесен зурлабрак каршы алырга ниятлиләр. Авылның күренекле кешесе—«ЦИКа Гаян» өенә урнаштыралар. Аның өе пөхтә, зур була. Гаян апа Сәгъдиева егерменче еллар ахырларыннан авылның иң дәрәҗәле кешеләреннән санала иде. Самара өлкәсеннән Бөтенсоюз Үзәк Башкарма комитетына сайланган, мәшһүр Калинин баба белән бер өстәл артына утырып, ил язмышын хәл итешүдә дә катнашкан хатын ул. Ләлә ханым белән уртак сүз таба алыр, дип тә уйлагандыр колхоз рәисе Имам Мостаев. Гаян апа өенә клуб та, авыл идарәсе йортлары да бик якын, күршедә генә диярлек. Димәк, кунакларга авыл буйлап йөрисе дә түгел.

Фәйзулла Туишев бу кайтуында элекке мәчет бинасында ике көн рәттән төрле гармуннарда, төрле көйләр уйнады, авылдашларының күңелен күрде. Әйе, ул вакытта инде иң зур мәчет клубка әверелгән иде. Фәкать түр башының урамнан беркадәр эчкә кереп, кыйблага йөз тотуыннан гына аның элекке мәчет икәнлеген чамалап була. Тамашачылар «партер» эскәмияләрендә генә түгел, залның өчтән бер өлешенә чыгып торган киң балконына да шыплап тулган иде. Иде дим, чөнки авызны ачып, шул балкон киртәсеннән сәхнәдәге тамашаны йотлыгып күзәтүчеләр арасында үзем дә бар идем. Әйе, байтак кеше клубка балаларын да алып килгән—ил күләмендә танылган артистны, авылдашын күреп калсын. Авылдан кем чыкканын белеп торсын дигәннәрдер. Көндезге һәм кичке концертларга олау-олау төялеп күрше авыл кешеләре дә килгән иде. Бала-чаганы кызыктырып, мәчет каршында яңарак бер полуторка машинасы да тора. Димәк, кайдандыр еractан аңа да төялеп килгәннәр. Тамашачылар арасында, элекке мәчетнең бер почмагында бөрмә билле аксыл тунлы чуаш хатын-кызлары һәм ир-егетләре дә күренә. Димәк, Иске Салаван кешеләре дә көтүче Фәйзүкнең концертын күрергә һәм тыңларга дип килгән. Алар да, мөгаен, Фәйзулла абыйның уенын йотылып тыңлаган хәлдә, кайчандыр арабызга кертмәскә тырышып йөргән Фәйзүк шушымы соң?.. Әйе, шулдыр. Югыйсә безнең чуаш көйләрен бу кадәр оста уйный алмас иде, дип сокланып торалар иде шикелле.

Шушы кайту—Фәйзулла абыйның туган-үскән авылына соңгы мәртәбә аяк басуы булган икән. Шул елның көзендә үк финнар белән сугыш башланып китүе, аңа ялганып ук диярлек Бөек Ватан сугышының башлануы аны туган иленнән ераклата. Ә сугыш белән бергә катлаулы авырулар һәм картлык көннәре килә. Авыр сугыш елларында артистның Бәнат җиңгәсе вафат була. Ике энесе—Сәхаб белән Шәмсетдин ерак яу кырында ятып калалар.

Соңгы елларында иленә кайта алмаса да, Иске Тегәлбуга халкы бер дә онытмый үз улын, үз авылының мактанычы саналган бөек артист Фәйзулла ага Туишевны. Татарстан халкы да Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевны һич онытмый. Дистә елга якын инде Казан каласында Фәйзулла Туишев исемендәге мактаулы дәрәҗәгә ирешү өчен төрле төбәкләрдән килгән гармунчылар арасында ярышлар уздырыла. Шундый дәрәҗәле исемгә лаек булучылар арасында мәшһүр

артистның якташы Рөстәм Вәлиев тә бар. Күптәннән инде Татарстанның халык артисты исемен дә алган икенче бер виртуоз гармунчыбыз. Әйе, гәрчә ул Казанга Самара аша урап килсә дә, төп чыгышы буенча Иске Тегәлбуга даирәсенә кергән авылларның берсе саналган Төплистаннан була. Рөстәмнең ата-анасы шул авылдан. Үзенең дә бала чагы шул җирлектә, әби-баба карамагында уза. Рөстәм татар моңын күңеленә Фәйзулла агасын тудырган туфрактан ала.

Фәйзулла Кәбир улы Туишев оста музыкант-башкаручы гына түгел, көйләр тудыручы да. Аның яшьлек елларында иҗат иткән төрле сюита, экспромтлары нотага салынмаган, ил буйлап гастрольләрдә йөргәндә таралып, югалып беткәннәр. Ә инде Казанда төпләнеп яшәү елларында иҗат иткән утызлап җыры һәм башка төр музыкаль әсәрләре аны композитор буларак та таныта. Аның тарафыннан музыкальләштерелгән җырлардан байтагын халкыбыз яратып кабул иткән. Әйтик, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Халкыма», Сәхаб Урайский шигыренә нигезләнеп иҗат ителгән «Төзелештә», Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язылган «Дустыма» җырлары элегрәк елларда радиодан да бик еш тапшырыла иде.

Халык сүзләренә таянып музыкальләштерелгән «Кукмара» җыры да һаман онытылмый. Болардан тыш Фәйзулла Туишев Гадел Кутуй истәлегенә багышлап марш һәм кыллы квартет өчен «Пионерлар сюитасын» (соңгысын М.Юдин белән бергә) иҗат итә.

1930 елларда Фәйзулла Туишев Казанда гармун фабрикасын ачуда башлап йөрүчеләрдән була. Һәм 1933 елдан фабриканың техник советында баштарак баш белгеч, соңрак консультант вазифаларын башкара.

1944 елның февралендә Фәйзулла Туишевка Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә. Моннан тыш аның башка бүләкләре һәм орденнары да бар, әлбәттә. Әмма иң зур бүләк—халкы күңелендә сакланган олы ихтирам, билгеле. Берданбер үкенеч—соңгы елларда мәшһүр гармунчының уены радиотапшыруларда бик сирәк яңгырый. Бәлкем инде концертлардан язып алынган язмалар да юкка чыккандыр. Соңгы дистә елда безнең радиотапшырулар оешмасында андый югалтулар булгалады бит.

Әле күптән түгел матбугатта бер сөенечле хәбәр урнаштырылган иде. Ленинград шәһәрендә яшәп вафат булган күренекле рәссам Фәйзерахман Әминев гаиләсе Казан музеена Фәйзулла Туишев язмаларыннан унбер пластинка тапшыра. Димәк, Туишевның үзенчәлекле итеп уйнау үрнәкләре әле кая да булса сакланган булырга мөмкин, дигән өмет тә бар. Ә Габдулла Тукай музеенда (Казан, Г. Тукай урамы) мәшһүр артистның төрле тавышлы, төрле рәвешле егерме концерт гармуны һәм концерт киемнәре күргәзмәгә куелган. Алар белән һәркем таныша, гармунда моң чыгара белүче тотып карый ала. Белгән кешеләр артист кулында иллеләп шундый гармун булган дип язалар. Аларның бер өлеше Милли музей архивында сакланадыр.

*1972—2007 еллар.*

**Искәрмә:** *Ф. Туишевка мөнәсәбәтле фотолар Милли музей архивыннан алып кулланылды.*

# НИЯТ ГАМӘЛНЕҢ БАШЫ

Президент Минтимер Шәймиев әмере белән 2007 ел Татарстанда Хәйрия елы дип игълан ителде. Әлбәттә, бу әмерне тыныч кына эшкә кулланма итеп алырга да мөмкин булгандыр. Әмма һәрбер ният уйлыларны уйлату өчен бер этәргеч ул. Чөнки игелек темасы борын-борыннан фәлсәфи бәхәсләр үзәгендә булган. Ахыр килеп, борынгыдан бүгенгәчә булган гакылияләре чылбыры бу төшенчәне кемнең кемлеген бәяләү үлчәме итеп кабул иткән. Изге китап Коръән-кәримдә исә иң мөһим аятьләрнең берсе итеп шушысы—изге гамәлләр кылуда үзара ярышыгыз! дигәне куелган.




Минтимер Шәрип улы Шәймиев тә бер елда башкарылган изге гамәлләр соңында барыбыз да кинәт кенә әүлия булып китәрбез дигән максатны куймый. Ул аны гап-гади генә аңлата: «Игелек кылган кеше алдагы елны мөгаен үз-үзеннән канәгатьлек тойгысы кичереп каршылар. Кем дә кем игелекле кешенең ярдәмен тойган, ул инде, һичшиксез, дөньяга якты өмет белән карый башлар, кешеләргә карата мөнәсәбәтен үзгәртер»,—ди.

Ният бурычка әйләнүгә игелекле гамәл кылырга җиң сызганып торган эшмәкәрләр һәм гап-гади яхшы күнелле кешеләр көн яктысына чыкты. «Көн яктысы» дип ассызыклауның хикмәте шунда ки, күнелен игелеккә бер көйләп куйган кеше андый гамәлне инде махсус әмерне көтеп тормастан башкара килгән. Форсат туып торганга күрә бу язмада шундый игелек ияләренең берсен—'Татэнерго» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Илшат Шәех улы Фәрдиевне нур көлтәсенә алабыз. Татарстанның халык депутаты, Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты дәрәҗәләрен йөрткән бу кешенең күнел нечкәртергә вакыты да юк сыман. Әмма ул бихисап җитди эшләре арасында иганәчелекне, юксылның хәлен белүне бөтен җитди эшләреннән дә өстенрәк күрә кебек. Минем кулыма «Татэнерго» ачык акционерлык җәмгыяте соңгы ике ел дәвамында эшләгән игелекле гамәлләр исемлеге килеп керде. Мин бу исемлектә «Татэнерго»дан иганә рәхәте күргән илле объектны санадым. Объект дип, телгә ят сүз белән атасам да, илле саны артында йөзләгән кеше язмышы тора. Болар хәлгә керүне тансыклаган, аз гына миһербанлы карашка да гөлдәй тартылган ятимнәр, гариплэр, мәхрүмнәр.

«2007 елны Хәйрия елы дип игълан итү «Татэнерго» коллективының игелекле эшләр ритмын акрынайтмады да, тизләтмәде дә... Без моңа кадәр дә әхлак кануннарына таянып яшәдек һәм эшләдек, алга таба да ятимнәр, юксыллар, мәхрүмнәр өлешен кысмабыз»,—дип белдергән иде генераль директор. Дөрестән дә, Минзәлә һәм Зәй балалар йортлары җылы кулның олы ярдәмен ун еллап тоеп яши. «Татэнерго»дан килгән кыш бабай күчтәнәчләренә инде алар ияләшеп беткән. «Татэнерго» иганәчелек иткән оешмаларның байтагы балаларны һәм яшүсмерләрне савыктыру, «Дзюдо федерациясе» кебек спорт тәрбиясе бирү үзәкләрен, «Мизгел» иҗат үзәген, «Сәйяр» хәйрия фондын, «Әкият» курчак театрын, «Шаһбан» иҗат студиясен—тагын бик күп иҗат һәм спорт мәктәпләрен санаган исемлектә Актанышта, Түбән Камада төзелгән мәчетләрне, Ютазы, Түбән Кама

мөхтәсибәтләренә, Раифа ирләр монастырена саллы ярдәмне күрәм.

Татарстан энергетиклары адресына рәхмәт хисе белән сугарылган хатлар гел килеп тора. «Миһербан һәм шәфкать кебек сыйфатлары калку кешеләр генә гарипләргә ярдәм итеп, аларны бу тормышта яшәтеп кала, хәлен жиңеләйтеп тора. Сез нәкъ менә шундый кеше»,—дип яза Ютазы инвалидлар җәмгыяте рәисе Олег Соловьев. «Татэнерго»ның тармак житәкчеләре арасында, Илшат Фәрдиев кебек, «Алтын йөрәкле кеше» титулына лаек булучылар тагын да бар.



Ярдәмне ничек күрсәтәсен бит аны. Юксыл кулына бирелгән акча, ятим кулына сонылган курчак, инвалидка тәкъдим ителгән арба, ял итү яки дәвалану өчен юлламалар, хәтта төзеп куелган мәчет, мәдәният йорты биналары гына да түгел әле ул. Ярдәмнең иң олысы, саваплысы—кешенең үзенә көн итәрлек табыш китерердәй, күнелен юатырдай, рухын үстерердәй хезмәт белән тәэмин итү. «Без сезнең заказларны дәртләнеп үтибез. Эшләү мөмкинлеге тудырган өчен сезгә зур рәхмәт»,—дип язалар Әлмәттәге җәмгыяви тернәкләндерү предприятиесендә эшләүче чукраклар. Рәхмәт хатлары сукырлар җәмгыятеннән дә, өйдә эшләүче инвалидлардан да, хәтта авырулары кырыс күзәтүгә алынган Казан психиатрия хастаханәсеннән дә килеп тора. Теләк булганда җаны сырхауларны савыктыруга да өлеш кертү мөмкин икән. Ә нигә—файда ике яклы бит. Бер елда гына да республика инвалидлары энергетикларга дүрт миллион сумлык бияләйләр, эш киемнәре теккән. Шул арада хезмәт дигән олуг табиб ничә кешене тернәкләндереп өлгергәндер әле.

Илшат Фәрдиевнең якташы Ләбиб Леронның да өметтә йөргән көне. Аның өмете җанны тетрәндерерлек дәрәҗәдә гади—16 яшькә житкән, бәхет юрап Бәхтияр исеме кушылган улының «әти!-әни!» сүзләрен ишетү! Моның өчен буе житкән, акылы сабый калган малайны 56 нчы санлы тернәкләндерү мәктәбенә көн дә йөртү кирәк. Илшат Фәрдиев Бәхтиярның хәлен жиңеләйтү, «әни» сүзенә юлны кыскарту әмәлен тапкан. Моңа кадәр автоузышларны телевизордан гына талпынып күзәткән малай хәзер А-369-ОТ номерлы машинаны әллә кайдан танып тора.

Түбән Камада яшәүче дүрт яшьлек Айлин Мәхмүтова исә Илшат абыйсына рәхмәт әйтергә үзе килер. Үсә төшкәч, әлбәттә. Тумыштан зирәк бу бала, әгәр «Татэнерго» җәмгыяте каршында аның кебек мәхрүмнәргә ярдәм итү өчен «Кайгырту» фонды оештырылмаган булса, мөгаен, гомерен инвалид арбасында утырып үткәрер иде. Йөзләрчә меңгә төшкән операцияләр кызга «аяк» китерде. Әле унсигез яшькә кадәр—кыз үскән саен—алыштырыласы ортопедия аппаратларының түгәрәк бәясе дә хәзер инде кызның әнисен куркытмый.

Бу санаганнарым игелекле гамәлләр дисбесендә аерым төймәләр генә. Чараларның бүтәннәргә үрнәк, матур гыйбрәт булырлык итеп эшләнгәннәре дә бар. Әйтик, Түбән Кама драма театры бинасында уздырылган ярминкә шундыйлар рәтендә. Анда җыелган халык күргәзмәгә куелган әйберләрне җыелган акчаның балалар санаториена адресланачагын белгәнгә күрә бик теләп алды.

Әгәренки акционерлык оешмасының җитәкчесе, чит-ятларга карата бик юмарт, миһербанлы булып та, үз хезмәт иясләрен онытса, килештермәс идек. Әмма без Энергохолдинг пенсионерларының ай саен матди ярдәм алып торуларын, 2006 елда гына да эшчеләргә 174 миллион сумлык җәмгыяви түләүләр күрсәтелүен беләбез. Теге миллионнарның ундүрт миллионга якыны аларга тәгаенләнгән ләбаса.

Энергетикларның нинди шартларда ял иткәнен күргән кешенең күзе шар

булырлык. 160 урынлы «Балкыш» санаторий-профилакторие вакыт-вакыт иҗат кешеләрен дә үзенә кунак итеп дәшеп ала. 2007 елны мин үзем дә шундый бәхетле кунак булу рәхәтен татып карадым. Гыйнвар аенда зәңгәр сулы бассейнда йөзүнең, андагы табибларның шәфкатьле мөнәсәбәтен тоюның ни ләззәт икәнен беләм димәкче булам. «Татэнерго» системасында эшләүчеләрнең сәламәтлеге турында кайгырту моның белән генә бетми әле. Дөресрәге, кайгырту хезмәткәрләрнең балалары турында кайгыртудан ук башлана. «Дуслык», «Прометей», «Бөркеткәй», «Энергетик» савыктыру лагерьларын, Кара дингез буендагы ял базаларын искәртүем.

«Татэнерго»ның генераль директоры Илшат Шәех улы Фәрдиев турында сүз чыктымы, кешеләр ашыга-ашыга аның холык сыйфатларын, игътибарлы мөнәсәбәтен дәлилләүче мисалларны санарга тотыналар. Камал театры директоры Шамил Закиров белән соңгы сөйләшүемдә дә сүз гел шул тирәдә барды. «Ә бит театрда ел саен «Яңа татар пьесасы» конкурсы уздырылып тору да безнең казаныш түгел, Илшат Шәех улыныкы,—диде ул.—Без сүлпәнләнә төшсәк, ул безне ашыктыра башлый: «Сезнең артистларыгыз миңа берәм-берәм мөрәҗәгать итәләр. Миңа исә сезнең бөтенегезгә берьюлы ярдәм итү кулайрак»,—ди ул. Бу конкурс уңаеннан гына түгел, һәрбер ерак гастролебезгә яшел ут ачучыларның да берсе Фәрдиев». Шамил Зиннур улының тагын-тагын мисаллары бар. Тынлар идем мин аларны, әмма берочтан Илшат Фәрдиев белән үз очрашуларымны да искә төшереп үтәсем килә.



**Беренчесе.** 1998 елны Әлмәттә булган иде анысы. Бөек мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдин музей йортын һәм аның исемендәге мәчетне ачкан вакытта Әлмәтнең яңа хакиме сыйфатында язучы халкын кабул иткән иде ул. Музейны да, мәчетне дә ачу өчен күп тырышлык куйса да, тыйнак кына күләгәдә кала белүе белән әдипләрнең күңелен әсир иткән иде. Хакимнәрнең төрлесен күргән юлдашларымның берсе—Гариф Ахунов әйткән мәгънәле сүзләр хәтердә калган: «Гаҗәп зыялы, әдәпле бу кеше әле тагын бик күп матур эзләр калдырыр»,—дигән иде ул. Юраганы юш килде ләса.

**Икенче очрашу.** Анысы, быел февраль аенда Ютазы районында «Фәнис мәдрәсәсе»н ачканда булды. Бу эчтәлекле һәм истәлекле вакыйганы Ютазы халкы озак онытмас әле. Чөнки бу гади бер гамәл генә түгел, бәлки дуслыкка һәйкәл, әйткән сүзгә тугрылык символы да иде. Мәдрәсә исеме бирелгән Фәнис Кәримов шактый вакыт «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең режим һәм иминлек идарәсе җитәкчесе булып эшләп, Ингушетиядә хезмәт вазифасын үтәгәндә һәлак булган. Бу ике егетне хезмәт вазифалары гына түгел, дуслык бәйләнешләре да бәйләп торткан. Хәзер инде Фәнис Кәримовның якты истәлеге белем йорты рәвешен алган, ә дөньялыкта олы эшләр башкару өчен тәгаенләнгән дусты аның ике баласын кайгыртып тору кадәресен өстенә йөкләгән.

Физикада атом хәрәкәте турында дәреслекләрдән үк таныш бер тәгълимат бар. Ул чылбырлы реакция дип атала. Бильярд уйнарга яратучылар да бу чылбырлы реакцияне яхшы күз алдына китерер. Бер шар икенчесенә бәрелсә, теге икесе тагын өчне, дүртне кузгатырга мөмкин. Игелекле гамәл дә шулай. Берәүдән яхшылык күргән кеше икенче берәүгә тора салып зыян салырмы? Һич юк. Ә менә, мин яхшылык күргән идем, миннән дә күрсеннәр әле дип, гамәлләрен уңайга боручы-

лар байтак табылыр. Илшат Шәех улы биографиясеннән мин шул башлангыч чорны эзләп карадым, һәм бик жинел генә, бик якыннан гына таптым да. Булган ул андый кеше—бернинди жавапка өмет итмичә генә үсмер егет алдындагы көч житмәстәй кебек киртәләрне алып ташлаучы. Ул хәзер генә жинел кебек тоела. Ә бит юлында Энергетика институты ректоры Форель Закир улы Тинчурин очрамаган булса, күпме мохтажларның хәле жиңеләйми калырга мөмкин иле. Илшат Шәех улы үзе өчен маяк санаган Форель Тинчуринны олы йөрәк, акыл, миһербан үрнәге итеп күрә.



Хәрби училищеда документлары калган егетне Энергетика институтына кабул итеп алучы да, биш ел уку дәверендә тормыш елгасы төбендәге бусагалардан исән-имин алып чыгучы да шушы кеше. «Тормышымда бик яхшы остаз булды ул. Без аның исеменә тап төшермәдек,—ди бүген дә Илшат Шәех улы олы канәгатьлек белән.—Ул безнең күнелдә энергетик һөнәренә карата ихтирам уятты. Аның кешелек сыйфатларын без үзебездә кабатларга тырыштык. Тормышның язылмаган кануннарына фәкать шәхси үрнәк белән генә өйрәтәләр».

Татарстандагы Хәйрия елының игелекле эшләр дилбегәсен тотучыларның берсе—Илшат Шәех улы Фәрдиев кылган гамәлләрнең бик азын гына телгә алып үттек. Елның әле уртасына гына життек. Гамәлләр тагын да булыр. Тамгалы ел да тәмамланыр. Әмма бу кешенең игелек коесында су саекмас.

**Асия ЮНЫСОВА**

# Г

**ГАЛИУЛЛИН** Тәлгат Нәбиулла улы (22.7.1938, Норлат р-ны Кычытканлы а.), әдәбият галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1981), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1961). 1962 елдан СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1965-86 да Алабуга пед. ин-тында (1967-71 проректор, 1971 дән ректор, 1983 тән проф.). 1986 дан Казан пед. ин-тында, 1988 дән Казан ун-тында (1989 дан татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. мөдире, бер үк вакытта 1989-2000 дә татар филологиясе, тарихы һәм шәрекъ телләре фак. деканы). Хезмәтләре 1920-30, 1960-90 еллар татар поэзиясенә, Х.Туфан, Һ.Такташ, С.Хәким, М.Мәһдиев, Г.Бәширев, Р.Фәйзуллин h.б. иҗатларына карый. «Замана балалары» (1993) документаль повесте, «Дәгъва» (1995) хикәяләр һәм публицистик мәкаләләр җыентыгы, «Сәет Сакманов» (2005) трилогиясе авторы. «Почёт Билгесе» һәм Дуслык орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Шагыйрьләр һәм шигырьләр. К., 1985; Дәвамлык. К., 1987; Здравствуй, поэзия! М., 1987.

Әд.: Илһам чишмәләре / Предисл. Юзиев Н. Иҗат серләрен эзләүче галим. К., 1988; Гыйләҗев А. Сирәгәеп калды урманлык // Ватаным Татарстан. 1998. 22 июль.

**ГАЛЬГАФ** (Галиев Нургали Гали улы) (1902-40), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе. Беренче тәнкыйди мәкаләләре матбугатта 1920 елларда басыла башлый. «Буталчык көннәрдә» (1925) пьесасы, «Авылыма хат» (1927) шигырьләр җыентыгы, «Манёврдан соң» (1927) хикәяләр җыентыгы авторы. Татар теленә А.Неверовның «Ташкент—икмәкле шәһәр» («Ташкент - город хлебный», 1929) повестен тәрҗемә итә. Нахакка репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

**ГАМБӘР** (Гамбәрев) Наис Гыймран улы (25.8.1947, Мөслим р-ны Бүләк а.—4.5.2005, Казан, күмелде туган авылында) язучы, әдәби тәнкыйтьче, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1974-92 елларда (өзекләр б-н) Татарстан китап нәшриятында редактор. 1992 дә «Татарстан», 1993 тән «Казан утлары» ж-лларында җаваплы сәркәтип. Х.Туфан, Р.Фәйзуллин, Р.Гатауллин, Гәрәй Рәхим, М.Әгъләмев, Зөлфәт, М. Хәбибуллин, Т.Галиуллин иҗатлары турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре авторы. Лирик шигырьләре тупланган «Баш очымда - Кояш» (1991), «Күзләрем яфрак коя» (2001) җыентыклары авторы.

Әд.: Кутуй Р. Мир своих детей не прячет // Казань. 1984. N 7/8; Сафин Ф. Күңелемнең ачык тәрәзәләре // Мәдәни җомга. 1998. 17 апр.

**ГАНИЕВ** (Мөхәммәтганиев) Азат Вәли улы (1.5.1942, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль а.), язучы. Лениногорск сәнгать уч-щесын тәмамлый (1966). Заводта токарь, мәктәпләрдә рәсем укытучысы булып эшли. Әсәрләре 1960 еллар башыннан басыла башлый. «Тагын күченәбез» (1969) исемле хикәяләр, «Сүзсез җыр» (1972), «Габделхак» (1984), «Адашкан җаннар» (1993) кебек повесть китаплары авторы. Әсәрләренә фәлсәфилек хас, әхлак мәсьәләләре кискен куела.

Әд.: Вәлиев М. Учагың сүрелмиме? // Учагың сүнмәсен. К., 1988.

**ГАНИЕВ** Вил Хәлил улы (10.7.1934, Норлат, хәзерге Яшел Үзән р-ны Норлат а.—7.4.2005, Мәскәү), әдәбият белгече, тәрҗемәче, РФнең атказ мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957) «Казан утлары» ж-лы редакциясендә эшли. 1959 елдан Мәскәүдә яши. 1964-67 дә «Советский писатель» нәшриятында, 1967-91 дә СССР Язучылар берлеге идарәсендә, бер үк вакытта 1986-94 тә Әдәбият ин-тында эшли. 1997 дән РФАнең Дөнья әдәбияты ин-тында. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбиятына (Г.Тукай, Г.Исхаки, З.Валиди, С.Максуди, М.Гафури) карый. «XX йөз татар әдәбияты» (2001) очеркы авторы. Рус теленә татар шагыйрьләре Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Гафури, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Х.Туфан, Г.Кутуй, Ә.Ерикәй, С.Хәким, Г.Афзал,

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

З.Нури, төрки телле шагыйрьләр Н.Хикмәт, Мәхтүмкули, Җамбул, М.Кәрим шигырьләрен, Г.Әпсәләмевнең «Ак төннәр» (1959) повестен тәрҗемә итә.

Әд.: Мустафин Р. Поэтическая интонация переводчика // Образ времени. К., 1981; Гаффар Ә. Игелекле эш кешесе // Казан утлары. 1984. N3.

**ГАНИЕВА** Резеда Кадыйр кызы (13.11.1932, Норлат-Ачасыр, р-ны Кече Шырдан а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1962 дән шунда укыта. Хезмәтләре татар әдәбиятының тарихына һәм теориясенә, татар әдәбиятының Көнбатыш Европа, рус, украин, гарәп, фарсы-таҗик, төрки әдәбиятлары б-н багъланышларына, Шәрекъ әдәбиятларында иҗат методлары мәсьәләләренә, Г.Тукай, Г.Исхакый, Н.Думави иҗатларына карый.

Хезм.: Сатира в творчестве Тукая. К., 1964; Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. К., 1988; Татарская литература: традиции, взаимосвязи. К., 2002; Шагыйрьнең рухи дөньясы. К., 2002; Думавиның иҗат сәхифәләре. К., 2003.

Әд.: Саяпова А. Говорю о своём учителе // Идель. 2002. N10; Бакиров М. Чын галим һәм педагог // Фәнни Татарстан. 2002. N 3-4. Миңнегулов Х. Й. «Каюм бабайның дәвамчысы» // Гасырлар өнен тыңлап... К., 2003.

**ГАРЗАВИНА** Алла (Алевтина) Викторовна (20.11.1936, Казан), төбәк тарихчысы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1958). 1959-69 елларда ТАССР Дәүләт музеенда, 1969-79 да Казан сәяхәтләр һәм экскурсияләр бюросында (1972-79 да директор), 1979-91 дә Татарстан китап нәшриятендә мөхәррир, 1992 дән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында эшли. Әсәрләре 1959 да басыла башлый. «Минем Казаным» («Моя Казань», 1984, А.И.Новицкий б-н автордаш), «Казанга, профессор К.Ф.Фукскa:» («В Казань, профессору К.Ф.Фуксу:», 1987), «Күңелебезнең матур дәртен Ватанга багышлыйк!» («Отчизне посвятим души прекрасные порывы!», 1990), «Мәшһүр кешеләр Казан һәм Казан төбәге турында» («Знаменитые люди о Казани и Казанском крае» (1999, А.И.Новицкий б-н автордаш) исемле документаль-нәфис китаплар авторы. Дәүләт бүләге лауреаты (2007)

Әд.: Ефремов А. Почему скучает турист? // Советская культура. 1979. 24 апр.; Аристов В. Вначале был поиск // Советская Татария. 1987. 2 авг.

**ГАРИФУЛЛИН** Дамир Хәйрулла улы (5.5.1939, Сарман р-ны Яхшыбай а.), шагыйрь, публицист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1962 елдан КПССның Сарман райкомында (1970-91 дә пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире) эшли. 1991-93 тә «Ватаным Татарстан» г-тасының үз хәбәрчесе. Әсәрләре республика газета-журналларында 1962 дән бирле басылып килә. Балалар өчен «Тылсымлы шакмаклар» (1984), «Кикринур - гаҗәп этәч» (1985), «Ишегалды» (1990) исемле шигырь җыентыклары авторы. Форма ягыннан җыйнак, хәтердә җиңел кала торган шигырьләрендә шагыйрь балаларны кыю, гадел, мәрхәмәтле булырга өнди. Г. борынгы кульязмалар, фольклор әсәрләре җыйнап матбугатта бастыра, шулай ук татар мәдәниятенең күренекле эшлекләре турында публицистик мәкаләләр, очерклар яза.

Әсәр.: Мең дә бер робагый. К., 1997.

Әд.: Энә белән кое казый ул // Мәдәни җомга. 1999. 7 май.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БИШБАЛТА ЕГЕТЕ

Исән чагында Гариф абый белән күрешеп сөйләшергә туры килмәде. Мин әле башлангыч класста укыганда—1983 елда, 75 яшендә бакый дөньяга күчкән ул. Әмма аның мавыктыргыч әсәрләрен укыганда авторның үзе белән очрашасы, алай гына да түгел: "Гариф абый, Гарәфетдиннең язмышы ничек булып бетте соң... ә Таһир белән Гүзәл бергә калдымы?"—дип күңелне ымсындырган сорауларга үзеннән җавап аласы килгән чаклар була иде.



Шунысы кызык—әдәбият дәресендә Гариф Гобәй иҗатын безгә "Маякчы кызы" аша гына "сеңдерделәр". Әлбәттә, чорлар алышыну, дөньяга карашлар үзгәрү нәтиҗәсендә революцион романтика, патриотизм хисләре белән сугарылган ул әсәр бүгенге көндә актуальлеген югалткандыр да. Ләкин бит Гариф Гобәйнең иҗаты "Маякчы кызы" белән генә чикләнми. Менә калса, аның "Ләйсән янгыр" һәм "Без үскәндә"се күпкә кызыклырак һәм шул чорны аңлау өчен күпкә үтемлерәк повестьлар.

Чыбыркы белән кыйнап та кулына китап тоттырып булмаган малайлар бар. Әмма алар "Тимур һәм аның командасы"н, "Том Сойер маҗаралары"н яхшы белә. Алар анда үзләрен, үз тормышларын, үзләре хыялланган яшәү рәвешен күрәләр. Аларга маҗара, романтика, "чын егет" булу кирәк. Гариф Гобәй дә әнә шундый сюжетлы, эпик әсәрләр иҗат итте. "Ләйсән янгыр"ны уку—гаҗәеп мавыктыргыч кино карауга тиң. Повестьны су кебек бер тында эчеп бетерәсең. Вакыйгалар күбрәк Казанның Бишбалта бистәсендә бара. Геройлар—ата-ана тәрбиясе күрмәгән малайлар-кызлар, наив эшчеләр, караклар... кыскасы, "халык вәкилләре"... Повестьтагы хәлләр күз иярмәс тизлек белән алышынса да, күп нәрсә хәтердә кала. Гариф Гобәй кыска, ләкин үтемле диалоглары белән укучыны үз кулында тота белә, аны повесть эченнән "чыгармый":

"Бер тапкыр тел дәресендә укытучы Җиһангирны тактага чыгарып, Фатих Кәрим шигырьләреннән берничә юл язарга кушты. Дәрес бетәргә күп калмаган иде. Җиһангир вакытны сузар өчен юри беренче ике иҗекне боза-төзәтә язды да, сүз арасында гына әйткән кебек итеп әйтеп куйды:

—Ә минем Фатих абыйны күргәнем бар...

Бөтенесе башларын күтәреп Җиһангирга карадылар.

—Син? Фатих Кәримне?

—Әһе.

—Кайда күрдең?..

—Окоптадыр инде...—дип көлде берсе.

—Окоптамы, түгелме—күрдем...

Җиһангирнын хәбәре белән укытучы да кызыксынмый калмады.

—Бу бик кызык. Тиздән бездә Фатих Кәримгә багышланган кичә була. Истәлек белән чыгарсың, яме?.. Кайда күрдең, Хәррәмов?

—Детдомда.

—Очрашуга килгән идемени? Йә, йә...

—Әһе. Әй, бер заман дак-док басып килеп керде. Безнең комендант ише генә түгел, зу-ур, таза, күзләре янып тора. Чәчләре генә коела башлаган түлке... Барыбыз белән дә күрешеп чыкты. Аннан ул безгә... "Мокамай"ны...

Балалар көлеп җибәрделәр, Фатих Кәримнең кыяфәтен тасвирлаганда ук Җиһангирнын ялганлаганын укытучы белгән иде инде. Шып туктатып, өзекне язып бетерергә кушты. Ләкин вакыт Җиһангир файдасына хезмәт итеп өлгергән иде инде. Звонок яңгырады."

20 гасыр башындагы Казан тормышы, Иделдәге Үсия пристане, һөнәрчеләр, Алафузов фабрикасы, шул чордагы урыс-татар мөнәсәбәтләре, дин, муллалар, шәкертләр... "Без үскәндә" повестында һәр деталь, һәр герой үз урынында. Авторның күпмедер дәрәҗәдә үзенең дә кайчандыр шул дөньяда кайнаганлыгы нык сизелә. 1907 елның 26 августында вак һөнәрче гаиләсендә туган Гариф Гобәй кайларда гына эшләми: трамвай да йөртә ул, типографиядә хәреф коючы, балалар йортында тәрбияче булып та эшли. 1936 елда Казанның педагогия институтын тәмамлагач Татарстан китап нәшриятында, "Кызыл Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасында, Радиокомитетта главлит, соңрак рәис булып эшли. 1950—53 елларда Гариф Гобәй Татарстан Язучылар оешмасының идарә рәисе вазыйфаларын башкара. 1953 елдан ул—профессиональ язучы.

Югарыда әйтеп үткән әсәрләрдән тыш аның сыйнфый көрәш мотивларына нигезләнгән "Каланча", "Ялгыз йортта", Бөек Ватан сугышы чоры турындагы "Замана балалары", "Маратның язмышы" повестьлары, "Коръән серләре" исемле шактый каршылыклы публицистик хезмәте дә укучыларга яхшы таныш.

Гариф Гобәйнең иҗатына, аның тоткан кыйбласына төрле караш булырга мөмкин, әмма бер нәрсә хак—ул үз заманының идеологиясенә тугрылыклы иҗат иткән язучы. Һәм нәрсә генә булмасын, татар балалар әдәбиятында Гариф Гобәй дигән олы язучы бар һәм аның мавыктыргыч әсәрләре бүгенге чор укучыларына да һичшиксез кызык тоелачак. Чөнки аларда балалар-үсмерләр үзләре, аларның үз шуклыклары, үз сөенечләре, үз хаталары.

**Алмаз ГЫЙМАДИЕВ**

## *Зәет Мәҗитовның тууына 80 ел*

Шагыйрь һәм әдәбият галиме Зәет Мәҗит улы Мәҗитов 1927 елда Татарстанның Актаныш районы Иске Айман авылында крестьян гаиләсендә туа. 1944 елда Пучы урта мәктәбен, аннан Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Укуын аспирантурада дәвам итеп 1955 елда "Фатих Кәрим поэзиясе" дигән темага диссертация яклый. 1954—1957 елларда "Совет Татарстаны" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1962 елдан университетта әдәбият кафедрасы доценты хезмәтләрен башкара.

З. Мәҗитовның беренче шигырьләре район газетасында, соңрак республика матбугатында басыла. 1953 елда "Таңгы җыр" исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Шагыйрьнең поэтик иҗаты Ватанга, туган җиргә мәхәббәт хисләрен чагылдырган лирик-фәлсәфи шигырьләре, этика-мораль темаларына багышланган мәсәлләре һәм юмор-сатирасы белән кызыклы. Күләмле әсәрләреннән "Ярсу Ык" шигъри повесте, "Һәйкәл янында", "Кияү каршылаганда" кебек поэмалары шагыйрьнең уңышы булып саналырга хаклы. Әдипнең иң яхшы поэтик әсәрләре 1977 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан "Рәхмәт язсын" исемле күләмле китабында урын алган.

З. Мәҗитов әдәбият тарихын, аерым язучыларның иҗатын өйрәнү һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә нәтиҗәле эшләде. Аның Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турындагы монографиясе (1963), Бөек Ватан сугышы елларында татар поэзиясен тикшерүгә багышланган "Сугышчан поэзия" дигән зур хезмәте (1975) бай фактик материалы һәм кызыклы күзәтүләре, фикри нәтиҗәләре белән җәлеп итә. З. Мәҗитов Фатих Кәримнең әдәби мирасын барлау һәм җыеп бастыру эшенә күп көч салды, әтрафлы сүз башы һәм искәрмәләр белән шагыйрьнең өч томлык әсәрләр җыелмасын ике тапкыр басмага әзерләде.

1998-99 елларда З. Мәҗитовның дүрт китаптан торган "Мәхәббәт дәфтәрләре" исемле шигъри җыентыклары дөнья күрде.

Ул—1965 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

З. Мәҗитов 2000 елда вафат булды.



*Бер төркем язучылар Муса Җәлил һәйкәле янында. Сулдан уңга— М. Хәбибуллин, Г. Шәрәфи, Р. Харис, С. Хәким, Р. Мөхәммәдиев, Ч. Җәлилова, Г. Ахунов, Ә. Җәлилова, М. Вильданова, Р. Фәйзуллин, Р. Мингалим, Н. Юзиев. Үткән гасырның 80 нче еллары.*




*Композитор Сара Садыйкова һәм шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин. 1984 ел.*



*«Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә бер төркем язучылар һәм сәнгать әһелләре. Өстәл артында кара-каршы утыралар—М. Садри, С. Хәким; беренче рәттә: Н. Дәүли, Р. Ишморат, Х. Госман, Г. Бәширов, З. Хәйруллина, Х. Хәйри, Ә. Бакиров, Ш. Хамматов; икенче рәттә: Ә. Раков, И. Юзеев, И. Сәттаров, Н. Юзиев, Ф. Мусин, Р. Мостафин, Ш. Маннапов, З. Мансуров. 1980 ел.*



*Татар шагыйрьләренең байтак әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткән шагыйрь, Державин премиясе лауреаты Николай Беляев. 1979 ел.*



*«Казан утлары» редакциясендәге бер җыелыштан күренеш. Сулдан уңга—К. Кәримов, М. Вәлиев, Р. Гаташ, Р. Шаһиева, М. Шабай, Н. Гамбәр. 2003 ел.*

## Рөстәм Зәкуанов



Рөстәм Газизҗан улы Зәкуанов 1957 елның 25 маенда Татарстанның Азнакай районы Үчәлле авылында туа. Урта мәктәпне Тымытык авылында тәмамлагач, туган авылында шофер булып эшли башлый.

1975-1980 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының журналистика бүлеген тәмамлап, «Маяк» район газетасында эшли. Чорыбызның хезмәт кешеләре, җәмгыятьне борчыган мәсьәләләргә багышланган публицистик язмалары, очерклары район һәм республика матбугатында еш басыла.

1985 елдан хуҗалык һәм партия эшендә. 1985 елдан 2000 елга кадәр Азнакай районының Илбәк авылында «Янтарь» совхозы директоры булып эшли.

Бу чорда авыл хуҗалыгы өлкәсендәге хезмәтләре һәм җәмәгать эшендә актив катнашуы өчен «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исеме бирелә, күп санлы мактау кәгазьләре, истәлек медальләре белән бүләкләнә.

2000 елдан Әлмәт шәһәрендә «Татнефть» берләшмәсенең эшчеләрне тәэмин итү идарәсе директоры урынбасары булып эшли. Озак та үтми, кабат туган ягына, Азнакай районы һәм шәһәренең администрация башлыгының беренче урынбасары итеп эшкә чакырыла.

Күп еллар район советы депутаты була. 2004 елның мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты итеп сайлана. Бүгенгесе көндә Дәүләт Советында Комитет рәисе урынбасары булып эшли.

Милләтебезне, әдәбият һәм мәдәниятыбызны борчыган, татар авыллары язмышына кагылган мәсьәләләрне еш күтәрә, республиканың иҗади җәмәгатьчелеге белән даими элемтәдә яши.

Рөстәм Зәкуанов Татарстан Республикасы журналистлар берлеге әгъзасы.

2006 елда каләмдәшебезнең «Рухият» нәшриятында «Яшәү мәгънәсе» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Соңгы елларда республика матбугатында да шагыйрьнең яңа әсәрләре еш басылып тора.

50 яше тулган көннәрдә Рөстәм Зәкуанов Татарстан Республикасы Президентының «Рәхмәт хаты»на лаек булды.

2007 елның 25 маенда, Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар—Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гәрәй Рәхим, Рафис Корбан) Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Зәкуанов Рөстәм Газизҗан улын (Рөстәм Зәкуан) Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул итте.

Кадерле редакция!

Үземнең тормышымда булган «Казан утлары»на бәйләнешләрем, фикерләрем турында язасым килде.

Безгә сугыш елларында 3 нче, 4 нче класс укучыларына ана теле дәресләрендә яшь апа укытучыбыз дәресләрне сораганнан соң «Совет әдәбияты» журналыннан өзекләр, сугыш турында мәкаләләрне укый иде. Дөнья, тормыш турындагы беренче мәгълүматларны үзләштерү шушы журнал битләреннән һәм әнинең сукыр лампа яктысында укый торган, гарәп шрифтындагы иске татар китаплары булгандыр. Ядегәр авылыннан киткәч, журнал белән элемтә бетте, өзелде һәм бик зур тырышлык куеп рус телен үзләштерү башланды.

Кыскача әйткәндә, без татарларны үзенең укуы-язуы булмаган, әә мәдәниятнең нәрсә икәнен үз кул астына килеп эләккәч кенә белә башлаган кыргый бер халык рәвешендә күрсәтергә тырышты Россия. Нәтиҗәдә тарих турында, бигрәк тә үзебезнеке турында, мәгълүмат бик сай иде.

Төрле милләт вәкилләре катнашында, күбесенчә очраклы рәвештә башланып киткән әңгәмәләрдә безгә шулай өстен карачы «оппонентлар» белән килешә алмый идек, әлбәттә. Ул вакытта, Казанда торган чакта инде, узган гасырның 60нчы еллары бара иде. Менә шушы вакытлардан башлап хәзерге көннәргә хәтле «Казан утлары»ның әһәмияте безнең өчен бик зур булды. Тарихны дөрес күрсәтергә тырышучы, дөрес күрсәтергә омтылучы бердәнбер матбугат органы шул иде. (Әлбәттә, тагын тарихчыларның шул турыдагы кайбер китаплары инде.) Һәр, бер тарих ягыннан гына түгел, безнең өчен ул күп кырлы, «универсаль» журнал иде.

Бүгенге көндә аны янә игътибар белән укып-күзәтеп барам.

Мина аеруча Айдар Хәлимнең мәкаләләре ошый. Россиягә карата булган килешмәүчән позициясе өчен. Аның шушы юнәлештә нык торуы, какшамас булуы Балтыйк буе республикаларының Россиягә булган мөнәсәбәтләренә, позицияләренә тиңдәш диясем килә. Шушы мәсләген, принципларын яклап ул беркемне дә кызганмый, аямый. Мин аның «Безнең заман герое» дигән бәхәстәге чыгышын да күздә тотып әйтәм моны. Татар язучысы каләменнән шундый әйбер чыгар дип башыма да килгәне булмады... Безгә хәзер бу республикаларны өлге иттереп алу кыен, әлбәттә. Ләкин татар халкының телен һәм үзен саклап калыйм дисән шулай эш итәргә кирәктер...

Безнең шәһәрдә исә хәзер 10га якын урта мәктәп арасында нибары бер мәктәптә атнага 2-3 тапкыр академик сәгать булып татар теле керә. Анысы да милли-мәдәни мохтарият вәкиленең нык тырышуы аркасында.

Эшегездә зур уңышлар теләп калам. Шушы хатым озак еллар укыган журналым һәм аны шушылай матур иттереп дөньяга китерүчеләр белән сабуллашу хатыдыр инде дип уйлыйм.

**Айдар ӘКБӘРОВ,**
*Удмуртия, Можга шәһәре.*

## ШАРТНАМӘ ЯКЛАУ ТАПТЫ

11 июльдә Федерация Советы утырышында Россия һәм Татарстан дәүләт органнары арасында вәкаләтләр бүлешү буенча Шартнамәне кабул итү булды. Яклап—122, каршы 4 сенатор тавыш бирде, берсе битараф калды.

Үткән ел РФ Дәүләт Думасы әлеге Шартнамәне яклап тавыш биргән иде инде, әмма февраль аенда Федерация Советы аны кире какты. Кайбер үзгәрешләр кертелгәч, 4 июльдә ул кабат Дәүләт Думасы тарафыннан якланды. РФ Президентының Федерация Советындагы вәкиле Александр Котенков Шартнамәнең халыкара хокукның барлык нормаларына да туры килүен билгеләп үтте. Сенаторларның Шартнамә буенча икенче тапкыр фикер алышулары тиз булды. Федерация Советы әгъзасы, Төньяк Осетия Республикасы Парламенты вәкиле Валерий Кадохов бу мәсьәлә буенча бәхәсләр кузгатмаска тәкъдим итте. «Президент безгә бу Шартнамәне икенче мәртәбә кертә. Документның тексты тел тидермәслек»,—дип ассызыклады ул.

Шартнамәдә РФ хөкүмәте һәм Татарстан Министрлар Кабинеты арасында республиканың икътисади, экологик, мәдәни һәм башка өлкәләре белән бәйле мәсьәләләрне уртак хәл итүне күздә тоткан килешүләр төзү каралган. Шартнамә нигезендә, республика татар телендә язылган һәм Татарстан гербы төшерелгән битле Россия гражданы паспорты бирергә хокуклы. Шулай ук бу документ Россия Президенты тәкъдим иткән Татарстан Президентына кандидат республиканың ике дәүләт теле—татар һәм рус телләрен белергә тиешлеген законлаштыра.

Шартнамә Россия Президенты тарафыннан имзалангач гамәлгә керәчәк.

## ТАРИХИ БУРЫЧЫБЫЗ

19 июньдә Бөтендөнья мирасы булган шәһәрләр оешмасының IX Бөтендөнья конгрессы делегатлары Казанга җыелды.

Өч көнгә сузылган мондый конгресс Россиядә беренче тапкыр үтә. Аны уздыру урыны итеп нәкъ менә Казанның сайлануы очраклы түгел. Безнең Кремль ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгәч, башкалабыз да Бөтендөнья мирасы шәһәрләре сафына басты.

Конгресста катнашучыларны Татарстан Президенты Минтимер Шәрипов котлады. Россия Президенты Владимир Путин да конгресска сәламләү хаты юллаган.

«Шәһәрләрнең зур тизлек белән үсүе аркасында, күпгасырлык мәдәни мираска югалу куркынычы яный,—диелә Президент хатында.—Без кешелек дөньясының зур кыйммәткә ия булган тарихи һәйкәлләрен киләчәк буынга тапшыру өчен бурычлы. Шуна күрә шәһәр төзелеше сәясәтен борынгы объектларга карата саклык белән алып барырга кирәк. Бу өлкәдә Казанның тәҗрибәсе зур. Мегаполисның кабатланмас архитектура һәйкәлләре заманча инфраструктура рәтендә уңышлы урнашкан». Төрле илләрдән җыелган вәкилләр (алар дөньяның 35 иленнән килгән) әнә шул тәҗрибәне уртаклашу һәм дөнья мирасын саклап калу юлларын эзлиләр.

Тарихи биналар төрле сәбәпләр аркасында юкка чыга. Мондый куркыныч барлык илләргә дә хас. Ә менә бу мәсьәләне хәл итүнең төрле юллары бар. Әйтик, кайбер чит илләрдә тарихи биналарны саклап калу белән махсус институтлар шөгыльләнә. Казанда исә һәйкәлләр рәтенә керүче тарихи биналарның 60 проценттан артыгын шәхси милеккә тапшырмакчы булалар. Әмма эшмәкәрләр бу корылмалар ярдәмендә табыш алу белән бергә, үз җилкәләренә җаваплылык та алачаклар.

Конгресс кысаларында оештырылган «түгәрәк өстәл»ләрнең берсе татар телендә узды. Фикер алышуда катнашучылар «Казандагы тарихи һәйкәлләрнең шәһәр икътисадына йогынтысы, кайбер корылмаларның рөхсәтсез куллануы кебек мәсьәләләрне хәл итү юллары турында сөйләделәр. Белгечләр күбрәк Казандагы Иске Татар бистәсен торгызу турында борчыла. Аны Яна Татар бистәсе белән кушып, тыюлык оештыру кирәк кебек фикерләр дә яңгырады. Тарихчылар әйтүенчә, Казандагы һәйкәлләрне дөньякүләм татар туризмында куллану, шуның ярдәмендә шәһәр казнасына акча кертү мөмкинлеге дә зур.

Кунаклар Казанның истәлекле урыннарында булганнан соң, Петропавел соборына җыелып фикер алышуны дәвам иттерделәр. Казанда агачтан салынган биналарның югала баруы, аларны саклап калуда зур кыенлыклар булуы турында борчылып сөйләде ораторлар. Салым сәясәтенә үзгәрешләр кертергә, бу биналарны төзекләндерергә җые-

нучыларга ярдәм итәргә кирәк, диделәр. Бу мәсьәләдә кунаклар Истанбул һәм Тель-Авив шәһәрләре үрнәген искә төшерде. Анда туризмнан кергән акчаны тарихи мирасны торгызу өчен тоталар икән. Франциядән килгән кунаклар тарихи биналарны торгызу эшләрен махсус оешмаларга йөкләргә киңәш итте. Инвесторларны җәлеп итәрлек шартлар тудырырга кирәклеген дә искәртте.

Делегатлар туган телебезне конгрессның рәсми теле дип игълан итте һәм барлык чыгышлар да татарчага тәрҗемә итеп барылды.

### ЖУРНАЛИСТЛАР КОНГРЕССЫ

14-16 июнь көннәрендә Казанда төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чараларының III конгрессы булып узды. Анда Россиянең 50гә якын төбәгеннән һәм БДБ илләреннән 250ләп журналист катнашты. Конгресска шулай ук Балтыйк буе илләреннән һәм Казакъстаннан да вәкилләр килгән иде. Форум «Казан» милли-мәдәният үзәгендә пленар утырыш белән ачылып китте. Аның эшендә Татарстан Премьер-министры Р.Миннеханов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Россия Дәүләт Думасының мәгълүмат сәясәте комитеты урынбасары Әнвәр Кармеев, Россия Журналистлар берлеге генераль секретаре Игорь Яковенко, гаммәви коммуникацияләр, элемтә һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Идел буе төбәге җитәкчесе Светлана Жданова, «Татмедиа» агентлыгы генераль директоры Марат Моратов катнашты һәм чыгыш ясады. Конгрессның максаты—Россиядә һәм Бердәм Дәүләтләр Берлегендә чыгып килә торган төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чараларының гомуми хәле, алга таба үсү перспективалары турында фикер алышу, үзара тәҗрибә уртаклашу иде.

Шул ук көннәрдә «Эфир—2007дә мәдәният» дигән V Бөтенроссия фестивале дә булып узды. Конгресс делегатлары Түбән Камада Сабантуй бәйрәмендә дә катнаштылар.

### ТӨРКИЯДӘ МӘДӘНИЯТ КӨННӘРЕ

7-10 июнь көннәрендә Төркиядә Татарстанның Мәдәният көннәре булып узды. Зур сәяси-мәдәни мәгънәгә ия бу бәйрәмдә Татарстанның иң яхшы сәнгать коллективлары—Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Primavera» дәүләт камера оркестры, «Бәхетле балачак» балалар ансамбле катнашты. Шагыйрьләр—Р. Харис, Р. Миңнуллин, З. Мансуров, композитор А. Монасыйпов, җырчылар Р. Ибраһимова, Р. Маликов һ. б. Мәдәният көннәренең уңышлы үтүендә зур көч куйдылар. Татарстан сәнгать осталары Р. Рей исемендәге Концертлар залында һәм шәһәр мәйданнарында чыгыш ясадылар. Алар, шулай ук Истанбул читендәге М. Эрсой исемен йөрткән урман аланында уздырылган татар Сабантуенда катнаштылар.

### ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ ГАЛИМНӘРЕ КАЗАНДА

4 июльдә Казанда беренче тапкыр зур җыен—Фәннәр академиясе президенты Ә. Мазһаров рәислегендә «Татарстан Республикасында һәм Ислам илләрендә мәгариф, фән һәм яна технологияләр» дигән халыкара симпозиум ачылды. Ул 2008 елда Казанда узачак Ислам дөньясы Фәннәр академиясе конференциясенә (анда 100дән артык илнең галимнәре катнашуы көтелә) әзерлек чарасы да булып тора.

Ислам дөньясы Фәннәр академиясе—Иордания һәм Пакыстан җитәкчелеге тәләктәшлегендә 1984 елда ук барлыкка килгән халыкара оешма—төрле илләрнең фәнни һәм техник үсешенә булышлык итә. Ул бүген 55 илнең галимнәрен берләштерә.

Үзара танышуга, фикер алышуга багышланган бу җыенда Ислам дөньясы Фәннәр академиясе президенты, Иорданиянең элеккеге премьер-министры А. Маджали, аның урынбасары А. Маракчи, академиянең генераль директоры М. Зуби, генераль секретарь М. Эргин, академиянең фәнни басмасы баш мөхәррире Н. Бор, Россия Фәннәр академиясе академигы Р. Нигъмәтуллин һәм Татарстан вәкилләре чыгыш ясады. Шулай ук республика җитәкчеләре белән эшлекле очрашулар булды, шәһәрнең тарихи-истәлекле урыннарына кызыклы экскурсияләр оештырылды.

### ГАЛИМНӘРНЕҢ ЕЛЛЫК ҖЫЕНЫ

26-27 июнь көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясенең гомуми еллык җыелышы булып узды. Галимнәр дөньясында вакыйга санала торган бу җыенда Татарстан Президенты М. Шәймиев, Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм башка рәсми вәкилләр катнашты. Татарстан Фәннәр академиясенең узган елдагы эшчәнлеге турында аның президенты Ә. Мазһаров хисап доклады белән чыкты. Фикер алышуларда дистәләгән академиклар катнашты.

Татарстан Фәннәр академиясенең гомуми җыелышында үткәрелгән сайлаулар, мөгаен, академиянең 15 еллык тарихында иң колачлысы булгандыр. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәсендә 7 яңа академик, 3 вице-президент һәм баш гыйльми сәркатиб сайланды.

Гуманитар фәннәр бүлегенең академик-сәркатибе итеп Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Рәфыйк Мөхәммәтшин, социаль-икътисадый фәннәр бүлегенә—академик Җәүдәт Сөләйманов, медицина һәм медицина һәм биология фәннәре бүлегенә—академик Марс Михайлов, авыл хуҗалыгы фәннәре бүлегенә—әгъза-корреспондент Рөстәм Сахәпов, математика, механика һәм машиналар бүлегенә—академик Геннадий

Дегтярев, физика, энергетика һәм Җир турындагы фәннәр бүлегенә—академик Наил Сөхибуллин, химия һәм химия технологияләре бүлегенә әгъза-корреспондент Владимир Галкин билгеләнде.

Вице-президентлар һәм Фәннәр академиясенең баш галим-сәркатибе вазифаларын башкару өчен тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышкач, яшерен тавыш бирү үткәрелде. Нәтиҗәдә техник фәннәр буенча вице-президент итеп әгъза-корреспондент Айрат Абдуллин, гуманитар фәннәр буенча—академик Рүзәл Йосыпов, икътисадый фәннәр буенча—академик Марат Сафиуллин билгеләнде.

ТФАның мөхбир-әгъзалары исемлегендә дә безгә яхшы таныш булган затлар бар: Гали Арсланов («Сәнгать белеме» белгечлеге буенча), Искәндәр Гыйләҗев («Татар халкы тарихы»), Дания Заһидуллина («Әдәбият белеме»), Рәфыйк Мөхәммәтшин («Диннәр белеме») һ.б. Өстәвенә Дания Заһидуллина баш гыйльми сәркатиб итеп тә тәгаенләнде.

Шунысы куанычлы, шәрәфле академиклар арасында күренекле әдәбият һәм сәнгать әһелләре дә бар: артист Шәүкәт Биктимеров, драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрь Равил Фәйзуллин...

Фәннәр академиясенең еллык җыелышында фәнни киңәшчеләр институты булдыру турында да карар кабул ителде. Академиклар Шамил Чабдаров, Миркасыйм Госманов һәм Әхәт Ильясов хәзер академиянең фәнни киңәшчеләре булып санала.

Гомумән алганда, Татарстан Фәннәр академиясендә бүгенге көнгә 38 академик, 71 мөхбир-әгъза һәм 19 шәрәфле академик бар.

### КИТАПНЫ ОЛЫЛАГАН САРАЙ БУЛАЧАК

Казан Ратушасында ТР Милли китапханәсе урнашачак кварталның эскиз проектлары конкурсына нәтиҗә ясалды. Анда Голландиянең танылган архитекторы Эрик ван Эгераат проекты җиңде.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З.Вәлиева билгеләп үткәнчә, Милли китапханә XXII гасырда да Казанның иң матур биналарыннан берсе булырга тиеш. Архитектор булачак китапханә бинасының эскизын тәкъдим иткәннән соң, Казан шәһәре башлыгы И.Метшин болай диде: «Дөньяда башка мондый проект юк, һәм мин Татарстан Милли китапханәсенең яңа бинасы башкалабызның визит карточкасына әйләнер, дип ышанам. Президент М.Шәймиев һәм Премьер-министр Р.Миңнеханов тарафыннан китапханә төзү турында карар кабул ителде, һәм әлегә барысы да күрсәтелгән вакыт кысаларында бара».

Булачак китап йортының гомуми мәйданы 50 мең квадрат метр тәшкил итәчәк. Некрасов урамында төзеләсе биналар комплексында гомуми мәйданы 17 мең квадрат метр булган офис үзәкләре һәм затлы торак йортлар да калкып чыгачак. Китапханә проектының бәясе—80 миллион евро, ә бөтен комплексныкы 206 миллион еврога төшәчәк. Офис мәйданнары һәм затлы фатирлар сатудан кергән акча китапханә төзелешенә тотылачак. Архитектор күзаллавы буенча, китапханәнең ике бинасы ачык китапны хәтерләтәчәк. Хром һәм ак мәрмәрдән төзелгән манаралар арасында 18 метр биеклектәге вестибюль урнашачак. Комплекста 5 миллион китапка исәпләнгән саклау урыны, 1000 кешегә исәпләнгән 20 уку залы, китап кибетләре, интернет-кафе булачак, машиналар җир асты гаражына куелачак.

### ОЛУГ ҖИҢҮ

Мәскәүдә үткән П.Чайковский исемендәге XIII халыкара конкурста «Ялгыз җыр» номинациясендә якташыбыз Альбина Шаһиморатова җиңде. Казан консерваториясенең тагын бер шәкерте, әлеге конкурста элегрәк җиңү яулаган Михаил Казаков кебек үк, беренче премия, алтын медаль белән бүләкләнде, лауреат исеменә лаек булды. Альбина Казан дәүләт консерваториясендә 4 нче курска кадәр Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, профессор Зилә Сөнгатуллина классында, аннан соң СССРның халык артисты, Мәскәү консерваториясе профессоры Галина Писаренкода укыды. Альбина Шаһиморатова—К.Станиславский һәм В.Немирович-Данченко исемендәге Мәскәү академия музыка театры һәм былтыргы сезоннан—М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты. Казан сәхнәсендә ул беренче тапкыр Ф.Шаляпин исемендәге XXIV халыкара фестивальдә Моцартның «Тылсымлы флейта» операсында Төн патшабикәсе партиясен җырлаган иде.

Альбина Шаһиморатова моңа кадәр дә берничә халыкара конкурсларда катнашып җиңү бәхетенә ирешкән иде инде.

### «СОЗВЕЗДИЕ-ЙОЛДЫЗЛЫК» ХАЛЫКАРА МӘЙДАН ДАУЛЫЙ

28 июнь көнне Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов «Созвездие-Йолдызлык-2007» фестивале җиңүчеләренә дәүләт стипендияләре һәм бүләкләр тапшырды. Министрлар Кабинетында узган очрашуда Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Марат Бариев, фестивальнең жюри рәисе Зилә Сөнгатуллина катнашты.

«Созвездие-Йолдызлык-2007» фестивале елдан-ел киңрәк колач ала бара. Ул 2000 елдан бирле Президентыбыз Минтимер Шәймиев ярдәме белән үтә. 2001-2007 елларда фестивальнең сайлап алу бәйгеләрендә 270 мең бала һәм яшүсмер катнашты. М.Бариев әйтүенчә, фестиваль хәйрия максатын-

да да зур эшләр башкара, чөнки анда катнашкан балаларның 70 проценты аз керемле гаиләләрдән. Ә Министрлар Кабинеты карары нигезендә барлыкка килгән, сәләтле балаларга һәм яшүсмерләргә булышлык итү буенча «Созвездие-Йолдызлык» республика үзәгенең эшчәнлеге фестивальне тагын да колачлырак итте.

Шунысы да сөендерә: Р.Миңнеханов белән аралашкан вакытта балалар үзәге өчен аерым бер бина бирү, фестивальне халыкара дәрәҗәгә күтәрү турында да сүз булды. Премьер-министр җәмгысе 60 бала һәм яшүсмергә стипендия һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

## «АЛТЫН КАЛӘМ» ДУСЛАРЫН ҖЫЙДЫ

Казан дәүләт университеты инде күп еллар буе, Журналистлар берлеге, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы белән берлектә, «Алтын каләм—Золотое перо» балалар, үсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивален уздыра. Быел ул 12 нче тапкыр үткәрелде. 26-29 июнь көннәрендә республиканың төрле районнарыннан җыелган 146 яшь каләм тибрәтүче, «Борис Полевой» теплоходына утырып, Идел буйлап сәяхәттә, Түбән Новгород шәһәрендә булып кайтты.

Сәяхәт дигәч тә, табигать хозурлыгында соклану гына булмады ул. Теплоходта 8 яшьтән 18 яшькәчә булган яшь каләм осталары арасында кызу эш барды. Алар 10 номинациядә үткәрелгән иҗади бәйгедә «бил алышты». Моннан тыш, теплоходта 3 көн дәвамында осталык класслары эшләде, Россиянең башка төбәкләреннән килгән яшь журналистлар белән очрашулар уздырылды.

Сәләтле каләм тибрәтүчеләргә ана каләр дә күп сынаулар аша узарга туры килгән. Мәсәлән, алар май ае дәвамында Баулы, Нурлат, Яшел Үзән, Чаллы, Казан шәһәрләрендә зона бәйгеләрендә катнашкан.

Фестивальнең гран прие—Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультетына ташлама белән укырга керү хокукына ия булу. Моннан тыш, җиңүчегә тагын бер мөмкинлек ачыла: ул «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында Россия Президенты грантын дәгъвалый ала.

Фестиваль эшендә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Марат Бариев, КДУның журналистика һәм социология факультеты деканы Васыйл Гарифуллин һ.б. катнашты.

## БАЛАЛАРГА БҮЛӘК

«Татнефть» ачык акционерлар җәмгыятенең «Рухият» рухи янарыш фонды тарафыннан нефть төбәгендә яшәүче авторлар арасында үткәрелгән «Балаларга бүләк» исемле иҗади бәйгегә йомгак ясалды. Бу конкурста республикабызның 11 шәһәр һәм районыннан 61 автор катнашып, үзенең балалар өчен язган әсәрләрен тәкъдим итте.

Әлмәт шәһәренең Яшьләр үзәгендә әлеге бәйгедә катнашучыларны һәм җиңүчеләрне тәбрикләү һәм бүләкләү тантанасы булып узды. «Балаларга бүләк» конкурсының премияләренә башлап язучылар номинациясендә—Әлфирә Батырова (Әлмәт), Резеда Шәрипова (Азнакай), Андриян Григорьев (Нурлат), Николай Садовин (Лениногорск); профессиональ язучылар арасында Рәмзия Габделхакова (Лениногорск) һәм Мөҗәһит Әхмәтҗанов (Мөслим) лаек дип табылды. Нина Афанасьева һәм Альберт Хәсәновка (Лениногорск) кызыксындыру бүләкләре бирелде.

Ә менә Ирина Шиманова, Раил Шәфыйков, Гөлнара Миранова (Әлмәт), Лилия Шәйдуллина (Азнакай), Светлана Вотчинникова (Баулы), Ирина Ишкова (Бөгелмә), Камил Гыйльмуллин (Түбән Кама), Гафифә Гаффарова (Сарман районы, Җәлил бистәсе) конкурсның дипломантлары булды.

«Татнефть» ачык акционерлар җәмгыяте «Рухият» фондының башкаручы директоры Флүрә Шәйхетдинова әйтүенчә, әлеге конкурста катнашкан авторларның иң яхшы әсәрләре тизДән «Балаларга бүләк» китабы булып дөнья күрәчәк һәм әлеге мәҗмуга Татарстан нефтьчеләренең 3 нче миллиард тонна нефть табу көненә матур бер бүләк булачак.

## РЕСПУБЛИКА МӘГАРИФЕНДӘ ЯҢА МИНИСТР

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры итеп Наил Вәлиевне билгеләү турындагы Указга кул куйды.

1949 елның 3 сентябрендә Чистай шәһәрендә туган Наил Мансур улы Вәлиев, Алабуга дәүләт педагогика институтын тәмамлаганнан соң, хезмәт эшчәнлеген 1971 елда Чистай шәһәренең 3 нче урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлаган. Ул—филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы. 2000 елдан алып Алабуга дәүләт педагогика институты ректоры.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының элеккеге башлыгы Рәис Шәйхелисламов башка эшкә күчерелде.

## ТӨРКИЯДӘН ДОКУМЕНТЛАР КАЙТА

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы баш архив идарәсе хезмәткәренең Төркия Премьер-министры каршындагы Осман архивына эшлекле сәфәре булды.

Анда төрек архивчылары Татарстандагы

хезмәттәшләренә татар халкы тарихы буенча 50 гә якын документ һәм 20 дән артык документлар җыентыгы, шулай ук фәнни-методик басмаларның күчермәләрен тапшырганнар.

Төрек архивчылары белән сөйләшү барышында Төркия һәм Татарстан Республикасының дәүләт архивлары документларын уртак фәнни басмалар итеп чыгару, Төркия һәм Татарстанның тарихи-документаль мирасын популярлаштыру өлкәләрендә хезмәттәшлек итү мәсьәләләре дә каралган.

### СИБГАТ ХӘКИМ УРАМЫ

Башкалабызда язучыларыбыз исемен йөрткән урам-проспектлар байтак. Бу исемлеккә яна урам өстәлде. Элеккеге Кәҗә бистәсенең Казансу буендагы зур яңа биналар төзелүче урамына Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким исеме бирелде.

### «ДӘРВИШ»—АМЕРИКА СӘХНӘСЕНДӘ

Язын Америкадан Казанга кайткан композитор Мәсгудә Шәмсетдинова үзенең әсәрләре белән Америка тамашачысын да таныштырырга уйлавы турында әйткән иде. Бу уе тормышка ашкан. Сиэтл шәһәре консерваториясенең 800 кешелек залында татар композиторы Мәсгудә Шәмсетдинованың «Дәрвиш» дип исемләнгән симфоник поэмасы яңгыраган.

Мәсгудә Шәмсетдинованың «Дәрвиш» дип аталган әсәрен Татарстан тамашачысы композиторга 50 яшь тулуга багышланган кичәдә тыңлаган иде инде. Хәзер Америка тамашачысы Мәсгудә Шәмсетдинованың соңгы вакытта язылган күләмле әсәре аша татар музыкасының бер тармагы белән танышты.

### АРТИСТЛАР САБАНТУЕ

20 июнь көнне Саба районындагы Лесхоз авылында театрлар Сабантуеның өченчесе үткәрелде. Алдагылары Әлдермештә һәм Арчада булган иде.

Сәхнә каһарманнары Сабантуй каһарманнарына әйләнде ул көнне. Театр эшчеләре, хезмәткәрләре белән бергә 1200 дән артык кеше мәйданда иде.

Бәйрәмне Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева ачып җибәрде. «Республикада шуның кадәр театр булу безнең байлыгыбыз. Шушы хәтле талантлы артист катнашкан Сабантуй юктыр», —диде ул.

Бәйрәм флагын халык артистлары Ринат Таҗетдинов һәм Исламия Мәхмүтова күтәрде. Мәйдан уртасында төрле тамашалар җыр-моң белән үрелеп барды. Туфан Миңнуллин үзе алып килгән бүләкләрен таяк тартышкан һәм кул көрәштергән иң көчле кызларга тапшырды. Буалылар япон көрәшендә, судан кул белән балык тотуда, колгага менүдә иң җитезләрдән булды.

Программаны алып барган язучы Рабит Батулла, ниһаять, дулкынландыргыч мизгелләр якынлашуын игълан итте. Келәмдә бил алышкан егетләр арасында 70 килограммга хәтле үлчәүдә беренче урынны Казан дәүләт Яшь тамашачы театрыннан Рамил Гарипов, 80 гә кадәрдә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрыннан Алмаз Фәтхуллин алды. 80 килодан югары үлчәүдә җиңүче һәм абсолют батыр булып Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Минвәли Габдуллин калды. Ул тәкә белән «Фиат» машинасына ия булды.

### ГЫЙЛЬМИ ДӘРӘҖӘЛЕЛӘР АРТА

Язучы Факил Сафин «Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның сәнгати дөньясы» дигән темага (фәнни җитәкчесе—филология фәннәре докторы Ф. Галимуллин) диссертация яклап филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алды.

***

Шушы елның 27 июнендә 70нче яшендә шагыйрь **Закиров Рифкать Хәйдәр улы** вафат булды.

***


Июнь аенда шагыйрь һәм тәрҗемәче, «Идел» журналының бүлек мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Малышев Сергей Владимирович** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Бәйрәм мизгелләре.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Азат Вергазов**.

# Яңа китаплар




Гаспринский Исмәгыйль: тарихи-документаль жыентык / төз. **С. Рәхимов**.—Казан: «Жыен», 2006.—544 б.—(«Шәхесләребез» сериясе). Тиражы—2000 данә.

Бу жыентыкта XIX гасыр ахыры—XX гасыр башы татар дөньясының мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, мөхәррир һәм матбагачы, җәдидчелек хәрәкәтенең юлбашчысы, публицист, язучы Исмәгыйль Гаспринскийның эшчәнлеген һәм тормышын яктырткан материаллар, аңа багышланган мәкаләләр, библиографик мәгълүматлар тупланды. Китап галимнәр өчен дә, киң катлау укучылар өчен дә һичшиксез кызыклы булачак.

Китапның фәнни мөхәррире—академик Миркасыйм Госманов, бизәлеш рәссамы—Шамил Насыйров.




**Равил Рахмани.** Мең чакрымга мең чакрым: Шигырьләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.—351 бит. Тиражы—2000 данә.

Равил Рахмани—әдәбият галиме. Аның татар балалар әдәбияты тарихына караган китап-хезмәтләре, әдәби-иҗат теориясенә һәм классик язучыларыбызның әсәрләрен анализлауга багышланган иҗат портретлары әдәбият сөючеләргә яхшы таныш.

«Мең чакрымга мең чакрым»—авторның укучыларга шагыйрь буларак тәкъдим ителгән беренче китабы. Ул—гадәти шигырьләр җыелмасы түгел, лирик геройның, бүлектән бүлеккә күчеп, катлаулана барган хис-кичерешләренә, яшәү тәҗрибәсенә, фикер-фәлсәфәсенә таянып үскән милли үзаң эволюциясен чагылдырган бербөтен китап.



Азат Вергазов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)